# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Исән килеш исемлектән төшмик. *Шигырьләр.* ...............................3
Наилә ХАРИСОВА. Үтте инде. *Повесть.* ....................................................................................8
Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ. Гөрләгән сулар. *Мәрсия.* .........................................................................41
Рафаил ГАЗИЗОВ. Туган телем – болыннарың таҗы. *Шигырьләр.* ...................................75
Кәрим КАРА. Биек бәхет таулары. *Повесть.* ..........................................................................79
Марсель БАКИРОВ. Җаным әрнер яшәп туймаганга... *Шигырьләр.* .....................................96
Илсөяр ИКСАНОВА. Матәм. *Хикәя.* ........................................................................................100

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Мансур ГЫЙЛӘҖЕВ. Соңгы мираж. *Ике бүлектән торган романтик кыйсса.* .......................48

*Яңа исемнәр:* Фәрдилә ЯР. Өмет тама җанны куандырып... *Шигырьләр.* ...............................109

*«Мәйдан – батырлар өчен!» әдәби конкурсы:* Рашат НИЗАМИ. Келәмдә очрашу. *Хикәя.* ...112

*«Казан утлары»ның 100 еллыгын каршылап:* Илфак ИБРАҺИМОВ. Еракка китеп карап. .....118

*«Казан утлары» – минем язмышымда:* Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. «Бу бит – академик басма!..» ......................................................................................................................................121

*Юбилейга барышлый:* Фотоархив. ..........................................................................................124

*Юбилейлар:* Рәдиф ГАТАШ. Яралы хәтер, милли сүз китабы *(шагыйрь Ләис Зөлкарнәйгә – 60 яшь).* .......................................................................................126

*Әдәби тәнкыйть:* Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Татар әдәбияты ни хәлдә? ................................129
*Сәнгать:* Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Абагалар чәчәк атса... ......................................................136

*Китап күзәтү:* Марсель ИБРАҺИМОВ. «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар». .............................................................................................................139

*Бер юбилей тарихы:* Ләбиб ЛЕРОН. Тукайның йөз еллыгын үткәргәндә. .............................144

ЯКУТЛАР ТАБЫЛАДЫР ВАКЫТ БЕЛӘН

Бакый УРМАНЧЕ хатирәләре *(Зөфәр МӨХӘММӘТШИН әзерләде)*.......................................153

*Кардәш халыклар әдәбияты:* Айдарбәк САРМАНБЕТОВ. Дөнья киң ул, әгәр күңел киң булса... *Шигырьләр. (Кыргызчадан Ленар ШӘЕХ тәрҗемәләре).* ...................................165

*Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел*: Илдус ЗАҺИДУЛЛИН. XIV гасырның беренче яртысында Алтын Урдада ислам дине институтлары. .......................168

*Кайтаваз:* Нәҗибә САФИНА. Күп нокталар ни турында сөйли? ............................................175

*Газиз тавышлар:* Алтмыш – алтын чор башы. *Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара*............181

*Замандашыбыз:* Ландыш НӘСЫЙХОВА. Хөрлек сүздә түгел, йөрәктә. ..............................183

*Печән базары:* Йолдыз ШӘРӘПОВА. Чиратсызлар чираты. *Шигырьләр.* ...........................187
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ......................................................................................190

КАЗАН УТЛАРЫ

*№ 4 (1194) 2022*

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**

*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.03.2022, график буенча 29.03.2022, басылып чыгу вакыты 01.04.2022
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-0928. Тираж 7787.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

12+

© «Казан утлары», 2022 ел



Сания
Әхмәтҗанова

# ИСӘН КИЛЕШ ИСЕМЛЕКТӘН ТӨШМИК

## Апрель кәефе

Апрель, апрель... Бераз өшетәсең –
Боз салкынын саклый елгалар.
Кояшы да чыгар, явар яңгыр,
Карлары да әле булгалар.

Моңсулыкның чикләренә җитеп,
Яшьләремә торам төелеп.
Узган елгы яфрак арасыннан
Яшел үлән эзлим иелеп.

...Эчтән сулап, җылы кояш көтә –
Җир Анада бетмәс сабыр бар.
Ярасына япкан кулъяулыктай,
Уйдык-уйдык ята соңгы кар.

Тезләренә кадәр бозлы суда
Өянкеләр тора уфылдап.
Сискәндереп, камыш арасыннан
Әнкә үрдәк чыкты пырхылдап.

Чү, туктале, оясы бар бугай...
Бер читкәрәк киттем кырынлап.
Насыйп булса, димәк, җәй башында
Бәбкәләре чыгар борынлап.

Үзгәрде дә китте кинәт дөньям,
Моңсу уйлар инде иярле.
Эзләремә басып, сикергәләп,
Шат кәефем миңа иярде.

Сания ӘХМӘТҖАНОВА (1962) – *шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; Һ.Такташ һәм С.Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Пар алма», «Гәрәбә», «Язмышлар такыясы» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Без бар әле!

Кадимидән килгән замана бу:
Шатлык катыш шул ук зар бит әле.
Әүлия дә, пәйгамбәр дә түгел,
Ә шулай да без бар, бар бит әле!

Алмашчылар үз буена үлчәр –
Барыбызны тигез сөялмаслар.
«Шагыйрь түгел иде» дисәләр дә,
«Кеше түгел иде» диялмаслар.

Чын тәнкыйтькә чыдам безнең холык,
Төче сүзгә, шөкер, «колаксыз» ул.
Кәгазь безгә намазлыктай изге,
Каурый каләмебез гөнаһсыз ул!

Тукайларча, Такташ, Туфаннарча,
Сүз-кылычың айкап бер карале!
Без Зөлфәт үк, Мөдәррис үк түгел...
Ә шулай да бар бит, без бар әле!

Тын алырга өркеп кенә түгел,
Рух хөрлеген бөркеп сулыйк әле!
Исән килеш исемлектән төшмик,
Заман мөнбәрендә булыйк әле!

Кыл иләктән беркөн иләнәсе,
Сайланасы безнең бар бит әле...
Сирәгәя бара тыгыз сафлар, –
Ә шулай да без бар, бар бит әле!

## Кеше кадере

Күрше хакы – Алла хакы, дибез,
Кеше хакы йөри нинди хакка?
Кадерсезгә калганымны тоям,
Сукбай эттәй җан улаган чакта.

Читләштек без никтер якыннардан,
Күршеләрдән биздек акрын-акрын.
Балтырганга батырдык без илне,
Таптап йөреп читтә юл такырын.

Кайтсаң – кунак, китсәң – ерак, диеп,
Без ул туган йортны атап йөрткән!
«Күрше хакы – Алла хакы» сүзен
Оныттык та бугай инде күптән.

«Җир бәгыре, су кадере» диеп
Әйтер микән без үстергән буын?!
Туфрак арчып татып карамагач,
Җирдән кайнап чыккан чишмә суын.

Түбән төште ил абруе-даны,
Очсызланды аксакаллар сүзе.
Яшәү хакын даулап, ни кырабыз,
Якалаган чакта үлем үзе?!

Аңлый белсәң, «гомер» дигән юлның
Газиз икән хәтта карышы да.
Сулар сулышка да бәя арта
«Яшәү» белән «үлем» ярышында.

Олыгая бу да, дисез булыр,
Хаклык бардыр, яшьне санап баксаң.
...Уйдык-уйдык уйлар сара җанны,
«Төннек» аша күккә карап ятсаң,
Иртәгегә нәүмиз караш атсаң...

## Дәвамчылар калырмы?

Авыр кайгы сулышларга капкан чакта,
«Әни!» диеп яшь аралаш илерәбез.
Аянычта таянычсыз калган көндә
Әткәйләрнең бер сүзенә тилмерәбез.

Догалардан калдырмыйк без әткәйләрне,
Догаларсыз мәхрүм итмик әнкәйләрне...
Күп кирәкми: җитә бары, истә тотсак,
Васыять итеп алар безгә әйткәннәрне.

Олыгайган көнебездә үкенсәк тә,
Нигә диеп, элегрәк аңламадык.

Бүген менә зикер әйтеп куанабыз...
Соңламадык, шәт, иншалла, соңламадык.

«Догалардан калдырмагыз, балалар!» – дип
Сорар көннәр килеп җитәр безгә дә бер.
Азан әйтер, «Йәсин» чыгар дәвам калса,
Иман белән кичкән булыр безнең гомер.

## Булачак!

Минем халкым сәйяр җанлы булган
Элеккедән, борын-борыннан.
Сәфәр чыккан ерак кыйтгаларга,
Аң-мәгърифәт, гыйлем юлыннан.

Минем халкым галим җанлы булган:
Тамырларын барлап тирәннән,
Нәсел агачына бөҗра өстәп,
Төрки шәҗәрәсен өйрәнгән.

Минем халкым тәкъва җанлы булган:
Биштәренә Коръән төйнәгән.
Хәттатлары кулдан күчереп язган,
Хафизлары яттан көйләгән.

Минем халкым булган, бар, булачак –
Җирдә эзе мәңге калачак!
Кол Галиләр, Курсавилар әле,
Мәрҗанилар кабат туачак!

## Язылмаган канун

***яки татар кызының әхлак кодексы***

Заман сорый гүя: «Син кем? – диеп,
– Кайсы халык, өммәт баласы?»
Әйе, миңа – үз милләтем данын
Яшәтәсе, саклап каласы!

Кан тибешем булып, тамырымда
Татарлыгым ярсып сүз ала:
«Үз дәвамың, нәсел шәҗәрәңә
Лаек булырсыңмы, кыз бала?!»

Буең-сының, гүзәл холкың белән
«Үрнәк бул!» – дип дәшә йөрәгем.
Гадел сайланышка уй тотканда,
Милли рухым – иң зур терәгем.

Ата-баба сүзен кечкенәдән
Салып куйдым күңел түремә:
«Йортың балкып торса, калебеңнең
Сафлыгы да шуннан күренә!»

Вак-вак кына кисәм токмачымны,
Чәкчәк, өчпочмагын пешерәм,
Көйли-көйли чигү чиккән чакта,
«Бишек җыры»н искә төшерәм.

Бисмиллалы дога-теләк белән
Каршы алам һәрбер көнемне.
Бурычым ул – киләчәккә илтү
Ана телем – туган телемне!

Заман сорау бирсә, җавабым нык:
«Кем булуым һәрчак исемдә!»
Ышандыра алам: тап төшермәм
«Татар кызы» дигән исемгә!

## Гомер-корама

Корамалы-корамалы
Гомер юлым җәймәләре.
Аклы-күкле фасыллары,
Аллы-гөлле җәйләүләре.

Бер – тыйнагы, бер – җетесе:
Тотам-тотам үрнәкләре.
Бар тоташтан бертөрлесе,
Бар затлысы – сирәкләре.

Әниемнең җитез кулы
Теккән җөйләр сүтелмәгән;
Чәчәкләре – сабый гөлләр –
Челләләрдә өтелмәгән.

Күзнең явын алып тора
Яшьлегемнең балкышлары:
Саф фирүзә – күк-чатыры,
Каурый болыт – аккошлары.

...Төсен җуйган – тоныкланган
Урыны белән бизәкләре.
Ялгау-ялгау ялгышларым
Өзеп ала үзәкләрне.

Кул астымда булмагандыр
Кайчак якты өлгеләре.
Корамамда караңгы төс –
Ашыгычлык билгеләре.

Җөйләре дә салулаган,
Чиянлгән җепләре дә...
Гел-гел тәңгәл килмәгәндер
Язмышымның җекләре дә.

Күчкәнгәдер мирас булып
Әти-әни хәстәрлеге,
Таркалмаган, сүтелмәгән,
Бәз тукыма астарлыгы.

Терким әле гомеремне
Һаман шул бер корамага,
Ирешкәнче Аллаһымның
«Тәмам!» дигән карамагы.

Сайлап куйган өлгеләрем
Җитү түгел, артып китәр!
Шөкер, нәсел дәвамым бар
Корамамны мирас итәр.

## Өмет итик бары яхшыга

Гел кояшсыз түгел көннәр,
Дөм караңгы булмый төннәр –
Бар бит тулган айлы чагы да.
Язмыш шулдыр, дигәннәргә,
Кара күлмәк кигәннәргә
Насыйп булмый калмас агы да.

Кемгә килә иртә язда,
Кемгә соңлап – бары азга,
Бәхет елмайганны көтә бел.
Гафу итә алганнарга,
Тугры юлдаш булганнарга
Соң җылыңны бүләк итә бел.

Кайгы ала җанны китеп,
Каршы торыйк без үч итеп,
Учка төйнәп сагыш-зарларны.
Мәхәббәтне корбан итмик,
Ярты юлда ташлап китмик
Безгә язган хәләл ярларны.

Артка борылып карамый,
«Хәлләр ничек?» дип сорамый,
Үз көенә гомер ашыга...
Моңа кадәр сынатмадык,
Ышанычны югалтмадык,
Өмет итик бары яхшыга.

## Артык яратудан

Утлы өермәдәй ярсу идем,
Сөйдем сине, башым җуеп сөйдем.
Давылларны уза белдең урап,
Йөрдем сине яратмый дип юрап.

Йолдыз сыман атыласы килеп,
Дөнья тоташ мәхәббәт дип белеп,

Дөрләп алгач хыял учагында,
Уяндым мин сабыр кочагында.

Беребез – ут, беребез су идек,
Икебез дә сөя белеп сөйдек.
Сүнеп-яндык, ләкин алдашмыйча,
Бураннардан чыктык адашмыйча.

Тынмый әле, тынмый җанда буран,
Хисләремне тыеп кына торам.
Бер буранлап дулап алуларым
Сине артык яратудан булган.

## Ничек яратмыйсың бу язларны!

Ничек яратмыйсың бу язларны, ничек сагынмыйсың?
Күзне кояш-чакма чагып алгач, ничек кабынмыйсың?

Сабый гөлләр, иркә киерелеп, буйга үскән чакта,
Өр-яңадан таҗын ача бәхет, язын, туган якта.

Җилләре дә ялмап ала гүя кышкы кәефләрне.
Сиңа кабат гашыйк булдым, дисәм, ярым гаепләрме?!

Иелдерә бөгелмәстәй буйны тәүге үләне дә.
Әллә язын ягымлырак шунда күрше-күләне дә?

Адымнар да йөгерекләнеп китә, оныклардан күреп.
Онытыла кышкы «олыгаю», саф һавада йөреп.

Әй, туган як, гүзәл һәр фасылың, язың бигрәкләр дә!
Дәрткә тула тәүге күк күкрәүдән салмак йөрәкләр дә.

Ничек яратмыйсың бу язларны, якты җәйләр алда!
Бу дөньядан ничек ваз кичәсең, тәндә җаның барда?!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Наилә
Харисова

# ҮТТЕ ИНДЕ

ПОВЕСТЬ*

### Автордан кереш сүз

Мин бер яңалык та ачмам, мөгаен. Бөек Ватан сугышы һәм аннан соңгы елларның тылдагы авырлыгы, шул авырлыкны үз җилкәсендә татыган татар хатын-кызларының язмышы турында татар әдәбиятында язылмады түгел. Кайберәүләр, бәлки, әлеге чор тулы фаҗигаләргә гаҗәпләнүдән дә туктагандыр. Тик һәрбер язмыш үзенчә, кабатланмас. Бүген якты дөнья белән хушлашып бетә язган буын тарихы белән танышканда, кеше психологиясенең сугыш ачып җибәргән саф, самими яклары белән бергә, хөсетлек, шәфкатьсезлек, азгынлык кебек сыйфатларның күплеген күреп шаккатасың. Алар бит дошманнарга карата түгел, үзенекеләргә карата күрсәтелгән: илдәшеңә, авылдашыңа, милләттәшеңә һәм, ниһаять, туганыңа, хәтта балаңа. Андыйларга каршы торырдай сабырлык, миһербанлылык, рәхим-шәфкать хисләре халкыбыз күңелендә гел табылып торган, шөкер.

Бу әсәрнең нигезендә реаль вакыйгалар ята. Алар миңа таныш булмаган, инде бакыйлыкка күчкән бер әбекәйнең истәлекләренә таянып бәян ителде. Аннан тыш интернетта булган сугыш чоры хатирәләре файдаланылды. Укучы шушы чорны ачыграк итеп күз алдына китерә алсын өчен аларны кайбер эпизодларда әсәремә кертеп җибәргәнгә авторлар мине кичерерләр дигән өметтә калам.

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсында «Повесть» номинациясендә 1 урын алган әсәр.

Наилә ХАРИСОВА (1959) – *язучы; Таҗи Гыйззәт исемендәге премия иясе. «Агымсулар ни сөйли?», «Гомер йомгагын сүтәм» исемле китаплар авторы. Әгерҗедә яши.*

***

Май аеннан да матур ай юктыр ул. Бөтен табигать, табигать белән бергә кешеләр дә яшәреп киткән кебек. Аңа гына түгел инде. Тиздән уку елы бетә! Каникуллар җитә. Шатланыр өчен моннан да шәп сәбәп булырга мөмкинме соң?! Дөрес, каникулга хәтле дә май аенда календарь безне ял иттереп-иттереп ала. Башта 1 Май бәйрәме. Аның исемен безнең өйдә төрлечә әйтәләр. Календарьга карап, эти: «Яз һәм хезмәт бәйрәме», – ди. Әни: «Без бәләкәй чакта бу көнне Карга боткасы пешерергә болынга чыга идек», – ди. Миңа монысы ныграк ошый ошавын, тик хәзер болынга чыгып, ботка пешереп, берсе дә без бала-чаганың күңелен күрми.

Аннары 9 Май. Монысының ни икәнен беләбез. Дөрес, күп әйбер аңлашылып бетми әле. Мәктәптә, ел саен апрель уртасы җитүгә, шушы бәйрәмгә әзерләнә башлыйбыз. Геройлар турында да искә төшерәбез, өлкәнрәк класслар, ветераннарны чакырып, очрашулар оештыра, бәйрәм көнне үтәсе демонстрациядә күтәреп йөрергә ак кәгазьдән чәчәкләр дә ясыйбыз.

Бәйрәм көнне клуб янындагы һәйкәл дә матурланган була. Без кайтып киткәндә, чәчәкләргә күмелеп кала. Ветераннар каршына басып, концерт куябыз да без, бала-чага, таралышабыз. Ә сугыш һәм тыл ветераннарын клуб эчендә әзерләнгән бәйрәм табынына алып кереп китәләр. Әби-бабайлар нишлиләрдер инде анда – белгән юк. Белер идем дә, тыл ветераны булса да, карт әбием Рауза соңгы елларда анда бармый. Ел саен клуб мөдире Фирая апа килеп чакыра югыйсә. Әби: «Рәхмәт, балам, рәхмәт! Мин бара алмам инде. Ачуланма!» – диюдән узмый. Фирая апа ныграк кыстый башласа, булмаган авыруларын уйлап чыгарып, барыбер бармаска сәбәп таба. Ел саен шулай. Аңа эти белән әни дә барырга кушалар. Сәбәбен сорасалар: «Үзем беләм, сорамагыз», – ди дә түр якка, үз «биләмәсенә» кереп югала.

Быел да шулай булды. Мин инде хәзер зур кыз. Сигезенче сыйныфны тәмамлыйм. Әби генә быел бик биреште. Күбрәк ятып тора. Өйдә кеше булмаганда, зал ягына чыгып, күзлеген кия дә саргаеп беткән дәфтәр битләренә нидер яза. Сорасаң, кеткелдәп көлә: «Бәет язам», – ди. Укырга сорасаң бирми. «Бетмәде әле», – ди.

Быел бәйрәмдә без малайлар белән солдат киеме киеп, вальс әйләндек. Бик матур булды, диделәр. Үзебезгә дә ошады. Өйгә кайткач та, бәйрәм хисләреннән аерыла алмыйча, залны иңләп-буйлап җырлый-җырлый, вальс әйләнеп йөрим:

С берёз неслышен, невесом,
Слетает жёлтый лист.
Старинный вальс «Осенний сон»
Играет гармонист...

Хисләнеп китеп сизми калганмын: Рауза әбекәй чыгып карап тора икән. Аны да үзем белән ияртеп әйләндереп китмәкче идем, булмады.

– И-и, бакчы, ни булган бу балага? Канатым, әллә берәрсе башыңны әйләндердеме?

Битендәге һәр җыерчыгыннан хәйләкәр елмаю, җылы нур бөркегән карт әбиемнән берни дә яшереп булмый.

– Менә атьмим әле! – дим мин, боргаланып. – Үзең бер дә яшерә-яшерә нәстә язганыңны миңа атьмисең.

– Белерсең, сабыем, озакламый белерсең. Барыгыз да белерсез. Шының өчен язам инде мин аны. Йә, әт инде, бәйрәмдә кемнәр бар иде соң?

Мин таныган-белгән әби-бабайларны саныйм. Әбекәем кайсының исемен әйткәндә хуплаган кебек, кемнедер әйткәндә ошатмыйча, башын селкеп тора, «Ул да бар идеме?» – дип кабатлап сорый.

– Сине сорадылар. «Нигә килмәде?» – диделәр.

Карт әбиемнең йөзеннән моңсулык дулкыны йөгереп узды. Яулык астыннан күренеп торган ак чәчләрен рәтләштергән булып, күзен дә сыпырып алды бугай. Аннары орчык хәтле генә гәүдәсе чаршау артына кереп югалды.

Карт әбием мин өйдә юк чакта, район үзәгендә җәйге лагерьда булганда, мәңгелеккә китеп барган. Өйгә мине карт әбиемне озатасы көнне генә алып кайттылар.

Болай да юка гәүдәле әбием бөтенләй кечерәеп калган кебек. Менә хәзер күзләрен ачар да: «Әйдә, канатым, кура җиләкләрен җыеп керик әле, коела башларлар», – дип әйтер кебек. Тик ул бүтән күзләрен ачмады.

Өлкәннәр сөйләшкәннән мин карт әбиемнең ниндидер язулар калдырганын беләидем. Балалыгым белән мин аларга әллә ни әһәмият бирмәгәнмен. Аның вафатыннан соң берничә ел үткәч, Кәүсәрия әбием миңа бер кәгазь төргәк бирде.

– Карт әбиең калдырды. Үләренә берничә көн калгач, мине үзе янына утыртты да:

– «Кызым, син минем бердәнберем булдың. Бу дөньяда яшәвем дә синең өчен булды, сөенечем дә, көенечем дә син идең. Аннары – синең балаларың. Минем тормышым синең күз алдыңда үтте, рәхәт чакларыннан авыр чаклары күбрәк булса да, мин бу дөньядан Аллакаема шөкерана кылып китәм. Бәхетемне картлык көннәремә калдырган булган икән. Һәрбарчагыздан риза-бәхил. Соңгы үтенечем: менә бу язуларны теге татарча сөйли торган телевизорга илтеп бирегез. Анда минем күргәннәрем язылган. Син белмәгәннәре дә бик күп. Берәрсе, бәлки, китап язар, кино ясар. Дошманнар ул нимесләр генә түгел. Кайчан да булса, тылда михнәт чиккәннәрнең дә хәлен аңларлар әле», – диде. Шуннан соң ул күп тормады. Гел сине сорады. Ишек ачылган саен: «Минем наныем катьтеме әллә?» – ди иде. Күреп каласы килгәндер инде. Без дә синең кайтканны көтәрме әллә дигән идек тә бит...

* * *

Мин мәктәпне күптән тәмамладым инде. Кәүсәрия әбием дә бакыйлыкка китеп барды. Һаман Рауза әбиемнең аманәтен тормышка ашыра алмый йөрим. Моның өчен аннан калган истәлекләрне үземә укып чыгарга, йөрәгем аша уздырырга кирәк. Хәзер дә саргаеп беткән дәфтәр битләрендәге Рауза әбиемнең истәлекләрен укып, аңларга тырышып утырам. Ул, мөгаен, аларны күптән, бик күптән яза башлагандыр. Кайбер битләре инде

таушалган, кайбер вакыйгалар кат-кат язылган. Сызгаланган, төзәткән җирләре дә күренә. Күрәсең, сикәлтәле тормыш юлында чыгымчы язмыш аты Рауза әбиемне, сыртыннан төшереп калдырырга теләгәндәй, әле тегендә, әле монда селтәгәндер. Шул вакыйгалардан соң дистә еллар үткәч, карт әбием кулына каләм алгандыр. Хәтер җебен эләктереп, үткәннәренә сәяхәт иткәндә дә, ул кайбер урыннарны тыныч кына узып китә алмаган: әле кәгазь битен ачы күз яшьләре белән чылаткан, әле язганын бозып атып, яңабаштан язарга тотынган. Аның авыр хезмәттән кәкрәеп калган кул бармакларына охшаш хәрефләре аша мин аның үзен күрәм сыман. Ул үзе турында сөйли, ә мин, аның туруны, Рауза әбием булып, узган гасырда яшим, ул булып сызланам, елыйм, ул булып кайгырам, түзәм, кайчагында шатланам да...

**Беренче дәфтәр**

## Ятимлек ачылары

Туганчы ук Аллаһы Тәгалә мине фанилыкта сабырлыгыңны сынармын дип әйтеп куйган булгандыр. Әткәй үзе 14 нче елгы герман сугышыннан исән кайтса да, өч абыйсы, кияве чит җирләрдә калып, туфрак булганнар. Ә бер абыйсын сәнәкчеләр артыннан куып килгәннәр дә, салам эскертенә кереп качканын сизеп, саламы-ние белән ут төртеп яндырганнар. Бу – 1924 нче елны булган. Әтинең сеңлесе Шакирә апа, ирсез калып, балалар үстерде.

1936 нчы елның кышы иде. Кеше күрмәгәндә, алласызлар мәчет манарасын кисеп төшерәчәкләр икән, дигән хәбәр таралды. Төнлә белән без дә урамга чыктык. Аркылы пычкы, балта белән манара кисүчеләрне җирдәге дистәләгән авыл кешесе каргап басып торды. Беркем дә якынрак килеп, аларны тыярга җөрьәт итмәде. Манара бирешергә теләмичә ыңгырашты, сызлангандай улады, аннары гөрселдәп, җиргә ауды. Шунда әни аңын югалтып егылды. Ул, мөгаен, аңарчы да авырган булгандыр. Без, беребездән-беребез бәләкәй дүрт бала, әни янында елап торудан ары нишли ала идек соң? Әнине Шакирә апа карады. Шул елны әни утыз ике яшендә, унбер, тугыз, җиде, дүрт яшьлек балаларын калдырып, вафат булды. Әниебез үлгәннән соң кечкенәбез дә озак яшәмәде. Мескен энебезгә тәрбия дә җитмәгәндер. Барыбыз да ачлы-туклы идек. Шулай итеп, әни иң беренче үзе янына нәни улын алды. «Интекмәсен!» – дигәндер инде.

Бәла ялгыз йөрми, диләр. Беркөнне әти манма суга баткан, дөресрәге, киемнәре бозланып шыкраеп каткан килеш кайтып керде. Ул артельдә эшли, Казаннан Чистайга товар ташый иде.

– Балалар, харап булдык. Чак үлемнән калдым бит. Каманы чыкканда, боз ярылып, ат товары-ние белән төпкә китте. Рәхмәт, иптәшләрем, дилбегә ташлап, үземне коткарып калдылар, – ди. Үзенең теше-тешкә тими. Без, балалар, әтигә сарылдык. Аннары, искә килеп, аның бозлы киемнәрен салдыра башладык. Үзебез елый-елый аңа:

– Әткәй, син булса да безне калдырып китмә инде. Синсез без нишләрбез?

– Әткәй, чишен тизрәк, чирләрсең бит!

– Безнең бәхеткә исән калгансыңдыр инде, әткәй, – дибез.

– Әй балалар, моның белән генә эш бетми шул әле. Без авылга кайтып

керүгә, арттан бастырып районнан килеп җиттеләр. Кәнсәгә кертеп, бик озак сорау алдылар. «Нигә үзең исән калдың да артель милке су төбенә китте? Син – корткыч. Иптәшләрең белән сөйләшеп, шулай эшләгәнсең», – диләр. «Башыңны төрмәдә черетәбез», – дип куркыталар бит, балакайларым.

Хаклы булган икән: әткәйне биш елга төрмәгә утырттылар. Суга баткан ат өчен өйдәге атыбызны, товарлар өчен сыерыбызны тартып алдылар.

Без, өч ятим, Шакирә апага сыенып калдык. Ул үзе бик көчле дә, мәрхәмәтле дә хатын иде. Үзенең тегү машинасында, иске киемнәрен кечерәйтеп, безгә киемнәр текте. Безне яклап, каенанасы белән дә телгә килә иде. Ул күрмәгәндә, безгә каты-коты булса да, ризык бирергә тырышты. Әти төрмәдә чакта без, ягарга утыныбыз булмагач, кышны аның янында чыга идек. Җәйне үзебездә яшибез. Мин көндез кем чүплеккә нәрсә чыгарып ташлый, шуларны карап йөрим, караңгы төшкәч, тула оек кисәкләрен, иске чабаталарны җыеп кайтам да төне буе шулардан аягыма берәр нәрсә әмәллим.

Мине Шакирә апа ун яшьтән эшкә урнаштырды, чөнки кырда эшләгән кешене бер тапкыр ашаталар иде. Шул ашауга кызыгып, сигез яшьлек энем дә миңа булыша иде. Эштән туктап торган арада җиде чакрымдагы урманга чабабыз. Балтырган, какы, юа җыябыз, әнис белән саз үләненең орлыгын авызыбызга тутырабыз, кычыткан, алабута – берсе дә бездән артмый. Чөнки без эштән кайтуга, авылга якын җирләрдә боларның берсе дә калмый. Шакирә апам – балачактан бирле безне үзенең канаты астына алып, үксез җаннарга җан җылысы биргән апам ул. Әтидән дә күрмәгән изгелекне аннан күрдек.

– Түзегез инде, балакайларым! Әтиегез исән-имин кайтсын дип теләгез! – ди торган иде Шакирә апа. Түзәргә! Түзәргә! Түзәргә! Берәр вакыт безнең урамда да кояш чыгар әле!

## Атлар да сагына микән?

1941 елның язында мине һәм авылдан берничә кешене Казан – Бөгелмә тимер юлын салырга җибәрделәр. Меңләгән кеше, йөзләгән ат карьердан таш чыгарды. *(Тарихи белешмә. 1941 елда тимер юлның Казан – Бөгелмә сызыгы төзелә башлый. Аның маршруты Дәрвишләр разъездыннан башланып, Биектау, Питрәч аша узып, Чулман елгасын Чистайдан 12 чакрым читтә, Кубас авылы янында кичеп, Чистай, Каргалы, Яңа Чишмә, Кичү, Мәмәт, Писмән аша Бөгелмә янындагы Акбаш станциясендә Куйбышев тимер юлы белән тоташырга тиеш булган. Төзелеш эшләре сугыш башлангач та дәвам итә, 1942 елда гына туктатыла.)* Таза ирләр кувалдалар, ломнар, киркалар, балталар, көрәкләр белән ташны ваталар, хатын-кызлар шул ташларны арбаларга төяп торалар. Без, уналты яшьлек кызлар-егетләр, юлга чыгарабыз. Килеп җиткән арбаны хатын-кызлар бушаталар да, ирләр шул ташларны вак ташлы ком белән бутап, юлга тигез итеп җәяләр. Эшебез бик авыр. Әле буыннары да ныгымаган балаларга көн буе эшләүнең газабы яшьлек белән генә сизелмәгәндер. Дөрес, ашата иделәр. Безгә бу тимер юлның кирәклеге турында гел аңлатып тордылар. Тырышып эшләмәсәк, Сталин сүзен тыңламаган, матур киләчәк төзүгә

аяк чалган булып чутланасың, диделәр. Кирәген кирәк булгандыр ул. Тик колхозчыда булган корал, колхозлардан алып килгән мескен атлар белән генә ерак китеп булмый шул. Кичкә бөтен буыннар сызлый, уч төпләре башта канап интектерде, аннары бирчәеп катты. Шулай да Каманың теге ягында тимер юл үтәсе юлларны (ничә чакрым булгандыр) салдык. Кайда ун, кайда егерме метрдан биегрәк валлар күтәрдек, калку урыннарны кистереп тигезләдек.

Авыр хезмәт иң куркынычы булмаган икән әле. Кар эреп бетүгә җибәргәннәр иде, 22 июнь көнне төшке ашка китәр алдыннан: «Сугыш башланган!» – дигән хәбәр килде. Китте елаш, ыгы-зыгы. Мәхшәр купты. Эшне туктатып, безне мәйдан кебек җиргә җыйдылар. Участок начальнигы калкулыкка менеп басты. Исәнләшеп-нитеп тормый гына сүз башлады:

– Сугыш төрле саботажга сәбәп була алмый, иптәшләр. Берегез дә беркая таралмый. Өйләрегезгә кайтып китү турында онытыгыз. Туган елы 1905нче елдан башлап, 1918 нче елга кадәр булган ир-атлар военкоматка барырга тиеш. Хәзер үк. Нишләргә кирәген анда аңлатырлар. Ә калганнарыгыз бөтен эш кораллары, атлар белән бергә Мәскәү янына окоп казырга җибәрелә.

Мәйдан аның сүзләрен каплап гүелдәргә тотынды:

– Киемнәр теткәләнеп бетте. Шул килеш җибәрәсезмени? Анда безне кем көтә?

– Хет өйдәгеләрне күреп, китәселәрне озатып калырга рөхсәт итегез! Бәлки, соңгы күрешү булыр.

Участок начальнигы башта кулын күтәреп, халыкны тынычландырырга тырышып карады. Куркыныч хәбәрдән һәм билгесезлектән ярсыган халыкны алай гына туктатып буламыни?!

– Молчать! Дошман сезнең елый-елый солдат озатканыгызны көтеп тормый. Сезнең анда бүген булуыгыз, менә хәзер китүегез кирәк. Немец бүген анда, иртәгә Мәскәү янында булырга мөмкин.

*(Бу сүзе өчен ул бик үкенәчәк әле. Аны «Совет властена каршы пропаганда алып бара, аның көченә ышанмый», – дигән яла белән кулга алганнар. Ахырда эзсез югалган.)* Аны бүген туктатырга кирәк. Шуңа күрә сезне кичекмәстән Мәскәү астына окоп казырга җибәрергә приказ булды. Һәм бу приказны берсүзсез үтәячәкбез!

Безне бөтен арбаларыбыз, атларыбыз белән бергә товар ташучы вагоннарга төяп алып киттеләр. Башта атларны берничек тә вагонга кертә алмадык. Чөнки «Аналарына комачаулыйлар!» дип, колыннарны аерып калдырмакчылар иде. Аналар һич кенә дә балаларыннан аерылырга теләмәделәр. Менә ул балага карата бөек мәхәббәт! Мин баласын ташлап киткән аналар турында ишетсәм, гел шул атлар күз алдына килә. Ничек кенә тырышсалар да, аларны колыннарыннан аерып, вагонга аяк бастыра алмадылар. Тайлар елый, атлар елый, аларга кушылып, без елыйбыз! Адәм балаларына мәрхәмәтле булырга хайваннардан өйрәнергә кирәк! Ахырда, алдан тайларны, аннары атларны керттеләр дә, аннары ничек кирәк алай, тайларны чыгарып җибәрделәр.

Барабыз, барабыз... Вагонда эссе, тынчу. Әле һәркайсы үз уена чумып утыра, нидер уйлый. Әле алда нәрсә буласын гөманлап сөйли башлый.

Барыбызның да яхшыга өметләнәсе килә. Берәрсе куркынычрак фараз әйтсә, тизрәк:

– Авызыңнан җил алсын! Тфү-тфү дип әйт, – дип, аны туктатабыз.

– Кызлар, бер атна барабыз бит инде. Кайчан килеп җитәбез инде бу Мәскәү дигәненә?

– Туктамыйча булмыйдыр шул. Сугышка солдатларны алып китәләр. Аларны үткәреп җибәрмичә буламыни?

– Әйе, кичә дә танклар төяп, ике состав узып китте.

– Кайсы станциядә вагоннан чыгарга рөхсәт булыр икән? Атларның су эчәсе килә. Бөтенләй хәлсезләнеп бетәләр бит болай булса.

Минем Адюрым да авырый. Авыз-борыны чабырып чыкты. Бертуктамый ыңгыраша. Әллә авыртынудан, әллә колынын сагынудан.

– Атлар да сагына микән ул, кызлар?

– Ничек сагынмасын, күрдегез бит аерылмас өчен ни генә кыланмадылар.

– Кызлар, минем Адюрымны беләсез бит: гәүдәсе дә ике ат хәтле, ике ат хәтле эшли дә. Безнең авылда берәрсе зарлана башласа: «Адюр хәтле башың белән шыңшып утырасың», – диләр.

– Менә шундый атны да сагыш җиңде, диген.

– Рауза, ул бит сине генә тыңлый. Ир-атларны да бар дип тә белми.

– Соң, ул бит безнеке, кызлар! Үзебез карап үстергән ат. Колхозга тартып алдылар, тик тыңлата алмадылар. «Бандит» кушаматы тагып куйдылар.

## Мәскәү янында

Мәскәү янында безне урман чыгару эшенә куйдылар. Утыз яшьлек хатыннар кул пычкысы белән урманны кисәләр дә безгә төяп җибәрәләр. Халык окоп казый. Илле яшьлек ирләр китергән агачлардан блиндажлар, землянкалар төзиләр, окоплар ныгыталар.

Мине Гөлҗиһан исемле кыз белән бер рус карчыгына торырга керттеләр. Гөлҗиһан – Донбасстан. Русчаны су кебек эчә. Кайткан саен хуҗа карчык бездән:

– Детки! Эштә нәрсәләр сөйлиләр? Сугыш бетә димиләрме? – дип сорый.

– Нинди бетсен, ди? Торган саен якыная гына. Ишетмисеңмени, бабуля, туп шартлаган тавышлар монда кадәр ишетелә бит, – ди Гөлҗиһан.

– Мылтык, туп тавышларыннан куркып, атлар сикереп куя, – дип, мин дә өстәп җибәрәм.

– Атлар гынамы? Үзебез дә белгән догаларыбызны укыйбыз. Руслар Гитлерны каргап чукынып куя.

– Болай гына соравым инде, детки. Һаман да яхшы хәбәр ишетәсе килә бит, – дип уфтанып куя хуҗа карчык.

Гөлҗиһан ничектер олы кешене бик санлап бетермичә сөйләшергә ярата торган кыз иде.

– Һи! Сиңа нәрсәсе? Үз өеңдә торасың. Эш кушкан кеше юк, – димәсенме.

– Хикмәт эш кушудамыни? Менә сез дә урамда түгел, өйдә торасыз. Үзегезнеке булмаса да. Аңа карап кына сугышның авырлыгы кимеми бит. Минем ике улым фронтта. Киткәннән бирле бер хәбәрләре дә юк. Тиз генә

бетмәсен белсәм дә өметләнеп сорыйм инде. Патшалар сөйләшеп, тизрәк туктатмаслар микән, дим.

– Тиз генә бетмәс әле ул. Атларны саклап кунганда, «Хәзергә көннәр җылы. Суыта башлагач нишләрбез икән?» – дип уйлый башлаган идек инде. Бер рәхимле бәндә табылды. «Балалар, төнлә атларыгызны үзем карармын, сез йоклагыз!» – диде. Без төнлә ат сакларга йөрмәячәкбез моннан соң, – дибез. Күңеле нидер сизгәндәй, әбиебез:

– Шулай әйткәнчә генә булса ярый да... Хәзер кешеләргә дә ышаныч юк. Атларыгызга зыян салмаса ярый инде, – диде нигәдер.

Ул хаклы булып чыкты. Теге абзый төннәрен безнең атларның солысын алып, үзенең атына ашата икән. Шуңа аның аты хәлле. Ә без норманы үти алмыйбыз. Безгә көнгә чирек ипи бирәләр, аңа – яртыны. Аны мактыйлар, ә безне ялкаулар дип сүгәләр.

Берничә көннән Гөлҗиһан белән безнең юллар аерылды. Анысы болай булды: Гөлҗиһан, әби көтү озатырга киткәч, әбинең калган ризыкларын ашый икән. Ә мин йоклыйм. Әби кич белән кайткач: «Кайсыгыз минем ризыгыма кагылды, девки? Мин сезне үз балаларым кебек күрдем. Фатирга кертеп, түремә үткәрдем. Ә сез?» – ди икән. Мин бит барысын да ныгытып аңлап бетермим. «Рауза ашагандыр, мин күрмәдем» ,– ди икән Гөлҗиһан. Әби миңа акаеп кычкыра. Мин, аптырап, Гөлҗиһанга карыйм, ә ул бернәрсә дә аңлатмый. Беркөнне бригадир миңа иртәнге өчтә килергә кушты. Әби мине уятып җибәрде. Гөлҗиһан минем киткәнне белмичә калды. Иртән әби көтү куып кайтса, ашарына юк. Әби шунда кем гаепле икәнен аңлап алган да Гөлҗиһанны куып чыгарган. Үзебезнең татар кызлары арасында да шундыйлар очрады.

Ә бу хәлләрдән соң әби миңа карата үзгәрде: кайтуыма юынырга, керләремне юарга җылы су әзерләп куя торган булды, үзеннән калган ашауларын да бирә башлады. Тормышымда, шөкер, мәрхәмәтле кешеләр очрап торды. Әгәр алар булмаса, мөгаен, бу көнгә кадәр яши дә алмаган булыр идем. Бу рус карчыгына мин хәзер дә рәхмәт укыйм, догамнан калдырмыйм.

Бүгенгедәй хәтеремдә, бер иртәне ипләп кенә мине уята:

– Доченька, тор әйдә. Бүген күрше хатыннар җиләккә баралар. Син дә шулар белән бар. Ашарыңа булыр.

– Син, нәстә, бабушка, – дим,– эшкә чыкмасам, мине бит үтерәләр. Мин атлар башында, минем юклыкны шунда ук сизәчәкләр.

– Анда кеше күп, бер генә көн синнән башка да эшләрләр. Мин синең бригадирыңа авырыйсың дип әйттем инде. Бар, курыкма. Болай ачка үләсең бит. Көн дә бер стакан җиләкне ипи белән ашасаң, хәтсезгә җитә әле ул. Безнең күршеләр берәр чиләк җыялар. Син җитез бала, алай гына син дә җыярсың, – ди, ике уйларга ирек куймыйча әбием.

Әби дөрес әйтә. Төшке ашка биргән бер тәлинкә аш, бер калак борчак боткасы, бер стакан чәй белән генә әллә кая китеп булмый. Эш авыр. Татарстаннан килгән күп кенә кызлар, йоклаганда ипи талоннарын урлатып, бөтенләй коры сөяккә калдылар. Бик күбесе ачтан үлде.

Окоп казу эшләре беткәч, атларыбызны алып калып, үзебезне кайтарып җибәрделәр. Ә егетләрне учениегә алып калдылар. Сугышка әзерлиләр.

Бергә эшләп, якын кешеләр булып беткән егетләр белән бик авырдан аерылыштык. Кайбер кызлар егетләр белән ныгытып дуслашырга да өлгергәннәр иде. Яшьлек – җир йөзендә нәрсә актарылып ятса да, яшьлек бит инде ул! Аларга аеруча кыен булды. Күңелләре белән мәңгелеккә аерылышуларын белеп, шулай да күрешергә өмет итеп аерылышу иде бу.

Утыз биш кыз туган якларга кайтып киттек. Төгәл өч ай кайттык. Көндез поездлар йөрми, төнлә генә кайтабыз. Сугышка баручыларны, фронттан яралыларны ташучы поездларны үткәреп җибәрәбез. Юлда ниләр генә күрмәдек. Яралы солдатларны бер поездан чыгарырга ярдәм итәбез, яраларын юып, икенче поездга кертешәбез. Шуның өчен азрак ашарга да бирәләр. «Кызлар, калыгыз, кием дә бирербез, ашатырбыз да», – дип үгетләделәр. Күрәсең, безнең хәлләр аларныкыннан да яманрак икәне күренеп торган. Ә без: «Авылны сагындык!» – дип кайтып киттек.

***

Беренче дәфтәр шунда тәмам. Мин укыганнарымнан алган тәэсирләр чолганышында утырам. Рауза әбием бу хәлләрне кичергәндә, миннән берничә яшькә яшьрәк тә булган бит. Шушы яшенә кадәр авылыннан чыкмаган, русчасы да такы-токы булган, тормышны – хәйләсез, кешеләрне самими итеп кенә күрә белгән татар кызы. Ничекләр түздең икән син?!

Кайберәүләр мине Рауза әбиемә охшаталар. Сүзләрендә, бәлки, хаклык та бардыр. Мин үземне аның урынына куеп карыйм да: «Ә мин әбием кичергәннәргә түзә алыр идем микән?» – дим. Картлар әйтмешли, рәхәтлектән бозылган буын баласы бит мин! Бер караганда, яннарында автоматын тезәп, фашист та тормый, баш очыннан пулялар да очмый. Ә шулай да... Бик авыр булгандыр. Нигә? Эш авырлыгыннан гынамы? Ачшәрәлектән генәме? Башыма килгән фикерне хәзергә әйтми торам әле. Бәлки, мин ялгышамдыр. Шулай гына булсын иде. Мин икенче дәфтәрне укый башлыйм.

**Икенче дәфтәр**

## Авылда өч көн

Унбер кыз авылга кайтып егылдык. Юлда өч кызыбыз үлеп калды. Аларның мәетләрен станцияләрдә бер-бер артлы вагоннан алып чыктылар. Кайларда ничекләр күмелгәннәрдер инде ул мәрхүмәкәйләр?! Бер авыл туфрагында аунап үскән, ничә ай бергә эшләгән, сер бүлешкән кызлар, әле яшәргә дә өлгермәгән, сабыйлыктан чыгып кына баручылар иде бит алар! Кайткач, ата-анасына ниләр әйтербез?

Ачлыктан хәлсезләнгән гәүдәбезне сөйрәп, аннан да авыр кайгы күтәреп, авылга кайтып кердек.

Кайтып җиткәнче, әби киендереп җибәргән киемнәр, чабаталар теткәләнеп бетте. Авылга кайтып өс-башны бөтәйтү турында артык хыялланмасам да, бу кадәр үк булыр димәгән идем. Өйгә кайтып керсәм, илле бер яшьлек әтине Златоустка хезмәт армиясенә, апамны Шәмәрдәнгә урман кисәргә, энемне ФЗӨгә җибәргәннәр иде. Төрмәдән кайткач, әти өйләнергә өлгергән иде. Өйдә авырлы үги әни. Кычкырып еладым. Җанына

да, тәненә дә җылылык эзләп кайткан уналты гына яшьлек кыз бала бит мин! Кая барып сыеныйм?!

Минем бердәнбер сыеныр кешем һаман да шул әтиемнең сеңлесе Шакирә апа иде. Аның улы Габбасны да сугышка алганнар.

– Ил белән күрәбез, балам, сабыр бул! – ди Шакирә апа.

Авылда озакка калырга туры килмәде: без кайтуга, торф чыгарырга чакырып, повесткалар килгән иде инде. Калудан мәгънә дә юк. Монда хәлләр тагын да авыррак. Авыл тып-тын. Карт-коры, бала-чага, әзрәк хатын-кызлар һәм сугышка яраксыз ирләр генә. Авылда ачлык-ялангачлык. Кызларның 1923-24 нче елгыларын сугышка алып бетергәннәр.

Кичтән Сафифәләрнең мунчасын ягып кердек. Аннары егетләрне сугышка озаттык.

Егетләр, гармун белән җырлап, урам әйләнделәр.

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласың.
Мин киткәчтен кемнәр сөяр
Син сандугач баласын.
Безнен авыл – зур авыл,
Килә кыйбладан давыл.
Алдагысын белеп булмый,
Их! Хәзергесе бик авыр.
Килче, иркәм, җиләк бирәм,
Җиләктән кайтып киләм,
Синең нурлы йөзләреңне,
Мин тагын кайчан күрәм?
Без китәбез иртәгә,
Шинель салып җилкәгә.
Китмәс идек иртәгә
Сугыш тия теңкәгә.

– Их кызлар, каласыз бит Пыртый Сәлимнәренә!

Янымда сөйгән егетем Мөхәммәт. Ул да иртәгә китә.

– Рауза, мәгәр берәрсен үзеңә якын җибәргәнеңне ишетсәм... Үзең беләсең... – дип, мине шытырдатып кочаклый.

– И Мөхәммәткәем, күңелеңә дә кертмә андый уйны. Миңа синнән башка берәүнең дә кирәкмәгәнен үзең дә беләсең бит инде. Син исән-сау йөреп кайт. Ходайдан көн дә ялварып сораганым шул булыр. Мин көтәрмен, син кайт кына! – дим аңа, тагын да ныграк сыенып.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява
Өй түбәсе калайга.
Җанкисәкләр, каласыз бит
Шул селәгәй малайга.

Җырның монысы яшьрәк егет-малайларга ошап бетми.

– Нигә алай әтәсең инде, Зариф әзи? Сезнең арттан безгә дә цират җитәр.

– Курыкмагыз, без аларны күз карасыдай саклырбыз. Ызбаларыннан да цыгармабыз. Үзебездән башка берәүне дә якын китермәбез.

– Матри аны, малай, Гелүзә апаңа якын киләсе булма! Кайтып, артык-портык зирләреңне кыцыткан белән... Әпәй сәндерәңә менеп кенә калмам...

– Юк-юк! Багарга да рөхсәт сорап кына...

Шулай аерылу ачысын уен-көлке астына яшереп, кич узды. Иртән аларны озатып калдык. Күбесеннән мәңгелеккә аерылдык. Егетләр белән бергә моңарчы бронь белән калган тракторчы Мәхмүт абый да китте. Соңгы минутка кадәр нык кына булып йөрде үзе. Атлар кузгалып киткәндә, гармунны каерып ачты да сузып җырлап җибәрде:

Аклы ситсы күлмәгеңне
Көн дә киеп каралтма.
Мин китте дә бетте диеп,
Балаларны таратма…

Берсеннән-берсе вак балаларының кайсын күтәреп, кайсын итәгенә сыендырып басып торган хатыны аһылдап елап җибәрде. Аның өзгәләнеп елавына бөтен хатын-кыз җәмәгате кушылды. Шушы үксү тавышы астында авылдан чыгып киттеләр.

## Торфта яки су кызлары

*Тарихи белешмә. Бөек Ватан сугышы башлангач, ягулык буларак кулланылган торф чыгаруның әһәмияте нык арта. 1942 елда халыкны торф әзерләү эшләренә мобилизацияләү турында халык комиссарларының 260 нчы карары чыга. Бу эшләргә хезмәткә яраклы колхозчылар, 16 яшьтән 55 яшькә кадәрге ир-атлар, 16-45 яшьлек хатын-кызлар җибәрелергә тиеш була. Һәрбер авылга, колхозга ничаклы кеше җибәрелергә тиешлеге турында «разнарядка» килә. Дәүләт Оборона комитетыннан килгән документта, бу карар үтәлмәгән очракта, һәркемнең җавапка тартылачагы кисәтелгән.*

*Ир-атлар сугышта, колхоз эшләрен алып бару, гаиләләрен туендыру хатын-кызлар өстендә. Карарны үтәргә яраклы булып яшьләр кала. Туган авылларыннан читкә чыкмаган, бер авыз русча белмәгән яшь кызлар һәм ир балалар шушы эшкә алына.*

Авылдан 1925-27 нче елгы унбер кыз торф чыгарырга киттек. Юлга чыкканда, Һадиянең әнисе кырык кабартма пешереп, киптереп: «Кызым, һәркөн берсен аша!» – дип җибәргән. Алар хәллеләр шул. Әтисе дә ничектер сугышка китмәгән. Бригадир булып эшли. Үзен ничек торфка җибәргәннәрдер. Һадиягә шуннан «Кырык кабартма» дигән кушамат ябышып калды. Менә бит ул ятимлек! Адым саен үзенең кара шәлен синең өскә ябып, кем икәнеңне искә төшереп тора.

Бер атнадан Мәскәү янына килеп җиттек. Минем үземне генә бер әбигә керттеләр. Эре гәүдәле, акрын гына атлап йөри торган рус карчыгы иде ул. Калын тавышлы. Күп сөйләшми. Әйтсә, берәгәйле әйтә.

– Әллә синең әниең юкмы? – диде әби, өйгә кереп, бераз вакыт узгач.

– Юк шул...– дим.

– Күренеп тора! Күзләрең моңсу. Үземнең янга ятарсың. Идән бик салкын.

– Рәхмәт инде, әбекәй! – дим, күңелләрем тулып. Күзгә мөлдерәп яшь тулды. Мондый мәрхәмәтле карашка өйрәнгәнмени мин! Авырлык, кырыслыкны күтәрә алам – йомшаклык күрсәм җебим дә төшәм.

– Иртәгә эшкә киеп барырлык киемнәрең бармы соң?

– Менә, бары-югы шушы.

Әби минем киеп килгән киемнәргә күз салды да теше сызлаган кеше кебек йөзен чытты.

– Болар белән торфта эшли алмассың шул, балакай. Әле син белмисең. Каторга хезмәте ул. Ярар, булган кадәре иске киемнәремне бирермен. Ә аягыңа... Ярар, бирәр нәрсә уйлап табарбыз.

Минем җылы киемнәрем дә барлы-юклы иде шул. Бер-ике көн үтүгә, авылдан киеп килгән итегемнең табаны төшеп калды. Сыек торф измәсеннән таба да алмадым. Әбием икенче көнгә миңа бераз гына киелгән кирза итекләр күтәреп кайткач, сөендем дә, аптырадым да.

– Әбекәй, каян алдың боларны? Минем бит түләргә бер тиен дә акчам юк.

– Кирәкми акчаң. Мин аларны синең теге начальникларыңнан – тыл күселәреннән алдым.

– Мондый итекне ничек ала алдың соң, әбекәй? Әйбәт бит әле бу. Акча түләгәнсеңдер бит.

– Нинди акча? Бригадирны сугып ектым да, итеген салдырып, сиңа алып кайттым.

Бу сүзләрне ишеткәч, мин бөтенләй курка калдым. Итекләрне танып алып, караклыкта гаепләсәләр? Минем уйларымны курыкынган күзләремнән укыды, ахры.

– Алай-болай кыерсыта башласалар, үземә әйт. Мин аларның күрмәгәннәрен күрсәтермен, – ди әбием.

– Әбекәй... Син минем Адюрым кебек бернәрсәдән дә курыкмыйсың икән.

– Кем соң ул Адюр? Егетеңмени?

– Юк инде. Безнең Адюр кушаматлы ат бар иде. Башта артельгә тартып алдылар. Аннары сугышка. Ул миннән башка берәүне дә тыңламады, берәүдән дә курыкмады. Син дә аның кебек.

Әби дөрес әйткән. Торф әзерләү эшләре ел әйләнәсе диярлек (9 ай) бара. Кышын, җир туңдыргач туктап, март аенда яңадан башлана икән. Шулкадәр авыр, шулкадәр авыр – әйтеп аңлата торган түгел. Көненә 12-14 сәгать, кайчагында 16шар сәгать эшлибез. Көрәк белән торф казыйбыз, балталар белән карьер ачабыз. Өске катны алгач, төрле агачлар чыга, аннан соң гына ныклы торф күренә. Өченче кат торфны казуы бигрәк авыр була торган иде. Юеш торф кисәкләрен кибәргә өябез. Күп вакыт сыек торфны билдән, хәтта күкрәктән ерып йөрергә туры килә. Безгә резин киемнәр дә бирәләр. Тик барыбер ул гына коткара алмый, бөтен гәүдә су була. Төнлә катырган апрель йә октябрь иртәләрендә су эчендә ничек салкын булганын үзе шунда булмаган кеше күз алдына да китерә алмый. Карьер ача торган кызларны шуңа күрә «Су кызлары» дип йөртәләр иде. Тик нихәл итәсең? Бары тик түзәргә генә кала. Түзәргә! Түзәргә! Түзәргә! Сулы торф бик авыр. Эчләр суырылып килә. «Ничекләр бала табарбыз инде?» – ди торган идек. Шул чагында ук эчем бик нык авыртып калды. Мин әле аның бу вакытта гомерлек чирем буласын аңлап бетермәгәнмен. Торфны кәрҗиннәргә салып, вагоннарга төйибез. Хатыннарның буыннары сызлый. Эчке әгъзаларына салкын тиеп газапланалар. Норманы арттырып үтәргә тырыша идек.

Безне гел йә дәртләндереп, йә ачуланып торалар. Начар эшләсәң, немец тегермәненә су коясың, имеш. Норманы арттырып үтәсәң, өстәмә 300 грамм ипи бирәләр. Кайчагында шуны сатып, акчасына кирәкле әйберләр алабыз. Такы-токы булса да, ашханәдә ашаталар, көнгә 800 грамм ипи. Ашата дигәннән, ашау димәсәң хәтере калыр: бер чүмеч сыек шулпа; анда бер-ике тамчы өресе, берәр калак ниндидер ярма булырга мөмкин; аннан бер-ике калак ботка һәм чәй. Анысы да кайчагында гына баллы була торган иде.

Фронт сызыгының бездән ерак түгеллеген чамалыйбыз, чөнки самолётлар бик якын үтә, кайчагында шартлаган авазлар да ишетелгән кебек булып, безнең котны очыра.

Мин, әйткәнемчә, бәхетемә, әбидә тордым. Салкын баракларда торучылар да булды. Утызлап, зуррак баракларда хәтта йөзләп кеше яшәде. Урын-җирләре саламнан. Үзләре чыгарган торфны баракка алып кайтып ягалар, кызуы яхшы чыга. Тик кеше күп булгач, бөтен кешенең дә киеме кибәргә өлгерми. Иртән шул юеш киемне киеп, эшкә чыгарга кирәк. Атнага бер тапкыр мунчага бару (ул вагонда) каралган, аның исемлеген көнләп язып куялар. Сазлык суы керне бик агарта иде. Шуңа да карамастан беткә, кандалага баттылар мескеннәр. Кайда ачлык, кайда хәерчелек – алар шунда бит инде.

Без анда төрле милләт кызлары идек. Дус эшләдек. Бары – бергә, югы уртак булды. Кемнең кемлеге аның кайсы милләттән булуына карамый шул. Дөнья булгач, җүнсезләре дә, яхшы кешеләр дә очрап тора. Беркөнне безнең баракта торган кызлар янына таныш түгел кеше килеп кергән.

– Татариядән Фәлән авыл кызлары монда тора дип әйткәннәр иде, – ди икән. Ул фәлән авыл кызлары баракта табылмаган. Шулай да безнең кызлар, «Якташ икән бит!» дип, хәзинәдәгесе белән чәй әзерләп, кунак итеп чыгарганнар моны. Чыгып киткәч, читтән карап торган бер кыз әйтә икән:

– Әйберләрегезне барлагыз әле. Күзләре бик шикле иде бу кешенең. Куллары да сөйләшкән чагында гел урын-җир астын капшап кына торды.

Чынлап та тикшереп карасалар, ятак астына яшереп куйган барлы-юклы акчалары, әйберләре югалганы ачыкланган. Чыгып йөгергәннәр дә йөгерүен, тик «якташтан» җилләр искән инде.

Без көз, кыш һәм яз көне торф чыгарабыз да, җәй көне шуны киптереп, вагоннарга төяп озатабыз.

Шунысына гаҗәпләнәм: торф чыгарган урыннар тирәсендә авылларда нәкъ безнең кебек кызлар-хатыннар да бар иде. Нигә аларны бу эшкә кушмаганнардыр? Әллә кайдан кеше китертеп, аны өеннән аерып газаплаганчы.

Мондый хәл булганы хәтердә. Бервакыт без торган бистәгә күршедәге колхоз рәисе килде.

– Кызлар, сезнең тырышлыкны белеп, үтенеч белән килдем. Быел уңыш яхшы, безгә урак урырга килмәссез микән, игеннәр әрәм була бит, – ди.

– Безгә торф нормасын тутырырга кирәк бит, – дибез, бер-беребезгә карашып.

– Беләм инде. Ял көннәрендә, дим. Зинһар! Үскән ризыкны черетмәскә иде бит. Эшләгән өчен ашатырбыз, бераз ризыгын да бирербез.

– Безнең ял көннәре дә юк. Үз авылыгыздагы кешеләр эшләмимени?

Без аларның өлешенә кергән булып чутланырбыз бит. Ашатсагыз, алар да эшләр.

– Үз кешеләребез дә бар инде. Тик сезнең хәтле эшли алмыйлар шул алар. Үзләренең яшелчә бакчаларында казыналар. Татар кызларының эшчән икәнлекләрен белеп килдем мин.

Туйганчы ашыйсы килү җиңде. Шулай торфка китеп, колхоз эшендә дә йөрдек әле без. Кайда авыр хезмәт – шунда татар кызлары булды. Имгәнүчеләр дә, гомерлек чир алучылар да, үлеп калучылар да күп булды. Аларның хисабын кем белә? Безне анда меңәрләп кенә санадылар. Немецлар басып алган җирләрдән килүчеләр дә күп иде. Бигрәк тә 1942 нче ел авыр булды.

Арабызда авылдагы хәлләрдән качып килүчеләр дә бар иде.

«Мин фермада сыер сава идем, – дип сөйләде Мөнҗия исемле кыз. – Мөртәт ферма мөдире бәйләнә генә бит:

– Нигә сөтең башкаларныкыннан аз? Өеңә ташыйсыңдыр әле, – ди. – Бер эләктерәм әле мин сине! – ди.

Бу сүзләрдә хаклык та бар иде. Өйгә ташымасам да, урын өстендә ятучы апамның ике кечкенә баласы кеше күрмәгәндә яныма килеп бераз сөт эчеп китәләр. Мөдир күрмәсә ярар иде дип, бик нык курыксам да, сабыйларны да ачтан үтереп булмый бит. Күпме генә эчерә идем инде, Ходаем! Сөтнең азлыгы бөтенләй алар эчкәннән түгел, сыерларның ачлыгыннан, миндә күбрәк яшь таналар булудан иде югыйсә. Аңлатып та карыйм. Юк, үз туксаны туксан. Сугышка бармас өчен бер күзенә зыян салып, авыл хатыннарына хуҗа булып яшәгән мөртәт тәки бер көнне тотты бит. Килгән шәпкә балаларны сугып екты. Үзем – үзем инде, түзәргә өйрәнгән. Апам, аның балалары жәл. Мескен сабыйларны:

– Бүтән эзегез булмасын монда, ач бетләр! – дип, артларына тибә-тибә, фермадан куып чыгарды.

– Ә сине төрмәгә олактырам! – дигәч, пычрак итеген кочаклап ялындым.

Шуннан соң йомшаган кыланып:

– Ярар, бүген кич сугылырмын. Сөйләшербез, – дип китеп барды. Аның бу сүзләре нәрсә аңлатканын, яшь булсам да, мин яхшы аңлый идем инде. Ферма хатыннарын кан елаткан бу имансыз бәндәнең азгынлык белән күптән даны чыккан. Сугыш башлангач, бөтенләй ни кыланганын белми, авылда аны акылга утыртырдай кешесе дә юк. Мин сыерларымны савып бетерү белән апаларга торып чаптым. Аңа хәлне сөйләп бирдем. Балалар да әйткән булганнар инде. Теге иблиснең сүзләрен дә җиткергәч, апа көч-хәл белән сәкедән торды. Юка гәүдәсе җилдән дә чайкалырга тора.

– Син бераз утырып тор, – диде дә, өстенә иске бишмәтен салып, каядыр чыгып китте һәм озакламый әйләнеп тә кайтты. Сары йөзендә тәвәккәллек чалымнары белән бергә газап ярылып ята.

– Бар, сәвит Сәгыйдә апаларга кереп чык әле. Анда торфка җибәрергә кеше таба алмыйлар икән. Тагын өч кеше кирәк, ди.

– Мин китсәм, сез нишләрсез, апа?

– Илдә чыпчык үлми. Син безнең өчен кайгырма. Үзебезне кайгыртып, сине Харрас мөртәт астына салыйммыни? Киткәнче үзегездә кунма. Монда кил. Иртәгә әни белән кәҗәңне монда алып килербез. Ничек тә кышны

чыгарбыз әле, – диде апа. Менә, ахирәткәйләрем, мин шулай итеп, «су кызы» булдым.

Мөнҗия сүзен тәмамлады. Без, авызга су капкандай, сүзсез калдык.

«Эх кызлар! – диде уналты яшьлек Минзәлә кызы Гөлҗәүһәр. – Сине карак кына ясый язганнар. Ә мине чүт кенә политический ясамадылар бит! Мин дә фермада сыер сава идем. Ышык лапаслар юк та юк бит инде. Көзге җилгә чыдамыйча, Груша кушаматлы сыерым һич кенә дә саудырып бетерми. Артыннан йөри-йөри имчәген тартам. Үзем: «Хәзер бетә, хәзер бетә!» – дип такмаклыйм икән. Минем шулай сыер сауганымны ферма мөдире Чалыш Шәмси тыңлап торган. Мин савып бетерүгә яныма килде дә: «Син нәрсәгә бетә дә бетә дип кабатлыйсың. Нәрсә бетә? Сыерыңның башы бетәме? Сөте бетәме? Болай да иң аз савучы син. Әллә колхоз бетә дип телисеңме, гөнаһ шомлыгы?» – ди бу.

«Нишләп колхоз бетә дип әйтим, Шәмси абый. Сөтеңне савып бетерәм дип әйтүем. Тыныч кына саудырмый бит. Шуңа артыннан йөри-йөри савам инде». «Син мине диванага санама, яме. Синең кебек классовый дошманнарны биш чакрымнан сизәм мин. Бу сүзләрең өчен җавап бирерсең», – дип янап киткән иде, чыннан да, мине тикшерергә районнан кеше чакырткан булып чыкты. Идарәгә чакырталар беркөнне. Керсәм, председатель Мәликә апа, Чалыш Шәмси, нindидер форма кигән таныш түгел бер күзлекле кеше, мәктәп директоры Нәкыйп абый, бергә эшли торган савымчы Дария түти. Аның янына барып утырдым. Күзлекле кеше миңа карап, сүз башлады:

– Йә, сөйләп җибәр, Әхтәмова. Менә Шәмси иптәш сине колхоз бетә, дип сөйли, ди. Дөресме шул? Бас әйдә, сөйлә!

Мин аптырап калдым. Нәрсә сөйлим? Дария түти колакка иелеп:

– Тор! Ничек тырышып эшләгәнеңне сөйлә, – ди. Тор, дигәч, торып бастым инде. Шул чагында әллә Ходай тел ачкычлары бирде, җыелышларда ишеткән җөмләләрне кушып, киттем сөйләп:

– Мин әле уналты яшьтә генә булсам да, бүгенге көндә хезмәтебезнең фронт өчен кирәклеген аңлап, бик тырышып эшлим. Әтием, абыем фронтта. Тырышып эшләп, мин җиңүне якынайтам дип уйлыйм. Сыерларым яшь әле. Таналар гына. Шулай да мин бер тамчы сөтләре дә калмасын дип, артларыннан йөри-йөри, бетереп савыйм дип әйтүем иде. Мине Шәмси абый дөрес аңламагандыр. Быел да планны тутырырга сүз бирәм. Икенче елга тагын да тырышыбрак эшләрмен.

Дария апа, мин сөйләгәндә, пичәт суккандай «Әйе, әйе!» дип, башын селкеп утыра. Нәкыйп абый белән Мәликә апаның да йөзләре яктырып китте. Ә формалы кеше башта бик усал тоелса да, соңга таба миңа карап елмаеп ук җибәрде. Чалыш Шәмси генә кара коелып утыра. Шулай да формалыдан узып, нидер әйтергә йөрәге җитмәде.

– Шулайдыр, шулайдыр! Шәмси иптәшнең һәрвакыт уяу булуын хуплыйм, әлбәттә. Тик монда Әхтәмованың ихлас сөйләве, партиябез кушканны чын йөрәктән кабул итүе күренеп тора. Шулай дәвам ит, сеңлем. Синең кебек яшьләрнең булуы бик сөендерә, – диде формалы кеше. Алар арасында да әйбәтләре була икән.

Минем өстән тау төшкән кебек булды. Шәмсидән калганнар да җиңел

сулап куйды. Шулай да Чалыш Шәмси этлеген итте. Үзенең апасы урынына мине монда торф чыгарырга җибәрде. «Ходай язганны күрерсең. Ул чалыш белән көрәшеп ятканчы, кит, кызым», – диде әни.

Беркөнне әби мине уятмаган. Күземне ачып, көн яктысын күрүгә кычкырып җибәрдем:

– Әби, сәгать 9 тула икән бит инде. Нигә мине уятмадың? Нишләтәләр инде мине хәзер?

– Мин сине үзем уятмадым. Менә сиңа чиләк, көрәк, капчык. Бар бәрәңге кырына, анда мәктәп балаларыннан соң бик күп бәрәңге калган. Шуны казып җый да өстен бәрәңге сабаклары белән каплап калдыр. Караңгы төшкәч алып кайтырсың.

– Эләкмәсәм генә ярар инде. Эшкә бармаган өстенә бәрәңге белән дә эләксәм... Безне бит гел тикшереп кенә торалар. Арып егылсаң да, чирләсәң дә эшләргә тиеш.

– Куркак булма. Куркак кешене басалар. Ул тыл күселәре кушканны гына эшләп торсаң, аяк сузарга да күп сорамассың. Син әле яшь. Яшәргә дә яшәргә. Ходай биреп, улларым сугыштан исән-сау әйләнеп кенә кайтсын, олы улыма хатынлыкка алам мин сине.

Шулай кыш чыгарлык ризыгым булды. Әби кич белән мичкә ягып, 5-6 картоп (бәрәңге) тәгәрәтә дә, мин җылы өйгә кайтып, ашап-эчеп йоклыйм. Әй, ул картопның тәмлелекләре! Әй, ул әбекәйнең шәфкатьлелеге! Төнлә мин йоклаган арада үзе йокламыйча, киемнәремне киптереп, ямаштырып куя. Аллага шөкер, мәрхәмәтле кешеләр очрап торды үземә.

Ике елдан соң әбекәй иреннән калган телогрейкасын, үзенең яшь чактагы киемнәрен кидереп, тула шәленә төреп, мине елап озатып калды. Улларының гына икесеннән бер хәбәр дә булмады.

Юлда күргәннәрне сөйләсәң – үзе бер куркыныч тарих. Кайсы поездга утырма, кайсы станциягә карама – анда аяксыз-кулсыз солдатлар... Вагон ярыгыннан кружка сузып, су сораучы немец әсирләре... Алар да бит кемнеңдер газизләре. Бәлки, барысы да безгә үтерәм дип тә килмәгәндер. Ул мескеннәрнең дә канга-данга туймаган җитәкчеләре бар. Өйдә ата-анасы, сөйгәннәре, балалары көтәдер. Аларга су бирсәң дә – куркыныч, бирмәсәң дә җәл. Алар да – адәм балалары. Су эзләп, вагоннан төшеп, поездлан калулар... аның артыннан чапканда, кеше мәетләренә абынып егылулар, дисеңме... Коточкыч! Шуларны күреп, ачлы-туклы, әби кидергән киемнәремне яртылаш урлата-урлата, көч-хәл белән 1943 нче елның декабрендә Казаннан җәяүләп, авылга кайтып җиттем.

***

Икенче дәфтәр тәмам. Мин – совет һәм аннан соңгы чор әдәбияты белән яхшы таныш, белемле замана кызы. Дөрес, шәһәрдә туып үскәнгә, татарчам чамалы. Әби-бабам, эткәм-әнкәм телендә әдәби китаплар укып үстем дип әйтә алмыйм. Русчасы белән бергә чит телдән тәрҗемәләрне «су урынына эчтем» дип кенә мактана алам. Нигә соң минем бер тапкыр да тылда, дисеңме, сугыш кырында, дисеңме, йә булмаса сугышның утлы һәм утсыз бик күп нокталарында бөтен сәламәтлекләрен, гомерләрен, сафлыкларын корбан итеп, Бөек Җиңүгә үз өлешен керткән татар кызлары

турында совет әдәбиятында укыганым юк? Китапларда батыр яки эшчән итеп безнең әбекәйләр түгел, башка түти-апалар мактала. Безнең әбекәйләрнең сабырлыгы, көнне төнгә ялгап эшләгәннәре турында татар язучыларыннан башка берәү дә язмаганмы соң? Ә татарча китаплар бер дә башка телгә тәрҗемә ителмәгәнме? Башкалар рәтендә аларны телгә алмаска кушканнармы әллә?! Нигә? Мин әбиемнең истәлекләрен укыганда, үземә гел шул сорауны бирдем. Тик җавапны гына таба алмадым.

**Өченче дәфтәр**

## Авылкаем, никләргә кайттым сиңа?..

Авылга кайтышлый апам янына Шәмәрдәнгә кереп чыктым, ул анда пилорамда эшли иде. Аягында соры киез итекләр, өстендә җылы бушлат, кулында җылы бияләйләр. Апа миңа да биреп җибәрде. Биредә өч тапкыр ашаталар икән. Миңа да анда калырга була иде. Калмадым шул... Авылга кайтасым килде.

Торфта ипиен, аз булса да, бирәләр иде, ә авылда анысы да юк.

Авыл тагын да хәлсезләнгән. Сугыштан яраланып кайткан солдатлар да күренгәли.

Авылда «борын канау чире»ннән бик күп кеше үлгән. Бу чир кар астында кышлаган башакларны җыеп ашаганнан килеп чыккан, диделәр.

Кайту белән колхоз эшенә җигелдек. Ел әйләнәсенә авыр эшнең бетеп торганы юк. Үгез җигеп эшлибез, атларны сугышка алып бетергәннәр. Ашлыкны, урак башлангач, Чистай пристанена ташый башлыйбыз. Бер көн барабыз, бушатабыз да, колхозный дворга кереп кунабыз, икенче көнне көне буе кайтабыз. Алгы үгездә бер олы кеше бара, аның артыннан – унөч-ундүрт яшьлек балалар. Августның эссе көне. Кигәвеннәр үгезләрне бимазалый.

Җәй ахырына суы кибеп, сай гына кала торган елга аша үткәндә, арттагы үгез белән баручы кызыбыз Факия кычкырып елап җибәрде.

– Кызлар, Мостафа әзи, туктагыз инде. Үгезем арбасы белән суга кереп ятты, кымшанмый да.

Үзебезнең үгез җигелгән арбаларны яр буена чыгарып, тал күләгәсенә бәйләдек тә кире суга кереп киттек. Фурманкадагы бодай чәчелеп, су өстенә чыккан. *(Фурманка – зур булмаган фура, фургон. Бу очракта йөк ташу өчен җайланган өсте каплаулы арба.)*

– И Ходаем, ниләр дип җавап бирербез икән? Тагын корткычлыкта гаепләп ябып кына куймасалар ярар иде!

– Әйдәгез, кызлар, җыя алган кадәресен җыйыйк әле.

– Яулыкларыгыз белән җыегыз, кул белән генә җыеп булмый ул.

– Нәфисә, үгезне син куалап кара әле, синең чыбыркың җиллерәк.

Ул арада, чатанлый-чатанлый, Мостафа әзи дә килеп җитте.

– Ярар, наныйларым, каударланмагыз әле. Бераз яткач торыр. Ул да җан иясе бит. Төн буе басудан көлтә ташыган хайван бит инде ул. Үгез дигәч тә...

Факия һаман үксеп елый. Үгезне торгызырга маташып, кызыл балчыкка буялып беткән. Тузанлы йөзеннән буразналап яшь ага.

– Хәзер үлчәве җитмәс бит инде ашлыкның. Нәстә генә эшлим икән,

кызлар? Мине дә алып китсәләр, энеләрем ачтан үлә бит инде. Әткәем сугышта, әнкәем урын өстендә кибеп-сулып ята. Каһәр суккан сугыш!

– Тукта әле! Шыңшыма! Бер син генәмени шундый хәлдә. Ни дә булса уйларбыз. Чистайда да кешеләрдер, җанварлар гына түгел, – ди бездән бераз өлкәнрәк Таибә апа.

– Наныйларым, һәрберебез, үз йөгеннән бераз бодай алып, Факиянең фурманкасына салырбыз. Ашлыкның кимлеге ул кадәр сизелмәс. Елама, кызым, – ди Мостафа әзи, Факияне кызганып.

– Һәәәй! Бакчы! Аягына басты бит теге дошман!

– Дошман димә инде, шылар белән көн күрәбез бит.

– Әдәгез кузгалыйк. Үтереп ашарга келим. Әле бушатасы да бар.

Җәй көне башлар басудан кайтып кермәсә, кышын фермада узды гомер. Безнең eше яшь кызларны кайда авыр, кая балалы хатыннар бара алмый, шунда куя иделәр. Дөрес, аларга тагын да кыенрак булгандыр. Үзләре ач, өйгә кайтсалар, өе салкын. Ач-ялангач балалар тилмереп, күзләренә карыйлар, нидер өмет итәләр, түзә алмыйча елыйлар. Барып зарланыр, ярдәм көтәр кеше юк. Авылда күбесе шул хәлдә.

Яз көне кәлҗемә ашый идек. Аның өчен кырдан барып көздән калган бәрәңгеләрне җыеп кайтабыз. Ул яртылаш черегән, яртылаш кипкән. Кайчак хәтта кортлаган да була. Шуны чистартып, коймак кебек ясыйсың да мичтә пешереп аласың. Ач булгач, шуннан да тәмле нәрсә булмый иде.

Сыер фермасында эшләгән чагым. Минем бүген кизү чираты. Карлы-буранлы, ачы җилле иртә. Дөресрәге – әле төн. Иртәнге сәгать өчтән торып, фермага эшкә килдем. Атны җигеп, чанага какшаеп беткән зур су мичкәсен куйдым да ерак елгага суга киттем. Мин сыер савучылар килгәнче, су алып кайтып, имчәкләр юарга су җылытып өлгертергә тиеш. Кичә ачкан бәке инде калын боз белән капланган. Озын саплы тимер балта белән бәкене көч-хәл белән генә ачтым. Караңгы әле. Барлы-юклы киемнәрнең бөтен тишекләренә кереп, җил ыжгыра, буран себерә. Чәчрәгән су киемемә сеңеп, шунда ук шыкраеп ката. Мичкәгә су тутырырга дип, артыма борылып карасам, ат, салкын җилгә түзә алмыйча, дулап, кире фермага чаба. Елый-елый, фермадан атны борып алып килгәндә, инде бәке катарга өлгергән, кар катламы бәкене каплап киткән. Хайван да түзә алмаган суык җилгә. Адәм баласына түзәргә кирәк. Түзәргә! Түзәргә! Түзәргә! Бәкене тагын ачам, ул арада ат тагын фермага кача... Гомеремдә беренче тапкыр ачынып, атны таяк белән кыйнадым шул чакта.

– Сиңа салкын булган җил, миңа салкын түгелмени?! Син түзмәгәч, мин ничек түзим соң? – дип такмаклыйм. Бер сугам, ике, өч... Шунда атның мөлдерәп торган күз карашын күреп алдым. Сугарга дип кизәнгән таягым һавада асылынып калды. Их, йөрәгем әрнеде шул вакытта! Атның муенына асылынып, сыкранып еладым.

Беркөнне Шакирә апага Габбас абыйдан телеграмма килеп төште.

«Әни, Бөгелмәгә кил, мин сиңа каршы барам. Безнең поезд анда бер тәүлек тора. Начальнигым җибәрде. Сине бик күрәсем килә.»

– Балакаемны күрәсе көннәрем дә бар икән. Аллаһы Тәгаләм, мең шөкер, мең рәхмәт сиңа!

Шакирә апа атка атланып, Бөгелмәгә чапты. Улын күргән, тик улы

кире поездга барып җиткәнче, поезды китеп барган. Габбас абыйны дезертирлыкта гаепләп хөкем иттеләр. Апамның чәчләре төн эчендә агарып чыкты.

– Ичмасам, күрешик димәгән булсаңчы, балакаем! Ана белән ут эчендә йөргән, ут эченә китеп баручы баланы аңларлык та шәфкать калмадымыни соң кешеләрнең күңелендә?! Йа Ходаем! Түземлекләр бир! Улымның юлына рәхимле бәндәләреңне чыгар! – дип елый-елый Ходайдан сорап, ике көнен, ике төнен уздырды да:

– Рауза сеңлем, мин Габбас эзиеңне эзләп чыгып китәм. Бәлки, соңга калмаганмындыр әле, – диде. Аңа каршы килеп тә, юатып та нидер әйтүнең мәгънәсе юк иде. Шакирә апа дөреслек эзләп чыгып китте. Аны көтеп, күзләребез талды. Өметләребез мең өзелеп, мең ялганды. Капка ачылган саен күзебез аны эзләде. Хат ташучы да баштарак безнең нәрсә көткәнне белеп:

– Юк шул әле. Сабыр итегез, бәлки, икенче атнада килер. Күпкә түзгәнне, азга түзегез! – дип, безне юатырга тырышса, соңга таба күзгә карамыйча гына, сүзсез генә үтеп китәргә тырыша. Түзәргә! Түзәргә! Түзәргә! Шуннан башка нәрсә эшли ала идек соң без? Безнең кайгы-борчылулар кемгә кирәк инде? Без түздек... Һәм Ходайга ялвардык. Мәктәптә Алла юк, дип өйрәтсәләр дә, аннан башка сыеныр зат юк иде бит.

Шакирә апа бер елдан соң кайтып керде. Ябыккан, беткән, тире белән коры сөяге генә калган.Танырлык түгел иде. Хәтта кызы да танымады.

– Мин бу, балалар. Кайттым. Аллага шөкер, үз ызбама кайтып егылырга көч бирдең, Ходаем!

– Әнкәй! Синмени бу? Исәнмени син, әнкәй, бәгърем?!

– Без инде, озак кайтмагач, «Югалды инде!» дип, елап беткән идек бит, апа.

– Ниләр күрдең, кайларда булдың, әнкәй? Габбас әзине күрдеңме? Ул ничек?

– Юк, балалар, күрмәдем. Бармаган җирем, утырмаган поездым, күренмәгән вокзалым калмады. Магаданга барып җиткәч, Ходай Тәгалә минем юлыма бер татар офицеры белән очрашырга насыйп итте. «Апа, синең тагын балаң бармы?» – ди. «Кызым бар», – дигәч: «Булса, бар өеңә кайт, шул кызыңны үстер, ә улыңны башка эзләмә», – ди. Шул сүзләрдән соң Габбас балакаемны бүтән күрәчәгем юк дип аңладым инде. Менә Магаданнан чыгып киткәнемә өч ай. Аллага шөкер, менә сезне күрәм, үз үемдә утырам. Аңа да өметем өзелгән көннәрем күп булды. Сукбай этне аткан кебек вагоннан үле гәүдәмне кайсы урманда чыгарып ташларлар да, сөякләрем кадерсез булып, кайларда аунап ятар икән дип кайгырган идем. Аллага шөкер, кайтып җиттем.

– Әнкәй, монда син югында әллә нинди абыйлар килеп, сине сорап йөрделәр. Рауза апаны да аптыраттылар. Ахрысы, заём түләгәч туктадылар.

– Ул заёмны ничек түләдегез соң, балакайларым?

– И-и-и, ул заём дигәннәрен түләү әкәмәт нәрсә булды, апа, – дип, мин дә сүзгә кушылам. – Башта авылдагы һәр ызбадан берәр кешене чакырып, заёмны нигә түләргә кирәген аңлаттылар. Анысы билгеле инде: сугыш өчен,

фронт өчен. Түбән оч Гөләндәм апа: «Ничек түлим, балаларым сөяк тә тире. Аларны ачтан үтермәс өчен соңгы сарыгымны суйдым. Бер сатар әйберем дә калмады. Көн-төн үзем колхоз эшендә. Каян акча алырга кушасыз?» – дип елый башлаган иде, районнан килгәннәрнең фурмы кигәне өстәлгә сугып кычкырып җибәрде, апакаем. «Болай гына түлисегез килмәсә, себердә урман кисеп түләрсез», – ди. Ахырда Гөләндәм апага көз көне трудодингә тигән ашлыгын сатып түләгәнче тимәскә дигән карар чыгардылар. Идәнгә ятып елады мескенкәем. Без сыерны сатып түләдек инде, апа. Ачулансаң ачулан. Сине таптырып җанга тигәч, болай да бик курыккан идек. Сиңа да шаукымы тияр, дидек.

– Сыерны?

Шакирә апа сыгылып төште.

– Берүк ачуланма инде, әнкәй, бәгърем. Безнең башка чарабыз юк иде бит!

– Юк-юк, наныйларым, сезне ачуланмыйм мин. Җан биргәнгә җүн бирер әле. Шушы сугышны башлаган бәндәләргә Алланың ачы каһәре төшсен!

Сугыш вакыты дип тормый. Яшь бара. Яшь барган саен кызларга авылдагы ир-атларның мөнәсәбәте дә үзгәрә. Сугыштан калган бер адәм актыгы миңа беркөн болай ди:

– Әгәр миңа кияүгә чыксаң, апаңны кире кайтартам.

– Ничек кайтартасың, син бит Алла түгел.

– Әлегә монда мин – Алла! Әгәр дә апаң миңа кияүгә чыккан булса, ул хәзер Шәмәрдәндә урман кисмәс иде, – ди.

Хәзер моңа апа гына түгел, мин кирәк икән. Ачуымны күрсәтмәскә тырышып:

– Беләсең бит инде, минем егетем бар, мин аны көтәм, – дим.

– Сезнең ул егетләрегезне әллә кайчан Сталинградта мясорубкадан чыгардылар инде, – дип хихылдап көлә, иблис токымыннан яралган нәстә.

– Ну эчеп тә күрсәтәсез инде хатын-кызның канын! Ничә кызның башына җиттең инде, оятсыз. Анысы гына җитмәгән, кайсы ялгыз хатынның капкасын шакымыйча калдырдың?

– Ха-ха-ха! Сугыш бетсә дә, дөнья бетмәс бит әле. Фронттагы авылдашлар өчен дә хатыннарының күңелен күрмичә булмый. Безгә алар өчен дә тырышырга туры килә инде. Ха-ха-ха! Белмәсәң, бел: мин әле иң тәртипле «малай». Авылда уйнаштан туган баланың берсе дә минеке түгел.

– Оялыр идең азрак! Алар ут эчендә, ә сез хатыннар кочагында. Ходай биреп, исән генә кайтсыннар, күрсәтерләр әле сезгә!

– Күрсәтмәсләр! Алар да анда әллә бер гөнаһсыз гына йөриләрдер, дисеңме? Фронтта да хатын-кызлар җитәрлек. Син монда фәрештә булып кылангач та... Менә Мөхаең кайтсын әле, миңа чыкмаганыңа үкендерер, ачы яшьләреңне түктерер ул сиңа.

– Каркылдама, карга түгелсеңдер! Баласын ачтан үтермәс, йә төрмәгә китмәс өчен төн кунарга керткән хатыннарның күз яшьләре төшәр әле бер!

## Синең белән бәхетле булырмын, дигән идем

Миңа унтугыз тулган елны, Сталинградтан кулы яраланып, минем егетем дә сугыштан кайтты. «Минем берүземә бер егет», – дип горурланып, борынымны күккә чөеп йөрим. Беркөнне сельсоветта телефонда дежур торам. Авылдагы бердәнбер телефонны ташлап китәргә ярамый. Сугышта постны ташлап качкан кебек. Төрмәгә утыртулары бар. Шул вакыт яныма егетем Мөхәммәт килеп керде.

– Әйдә, киттек клубка. Минем дә синең белән күңел ачасым килә, – ди. Бик кызыксам да, телефонны ташлап китә алмыйм бит инде.

– Үзең генә бие инде бер генә көн, – дим.

Егетемнең үз сүзе сүз:

– Ни булсын синең телефоныңа, ул кемгә кирәк, беркем дә шалтыратмас, кайгырма, әйдә киттек.

– Үгетләмә дә, булмый да. Башым да авыртып тора, иртүк торып Чистайга ашлык илтәсе бар.

– Ярар, үзеңә үпкәлә! Сакла инде алайса телефоныңны! – диде дә чыгып китте бу.

Иртән торып, үгез җигеп, Чистайга киттем. Ике көннән әйләнеп кайттым. Атны туарып ята идем, яныма Билал килде.

– Рауза, Мөхаең өйләнде бит.

– Нишләп өйләнсен, ул бит мине генә ярата, йөргән кызын нишләп ташласын!

– Кичә никах укыттылар. Шакирова Рауза белән.

Билал шаяртадыр дип ышанмыйча, клубка барып керсәм, күзем шакмак булды: Мөхаем Рауза белән кулга-кул тотынышып утыралар. Ничек инде, Раузаның Әхәте: «Бер айдан кайтып җитәм, Розочкам», – дип язды бит. Мин сер бирмәскә тырышып җырлыйм да, биим дә, эчемдә ут яна, йөрәгем туктап, егылып үләрмен кебек. Йөрәк янганын сиздермәскә тырышып бии-бии, боларның кайтып киткәнен дә күрми калганмын. Өйгә кайтырга чыксам, күпер төбендә Мөхай басып тора, хатынын кайтарып куйган да мине озатырга килгән.

– Мин аны яратмыйм, сиңа ачу итеп кенә аңа өйләндем, – ди.

– Син мине адәм көлкесенә калдырдың, йөрмә дә, кирәгең дә юк, күрәсем дә килми икегезне дә.

Ул шулай һәр көнне артымнан йөрде. Егерме сигез көннән Әхәт сугыштан кайтты. Сеңлесе Мәрьям кибеттә Мөхайны күргән.

– Мөхәммәт абзый, нигә син Әхәт абзыйның кызына өйләндең инде? Синең бит үз кызың да бар иде. Әхәт абзый ашамый, эчми, беркем белән дә сөйләшми, түшәмгә карап тик ята, – ди икән.

– Бар, Әхәт абзыеңа кайтып әйт, мин хәзер өйгә кайтам да Рауза апаңны сезгә җибәрәм.

Мөхай ул көнне клубка үзе генә чыкты. Мин өйгә кайтырга чыксам, күпер астыннан чыга бу.

– Әйдә минем белән! –ди.

– Беркая да бармыйм мин синең белән! Синең хатының бар, өеңә хатының янына кайт. Ничек шулай җиңел генә кеше язмышы белән уйнарга

була? Кызлар песи баласымыни: теләгәндә, тотып алып иркәлә, туйгач чыгарып ыргыт!

– Әгәр бармасаң, муеныңны борам да күпер астына ташлыйм. Әтиең өйдә юк, үги анаң сине эзләп йөрер, дисеңме әллә?

Мин моны төртеп җибәрдем дә, үзем бар көчемә өйгә чаптым. Капкага җиткәндә, Мөхәммәт мине куып тотты да, җилкәсенә салып, үзләренә алып кайтты. Авылның иң зур егете – ул, ә иң кечкенә кызы мин идем.

Шушы хәлләрдән соң адашым Рауза Пермь ягына туганнарына китте. Әхәт – читкә, шахтага. Минем күземне ярату томалаган булгандыр. Егетемне бер дә мондый булып чыгар дип уйламаган идем. Аның акылсызлыгы, мин-минлеге аркасында мин күпме яшь түктем, Әхәт белән Раузаның арасы бозылды.

Ничек булса булды, без шулай яшәп киттек инде. Бер елдан минем кызым туды да бер айдан үлде. Мин ачлы-туклы булганга, ул баланың яшәү көче дә булмагандыр. Каенанам әпәйне ирләргә генә бирә, сыерны да үзе сава, базга да үзе генә төшә, дус хатыннары килгәндә, үзе алар белән әпәй ашый, чәй эчә. Балаларына да кисеп-кисеп биргәли. Ә миңа гел бәрәңге генә. Беркөнне безгә күрше авыл кызы килде, әни белән сөйләшә-сөйләшә, чәй эчтеләр. Китәр алдыннан теге кыз минем белән суга барды.

– Минем сезгә нигә килгәнемне сиздеңме? – ди.

– Юк, – дим. Аптырап калдым.

– Синең каенанаң мине синең ireңә димли. Рауза бик ялкау, хәерче кызы, өстенә юньле киеме дә юк, – ди.

Мин егылып китә яздым. Ничек? Мин исән бит әле. Бу хәбәрдән шаулап, башыма кан йөгерде, сыгылып төштем.

– Йа Аллакаем, нәстә генә ярамый микән инде?! Чәчем белән җир себерәм бит. Минем бит алардан берни сораганым юк. Минем хәтта аягыма кияргә итегем дә юк. Ирем кайту белән аның ботинкасын киеп, тизрәк су ташырга чыгып йөгерәм. Колхоз эшеннән йөгереп кайтып, хуҗалыктагы бөтен эшне эшлим. Сыерын да савар идем – үзе рөхсәт итми. Сөтен эчәр дип курка. Кешедән мунча сорап, су ташып ягам да, иремнең энеләрен күтәреп барып, мунча кертәм, аннары кире күтәреп кайтам.

– Күрдем инде. Син бер туктамый эшләп йөрисең, ул сине һаман яманлый. Янында хатыны булган өстенә малаена мине димләп ята, тфү! –диде нәфрәтләнеп кунак кыз. Бәхеткә, ул мәгънәле, акыллы кыз булып чыкты.

– Аерылып китәр идем, миңа бала кирәк, ирем өстемнән йөри. Шөкер, тагын авырга уздым. Гомере генә булсын, сәламәт булып кына тусын.

– Бу йортта рәхәт күрәсең юк синең.

– Юк икәнен беләм дә соң... Шул үзем күтәреп мунчага йөрткән дүрт яшьлек малайларына кадәр мине дошман иткән була бит. Беркөнне әни югында ипи сорап елый башлады. Мин моңа кисеп бирдем дә яфрак калынлыгы гына үземә дә кисеп алдым. Әни кайткач, шул малай әйтә:

– Апа әпәй кисеп алды, – ди.

– Сиңа кисеп бирдем бит, – дим.

– Үзеңә дә алдың, – ди бу.

Мин оятымнан кая барырга да белмәдем. Әй, тузынып та күрсәтте инде шуңа каенана...

– Ирең синең яклы булмагач... Ул якласа, ул кадәр кылана алмас иде. Ходай ярдәм бирсен. Ну, киткәндә ул аждаһа каенанаңа әйтеп китәм әле.

Әйттеме-юкмы, белмим. Минем тормышымда берни дә үзгәрмәде. Ирем ялгыз хатыннар яныннан кайтып кермәде, каенанам миңа карата тамчы да йомшамады.

***

Нәрсә дип әйтим? Укыган саен минем күңелдә сораулар арта гына бара. Нигә? Нигә? Нигә?! Без, кешеләр, бер-беребезгә нигә шулай шәфкатьсез икән?

**Дүртенче дәфтәр**

## Җиңү килде – җиңеллек килмәде

1945 елда исән калган бөтен солдатлар да кайтып беттеләр. Каенатам да сугыштан кайтты. Ул кайткач, мине әзрәк яклый башлады.

– Раузага да әпәй кис, ул бит авырлы, – ди торган иде.

Сугышта күпне күргәнгәме, каенатам мәрхәмәтлерәк кебек иде. Сугыштан кайтып керүгә, аның иң беренче сүзе шул булды:

– Рауза кызым, мин бит синең Адюрың белән бергә хезмәт иттем сугышта, – ди. – Судан кайтып, биш минутка утырган идем, бер ат кешнәп җибәрде. Башымны күтәреп карасам – Адюр! Яныма ук килде. Мин сикереп тордым да:

– Адюр, Адюр, син бит безнең Адюр, – дип кочаклашып елаштык. Саша исемле бер абзый аны җигеп, солдатларга чиста киемнәр, кораллар, азык-төлек ташый иде.

– Ахмет, твой земляк такой сильный, такой умный, фашист самолётын иң беренче сизә. Пошкырып җибәрә дә тиз генә куаклыкка кереп кача, калган атлар да аның артыннан чаба, – ди. – Озакламый Адюр колынлады. Һәркөнне минем янга тае белән хәл белергә килә иде, – дип сөйләде. Мин бик сөендем. Балачак дустымнан сәлам алган кебек булдым. Тик, кызганыч, Адюрның язмышы ничек булып беткәндер – каенатам белми иде.

Беркөнне әни дус хатынына киткән иде, әти кайтып керде, ашарга да юк, ачкычлар да әнидә. Каенатам чоланнан туң май кисәге табып керде.

– Мә, Рауза, шуның белән булса да, коймак пешер әле, – диде.

Коймакны пешердем дә өстәлгә чыгарып куйдым. Балалар да утырдылар. Мин чәй әзерләдем.

– Әдә, үзең дә утыр кеше белән, кимак та аша, чәй дә эч.

Шулвакыт каенанам кайтып керде. Өстәлгә күз төшерүгә ысылдый ук башлады:

– Нигә атаңа туң май белән кимак пешердең, ул бит туң май ашамый. Әллә син аны үзеңнең атаң белән бутадыңмы?

Әти арага керде, рәхмәт...

– Нишләп мин туң май ашамыйм? Сугышта күргәннәремне сөйләп багыйм әле мин сезгә. Без сугышта үлгән атларны да тизрәк суеп ашый идек. Дөрес, атны кызганабыз, ул бит чирләп үлмәгән, пуля тиеп кенә. Җәй көне ул итне

озак тотып булмый, солдатларны да сыйлый идек, алар безгә шикәр бирәләр. Мин поварга су ташыйм, утын кертәм, картоп әрчим, савытларны юам. Шул савыт төбендә күгән ботканы су белән җебетеп ашыйбыз. Машина бара, кузовта мич урнашкан. Алдан солдатлар сугышып баралар, без алар артыннан. Әгәр солдатлар үлсә, аларның боткаларын безгә бирә иде повар. Дивизия командиры:

– Мин сезне ашатырга тиеш түгел, мин солдатлар өчен генә җавап бирәм, – ди торган иде.

– Ә без соң нәрсә ашарга тиеш? – дип сорагач:

– Миңа димәгәе, теге әйберләрегезне ашагыз. Бу – сезнең проблема, – ди иде шул чагында безгә командир. Син туң май ашамый, дисең.

Сугыштан соңгы беренче Сабан туе да җитте. Сабан туе көнне каенанам миңа үзенең галушларын биреп, ике кечкенә малаен ияртеп җибәрде. Көн матур. Кешеләр шат. Тик минем күңелдә генә бәйрәм шатлыгы юк. Мөхай миңа бер сүз әйтмичә иртүк чыгып китте. Күрше абзый безне куып җитте дә арбасына утыртты. Сәнәкчеләр каберлеге яныннан менеп барганда, ирем Пыртый Әминәсе белән кулга-кул тотынышып, көлешә-көлешә, тауны менеп баралар. Без боларны узып киттек. Миндә Сабан туе кайгысы калмады. Күзләрем күрмәс булды. Килеп җиткәч, малайлар айбагыр сорый башладылар. Мин чиратка барып баскан гына идем, Шакирә апаның кызы яныма килде дә:

– Апа, җизни елга буенда Пыртый Әминәсе белән сөйләшеп ята, – ди.

Мин малайларга айбагыр алып бирдем дә: «Әнә анда абзыегыз ята, барыгыз аның янына», – дип, малайларны шунда җибәрдем. Үзем туптуры авылга чаптым. Юлдан кайтырга хурланам. Яшемә тыгылып кайтып җиттем, баз өстенә кереп ятып, туйганчы еладым.

Шулай кадерсезлектә яшәп ятыш. Хәтеремдә: февраль ае. Көмәнем инде шактый зур. Шулай булса да, колхозда да, өйдә дә йөгерә-йөгерә эшләп йөрим. Каенатам районда эшли иде. Беркөнне кайтты да:

– Әйдә әле, Рауза, чанадан ике капчык тозны алып керик, – ди. Бер капчыкны күтәреп алып кердек. Икенчесен күтәргәч, минем эчемнән лып итеп нәрсәдер төште. Өметләнеп күтәргән бу баламны да җитлектереп табарга язмаган икән. Әти тиз генә мине өйгә алып керде. Ул бала бер учка сыя. Озакламый Мөхай да кайтты. Әти:

– Йортта ат барында бар тиз генә Раузаны роддомга илтеп куй баласы белән, – диде.

Ул заманда һәр авылда кечкенә генә роддом һәм бер акушерка бар иде. Машиналар юк, ат та юк. Әни мич башында кечкенә малайларга Сөембикә бәетен җырлап утыра иде. Мин киткәнне сизмичә дә калды.

Роддомда баламны үлчәделәр: 700 грамм. Бөтен җирен йон баскан.

1 Майга туар дип чамалап тора идем, алты айдан төште. Күз ачып йомганчы, авылга «Рауза җен тапкан» дигән хәбәр таралды. «Алты айлык бала барыбер үлә», – диделәр. Кич белән каенанам килеп, тавыш чыгарды. «Мин биш баламны да өйдә таптым, әллә синеке алтынмы?» – дип акырды. Пыртый Сәлименең беренче хатыны акушер Рәхимә, хаста кешене борчып йөрмә дип, моны куып чыгарды. Роддомда миннән башка Җәмилә апа белән Җомгабикә апа яталар иде. Алар – килендәшләр, аларга каенаналары һәр

көнне йә коймак, йә аш пешереп китерә. Ә минеке килеп, тавыш күтәрде. Кабат-кабат килеп борчыгач, Рәхимә апа районга шалтыратты. Аны килеп алып киттеләр. Чистайда ит комбинатында бер ай эшләткәннәр моны. Шул ачудан ул минем баламны карамады: бала бишектә елап ята, беркем дә янына килми. Алай гына да түгел, урамга чыгып, минем турыда, балам турында теләсә нәрсә сөйләп йөри икән. Яклаучым булмаганга күрә, кем ничек булдыра, минем авырткан җиремә басып, мыскыл итәргә дә күп сорамадылар.

Беркөнне баламны коендырып салдым да чүпрәкләрен юып торам, каенанамның дус хатыны Закира апа килеп керде.

– Рауза, бу balaңны ихластан яратасыңмы? – ди.

– Нинди сүз бу, Закира апа? Нишләп инде ихластан булмасын, менә син үзеңнекеләрне ихластан яратасыңмы соң?

– Минекеләр бит алтын алма кебекләр. Җитлекмәгән, йонлач түгел.

– Әгәр минем кебек авыр эш эшләп, балаң иртә туса, синеке дә шулай йонлач туар иде. Әбисе-бабасына кадерле булса, ул да алтын алма кебек булыр иде. Син бала тапкач, каенанаң роддомга ашын-кимагын күтәреп килгәндер. Ә минеке – синең дускынаең, һәр көнне килеп, тәрәзәне кагакага акырды да бакырды, – дим.

– Әле, акушер Рәхимә белән бер булып, аны районга син озаттырдыңмыни?

– Аны Рәхимә апа озатты, мин түгел. Килешмәгәнне кыланганы, тәртип бозганы өчен. Әби кеше бит ул. Җүнле әбиләр оныклары өчен җанын бирергә әзер. Мин тапсам да, аның малаеныкы бит бу бала. Ә ул аңа якын да килми. Ник елап үлми шунда!

Мин баланы эшкә дә үзем белән йөртә идем. Баламны саламга куеп, эшемне эшлим. Балакаемның аяклары туңып бетә. Ярый әле амбарлардан ерак түгел классташым Мәгъсүмнәр тора. «Бар, Рауза апаңның баласын алып кайт, йә ул балага салкын тияр», – дип, Мәгъсүмнең хатыны минем янга кызын җибәрә. Фәймә баламны килеп ала. Төш вакытында үзем дә шунда кереп, баламны имезәм.

Мин, елый-елый, Закира апага шуларны сөйләдем.

– Ай Аллам, ай Аллам! Шулай укмыни? Мин тагын, аның сүзенә ышанып, сине ата ялкау, баласын да карый белми, эш рәтен дә белми, дип уйлап йөри идем.

– Бөтенләй үк хикмәтсез булсам, алты айдан туган баланы кеше итә алыр идеммени? – дидем Закира апага.

– Алай икән, алай икән! Чыгыйм әле. Исән булып тор. Мин әйткән сүзгә үпкәли күрмә! Мин белмәгәнлектән генә, белмәгәнлектән генә.

Эшем авыр, өйдә бөтен кара эш миндә. Тамагыма туярлык ризык эләкми, сөтем дә җитеп бетми. Әни, шуны күрә торып, миңа түгел, балага да сөт бирми бит. Беркөнне:

– Әни, ярты стакан гына сөт бир әле, балага әз генә боламык ясап ашатыйм, – дигән идем, каты тавыш чыкты.

– Нинди ботка тагын? Синнән дә, балаңнан да бер хикмәт тә юк! Син безнең өйне талкырга, бетерергә дип кенә килгән нәстә булып чыктың инде, хикмәтсез! Тагын сарыкларга кайнар су салгансың, шуңа күрә эчә алмыйлар, авызлары пешә, – ди.

– Нишләп кайнар булсын, бармагыңны тыгып кара, – дигән идем, минем әткәйне чакыртып зарланды.

– Мин монда хатын аерырлык нәрсә күрмим. Үз сөягем үземнән артмас, ярар, кызым, кайтырсың, – дип, әткәй мине үзләренә алып китте.

## Туган йортта чит кеше кебек

Минем балама алты ай. Балам туярлык сөтем юк. Үги әни ике баласы белән, апа, эти һәм бала белән мин. Җиде кеше бергә яшибез. Үги әни минем бала ияртеп, өйгә кайтуымны яратып бетермәде. Аны да аңларга була: өйдә туя ашарлык ипи дә юк, монда мин бала белән артык тамак булып кайтып төштем. Алар алай уйлагандырмы-юктырмы – мин үземне шулай тойдым. Колхоз эшендә норма буенча йөз илле – ике йөз хезмәт көне тутырасы урынга мең, аннан да артык хезмәт көне эшләдем. Минем генә түгел, елый-елый ашлык ташыган, урак белән игеннәрне урып җыйган, төннәрен ындырда ашлык суккан минем кебек мескен хатыннарның өстәлләрендә балаларын ашатырга, үзләре туйганчы ашарга ипиләре булмады. Кызымны кочаклап: «Һай, балакаем, күкрәгемә куеп, ипи кисеп ашаган көннәрем булыр микән? Синең дә тамагың туяр иде», – дип елый идем.

Беркөнне түзмәдем, баламны кабык арбага салдым да күрше авылга чыгып киттем. Өй саен кереп: «Мин эшләрдәй эшегез юкмы, туйганчы бер ашатсагыз, теләсә нинди эшкә риза», – дип йөрим. Әллә дүртенче, әллә бишенче өйгә кергәч (ул хәлле генә хуҗалыкка охшаган иде), миңа бәрәңге казырга куштылар. Көндез сыек булса да итле аш шулпасы, кич бәрәңге, ипи белән сөт бирделәр. Балам да туйганчы сөт эчте. Тик, кызганыч, бәрәңгене мин шул көнне үк казып бетереп, сарайга ташып бетердем, иртәгәгә эш калмады. «Безнең авылда бүтән эш таба алмассың. Мин дә үзем эшли алмаганга түгел, балаң белән сине кызганып кына эшләттем», – диде хуҗа хатын. Колхоз эшеннән качып китте дип, бригадирдан каты эләкте эләгүен. Шулай да мин ул көнне тук идем, шат идем. Балам да беренче тапкыр төн буе уянмыйча йоклады. Тамагы тук булгангадыр инде.

Иремнең сугыштан резин аяклар белән кайткан туганнан туган абыйсы сәвиттә эшли иде. Минем шулай тилмереп йөргәнне ишеткәнме, беркөнне мине күрде дә:

– Мин каенатаң белән сөйләштем, син аларга бар әле, ул сиңа бер чиләк он бирер, – диде. Мин баламны күтәреп бардым.

– Әти, мин он алырга килгән идем, – дидем. Ә ул:

– Бер балаңны ашата алмыйсың, адәм актыгы, – дип, минем артыма тибеп, җилкәмә сугып җибәрде. Мин капкага бәрелеп килеп төштем, битем белән җиргә кадалдым, балам әллә кая очып китте.

Нишлим? Минем, елый-елый, авыртынудан өзгәләнгән баламны күтәреп кайтканымны ярты авыл карап калды. Ни дип уйлаганнардыр – миңа барыбер иде. Башымда бер генә уй: нишләргә? Баламны алып, берәр кая чыгып олагыргамы? Паспортсыз кая барасың? Бер тиен акча, өскә-башка кием юк. Әллә болай газапланып яшәгәнче? Юк-юк! Үзем әнисез үсеп, бер көн дә рәхәт күрмәдем. Миннән калса, балам кемгә кирәк? Бер генә юл кала: түзәргә! Түзәргә! Түзәргә!

Икенче көнне Мөнип абзый очрады да:

– Рауза, бардыңмы, он бирделәрме? – ди. Мин хәлне сөйләп бирдем.

– Ярар, сабыр ит, ашлык биргәндә, Мөхәммәткә тиешле ашлыктан берике капчыгын сиңа бирербез, – ди.

Ашлык алганда, Мөнип абзый үзе карап торып, миңа йөз кило ашлык бирдерде. Аллаһның рәхмәте яусын, урыннары җәннәттә булсын.

Ул еллардагы тормышның авырлыгын әйтеп бетерә торган гынамыни? Эшләп-эшләп тә тамак ач, алам дисәң, алырга әйбер юк. Бер көнне колхоз атларының берсе өстендә таушалып беткән шинель күрдем. Кышкы салкыннан атны кызганып берәрсе япкан булгандыр инде. Бер көн карап йөрим моңа, ике көн, өч көн... Их, моны алып киеп куйсаң әйбәт булыр иде дә бит! Хуҗасы, танып, карак дип данымны чыгарса... Үземнән бигрәк баламның салкыннарда газаплануын уйладым да тәвәккәлләдем. Шул шинельнең чабуын кисеп алып, Шакирә апа кызыма бишмәт тегеп бирде. Ә өске ягын мин ун ел кидем. Эзләүче булмады, шөкер. Әллә белеп тә кызгандылар.

«Карак» дигәннән, безнең авылдан сигез хатын берәр кесә бодай белән тотылып, бишәр ел төрмәдә утырып чыктылар. Аларны чаккан кешеләр үзләре иркен тормышта яшәде. Балалары ипи телеме күтәреп, урамга чыгарлар иде дә безнең ише ачларның балаларын кызыктырып ашап йөриләр иде. Алай гынамы, күрше авылдан бер хатын, дүрт баласын ачтан үтермәс өчен, бераз бригадир белән чуалып алган булган. Ире сугыштан кайткач, моны җиткергәннәр. Ире аны-моны сиздермәгән. Яхшы гына яшәп ятканда, урманга утынга барырга җыена икән:

– Әйдә, син дә минем белән, җиләк җыярсың, – дигән. Хатыны бер чиләк җиләк җыеп, ире янына килгән. Арбасы тулгач, теге ир хатынының ыштанын салдырган да кырмыска оясына утыртып бәйләп куйган. Бу ананың эчен-тышын кырмыска яулап алган, ире кайтып киткән, ә хатын:

– Аллаһның нинди каһәре булса, барысы да сиңа төшсен, – дигән. Шунда газапланып үлгән, ди, бу хатын.

Балаларының анасын, сугыш елларының авырлыгына түзеп, үзен көтеп алган хатынын шундый үлемгә дучар иткән кемсәне кеше дип тә әйтәсе килми. Ерткычлыкка сугыштан өйрәнеп кайтканмы, үзе шундый булганмы? Алга китеп әйтим: бу кеше егерме ике ел мич артында сарык бәрәннәре, бозау белән урын өстендә яткан, бөтен тәне кортлап беткән, бик җәфа күреп үлгән, моны беркем дә җәлләмәгән. Шулай дип сөйләделәр. Ышанырга авыр булса да, андый хәлләр аз булмады.

Кайчагында янәшәдә йөргәннәрнең фашисттан да яманрак кыланган чаклары булды.

Тагын бер чын булган хәл турында сөйлим әле. Аны ул елларда телдән-телгә сөйләп йөрттеләр. Бер хатын шулай ике кесә борчак белән эләккән. Ире сугышка киткәндә, биш яшьлек кенә булып калган малае булган. Каторгадан исән-сау кайта алмам, дип уйлагандыр, ахры, иртән торган, мичкә салам ягып, өйне җылыткан, баласына ашарга пешереп, өстәлгә куйган да лапаска чыгып, үз-үзенә кул салган. Соңрак хуҗалар: «Без аны каторгага җибәрмәс идек, яшь баласы бар бит», – дип, авыл халкы алдында

акланып маташканнар да... Ана юк... Бала ятим. Мондый вакыйгалар аз булмады.

Балама ун ай тулгач, мине тагын урман кисәргә җибәрделәр.

– Баламны кем карар? – дим.

– Салисә апаңа калдыр, – ди бригадир.

– Алар үзләре дә катып утыралар, ягарларына утыннары юк, – дим.

– Менә сиңа рөхсәт язуы, бер олау салам кайтарып калдыр Салисә апаңа, – ди.

Салисә апа бик теләп риза булды. Бер айдан соң кайттым да (теге язуны саклаган идем) тагын бер олау салам алдым. Шулай итеп, язга чыктык. Безнең якта урманнар юк бит. Булганына да керергә ярамый. Сынган ботак табып күтәреп кайтканда да, каравылчы күзенә чалынудан Ходай сакласын! Салам булмаса – тирес, тирес булмаса, тизәк кирпече юк. Җәйнең коры көннәрендә төшкә кайткач, иптәш хатыннардан станоклар алып, тизәк кирпече суга идем. Бераз үскәч, кызым кул арасына керә башлады. Мин сәнәк белән тирес тутырам, кызым таптап тора. Ишегалдына чыгарып тезәбез дә, бер атнадан, кипкәч, абзарга кертеп өябез. Кыш чыгарлык кирпеч әзерлибез, ә утынны кабызлыкка гына тотабыз. Безнең якта урманнар булмагач, бөтен кеше кизәк кирпече суга иде.

Бас әле станокка,
Станнары станда.
Без генә кирпеч сугабыз,
Бөтен Татарстанда, –

дип җырлап, үз күңелебезне үзебез күтәрдек. Әллә көлә-көлә еладык шунда. Кыш көне шуны һәр көнне биш кирпеч алып кереп, рәхәтләнеп яктык. Өебез кичкә кадәр суынмый торган иде.

Ә урман чыгарганда күргән-ишеткәннәрне сөйләсәң...

Казан артыннан килгән кызларның күргәннәре янында безнеке пүчтәк кенә булган икән әле. Урман эше белән сугыш елларында ук танышып, хәзер бригадир булып йөргән кызларның берсе болай дип сөйләде:

– 1943 нче елда безне Суслонгерга урманга, агач чыгарырга җибәрделәр. Биш кубометр чыгарасың икән, ашарга талон бирәләр, атка – солы, үзебезгә – 500 грамм ипи, көнлек норманы үтәмәсәң, атка да, үзеңә дә ашарга юк. Көндез агач чыгарабыз, ә төннәрен болын буенда атларны саклыйбыз. Учак ягып, киемнәрне утта тотып, бетләрне коябыз. Унга кадәр санаганчы, шырпы тартмасы бет белән тула иде. Киенергә юньле кием булмады.

Безнең белән бергә авылдашыбыз Габдулла да бар иде. Эшли торгач, Габдулланың күлмәге таушалып, ертылып, өстенә кияргә яраксыз хәлгә килде. Бер мари хатынына яшереп кенә, утын алып кайтып биреп, күлмәкле булды. Ул мескен хатынның ире үлгән булган, күлмәк шул мәрхүмнеке иде. Минем аяктагы аяк чолгавы да тузды. Тагын утын алып кайтып, аяк чолгаулы булдым, ә чабатаны үзем үрергә өйрәндем.

Безнең анда күргәннәрне эт тә күрмәде. Көне буе эшлисең, ял юк. Әле шуның өстенә халыкны ач тоталар иде. Түзә алмаслык хәлләр... Бервакыт качып та карадык, куып тотып, кире алып кайттылар, каты итеп кыйнадылар. Безнең белән күрше авыл кызлары бар иде. Аларны хөкемгә

тарттылар, безнең яшебез җитмәгәч, җәзадан котылып калдык. Ворошилов мондагы тәртипсезлекне, вәхшилекне үзе килеп күргәннән соң гына тәртипкә салдылар.

Менә шулай дип сөйләделәр...

Шулай... Окоп та казыдык, торф та чыгардык, урман да кистек... Болары ни булса да читтә булды, күргәннәрне дә читләрдән күрдек. Үзебездә үзебезнекеләр белән җиңелрәк булырга тиеш иде...

***

Бер уйлаганда, кешегә күп тә кирәкми икән инде: ялангач тәнеңне каплардай кешедән калган булса да киемең булса – әйбәт, өеңне җылыта аласың – дөнья рәхәте; ташландык шинельдән балаңа кием тегеп кидерә алсаң – бәхет; тамагың туйганчы ипи ашасаң – Аллага шөкер! Бүгенге тормыш белән чагыштырсаң – шаккатасың. Кайвакытта: «Ул Җиңү көнен нигә һаман да шулай зурлап уздыралар инде? Ветераннар да бетеп бара. Акча түгү генә түгелме?» – дигән кебек фикерләр дә ишетелә. Бу тормышта бер тиенлек тә эш кырырга өлгермәгән яшьләрнең кулына сыра шешәсе тотып: «Бәйрәм белән!» – дип йөрүен күргәч, минем дә шулай уйлаганым бар. Җилсез дә селкенеп торган яшь буын вәкиленең, бәлки, әбисе йә бабасы сугышта катнашкандыр, бәлки, үлеп калгандыр. Әбисе минем Рауза әбием күргән михнәтләрне күргәндер. Алар өчен бирелгән фатирда яшәп ятучы замана баласы әби-бабасының хәлен барып белә микән яки сирәк булса да каберенә бара микән? Усалрак уй туды әле башымда... Үзем дә шушы буын баласы бит югыйсә. Әбиемнең истәлекләрен уку мине бөтенләй икенче кеше итте түгелме соң? Юк, барыбызны да бер чыбыктан сөрмик әле. Бар ул җирдә үткәннәрне онытмыйча, киләчәккә карап яшәүче яшьләр!

**Соңгы дәфтәр**

## Үз өемдә – үз көем

Авылда бер буш ызба бар иде. Җәй көне шунда күчтем.

Мине механизаторларга ягулык ташырга куйдылар. Кайтышлый караңгыда көнбагыш арасына кереп, көнбагыш җыям да, кайткач, шуны киптереп кагам, аннары төн буе шуны ашап утырам. Башка нәрсәм юк ашарга. Беркөнне бригадир Сәлим абзый килеп керде. Төрмәгә утырта дип, куркуымнан йөрәгем ярыла язды.

– Сеңлем, син кышка нәрсә ашамакчы буласың? – ди.– Мәктәп балаларыннан соң кырда бик күп бәрәңге калган. Ягулык илткәндә җый да бәрәңге сабаклары белән ябып куй, кайтышлый алып кайт.

– Әгәр мине тотсалар ни диярмен? – дим.

– Әгәр тотсалар, Сәлим абзый дуңгызларга җыеп илтергә кушты, диярсең, – ди.

Миңа тагын Аллаһ ярдәм бирде, кыш буе тәгәрәткән бәрәңге ашап чыктык, җәй буе да ашадык әле. Орлыкка да калды. Ун сутый бәрәңге утырттым.

Көн-төн эшләп, артыкны өмет тә итмичә, шуңа да сөенеп яшәлде инде.

Безнең илдә адәм баласына бер дә тыныч торырга, эшләгәненең әҗерен күреп, туйганчы ашарга ярамый микәнни соң? Үз балаларын нигә шул кадәр рәнҗетергә ирек бирә соң ул туган ил дигәнебез? Югыйсә гәҗите-радиосы гел Ватан-ана ди бит. Ана кеше үз баласына шундый буламы? Үксез балалары булдыкмы соң? Сугыш вакытында, «Барысы да фронт өчен!» дип эшләп, рәхәт күрмәдек. Анысы аңлашыла иде. Күпмесе фронт өчен булгандыр – бер Ходай белә. Сугыш беткәч тә, заём белән, налог түләтеп, җанга тиделәр. Кулыбыздан тотып, заёмга имза куйдыралар иде. Түли алмасаң, нәрсәң бар, шуны алып чыгып китәләр.

Беркөн төнге сәгать уникедә сарыгым бәрәнләде. Мин боларны өйгә алып кердем генә, Пыртый Сәлиме килеп керде. Утыра да утыра бу. Сәгать берләр тулды.

– Бар инде, Сәлим, өеңә кайт, безгә дә ял кирәк бит, – дим.

– Күпме телим, шулкадәр утырам әле. Бәлки, сарыгың тагын берне бәрәнләр, – ди.

Сарыгым тагын берне бәрәнләде дә бу өч сарык дип язып чыгып китте. Хәзер инде миңа өч сарык өчен йон тапшырырга кирәк иде.

Миңнеруй ападан тана сатып алдым. Сыеры да юк дип көлмәсеннәр, сер бирмим, имеш. Март аенда танам бозаулады. Өйгә кертеп юындырдым, салам белән суны бутап, әз генә он сибеп, саварга гына чүгәләгән идем, тагын Пыртый Сәлиме килеп керде бозау карауччы белән. Биш литр угыз сөтен алып чыгып китмәкче болар.

– Сәлим абый, бу бит угыз гына, – дим.

– Бозауларга ярый ул, – ди Пыртый.

– Сәлим абзый, бозавыма гына калдыр инде, – дигәч, бер литрын калдырдылар. Шул чакта кызым елап җибәрде. Сөт сорап.

– Сәлим абзый, кызыма бер стакан гына калдыр инде, аның бит әле сөт тә күргәне юк, – дим. Сүгенә-сүгенә, тагын бер стакан өстәделәр. Кызым шуны бер кисәк ипи белән ашап бетерде.

– Кичкә тагын киләбез, кара аны, урлап кала күрмә, – дип чыгып киттеләр.

Ул тананы алганчы, кәҗә генә алган булсам, чәй эчәргә сөт булган булыр иде дип уйлап куйдым. Кырык килограмм булгач, бозауларыбызны да колхозга алалар иде. Сыерым бер елны, көтүдән качып, уҗым ашап үлде. Шуннан соң кәҗә алдым. Кәҗәмне дә алып чыгып киткәч, Шакирә апа ике айлык бозау бирде, шул үсеп, тана булды. Ул бозаулады да ашарга сөтебез булды, ләкин туйганчы ашатырга булмагач, сөте аз иде.

Кәшифә ападан калган өй тузды. Шакирә апа миңа бер буаз сарык бирде, ул бәрәнләде. Шуларны Шакирә апа белән Чистайга илтеп саттык та, шуңа акча өстәп, миңа әзер бура алдык. Өй җиткереп кердек. Бер елдан бу өебез янды. Без тагын урамда калдык.

Авылыбызда яхшы кешеләр дә күп иде, шөкер. Өй салганда, рус авылыннан алып кайткан мүгебез җитмәде. Газзә апа миңа мүк бирде. Җәмилә апа казан бирде. Минзак абзый яргыч (кул тегермәне) ясады һәм 4 тәрәзә пыяласы бирде. Яз көне Аю Гомәре җиде олау салам бирде. Мин шул салам белән абзар башымны сипләттем, калганын сыер белән сарыкларга ашаттым.

Казанда укып кайткан Гайфи абыйны председатель итеп куйдылар. Яхшы җитәкче, мәрхәмәтле кеше иде. Бервакыт Гайфи абыйны райкомга чакыртып: «Нишләп син колхозчыларыңа акча белән ипи бирәсең?» – диләр икән. «Ач кеше эшли алмый», – дигән Гайфи абый. Менә шул Гайфи абый безнең өй янгач, утырышта:

– Раузаның өен рәтләргә кирәк. Бар булган ашлыгын дуңгыз фермасына тапшырсын да аның урынына амбардан яңа ипи алсын, – дигән.

Күмере белән бергә илтеп бирдем дуңгыз фермасына. Дүрт центнер бодай бирделәр. Күземә яшь тулды, ышанмыйча тордым. Шуннан соң без дә туйганчы ипи ашый башладык. Сабантуй көнне өебез өлгерде. Ул вакытта кызыма биш яшь иде.

Гомер ялгызлыкта үтә. Мин кызымның атасы – яшьли сөеп кавышкан иремнән бер яхшылык та күрмәдем дисәм дә була. Миннән дә бигрәк кызыма авыр иде. Беркөнне дус кызының әтисе сары тышлы кәнфит алып кайткан. «Шул чакта тамагыма төер утырды, кычкырып-кычкырып елыйсым килде. Аларның кәнфитләренә түгел, әтиле булуларына кызыктым. Башымны аска иеп, өйгә йөгердем. Әтисез үсү гомер буе бәгырьгә тиде». Бу сүзләрне кызым үсеп буйга җиткәч кенә әйтте. Әтиле килеш әтисез үсте шул балакаем.

Тормыш авырлыгын бүлешеп тартырдай кешесе булганнарга җиңелрәк. Акча, авыр эш, ашау-эчү ягыннан гына түгел, парлыларга караганда, ялгызларга болай да кеше арасында кыен. Аларга теләсә кем ни теләсә шуны әйтә. Ялгыз хатын кыңгыраулы. Кыңгыравы җил исмәсә дә чылтырый. Җитмәсә, эте дә, бете дә сине мыскыл итәргә тора. Дөрес, минем кебекләр авыл тулы.

Бервакыт авыл кибетенә «Кубанская» дигән кызыл аракы кайтты. Литры – туксан ике тиен. Беркөнне Гайнулла абзый минем капкага килеп сөялде дә:

– Нихәлләр, балдыз, туган,
Алып кайтчы бер Кубань.
Шуның белән ике арадан
Бөтен шайтанны куам,

– дип такмаклый башлады.

– Гайнулла абзый, туган,
Алып кайтмыймын Кубань.
Әгәр бер сум акчам булса,
Шикәр алып, чәй куям, –

дип җаваплдым мин.

Ялгыз хатын янына шулай мыскылларга килүчеләр күп була торган иде.

Шулай яшәргә тырышып яткан көн. Күрше авылдан бер шофёр егеткә мине сорап, эштә вакытта әткәйгә килгәннәр. Әткәй кечкенә энемне җибәреп, мине чакыртып кайтартты.

– Минем бит кызым бар, – дим.

– Кызыңны әтәң алып калыр, – диләр. Мин:

– Барсам, кызымнан башка бармыйм, – дидем. – Үзем дә әнисез үстем, баламны да әнисез үстеримме?

Бармадым. Кире киттеләр тегеләр. Андыйларның алларыннан артлары яхшы.

Нигә бәйрәмгә бармыйсың, дисез сез.

Менә тагын, шөкер, язлар җитте. Мин, үземне белә-белгәннән бирле, язларны көтеп алам. Бәләкәй чакта яшел үләнне көттек. Үлән чыкса, ачтан үлмибез, дия идек. Аннары көннәр җылыта, җылы кием кирәк түгел, дип. Өскә-башка сөенеп киярдәй җылы кием күрмичә үскәнгәдер инде. Үсә төшкәч, яз күңелләргә дәрт кертә бит. Тамагың тукмы, өстеңә киемең бармы дип сорап тормый, яшьлек үзенекен итә.

Олыгайдым инде. Кулыма каләм тотмаганга да күптән икән. Язам да бозам менә. Нигә язам? Кайчагында үземә шундый сорау биреп туктап та калам. Аннары тагын язып китәм. Бәлки, үзем киткәч, балаларым, оныкларым укыр. Акыллары булса, гыйбрәт алырлар. Бигрәкләр ачы булды бит инде безнең буынның язмышы.

Исәпләсәм исем китә,
Исәпләмимен генә,

– дип җырлый торган иде мәрхүмкәем Шакирә апа. Бәләкәй чактан алып, картайганчы бер рәхәт тә күрелмәгән кебек югыйсә. Барыбер үткәннәргә әйләнеп кайтасы килгән көннәр дә бар. Яшь чак булгангадыр инде. Яшьлек сагындырадыр. Ә бүгенгем Аллаһыма шөкерана кылырлык минем. Авырлыклар күреп үстергән кызымны, ничек итсәм иттем – аякка бастырдым. Кешедән ким-хур булмады. Көн-таң атса: «Оныгымны, аның балаларын кулга алып сөяргә, кимәгән киемнәрне кияргә, төшкә дә кермәгән ризыкларны авыз итәргә насыйп иттең, Ходаем. Рәхмәт сиңа!» – дим.

Шулай да күңел кырылган чаклар да бар. Менә бүген дә оныкчыгым – бәләкәй кычыткан чыпчыгым – бәйрәмнән кайтты да: «Нигә әбиең килмәде, дип сорадылар», – ди. Бара алмыйм шул. Нигә икәнен аңлатып бирә алырмын микән, юк микән? Бәлки, мин хаклы да түгелдер, дип икеләнеп тә куям. Тик «Мин дә тыл ветераны» дип, Пыртый Сәлимнәре белән рәттән утырасым килми минем. Андыйларның, кулларын болгый-болгый, сугыштан соң җыйган мидәлләрен шылтыратып, ничек тылда тырышып эшләп, мимечне җиңәргә булышканы турында сөйләгәннәрен тыңлап утырасым килми. Ничек тырышканы онытырлык булмады.

Баламның атасы Мөхәммәтнең ничек итеп ветеран исемен алдан йөртеп, үзенә генә түгел, икенче хатыныннан туган балаларына фатир, машина, кешедә булмаган товарлар алуын сөйләп мактанганын тыңлыйммы? Олы кызына сыңар оек та алып бирмәгән килеш.

Ә минем белән тубыктан карлы су ерып, симәнә ташыган, авызыннан өзеп, соңгы телем ипиен сындырып, минем белән бүлешкән иптәшләрем мәрхүмнәр шул. Язга чыкса үләндер, кәлҗемәдер ашап, ач үлемнән котыла алган балалар да олыгаеп баралар инде. Тик алар беркем түгел. Исән калганнарына рәхмәт әйтсеннәр, диләр микән?!

«Рауза усал ул!» – диләрдер инде. Усалдыр шул. 1946 нчы елда военкоматка чакырып, сугыш вакытында яхшы эшләгән өчен мидәл белән бүләкләгәннәр иде. Шуннан башка ничә еллар дөньяда бар икәнне дә белүче булмады. Шул 9 нчы Май алдыннан гына искә төшереп алдылар инде. Биш ел саен диярлек калай тактылар.

Сугышта катнашканнарга хөрмәт. Күпсенмим. Ут эчендә йөргәннәр. Аларга тиеш. Ире, атасы сугышта үлгәннәргә нәрсәдер бар – минекеләр үлмәде, шөкер анысына. Ә шулай да сабыйлыктан да чыкмаган кызларның кышкы зәмһәрир суыкларда үзләреннән юан агач кисеп интеккәннәре, күкрәктән су ерып, торф чыгарганнары, кутәрәмгә калган колхоз малларын саклап калып, үзләре ачтан газапланганнары «Барысы да фронт өчен, барысы да җиңү өчен!» булмадымыни! Аякларга туңып береккән чабаталарны куптарулар төшкә кереп, бүген дә йөдәтмиме әллә? Күккә ашкан агачлар астында калып имгәнгән иптәшләремнең ыңгырашуы, ачлыктан күбенгән ятим балаларны өеннән аерып, детдомга озатканда елаулары бүген дә колакта. Санап кына бетерерлекме?! Үтте инде! Баштан үтте! Фронт сызыгы безнең йөрәк аша да узды ул! Авырлык күрер өчен ут астына керү мәҗбүри түгел. Утны янәшәндәге кешеләр дә яга ала.

Күргәннәрне искә төшерәм дә бүгенгемә шөкерана кылам. Байлыгы да, клубка чакырып мактаулары да кирәкми миңа. Мин бары көн дә Ходайдан балаларыбызга, оныкларыбызга без күргәнне күрсәтмәсәң иде дип сорыйм.


Усал диярсез инде. Усал булсам да, мин берәүгә дә без күргәннәрне күрсен иде дип, үксезләр язмышы теләмим. Баштан үтте. Төрлесе! Үтте инде!

2000 ел, май.

***

Соңгы дәфтәрнең соңгы битен яптым. Күз алдымнан гади татар хатынының, юк, алай гына түгел, туган халкымның бер гасырлык тарихы үтте. Никадәр аз беләбез икән без әбиләребез-бабайларыбыз турында! Миңа Рауза әбиемнең әманәтен үтисем калды – алар күргәннәрне бүгенге буынга – безнең буынга җиткерергә кирәк. Бәлки, әбием әйтмешли, кем дә булса акыл алыр, кемдер бүгенге тормышына шөкерана кылыр.

Хәтер – гаҗәеп кызык нәрсә! Әгәр кешелекнең хәтере югалса, ул, мөгаен, киребаштан – таш гасырдан яши башлар иде. Һәм тамчы да алга китеш булмас иде. Аллаһы Тәгалә шуңа да Хәтер дигән нәрсәне бар иткәндер. Кешеләр үткәннәрдән гыйбрәт алсын, хаталарны кабатламасын өчен.



Ләис
Зөлкарнәй

# ГӨРЛӘГӘН СУЛАР

## ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ МӘРСИЯ

*Гөрләгән сулар башында,*
*Тыңлагыз,*
*Шунда үтәр –*
*Йөрсә сыктап таң-сәхәрләр*
*Моң-сагышлардан хыял.*
Дәрдемәнд

**I**

Яфрак асты күршем –
Әкәм-төкәм
Борынгы граммофон мәкамендә
Дәшә шигыремдә,
Сәерсетеп:
– Китте инеш...
Болыннарда – көмеш.
Сине көттем, болдырымда килеш!
«Мөгез чыгар», имеш...
Әйтче, зинһар:
– Ак буламы?
Кара сыер сөте...
Җиргә тияр-тимәс җиленнәрне
Тәмләр идем дә бит урлап кына,
Иртә таңнан!
Кичке таңга узган
Сыер көтүләре –
Бурлат кына...

Ләис ЗӨЛКАРНӘЙ (1962) *– шагыйрь; «Балачак күге», «Кар өстендә алмалар», «Мәңгелектән исә җил...» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Кара сыер сөте ак булалмас... –
Ак сыерның сөте булмый кара!
Кипте инеш...
Болыннарда – көмеш.
Көттем сине!
Болдырымда килеш,
Тумыштан
тумырга[1] –
болдырымда...
Борынгы граммофон мәкамендә...
Яфрак асты күршем әкәм-төкәм
Дөньялыктан дәшәр...
Кыбырсытып:
– Куш мөгезле[2] якташ,
Кашкарган баш,
Шан-шөһрәт көт!
Болдырыңда килеш:
«Мөгез чыгар», имеш...
Шигърияттә?!
Монарланып, манар бүзләреңне
Суалмас[3] сөт –
Кара сыер сөте...

**II**

Чык төшкәндә узар Садыйк морза –
Йөзеп барган йомшак тарантаста.
Сиртмәсеме сизгер, –
Дөбердәмәс,
Әллә бармы сихер ул арбада?! –
Арба төбен каккаларга
Ни генә юк ул арбада! –
Ялгышып та ялгаш...
Тавыш бирмәс,
Дөм өнсезме әллә?
Дөңгер-дөмбәс[4] –
Авылны уятып!
Дөбердәмәс.

Чык төшкәндә узган Садыйк морза,
Арбаңа җәйне дә...
Салыйк, морза! –

Юлык[5] юлларының кашлагында
Мул тукранбаш катыш
Юшан гына... –
Чап та тарантаска ташла гына!

---

[1] Тумырга – мал муенына тагыла торган җиз калай шөлдер.
[2] Куш мөгезле – Зөлкарнәй (автор тәхәллүсе).
[3] Суалмас – кипмәс-корымас.
[4] Дөңгер-дөмбәс – алтын юучыларның эш коралы: түгәрәк ялгаш белән киле төйгече.
[5] Юлык – ямчылар нигез салган татар авылы (Башкортстан, Баймак районы).

Әйдә, салыйк җәйне, кочак-кочак:
Узып барган
жылгыр
җәй айлары,
Кочаклап, күшеккән малайларны,
Басылып утырачак...

Җәй түшәген, түшәп салыйк, морза:
Закир черем итсен
бераз гына...

*– Һәр тырышкан бәндәсенең*
*тәңресеннән хакы бар, –*
*Син карга дип уйлаганың*
*асыл шоңкар булмасын.*
*Йорты Болгар булса булсын,*
*йортны болгар булмасын!*
*Иҗат итүче аталган:*
*Дәрдемәнд Акмуллаңыз,*
*Дөньяда зар булса булсын,*
*Гүрдә янар булмасын!*[6] –

Чәчән сүзе белән били морза:
Көйле бара йомшак тарантасы.
Сиртмәсеме сизгер –
Дөбердәмәс,
Ялгышып та ялгаш...
Тавыш бирмәс,
Дөм өнсезме әллә?
Дөңгер-дөмбәс –
Көйле сүзне бозып!
Дөбердәмәс.

Кош тоткандай йөргән алтынчының
Тарантасы да, юкса, җиңелчә, –
Чыкмас,
Мичәүгә[7]
Пар тай җикмичә:

Дилбегәне тойсыннар, –
Дәрт-дәрманны тыйсыннар, –
Эшкә өйрәнә торсыннар!
Эшкә өйрәнә торсыннар!

**III**

Инешнең комлы кичүендә
Шом бар...
Атларның
Су эчүендә:

[6] Дәрдемәнд Акмуллаңыз – моң-зарлы Акмулла шигыре.
[7] Мичәү – төпкә җигелгән ат янәшәсенә тәртәсез генә тай җигү.

Алтын догаларын отар морза,
Ор-Җаекны кулда тотар морза
Ат сугара!
Уйлар кичүендә...

Беренче гильдия сәүдәгәре!
Чигенергә соң түгелдер әле...

Типсәң дә, имеш, алтын чыгар... –
Чыккан юк!
Татардан!
Алтынчылар!

Инешнең комлы кичүендә
Ымлы...
Атларның су эчүе дә:
Дилбегәңне куеп,
Чөңгердә син!
Чорлар кичүендә...

Су тубыктан монда,
Ил тубыктан! –
Чәчәк аткан күбек,
Чәчрәп аткан! –
Тузгый яр үләне –
тубылгыдай...

Уртлый гына күбек чәчкәләрен
Мичәүгә җигелгән җабага тай,
Ял чөелдереп,
Баш чөертеп!
Төпкә җигелгән ат сусын басмый, –
Су эчәлми йөдәгән:
Тәртәдән су тама!
Йөгенүдән... –
Бәйдә тота тезген-йөгән,
Бәйдә тота
Чөелдерек!

Беренче гильдия сәүдәгәре,
Чигенергә соң түгелдер әле:
Типсәң дә, имеш,
Алтын чыгар... –

Урал тауның Хомай йомыркасын
Сарысына кадәр!
Арчырлармы?

Татар казнасына салмаганны
Казан кузнасына
Апчыгармы?

Чабаталы морза оныклары –
Болгавырдан талмас,
Болгарины салмас
Чабаталы
Алтынчылар!

Татар басмый тарих куласасын:
Төпкә җигелгән ат, сусын басмый, –
Баса
Мичәүдәге җабага тай.
Су тубыктан монда,
Ил тубыктан:
Лондоннардан килеп,
Сан-Тропедан...
Шантрапалар[8] монда
Тулышкан! –
Күбек чәчкә ата,
Тубылгыдай.

**IV**

Ә малайлар инде аргы ярда...
Шәрран яра Шакир,
Шәрран яр-ра, –
Сөенечтән чөя түбәтәен:
– Монда чык! Әтәем!
Монда!
        Чык!
                Әтәем!
Мондагы болынның чыгы кара,
Ышанмасаң,
Чыгып кара!

Боегучан, уйчан судай,
Капылт тартылганга коедан,
Шулай турсайганмы
Уймак болын?
Әллә караяктан[9]
Кара янган?!. –
Бар чыклары да
Кара коелган...

Картлар белә
Алтын догаларын:
– Ходай алтын сәйлән җуйган урын, –
Борынгылар алтын юган урын! –
Көмеш чыкны
Кучкыллата, улым...

[8] Шантрапа – XVIII йөз ахырында Көньяк Уралда алтын бизгәге башлангач, Европаның эре банклары да, кабалага салучы бурычка кәгазь акча биреп, арзан бәягә алтын җыеп алучы бүлекчәләрен ача.
[9] Караяк – үсемлекләрнең сабаклары каралудан гыйбарәт кизү.

Алтын догаларын отар морза,
Ор-Җаекны кулда тотар морза
Уйлар кичүендә, –
Ат сугара...

– Каяле, тезгенне чишик йәтрәк, –
Өшәнгән бияне сөендерик!
Су эчәлми мескен, йөдәгән лә:
Тәртәдән су тама!
Йөгенүдән... –
Бәйдә тота тезген-йөгән,
Бәйдә тота
Чөелдерек!

– Йәтрәк чишик, Закир,
Тезгеннәрне! –
Гөрләгән суларны сибелдереп,
Сөенечләр чөя
Бусага таш! –
Тәртә башы кыршыганмы?
Шахтёр лампасыдай ут элдереп, –
Алтын тиягенә юл саба таш! –
Ат башыдай
Алтын ташы –
Асаба таш!
Асаба таш!

Беренче гильдия сәүдәгәре!
Чигенергә иртәрәктер әле:

Тибә белеп типсәң,
Алтын чыгар... –
Чигенмәслек
Чиккә җитсәң,
Тәртә башы белән
Арчып чыгар! –
Чыгар ул!
Татардан!
Алтынчылар!

Ничек көйләмәссең
Сабакташны:[10]
*– Һәр җәүһәрнең асыллыгы –*
*Алтын ташы,*
*Берәүнең милиун сумлык кара башы;*
*Сөягең сөягемдән ким димәймен,*
*Затыңыз –*
*Затымызның сәдакасы! –*

[10] Сабакташ – Мөхәммәтсадыйк – шагыйрь Акмулланың чордашы, якташы. Икесе дә Стәрлебаш мәдрәсәсендә укыган, икесе дә – шагыйрь Шәмсетдин Зәки шәкертләре.

Көйли дәрдемәндле
Акмулланы
Эчтән көйли Садыйк,
Көйле чакта.

**V**

Закир тукранбашлы тарантаста
Гөрләгән суларны тыңлап ята, –
Чорлар кичүендә
Гөрләгән су,
Дәверләрне катып!
Эрләгән су, –
Әрәмәгә ятып, Китап ятлап,
Шагыйрьләрне
Әрләгән су:[11]
– Күпме әрекмәнне кыбырсытып,
Әкәм-төкәмнәрне
Кыерсыттың! –
Кара сыер сөте бирәм,[12] имеш...
Бергәләп көт!
Болдырыңда килеш... –
Болыннарда, имеш, –
Кара көмеш:
Монарланып, манар бүзләреңне
Җирдән савылган сөт! –
Кара сыер сөте...

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

[11] Әрләгән су – «Шагыйрьләр» сүрәсенә ишарә.
[12] «Әкәм-төкәм, мөгезеңне чыгар, Кара сыер сөте бирәм» – балалар такмагы.



Мансур
Гыйләҗев

# СОҢГЫ МИРАЖ

ИКЕ БҮЛЕКТӘН ТОРГАН РОМАНТИК КЫЙССА

**Катнашалар:**

Измаил бәй – Әстерхан сәүдәгәре, промышленник, 75 яшьтә.
Габдулла – Казан сәүдәгәре, фабрикант, 50 яшьтә.
Гаяз – бурлак, 31 яшьләрдә.
Гайшә – йөремсәк кыз, 27 яшьләрдә.
Мөслим – Измаил бәй приказчигы.
Олан – ятим бала, 13 яшьләрдә.
Туксан – карт бурлак.
Буран – урта яшьләрдәге бурлак.
Шәке – урта яшьләрдәге бурлак.
Мәхмүд – лоцман.
Шамилә – бурлак хатыны, 40 яшьләрдә.
Эшпай – бурлак, мари.
Пуян – бурлак, чуваш.
Бурлаклар төркеме, трактирга килүчеләр, официантлар, чегәннәр, жандармнар.

*Пьесадагы барлык вакыйгалар Әстерханнан алып, Казанга кадәр бөек Идел елгасы ярларында бара. Шуңа күрә пьесаның сценографиясе мөмкин кадәр җайлаштырылырга, билгеле бер формага китереп эшләнергә тиеш. Бу, үз чиратында, вакыйга бара торган урыннарны тиз алыштырырга ярдәм итәчәк, чөнки андагы җирләрнең күренеше һава торышы үзгәреш-*

Мансур ГЫЙЛӘҖЕВ (1961) – *драматург, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, «Бичура», «Казан егетләре», «Баскетболист» исемле һ.б. дистәдән артык сәхнә әсәрләре авторы. Казанда яши.*

*ләренә нык бәйләнгән. Шулай ук зур елганың сәхнә образын табу да бик мөһим: йә ул ярсып ага, йә бөтенләй туктап кала, йә ярларыннан ташып чыга, йә саегып кала һәм боз белән каплана, кыскасы – елга үз тормышы белән яши... «Мономах» дигән исем йөрткән агач баржа да пьесаның башыннан алып, ахырына кадәр безнең күз алдында булачак.*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Беренче күренеш

*1842 елның сентябрь ае. Әстерхан. Идел ярында яшь бурлаклар җыелган. Шәһәр пристане причалы. Причалда купшы сервировка белән берничә ресторан өстәле куелган. Шуларның берсе янында И з м а и л  б ә й утыра. Ул – Әстерханның иң эре сәүдәгәре. Җитмешне шактый күптән атлап чыккан булса да, ул әле бик таза һәм көч-куәте ташып торган ир. Аның үз-үзен тотышында ниндидер башбаштаклык яки картлык «маразмы» бар сыман, әмма ул моны юри кыланамы, яисә табигате шундыйракмы – башта тиз генә аерып булмый. Аның янында приказчигы М ө с л и м  басып тора.*

*Причал уртасында гитара һәм скрипкалар тоткан ч е г ә н н ә р  уен коралларында үз көйләрен башкаралар. Хатын-кызлар бии.*

*Измаил бәй затлы кәнәфидә утыра. Аның ике чалбар балагы да тезенә кадәр кайтарылган – горчицалы ваннада аякларын парландыра.*

*Аның кәнәфиенә якын гына катык салынган зур таз куелган. Таз янында О л а н  басып тора. Измаил бәй сюртук кесәсеннән тәңкә алып, тазга ташлый. Олан елгыр гына идәнгә чүгә дә йөзе белән катыкка чума. Ул күпмедер вакыт тазда эзләнә, бераздан башын күтәрә. Тешләренә тәңкә кыстырган. Измаил бәй моны күреп, ихлас сөенә. Олан пычрак сөлге белән битен сөртә. Күпмедер вакыт уза, Измаил бәй янә катыкка тәңкә ташлый...*

И з м а и л  б ә й *(кулына аракы чәркәсен тоткан килеш)*. Дәшмә, Мөслим, дәшми тор!.. Бер сүз дә дәшмә. Синең бер сүз дә дәшми генә тыңлавың ошый миңа... Менә Иделгә кара син. Искиткеч гаҗәеп елга! Аның киңлеге, аның тирәнлеге, ә купшылыгы! Балыгын мең ел чумыр – барыбер тотып бетерә алмаячаксың. Дәшмә, Мөслим, тыныңны чыгарма!.. Дәшми тору килешә сиңа. *(Аракысын йотып куя.)* Кызык, кешеләр вак-төяк елгалар буенда ничек яши икән? Яисә шыр-ялан җирләрдә, буш далаларда? Һич аңламыйм! Сәер кешеләр! Аларның миләре дә башка төрледер, мөгаен! Ми түгел, ә сазлыктыр аларның уй казаннарында! Вак, мескен, кызганыч алар! Эт сыртында яшәгән бет шикелле! Эш рәтен белмиләр! Дөрес фикерли алмыйлар! Башында акылы булган адәм зур елга буенда яшәргә тиеш! Идел кебек елгада! Зур корабларда йөзәргә! Зур эшләрне хәл итәргә тиеш! Дөрес әйтәмме мин, Мөслим? Дәшмә, дәшмә – шулай яхшырак!.. Карале, безгә таба кем килә анда? Бу бит Габдулла, Казанлы!

*Пристаньга Г а б д у л л а белән Г а й ш ә килә. Гайшә бик сылу-чибәр туташ, затлы кеш туныннан.*

*Габдулла Измаил бәй янына килә, алар бик җылы исәнләшәләр.*

Измаил бәй. Аякларым авырта, Габдулла әфәнде, буыннар сызлый...

Габдулла. Сакларга кирәк үзеңне, Измаил бәй. Синсез Идел туктап калачак бит.

*Габдулла белән Гайшә өстәл янына утыралар. Официантлар килеп хезмәт күрсәтә башлый. Измаил бәй Гайшәдән күзен дә алмый.*

Измаил бәй. Үзең белән кемне алып килдең? Хәләл җефетеңме?..

Габдулла. Юк, хатыным түгел, Измаил бәй... Балык тоту сезоны ничек узды? Без синең белән яздан бирле күрешмәгәнбез икән.

Измаил бәй. Күрәп акча эшләдем, Габдулла әфәнде. Дөрес, бурлакларымны да шактый югалтырга туры килде. Идел быел бик усал, ярсу булды. Аннары жандармнар да котырынды, кансызланды, бурлакларның бит күбесе, үзең беләсең, качаклар, сөргенгә сөрелүчеләр... Хатының түгел икән, кем була ул сиңа алайса?

Габдулла. Фахишә ул. Мин аны Казанда бер салонда күрдем. Күңелемә ятты, ошаттым. Сатып алырга туры килде үзен. Биш йөз алтын түләдем аның өчен.

Измаил бәй. Кыйммәтле тауар икән. Ни атлы дип белик үзен?

Габдулла. Диана.

Гайшә. Гайшә!.. Мине салонда гына Диана дип атыйлар иде. Аннан киттем бит инде, хәзер Гайшә мин!

Измаил бәй *(официантка)*. Боларга аю ите китер. Әле күптән түгел генә үзем аю ауладым. Үлеп яратам аю йөрәген! *(Баягы сүзгә кире кайтып, Гайшәгә ымлап.)* Чибәр кош. Әстерханда мондый гүзәлләр юк. Моңа өйләнсәң була...

Габдулла. Өйләнү турында уйларга иртәрәк әле миңа.

Измаил бәй. Әйе шул, аннары өйләнү сәүдә эшләрен алып барырга да комачаулык итәчәк. Йә, сөйләп җибәр, нинди җилләр ташлады сине монда, Габдулла әфәнде?

*Измаил бәй вакыты-вакыты белән катык салынган тазга тәңкә ташлый. Олан шунда ук аны таздан эзләп таба. Габдулла белән Гайшә моны кызыксынып күзәтәләр.*

Измаил бәй. Габдулла *(катыклы тазга ымлап)*, үзең шулай эшләп карарга теләмисеңме? *(Гайшәгә.)* Ә син, чибәркәй?..

*Габдулла белән Гайшә Измаил бәйгә җавап бирмиләр.*

Измаил бәй. Тыңлыйм сине, Габдулла әфәнде.

Габдулла. Казанда бик көчле янгын булды. Шәһәр тулысынча янып бетте диярлек. Минем складлардан да көл генә калды.

Измаил бәй. Сөйләп тормасаң да була, барысыннан да хәбәрдар мин. Тормыш ыгы-зыгысыннан калышмаска тырышам.

Габдулла. Миңа синең ярдәмең кирәк. Казанда икмәк тә, иген дә юк! Дарулар кирәк, халык төрле чирләрдән кырыла, туңа! Күп кенә авылларга холера зәхмәте үтеп керде.

Измаил бәй. Мин аңлыйм сине, Габдулла әфәнде. Мондый вакытта шәп табыш алырга була. Әмма син боларның барысын да Казанга ничек илтеп җиткермәкче буласың соң?..

Габдулла. Синең ярдәмеңә

өметләнәм. Миңа яхшы баржа һәм бурлаклар бир.

*Шул мизгелдә Измаил бәй Мөслимгә үз янына килергә ымлый. Мөслим йөгереп килеп, хуҗасына аякларын ваннадан чыгарырга булыша, аларны чиста сөлге белән сөртә һәм аяк киемен кидертә. Измаил бәй торып баса.*

Измаил бәй. Син әнә тегендә күз сал әле, Габдулла әфәнде. Күрәсеңме? Бурлаклар сугыша! Яратам бурлаклар сугышканны! Нәкъ менә шул аларны кеше итә дә инде. Сугышу аларны ярсыта, каннарын кайната, акылдан яздырта!.. Безнең бернәрсә дә килеп чыкмаячак бит, кадерле Габдулла дус.

Габдулла. Нишләп әле чыкмаска тиеш?!

Измаил бәй. Сезон төгәлләнде, балык тотулар бетте. Көз! Бурлаклар язга кадәр ял итә.

Габдулла. Мин тауарсыз калдым. Барысы да көлгә әйләнде. Бары тик син генә ярдәм итә аласың миңа!

Измаил бәй. Бурлаклар барып җитә алмаячак. Үзең дә яхшы аңлыйсың, җиде йөз чакрым, җитмәсә, агымга каршы. Иделдә су хәзер тездән генә калып бара, тиздән кыш. Бурлакларның барысы да үлеп бетәчәк һәм тауар салынган баржаның да башына җитәчәкләр, дим! Язга кадәр түзәргә кирәк булыр.

Габдулла. Баржа белән тауарны иминиятләштерербез! Нигә аның өчен шулай борчыласың?!

Измаил бәй. Ә бурлаклар кызганыч түгелме сиңа? Һәлак булып бетәрләр бит!

Габдулла. Әгәр иртәгә үк юлга чыксалар, салкыннар төшкәнче Казанга барып җитәргә тиешләр! Мин сораштырдым инде, элек тә шундый хәлләр булгалаган. Көз җылы килергә тиеш! Бурлаклар һичшиксез Казанга кайтып җитәрләр! Казанны коткарырга кирәк, анда кешеләр кырыла!

Измаил бәй. Менә ничек сайрый башладың син! Ә мин син акча эшләп калырга телисең дип торам тагын!

Гайшә *(сүзгә кушыла)*. Киттек моннан, Габдулла!

*Измаил бәй өстәлдән нидер ала, озак кына кулында әвәләгәч, катыклы тазга ташлый. Олан шунда ук башы белән катыкка чума. Озак эзли, әмма тәңкәне тапмый.*

Измаил бәй. Син Иделнең сул ярында яшисең, Габдулла әфәнде. Мин уң ярында. Әмма икебез дә шул елганың суын эчәбез. Барлык кешеләр дә шулай яши. Уртак тел таба, уртак карарга килә белергә кирәк.Тик моның өчен кайсы ярда яшәвеңне аңларга кирәк башта...

Габдулла. Тел төбеңә төшенеп бетмим, Измаил бәй…

*Олан таздан тәңкәне табарга теләп, тагын берничә тапкыр катыкка чумып эзләп карый.*

Измаил бәй. *(Оланга ымлап)* Тазда тәңкә юк... Ә ул аны барыбер эзли. Ипи катысы катыкта йомшап таралып китә. Ә аңа барыбер тәңкә табарга кирәк. Кызык уен бит, ә?

Габдулла. Теләсә нинди хакны түләргә әзермен, Измаил бәй.

Измаил бәй. Азартлы уеннар яратасыңмы син, Габдулла әфәнде?

Габдулла. Кәрт уенымы?

Измаил бәй. Син нәрсә инде, кәрт уены – кара халык эше ул. Җитди уеннарны күз алдында тотам мин, Габдулла дус. Идел ярына күз ташла әле. Күрәсеңме, анда күпме баркаслар, баржалар, пароходлар тора… Боларның барысы да минем суднолар. Складларым төрле тауар, төзелеш материаллары, фабрика өчен кирәкле станоклар белән тулы. Әнә анда минем бурлакларым сугыша… Мин сиңа бер бик кызыклы уен тәкъдим итәргә телим.

*Олан тәңкәне таба алмаудан арып-туеп, Измаил бәйне тыңлый башлый.*

Измаил бәй. Син бурлаклар Казанга барып җитә алырлар дип уйлыйсыңмы?

Габдулла. Әлбәттә, барып җитәләр, мин бөтен күңелем белән ышанам моңа.

Измаил бәй. Ә мин барып җитә алмаслар дим. Уенның бар асылы да шунда.

Габдулла. Ә уенның сере нидә? Нәрсә өчен бәхәсләшәбез? Уенның ставкасы нидән гыйбарәт?..

Измаил бәй. Монда барысы да көн кебек ап-ачык. Әгәр бурлаклар баржаны Казанга алып барып җиткерәләр икән, тауар өчен мин синнән акча алмыйм.

Габдулла. Әгәр алып барып җиткерә алмасалар?

Измаил бәй. Тауар өчен миңа тиененә кадәр түлисең! Бурлаклар белән дә үзең исәпләшәсең!

Габдулла. Шул гынамы?

Измаил бәй. Юк, шул гына түгел… Иң мөһиме... Бу туташны миңа бирәсең!

*Пауза. Чегәннәр уйнаудан туктый.*

Габдулла. Мин риза…

Измаил бәй. Димәк, килештек.

Гайшә. Ә сез миннән сорадыгызмы соң? Бу уеннан миңа нинди файда?

Измаил бәй. Карагыз әле моңа, нинди акыллы! Мин инде хәзер чынлап та синең минеке булуыңны телим!

Гайшә. Минем мондый уенга ризалыгым юк!

Измаил бәй. Син сатлык тауар! Синең фикереңберкемгә дә кызык түгел!

Гайшә. Хәзер бурлаклар янына барам да дөресен сөйләп бирәм. Сезне ярыш тараканнары итеп файдаланмакчы булалар, сезгә ставка куялар, диячәкмен! Сезнең бу уеныгыз барып чыкмаячак! Нәтиҗәдә, сезнең берегез дә сукыр тиен дә эшли алмаячак!

Измаил бәй. Афәрин!.. Афәрин, чибәркәй! Уен тагын да кызыклырак төс алды! Әгәр җиңсәм, сиңа Әстерханнан таш йорт алып бирәм!.. *(Пауза)* Ник дәшмисең, Габдулла әфәнде, телеңне йоттыңмы әллә?

Габдулла. Әгәр мин ота калсам, синең таш йортың Казанда булачак...

Измаил бәй. Менә хәзер килештек! Бурлаклар белән бергә үзебез дә Казанга юл тотабыз, барысы да гадел булырга тиеш! Хәзер безне иң авыры көтә. Бурлакларны күндерергә, аларның ризалыгын алырга кирәк.

*Габдулла чыгып барышлый тазга тәңкә ташлый. Олан үзенә бер елгырлык белән янә тәңкә эзләргә керешә.*

**Икенче күренеш**

*Пристаньнан ерак түгел генә трактир урнашкан. Анда һәрчак халык кайнап тора. Бу трактирда бурлаклар, йөк ташучылар, матрослар, бандитлар, караклар ял итә. Шәраб елга булып ага. Шау-гөр киләләр, кәеф-сафа коралар, өзек-төтек җырлар җырлана. Кайбер ирләр исерек кыз-хатыннар белән кочаклашып утыра. Өстәлләрдә «банк», «орёл и решка» уеннары уйнала. Өстәлләр арасында «сукыр кулын» уйныйлар. Бер өстәл янында Г а я з күренә. Ул ялгызы гына. Аның янына бер хатын килеп утыра, ирне кочаклый башлый. Гаяз аны читкә этәрә.*

Х а т ы н . Дивана! *(Китеп бара).*

*Гаяз янына Т у к с а н килеп утыра.*

Т у к с а н . Нигә моңланасың, Гаяз?! Күңел ачарга кирәк! Балык сезоны артта калды! Язга кадәр кәеф-сафа корабыз! Сыйлыйммы үзеңне?

Г а я з . Юк кирәкми, рәхмәт!

Т у к с а н . Сине танырлык түгел, Гаяз! Бер-бер хәл булдымы әллә?

Г а я з . Казанда көчле янгын булган. Халык ачлыктан үлә, холера дигән афәт барысын да рәттән кыра.

Т у к с а н . Ишеттем мин. Халык өстенә килгән зур кайгы бу.

Г а я з . Анда минем анам, атам, барлык туганнарым...

Т у к с а н . Бераз акча җибәр үзләренә, безгә түләделәр бит.

Г а я з . Акчам юк минем. Казаннан чыкканда, мин акчаны алдан алып куйган идем. Язга кадәр ничек җан асрармын инде...

Т у к с а н . Измаил бәй сиңа һичшиксез эш табачак! Йөк ташучы, агач егучы – ничек тә кыш чыгарсың, Алла боерса! Тик менә караклар белән генә әшнәләшеп китмә!

Г а я з . Юк инде, тагын сөргенгә барыр хәлем юк. Болай да минем баштан күп нәрсә узды, җитәр!

Т у к с а н . Акчамның яртысын сиңа бурычка биреп торам, Гаяз. Калган бурлаклар да хәлләреннән килгән кадәр ярдәм итәр, тамызыр! Язга кадәр ничек тә яшәрбез!

*Трактирга И з м а и л б ә й, Г а б д у л л а, Г а й ш ә һәм М ә х м ү д керә. Барысы да тынып кала, уеннар да туктала.*

И з м а и л б ә й . Измаил бәй барыгызны да сәламли! Күрәм, шәп ял итәсез!

*Халык куанып шаулаша.*

И з м а и л б ә й . Бурлаклар, мин сезнең белән сөйләшергә телим.

*Халык тынып кала.*

И з м а и л б ә й . Сезгә эш тәкъдим итәргә дип килдем. Сезнең каршыгызда минем дустым Габдулла әфәнде басып тора, үзенең хәләл җефете белән... Ул Казаннан, беренче гильдия сәүдәгәре. Анда зур янгын чыккан, бөтен шәһәр янган. Кешеләргә ипи, тоз, балык, йөзем кирәк. Барысы да кирәк, югыйсә халык ачтан үләчәк. Ярдәм итик аларга, туганнар!..

Т у к с а н . Син нәрсә, Измаил бәй, безне кышка каршы юлга чыгарып җибәрмәкче буласыңмы?

И з м а и л б ә й . Әйе, Туксан карт, тагын бер көннән безгә юлга кузгалырга кирәк.

Туксан. Син нәрсә сөйлисең, хуҗа?! Безгә бит агымга каршы барасы! Иделдә су тездән генә калды диярлек. Урамда елак көз бит инде. Әле язын юлга чыксак та, Казанга бару ике айга сузыла. Ачуланма берүк, әмма без бу эшкә алына алмыйбыз.

Измаил бәй. Казанны коткарырга кирәк.

Туксан. Барып җитә алмыйбыз без, Измаил бәй. Юлда һәлак булырбыз, сезнең тауарны да харап итәрбез! Аннары хәзер инде яр сукмагы да ашалып бетте! Юк, мондый юлга чыгарга фатиха бирә алмыйм мин бурлакларга!

Измаил бәй. Син хәзер карт бүре, Туксан. Исеңдәдер, бурлакларның көзен Казанга барып җиткән чаклары да булгалады бит! Хәтер төпкелеңне яңартып карале?!

Туксан. Яңартып та тормыйм! Сорама да! Көз көне Казанга юлыбыз бикле безнең! Һәрбер эшнең үз тәртибе бар! Идел – көчле елга, үзенә каршы чыгуны гафу итми!

Измаил бәй. Әй, бурлаклар, ишетәсезме мине?! Язларын мондый эш өчен күпмешәр төшерә идегез?

Бурлаклар. Җан башына җидешәр тәңкә! Сигезәр тәңкә! Үзең шулай түли идең бит, Измаил бәй!

Измаил бәй. Яхшы, язын җидене түләсәм, хәзер ун тәңкә бирергә ризамын!

Бурлаклар. Барыбер бармыйбыз! Җан тәслим кылыр хәлебез юк. Бармыйбыз! Язга кадәр тынычлап, кәеф-сафа корып яшибез!

Измаил бәй. Җан башына унбиш тәңкә бирәм!

Туксан. Салкыннарга кадәр барып өлгерә алмыйбыз! Боз уртасында катып калачакбыз. Измаил бәй!

Измаил бәй. Ярар, һәрберегезгә утызар тәңкә түләргә әзер!

*Салкын тынлык.*

Измаил бәй. Ник дәшмисез? Мондый акчаларны үз гомерегездә күргәнегез, кулыгызга тотып караганыгыз бармы?! Юк бит!

Бурлаклар. Барып җитә алмаячакбыз! Син язын түлә безгә андый акчаларны, Измаил бәй!

*Бурлаклар Измаил бәйне уратып алалар. Шау-гөр киләләр.*

Измаил бәй. Син нишләп бер сүз дәшмисең, Габдулла әфәнде?! Синең тауар ич бу! Кирәкме сиңа, юкмы?! (*Тынлык*).

Габдулла. Һәрбер бурлакка егермешәр тәңкә өстим... (*Пауза*).

Гаяз. Мин риза бу эшкә алынырга.

Туксан. Әгәр башка берәү дә чыкмаса бу юлга?

Гаяз. Баржаны Казанга берүзем илтеп җиткерәм… (*Пауза*).

Буран. Ә нәрсә югалтабыз без, туганнар? Мондый акчага җир читенә барып җитәргә була! Казан юлы нәрсә ул! Эһ тә итми илтеп җиткерәбез! Ә Казан кызлары! Барып җитүгә акча алабыз да – күкне күтәреп күңел ачабыз! Мондый акчага язга кадәр бар дөньясына төкереп яшәргә була!

*Халык сөенеп, шау-гөр<br>килә башлый.<br>Кәеф-сафа кору дәвам итә.*

Бурлаклар. Мин дә барам. Мин дә! Җылырак киенәбез. Мин дә сезнең белән!

*Измаил бәй, Габдулла, Мөслим һәм Гайшә читкәрәк китеп басалар.*

Измаил бәй. Шуның белән

шул, Габдулла әфәнде, кул сугыштык. Хәзер кирегә юл юк!

Габдулла. Риза булган адәм кем ул?

Измаил бәй. Иң яхшы шишкарь ул. Качакларның берсе, каторгага сөрелүче. Миңа Аллага ышанган кебек ышана. Артыгын сөйләми, бик мыштым...

Габдулла. Нигә юлга тагын бер көннән соң гына чыгабыз? Нигә иртәгә үк кузгалмыйбыз?

Измаил бәй. Баржаны әзерләргә кирәк. Юл озын, авыр, мәшәкатьле булачак... *(Мөслимгә)* Бар, бөтен бурлакларны кенәгәгә теркә.

Габдулла. Миңа синең яңа уеның ошый башлады бит әле, Измаил бәй!

**Өченче күренеш**

*Пристань. «Монамах»тан җиргә киң генә трап сузылган. Бурлаклар баржага товар төйи, капчыклар, мичкәләр, тартмалар ташый. Трап башында Мөслим басып тора, кенәгәсенә нәрсәдер теркәп бара. Аның янында лоцман Мәхмүд. Бурлаклар арасында хатын-кызлар да күп. Монда Идел буенда яшәүче барлык милләт вәкилләрен дә күрергә мөмкин: татарлар гына түгел, руслар, мари, мордвалар. Бу аларның кием-салымыннан күренә. Якында гына Измаил бәй, Габдулла, Гайшә. Измаил бәй кәнәфидә утыра. Ул товар төягәнне игътибар белән күзәтә. Мәхмүд трапка күтәрелгән һәр бурлакның муенына кыңгырау аса. Мөслим теркәп бара.*

*Туксан авыр капчык күтәреп, траптан менеп килә. Шәке сиздерми генә аңа аяк чала. Туксан пристаньга тәгәрәп төшә.*

Габдулла. Нигә товар төяүне озакка суздың, Измаил бәй? Без бүген иртән юлга кузгала ала идек. Әйдә, намуслырак булыйк әле бер-беребезгә карата!

Измаил бәй. Син бер генә күз сал, Габдулла! Күрәсеңме минем бурлакларны! Бөркетләр! Пәһлеваннар! *(Габдулланы котырта.)* Мондый егетләр белән Мәскәүгә кадәр барып җитәргә була!

Габдулла. Ә без барып та җитәрбез – һич шикләнмим моңа!

Гайшә. Нәрсә эшли ул алар белән, Измаил?

Измаил бәй. Син миңа Измаил диден̧ме? Мине барысы бәй дип атый.

Гайшә. Фәхешханәдә мине ирләргә исеме белән генә дәшәргә өйрәттеләр. Рәхмәт әйт әле син, пупсик димәгәнгә.

Измаил бәй. Шәке, минем ярдәмчем, аларның муенына кыңгырау аса. Югалмасыннар өчен. Идел киң, зур елга, бик тиз юкка чыгарга, төпкә китәргә мөмкин. Бу минем башка килгән фикер...

Гайшә. Сиңа бу адәмнәр бер дә кызганыч түгелме?

Измаил бәй. Кызганыч?!. Көлдермә инде, Гайшә! Болар җир йөзендә иң бәхетле кешеләр! Аларның ни өйләре, ни гаиләләре, ни Ватаннары – берсе дә юк! Алар салым түләми, нәрсәмне дә булса урларлар дип куркып яшәми! Алар теләсәләр җирдә, теләсәләр ташта, йә булмаса, суда ятып йоклый! Теләмәсәләр, гомумән, йокламыйлар! Алар искән җилнең үзе кебек иркле кешеләр! Һәм кая барасын, үзләренә ни кирәген беләләр! Мин

үзем дә яшь чагымда бурлак булдым. Тормышымның иң рәхәт чагы иде, Габдулла әфәнде!..

Габдулла. Бу тормышмы инде?

Измаил бәй. Син ышанмыйсыңмы миңа? Менә әйт әле, синең кайчан да булса Идел өстендә рәшә, ягъни мираж күргәнең бармы?

Габдулла. Бу нинди ахмак сорау? Иделдә мираж булмый. Минем бары тик Мисырда гына мираж күргәнем булды.

Измаил бәй. Ә син, Гайшә, Идел өстендә мираж күргәнең бармы?

Гайшә. Юк, күргәнем юк.

Измаил бәй. Ә менә алар күрә! Сорагыз әле алардан! Бурлакның теләсә кайсы Идел өстендә мираж күргәнем бар диячәк! Бу бит төш! Бу бит хыял! Соры, болытлы, пычрак күк йөзендә төсле, матур мираж... Минем дә беркайчан да мираж күргәнем юк... Беркайчан да!

Габдулла. Алар сине алдый гына, Измаил бәй. Бер генә сүзенә дә ышанырга ярамый аларның. Аларның бит өйләре генә түгел, ә гаиләләре, Ватаннары да юк. Һәм иманнары да юк... Мин бурлакларны яхшы беләм, кайчандыр алар белән бергә эшләгән идем... Алар бит сатылалар, фахешханәләрдәге фахишәләр кебек сатыла!

Измаил бәй. Нәкъ синең белән минем кебек үк... Шул исәптән бу асыл кош та акчага гына ышана!

*Товарны төяп бетерәләр. Мөслим Измаил бәй янына килә.*

Мөслим. Товарны төяп бетердек, Измаил бәй. Мин барысын да тикшердем.

Измаил бәй. Яхшы. Бурлаклар ял итсен бүгенгә. Иртәгә иртән юлга кузгалырбыз.

*Мөслим бурлакларны пристаньнан куып чыгара. Бары тик Шәке белән лоцман Мәхмүд кенә кала.*

Измаил бәй *(Габдуллага)*. Барыгыз, ял итегез. Юлга җыеныгыз.

*Габдулла белән Гайшә китә. Шәке белән Мәхмүд Измаил бәй янына килә. Мәхмүд Измаил бәйгә калын кенәгәсен күрсәтә.*

Мөслим. Менә, Измаил бәй, унбиш тоннадан артып китте. Тагын бераз төяргә була иде булуын.

Измаил бәй. Юк, җитеп торыр. Югыйсә баржа комга утырыр, Бурлакларга тартуы авыр булыр.

*Мөслим бераз читкәрәк китә.*

Измаил бәй *(Шәкегә мөрәҗәгать итеп)*. Игътибар белән тыңла мине, Шәке! Бу казанлы Гаязга күз-колак бул! Нигәдер ул миңа ошамый башлады әле. Бик үзгәрде соңгы вакытта. Күздән ычкындырма! Аннары складтан өч ящик аракы алырга онытма.

Шәке. Ярамый бит! Син үзең әйттең бит, Измаил бәй, юлда коры закон дип!

Измаил бәй. Син, бурлак, минем белән сүз көрәштереп торасыңмы?!

Шәке. Яхшы, барысын да син кушканча эшләрмен, Измаил бәй!

Измаил бәй. *(лоцман Мәхмүдкә карап)* Жигули тауларын узгач, баржаны комга утыртырсың!

Мәхмүд. Син нәрсә инде, Измаил бәй?! Гомердә булмаганны!

Измаил бәй. Тик тор! Дәшмә! Кабатлап әйтәм, баржаны комга утыртырсың! Шундый итеп утырт, ул анда язга чаклы калырлык булсын!

Мәхмүд. Ә товар? Товар әрәм була бит!

И з м а и л  б ә й . Анда синең эшең булмасын! Минем товар!

М ә х м ү д . Ә бурлаклар? Салкыннан катып үләләр ләбаса!

И з м а и л  б ә й . Бурлакларны олаулар белән килеп алырбыз. Мин барысын да әзерләдем! Җитте, күп сүз – юк сүз! Иртәгә таңнан юлга чыгабыз!

**Дүртенче күренеш**

*Икенче көннең таңы. Баржа юлга чыгарга әзер. Җилкәннәре күтәрелгән. «Монамах»ның палубасында И з м а и л  б ә й, Г а б д у л л а, Г а й ш ә һәм М ө с л и м күренә. Л о ц м а н М ә х м ү д үз эшләре белән мәшгуль. Бурлакларның барысы да яр буенда басып торалар. О л а н да алар арасында. Измаил бәй игътибар белән бурлаклар төркемен күзәтә.*

И з м а и л  б ә й . Бу малайны юлга кем алды?

М ө с л и м . Безнең белән барса яхшырак булыр. Ул бит гаиләсез-йортсыз. Мондагы бандитлар көн күрсәтмәсләр үзенә.

*Мөслим өстән кыңгырау ташлый. Аны Гаяз тотып алып, Оланның муенына аса.*

И з м а и л  б ә й . Ярар, барсын инде алайса. *(Бурлакларга мөрәҗәгать итеп.)* Барыгызга да бик зур рәхмәт, бурлаклар! Ишеткәнсездер, Казан каласы янган! Күпләрегезнең ул әле туган шәһәре дә! Казанда халык ачлыктан кырыла! Бөтен Россия һәм Император галиҗәнаплары үзе дә Казанга ярдәм итә! Бурлаклар, мин сезнең көчегезгә, мөмкинлекләрегезгә ышанам! Сезгә җылы көз, тирән сулы юл телим. Җил һәрчак уңай якка иссен. Аллага тапшырдык!

*Измаил бәй Габдуллага сүз бирә.*

Г а б д у л л а *(озын гына паузадан соң)*. Бурлаклар! Сезне бик авыр юл көтә. Баржаның йөге шактый зур, юл бик озын, тиздән көзнең җан өшеткеч салкыннары башлана… Мин сезнең белән бергә барам һәм Казанга барып җитәрбез, халыкны ачлыктан коткарырбыз дип ышанам! Аллаһы Тәгалә үз мәрхәмәтеннән ташламасын сезне! Амин! *(Пауза).*

Г а й ш ә *(кинәт)*. Бурлаклар! Мин дә исән-имин Казанга барып җитүебезне телим. Мин үзем дә Казанда туып үстем...

Ш а м и л ә . Авызыңны яп ичмасам, кәнтәй! Сез хәзер җылыда ананас белән уылдык тыгынып утырачаксыз, ә без тездән салкын су ерабыз! Әгәр шундый яхшы икәнсең, безнең белән бергә бас, әйдә! Нәрсә, туның юешләнер дип куркасыңмы?!

Б е р н и ч ә  б у р л а к  х а т ы н *(Шамиләгә кушылып)*. Сөйрәлчек! Уйнашчы! Азгын!

И з м а и л  б ә й *(Шамиләне бүлдереп)*. Җитте, кузгалабыз!

*Мәхмүд берничә тапкыр судногагы кыңгырауга суга, чаң кага. Башка бурлаклар да үз элмәкләрен кияләр. Гаяз Оланга элмәген кидерә һәм артель башына баса. Җилкәннәр җил белән тула. Бурлаклар элмәкләрен киеп бетереп, «Әйдәгез, киттек. Кузгалды! Үзе бара! Бара!» дип кычкырышалар. Баржа әкрен генә селкенеп борыла һәм кузгалып китә. Бурлакларның кыңгыраулары чыңы ишетелә. «Шаулама, камыш» дигән озын һәм сагышлы бурлак җыры яңгырый. «Монамах» баржасы зур суга чыга.*

**Бишенче күренеш**

*Бер көн узган. Кич җитеп килә. Баржа причалда тора. Җилкәннәре төшкән. Трап аны яр белән тоташтыра. Палубада Г а б д у л л а, И з м а и л  б ә й басып тора. Бурлаклар яр буенда ял итә. Күбесе йоклый. Зур гына шалаш. Казан астында учак яна. Учак янында О л а н утыра.*

Г а б д у л л а . Нигә син өйләнмисең, Измаил бәй? Синең бит дөньяң түгәрәк, бөтен әйбереӊ бар, хатыныңнан кала...

И з м а и л  б ә й . Әнием миңа бер яшь тулганчы ук мәрхүм булган. Әтием мине үзе генә үстерде. Ул атлар тота иде, зур гына ат абзарлары бар иде. Миңа унбиш яшьләр тулгач, ул өйләнергә, гаилә корырга уйлады. Йортка яшь кенә, гөнаһсыз кыз баланы алып кайтты... Шул ук көнне бу кызны ат абзарында кемдер көчләгән. Ат караучыларның барысы да миңа төртеп күрсәтте. Кыз үзе күрмәгән, аннары ат абзарында караңгы да иде бит... Шул ук көнне атам мине өйдән куды. Минем атам язмышын кабатлыйсым килми. Син күз алдына да китерә алмыйсың, ул картның ниләр кичергәнен... Коточкыч авыр язмыш... Ул үзенең бердәнбер улын өйдән куды...

Г а б д у л л а . Алайса бу Гайшә нигә кирәк соң сиңа?

И з м а и л  б ә й . Беләсеңме, мин сиңа хәзер бер вакыйга турында сөйләп бирәм... Мин якты дөньяга бик зәгыйфь, чирләшкә бала булып туганмын. Җиде айлык булып дөньяга килгәнмен. Җитлекмәгән бала булганмын. Шундый булып үстем дә. Йөгерә дә, сикерә дә, йөзә дә алмый идем. Бервакытны үз атам, ә ул гайрәтле купис иде, бөтен урам малайларын җыйды да болай диде: урамның теге башына бер чүлмәк алтын куям – кем беренче булып шунда йөгереп барып җитә, чүлмәк шуңа була, диде. Чүлмәк янына иң беренче булып, мин йөгереп барып җиттем!.. Күз алдына китерә аласыңмы син: мин, иң ябык, хәлсез малай, таза, куәтле малайларны узып китеп, чүлмәк янына алдан барып җитә алдым! Мин көчле, куәтле, курку белмәс кешегә әвеពелдем. Шуннан бирле һәр теләгән әйберемне кулга төшерергә һәм һәрчак беренче булырга гадәтләндем...

Г а б д у л л а . Бу юлы синең берни дә килеп чыкмастыр шул дип уйлыйм, Измаил бәй...

*Г а й ш ә чыга.*

И з м а и л  б ә й . Туңмадыңмы, чибәркәй?

Г а й ш ә . Мин чыныккан инде, Измаил, минем өчен эчең пошырма син.

И з м а и л  б ә й *(сокланып)*. Ах, нинди кайнар канлы син!..

*Гайшә тәмәкесен кабыза.*

И з м а и л  б ә й *(Оланга кычкыра)*. Әй, Олан! Уйныйсың киләме минем белән?

О л а н . Бик тә килә, Измаил бәй әфәнде!

И з м а и л  б ә й *(тәңкәгә күрсәтеп)*. Кара, Олан! Бу – алтын тәңкә! Мин аны хәзер суга ташлыйм, ә син чумасың да эзләп табып алып чыгасың!

О л а н . Мин риза!

И з м а и л  б ә й . Ә син Байгал исемле Балык-Анадан курыкмыйсыңмы соң?

О л а н . Балык-Ана бурлакларга тими ул!

Измаил бәй. Ого-го! Иреңдә әле ана сөтең кипмәгән, ә син бурлак та булдың инде!

*Олан ашыгып чишенә башлый.*

Габдулла *(шыпырт кына Измаил бәйгә)*. Син тәңкә ташламыйсың бит, әйеме, Измаил бәй?

Измаил бәй. Юләр түгел бит мин! Син әзерме, Олан? Мин ташлыйм!

*Олан янына Гаяз килә.*

Гаяз. Баладан көлмә, Измаил бәй! Салкын тияр, йә батып үләр! Су боз шикелле салкын!

Измаил бәй. Син әзерме, Олан? Мин тәңкәне ташлыйм! Чум әйдә!

Гайшә. Сикермә, Олан! Мин сиңа ике алтын бирәм!..

*Олан кире киенә башлый.*

Измаил бәй. Кыю кызый син, ошыйсың миңа!

Габдулла. Ярар, соң инде, йокларга вакыт.

Гайшә. Миңа аерым каюта кирәк!

Габдулла. Минем белән барырсың!

Гайшә. Бармыйм!

Габдулла. Нишләп әле бармыйсың?!

Гайшә. Мин бит хәзер бәхәс бүләге. Нәрсә, оныттыңмы әллә?! Уен әле башланды гына. Шуңа күрә кем белән йоклавым әлегә хәл ителмәгән!

Измаил бәй. Ул хаклы, Габдулла әфәнде!

Габдулла. Алайса ычкын моннан! Бар, әнә бурлаклар янында йокла! Монда аерым каюта юк синең өчен!

Гайшә. Һәм барам да, ник бармаска! Куркыр дип уйлыйсыңмы әллә?!

*Гайшә трап буйлап, бурлаклар янына ярга төшә.*

Измаил бәй. Син курыкмыйсыңмы?

Габдулла. Ул фахишә, азгын хатын, Измаил бәй! Акчасын күрмичә, беркем янына да ятмаячак. Туңа башлагач кире килер әле!

Измаил бәй. Син хаклы. Безгә дә йокларга вакыт.

Габдулла. Иртәгә таңнан юлга кузгалырбыз.

*Габдулла белән Измаил бәй китәләр.*
*Гайшә бурлаклар янына килә. Аның янына Шамилә очып килеп җитә.*

Шамилә. Нәрсә, байларың кудымы үзеңне? Шул кирәк сиңа! Яле, туныңны миңа салып бир! Бүрегеңне дә сал! Тиз бул!

*Шамилә Гайшәнең тунын һәм бүреген көчләп салдырып ала. Гайшә учак янына килә. Аның янына Шәке килеп баса. Кулыннан тотып, үзе белән өстери башлый.*

Шәке. Синең белән беренче булып мин ятам! Киттек әйдә!

Гайшә. Бәйләнмә миңа, кабахәт! Кит, диләр сиңа! Кит!

*Шәке янына Гаяз килә.*

Гаяз. Җибәр аны, Шәке. Җылынсын бераз.

Шәке. Бу кызыйдан ерак йөр! Синең тешең үтә торган җимеш түгел ул!

*Гаяз белән Шәке ике арада купкан бәхәстән сугышуга күчәләр. Бөтен бурлаклар аларны урап алып, кызыксынып күзәтә. Шау-шу, кычкырыш. Гаяз җиңеп чыга. Барысы да тарала. Шәке шалашка кереп кача. Бурлаклар йокларга ята. Учак янында Гаяз, Гайшә һәм Олан кала.*

Олан. Карале, кызый, син миңа чынлап та ике алтын бирерсеңме?

Гайшә. Чынлап та бирәм, Олан, алдамыйм.

*Олан үзенең бишмәтен салып, Гайшәнең җилкәсенә ташлый. Туксан чыга. Алар янына килеп утыра.*

Туксан. Гаяз, Шәке белән саграк бул әле. Измаил бәй белән бигрәк еш пышылдашып алалар. Нәрсә турында сөйләшәләрдер, шайтан белсен.

*Олан кинәт кенә сикереп тора да караңгы күккә күрсәтеп кычкырып җибәрә.*

Олан. Карагыз! Карагыз! Каян килә бу яктылык?! Бу янгын бит! Пожар!

*Барысы да сикереп тора.*

Туксан. Тизрәк көймәгә утыр, Гаяз! Иделгә чыгабыз! Нинди яктылык, нинди балкыш бу...

*Туксан, Гаяз һәм Олан яр кырыена барып, көймәгә утыралар. Алар артыннан Гайшә дә көймәгә утыра. Гаяз кулында ишкәкләр, ул ишә. Алар елга уртасына таба китәләр. Шау-шуга шалашыннан Шәке йөгереп чыга, китеп барган көймәне күреп ала. Палубага йөгерә, чаң кага.*

Шәке. Качтылар! Шишкарь Гаяз Казан кызые белән качты! Качтылар!..

*Көймә елга уртасында. Туксан, Гаяз, Гайшә һәм Олан. Караңгы күктә могҗиза шикелле гаҗәеп матур мираж пәйда була. Анда ап-ачык итеп күз нурын алырлык зәңгәр диңгез күренә. Ә диңгез уртасында искитәрлек серле гүзәл утрау барлыкка килә. Утрау өстендә әкияти матур оҗмах кошлары очып йөри.*

Гайшә. Гаяз, нәрсә бу?..

Олан. Минем мондый нәрсәне гомеремдә дә күргәнем юк иде…

Туксан. Бу мираж була, балалар…

Гаяз. Мин моны берничә тапкыр күрдем инде. Бер серле могҗиза шикелле.

Гайшә. Нindидер гаҗәеп утрау! Күз нурын алырлык зәңгәр диңгез! Карагыз әле, күпме ак кошлар анда! Ә кояш ничек нурларын сибә!

Олан. Анда искиткеч җылыдыр, әйеме?! Яр буендагы ком да шундый сары хәтта!

Туксан. Бу җәннәт утравы, балалар.

Олан. Анда кем дә булса яшиме соң?

Туксан. Үлгән бурлакларның җаннары яши ул бәхет атавында.

Олан. Үлгән бурлакларның җаннары?!. Ә ничек баралар соң алар анда?

Туксан. Бурлакларның җаннары, вафат булгач, бүтән гади кешеләрнеке шикелле күккә очмыйлар. Бурлакның җаны, ап-ак

кош каурыена әйләнеп, тигез Идел суы өстенә төшә. Агымсу аны бик еракларга агызып алып китә дә иксез-чиксез җылы зәңгәр диңгезгә илтеп чыгара. Ә җылы диңгездә ул искиткеч матур ап-ак кошка әверелә, әнә шул бәхет утравында мәңгегә яшәп кала…

Олан. Ә нишләп ул утрау бүген күренде икән?

Туксан. Бу мираж, улым, бары тик берәр бурлак вафат булган мизгелдә генә күк йөзендә барлыкка килә…

Гайшә. Алайса, бүген төнлә кайдадыр яр буенда бер бурлак теге дөньяга күчкән инде…

Туксан. Кемнеңдер жаны, ап-ак кош каурыена әйләнеп, бәхет утравына килеп эләккән.

Гайшә. Ә мираж нигә кирәк ул? Аллаһы Тәгалә нигә аны безгә күрсәтә?

Туксан. Бурлаклар гел алга таба барсыннар, үзләрен кайдадыр ак бәхет көтеп торганын белсеннәр өчен.

Олан. Ә бурлаклар ничек үләләр?

Туксан. Чын бурлаклар бертөрле вафат була. Йөрәкләре шартлап ярыла аларның. Бурлакларның йөрәкләре бик зур була бит. Күкрәкләренә сыймастай зур була. Шунлыктан шартлыйлар…

Олан. Туксан бабай, ә мин чын бурлакмы?

Туксан. Бәхет утравының миражын күрдең бит син. Шулай булгач, син хәзер рәхәтләнеп, тынычлап яши аласың. Киләчәктә сине җәннәт утравы көтә…

Гаяз. Ярый, барысын да аңладык... Баржага кире кайтырга вакыт... Безне анда качкыннар дип атарга да өлгерделәр инде...

*Гаяз, Гайшә, Туксан һәм Олан кабаттан ярга таба юл тоталар. Мираж әкренләп эреп юкка чыга.*

**Алтынчы күренеш**

*Гаяз, Гайшә, Туксан һәм Олан ярга чыгалар. Аларны Измаил бәй, Габдулла һәм бурлаклар җыелышып көтеп тора.*

Измаил бәй. Сез нәрсә, качарга уйладыгызмы?

Гайшә. Без күк йөзендә гаҗәеп мираж күрдек! Зәңгәр диңгездә җәннәт утравы. Үлгән бурлакларның җаннары шунда яши.

Габдулла. Нинди ахмаклык бу? Нинди мираж? Акылдан язган кызый!..

Гайшә. Без барысын да күрдек!

Олан. Анда искиткеч зур, матур мираж күренде! Бөтен күк йөзенә җәелгән иде!

Габдулла. Измаил бәй! Аны зинданга ташларга кирәк, Казанга җиткәнче шунда утырсын!

Измаил бәй. Мәхмүд! Зинданга ташлагыз аны! Күселәр белән шунда утырсын, уйлансын бераз!

*Мәхмүд Гайшәгә таба килә башлый. Аның юлын Гаяз бүлә.*

Гаяз. Юк, Измаил бәй! Матур хатынны күселәр янына ташлау мактаулы гамәл түгел! Гайшә Казанга кадәр безнең белән бара, ә анда кайтып җиткәч, күз күрер.

Габдулла. Син кем булдың әле монда, әй, бурлак, матур хатыннар күргәнең бармы соң синең?! Синең андыйларны кулларыннан да тотып караганың юк бит!

Измаил бәй *(Гаязга карап).*

Бу ни эшләвең, бурлак! Мәхмүд, матросларны чакыр! Төрмәгә илтеп ташлагыз кызыйны!

*Трап буйлап матрослар йөгерешә.*

Г а й ш ә . Туктагыз! Ашыкмагыз! Бурлаклар, Гаяз, мин башта сезгә бер нәрсә хакында сөйлим әле. Бу ике сәүдәгәр, казанлы Габдулла белән әстерханлы Измаил бәхәскә керделәр, бәхәснең бәясен билгеләделәр! Тараканнарга куйган кебек сезгә ставка ясадылар! Бәхәснең асылы шунда ки, сез Казанга барып җитә аласызмы, әллә юкмы?! Кайсы җиңә, мин – шуңа! Алар үзләренең җылы каюталарында утырып, баржаны тарта алуыгызны күзәтәләр! Алар сезне курчак урынына күрә!

Т у к с а н . Бу дөресме, Измаил бәй?!.

И з м а и л  б ә й . Әйе, ул дөресен әйтте... Булды андый бәхәс...

Т у к с а н . Сезгә баржадан китәргә кирәк. Без Казанга үзебез дә барып җитәбез.

Г а я з . Китегез моннан, Измаил бәй!

Б а р л ы к  б у р л а к л а р . Китегез! Күздән югалыгыз! Без дә – кешеләр! Без моңа юл куймыйбыз!

Г а б д у л л а *(Гайшәгә)*. Киттек әйдә!

Г а й ш ә . Юк, мин монда калам. Бу баржада мин бит иң кыйммәтле товар!

*Пауза. Измаил бәй белән Габдулла дәшми генә китәләр. Мөслим, ике зур чемодан күтәреп, алар артыннан иярә.*

Т у к с а н . Ягез, бурлаклар, нишлибез? Барыгыз да ишеттеме бәхәс хакында?!

Б у р л а к л а р . Бәхәсләшмәгәйләре, теләсә нишләсеннәр! Безгә акчасын тиешенчә түли күрсеннәр, шул гына!

Ш а м и л ә . Бу чибәркәйне елгага ташларга кирәк – бәхәскә дә нокта куелыр!

Г а я з . Бу бәхәсне ишеткәннән генә без тизлекне әкренәйтмибез бит инде, бурлаклар?! Аларның бәхәсенә карап кына, Казан халкы өзелеп көтә торган бу товарны да ярда ташлап калдыра алмыйбыз?! Бу безнең тормыш! Мин сезне Казанга кадәр алып барып җиткерәм! Барырга теләмәүчеләр, Әстерханга кире кайтып китә ала!

Т у к с а н . Ярар, бүгенгә сүз күп булды! Йокларга кирәк, иртә таңнан юлга чыгасы бар.

*Бурлаклар әкрен генә таралыша. Гаяз белән Гайшә сүнеп бара торган учак янында икәү генә калалар. Пауза.*

Г а й ш ә . Минем әтием дә бик көчле кеше иде. Дус, тату гаиләбез бар иде. Без әнием белән түбәтәйләр тектек, аларны базарда сата идек. Әтием прәннек фабрикасында эшләде. Без кредит алдык, Казанда таш йорт сатып алдык. Без энем белән мәктәптә укыдык... Аннары әтием ничектер эшен югалтты. Кредит түләргә акча җитми башлады. Өйгә жандармнар килде. Берничә айдан безне өйдән куып чыгардылар. Әтием түзмәде, бауга менде, асылынды. Әнием кайгырды, хәсрәттән янды-көйде, холера белән чирләде, хастаханәдә үлеп тә китте... Бу көздә энемне армиягә алдылар... Менә шулай итеп мин, үзем дә сизми, фахешханәгә барып эләктем, фахишә булып киттем..

Г а я з . Сөйләп тормасаң да була.

Г а й ш ә . Бүген минем иң бәхетле

төнем... Мин үземнең балачагымны искә төшерәм. Миңа күптән болай җылы, рәхәт булганы юк иде... Син бик кыю кеше, Гаяз. Шулай да бу сәүдәгәрләр белән саграк булырга кирәк. Алар син уйлаганнан, күпкә хәйләкәррәк...

*Г а я з белән Г а й ш ә кочаклашып басып тора. Эре-эре булып кар ява башлый. Шалаштан О л а н йөгереп чыга. Ул яр буйлап йөгереп йөри.*

О л а н . Кар ява! Карагыз әле, беренче кар ява! Беренче кар!

*Олан кулында кар әвәли, аларны бәреп уйный башлый, бик сөенә. Т у к с а н чыга.*

Т у к с а н . Кар ява! Җыеныгыз! Бурлаклар! Гаяз, юлга кузгалырга кирәк! Тизрәк! Юлга чыгабыз!

*Бурлаклар уяна, ярга чыгалар.*

Т у к с а н . Лоцман! Мәхмүд! Баржаны әзерләгез! Кузгалабыз!

*Чаң суккан тавыш ишетелә. М ә х м ү д баржаны әзерли, якорьларны җыя. Җилкәннәрне күтәрә. Бурлаклар элмәкләрне әзерлиләр. Г а й ш ә Г а я з янына баса. Ш а м и л ә Гайшә янына килә, тунын аңа кире кидертә.*

Ш а м и л ә . Мә, туныңны кире ал, миңа килешми лә ул.

Б у р л а к л а р . Әйдәгез, тагын бер тапкыр, тагын бер! Үзе бара, бара! Тагын әз генә, туганнар! Киттек!

*Б у р л а к л а р элмәкләрен киеп, тарта башлыйлар, баржа кузгалып китә. Бурлаклар җыры яңгырый.*

**ИКЕНЧЕ БҮЛЕК**

**Җиденче күренеш**

*Баржа причалда тора, якорьлар суга ташланган, җилкәннәр төшерелгән. Барлык бурлаклар да ярда, Гаяз белән Гайшә генә күренми. Халык күңел ача. Бурлаклар курайда уйный, ярык барабан әйләндерәләр, бииләр, җырлыйлар, кыңгыраулары чыңлый. Татарлар татарча, чувашлар, марилар үзләренең милли биюләрен башкара. Казан астында учак яна. Ярда тартмасы белән аракы тора. Бурлакларның барысы да бераз кызмача. Т у к с а н читтә утыра, бу шау-шуны күзәтә.*

Б у р а н . Их, туганнар, күңелле шулкадәр! Күңел җырлый, аяклар бии! Мин бит беренче тапкыр туйда күңел ачам!

Э ш п а й . Бездә бурлак бер дә өйләнергә тиеш түгел, диләр!

П у я н . Дөрес әйтәләр, бурлак ялгыз яшәргә тиеш! Бурлак буйдак булырга тиеш!

Э ш п а й . Бурлак очар җилнең үзе кебек иректә булырга тиеш!

Ш а м и л ә . Барыбер күңелле! Күңел ачабыз, бурлаклар! Без дә кешеләр бит!

*Бурлаклар аракы тартмалары янына киләләр, эчәләр.*

Эшпай. Ә минем чын туйда мулла булырга тиеш дип ишеткәнем бар. Догалар укырга тиеш ди ул.

Буран. Әйдәгез, үзем мулла булам!

Пуян. Нинди мулла син, Буран?! Син бер генә дога да белмисең бит!

Шамилә. Мин чын туйда бүләкләр булырга тиеш дип ишеткәнем бар. Гармунчы, скрипкачы, яхшы җыр-көйләр булырга тиеш! Кияү белән кәләш бер-беренә балдаклар бүләк итешергә тиеш!

Эшпай. Юк, бу чын туй түгел!

Пуян. Юк, чын туй түгел, исерек мәҗлесе генә бу!

Шәке. Нәрсә сайрашасыз монда? Нәрсә җитми сезгә?! Аракы бар, ашарга җитәрлек! Күңел ачыгыз рәхәтләнеп!

Шамилә. Ә кайда соң безнең кияү белән кәләш?

Буран. Кияү белән кәләштән башка нинди туй ди ул?!

Шамилә. Кайда Гаяз? Гайшә кайда? Гаяз, син кайда?

Туксан. Гаяз яр сукмагын карарга китте. Тиздән юлга кузгалырга кирәк. Бурлак юлда булырга тиеш, ә аракы эчеп ятарга түгел!

Шәке. Җитте инде, картлач, сиңа тиргәшергә генә булсын! Кешеләргә ял итәргә ирек бир!

*Кәеф-сафа корулар яңадан башлана. Бурлаклар бииләр, күңел ачалар. Гаяз күренә, аның янәшәсендә Гайшә. Ул бик үзгәргән, элекке купшылык юкка чыккан, туны да таушалган. Бурлаклар тынып кала.*

Гаяз. Бу нинди шайтан туе?

Буран. Синең туйны бәйрәм итәбез, Гаяз!

Гаяз. Нинди туй?

Буран. Син бит инде ничәнче көн бу кызый белән йоклыйсың! Димәк, ул синең хатының! Хатының икән, димәк, туй булырга тиеш! Мин шулай дип уйлыйм!

Шамилә. Молодец та инде үзең, Гайшә! Бурлаклар арасыннан иң яхшысын эләктердең! Мондый батырга мин үзем дә кияүгә чыгар идем!

Гаяз. Нинди ахмаклык бу?!. Каян аракы алдыгыз?

Буран. Моны Шәке баржадан алып чыкты!

Гаяз. Шәке, ник син бурлакларга аракы эчерәсең?!

Шәке. Юл бигрәк авыр! Бурлаклар ардылар, ял итәргә ирек бир үзләренә бераз!

Гаяз. Юлда аракы эчәргә ярамый! Безнең Казанга кайтып җитәсебез бар!

Шәке. Нәрсә шаулап торасың әле монда? Син безгә хуҗа түгел! Безнең хуҗабыз – Измаил бәй, ул рөхсәт итте!

Гаяз. Нишләргә инде болар белән, Туксан бабай?..

Туксан. Юлга кузгалырга кирәк. Бик суытып җибәрде. Әгәр яхшы гына барса, иртәгә Жигули тауларына җитәрбез, Алла боерса.

Гаяз. Әй бурлаклар, җыеныгыз! Кузгалабыз! Юлга! Әй, Мәхмүд, румпельны бор! Казанга кайтырга кирәк! Бары тик Казанга җиткәч кенә, кулыбызга акча керәчәк!

*Бурлаклар теләр-теләмәс кенә юлга җыена. Әкрен генә элмәкләрен кияләр, тезелеп басалар. Гайшә Гаяз янына баса, аның янына – Шамилә. Барысы да сүзсез. Арканнар тартыла, баржа әкрен генә кузгалып китә.*

**Сигезенче күренеш**

*Күпмедер вакыт узган. Баржа яр буенда комга утырган. Җилкәннәр төшерелгән. Тирән тынлык. Бурлаклар яр буенда ята. Т у к с а н ярда басып тора. Г а я з ауган бүрәнә өстендә утыра. Ерак түгел О л а н утыра, бик нык ютәлли.*

*М а т р о с белән М ә х м ү д палубада ята.*

Т у к с а н . Су кимегәннән-кими, тубыктан гына калып бара. Елга кибә бит! Җил дә юк ичмасам!

Г а я з . Ничек без баржаны комга утырта алдык, һич башыма сыймый.

Т у к с а н . Мәхмүд румпельны сул якка борды, уң якка кирәк иде.

М ә х м ү д . Гаяз үзе бурлакларны дөрес алып бармады! Су читеннән алып барырга иде, ә ул югарыга, тауга таба борылды!

Г а я з . Бу сайлыкны мин күп тапкырлар уздым! Су юлы һәрчак югарыданрак бара иде!

М ә х м ү д . Син шишкарь, Гаяз! Бурлакларны син алып бардың! Димәк, баржаны син комга утырттың! Син җаваплы барысы өчен дә!

Т у к с а н . Бурлакларга аракы эчәргә ярамый! Бернинди кысаларга сыймый бу!

М ә х м ү д . Бурлакларга өйләнергә ярамый! Син үзең шулай дия идең бит, Туксан бабай!

*Б у р а н килә. Бик шатланган.*

Б у р а н . Әй туганнар! Мин монда тирә-юньне күзләп килдем бераз! Өстәрәк станция бар икән, анда яхшы трактир да бар! Әйдәгез, киттек шунда, ял итик! Кәеф күтәрергә кыз-кыркыннар да бар!

Ш а м и л ә . Сиңа шул кызлар гына булсын инде!

Б у р а н . Соң мин яшь бит әле! Киттек, туганнар!

Г а я з . Беркем беркая бармый! Хәзер су күтәрелә һәм юлга кузгалабыз!

Б у р а н . Син нәрсә инде, шишкарь, тилердеңме әллә? Баржа бөтен корсагы белән комда ята, күрмисеңме әллә? Идел кипте! Баржаны хәзер язга чаклы да урыннан кузгатып булмаячак!

Г а я з . Тик тор, Буран! Син үзең беләсең, бурлак беркайчан да ярты юлда тукталып калмаячак. Без ни генә булса да, Казанга кайтып җитәргә тиешбез!

Б у р а н . Бер елдан соң! Киттек, туганнар! Безгә нәрсә, салкын җирдә ятаргамы әллә?!

М ә х м ү д . Барыгыз, бурлаклар, барыгыз, югыйсә монда юкка чыгасыз!

Г а я з . Мин сезне беркая да җибәрмим, бурлаклар!

М ә х м ү д . Тыңламагыз аны, акылдан язган ул! Аллага тапшырып, барыгыз әйдә!

*Б у р л а к л а р җыелышып китәләр. Ш а м и л ә Г а й ш ә янына килә.*

Ш а м и л ә . Гайшә, әйдә безнең белән! Монда катып үләсең бит!

Г а й ш ә . Юк, Шамилә, мин монда калам...

*Яр буенда Г а я з, Г а й ш ә, Т у к с а н һәм О л а н кала.*

Т у к с а н . Бары бер, соңгы өмет кенә калды... Балык-Ана Байгал...

Г а я з . Синең күргәнең бармы ул балыкны, Туксан бабай?

Т у к с а н . Ул балыкны беркемнең дә күргәне юк. Әмма ул бар... Бары

тик ышанырга гына кирәк. Байгал бернинди өмет калмаганда, иң соңгы мизгелдә Бурлакларга ярдәмгә ашыга: батып баручыларга ярга чыгарга, өшүчеләргә җылынырга, авыруларга терелергә булыша... Ышанырга кирәк, бары тик ышанырга...

Г а я з . Мин ышанам, Туксан бабай, бик ышанам…

*Трап буйлап баржадан М ә х м ү д һәм берничә м а т р о с төшә, кулларында шәхси әйберләре салынган чемоданнар, төргәкләр.*

М ә х м ү д . Без китәбез. Монда җан тәслим кыласыбыз килми.

Т у к с а н . Сез дә трактирга юл тоттыгызмы?

М ә х м ү д . Нинди трактир? Әстерханга, өйгә кайтабыз! Ә сез бу каһәр суккан баржа белән монда калсагыз да була!

*Мәхмүд белән матрослар китә. Пауза.*

Т у к с а н . Гаяз, синең алар белән бергә китәсең килмиме?

Г а я з . Әгәр мин китсәм, Измаил бәй бәхәстә өстен чыгачак.

Т у к с а н . Син Габдулла әфәнденең җиңүен телисеңме?

Г а я з . Мин үзем отарга телим бу уенда, Туксан бабай! Үзем! Сәүдәгәрләр безне аңгыралар, беткән кешеләр, булдыксызлар дип уйлыйлар. Без алар өчен теләкләрен үтәүче коллар гына. Алар безне, гомумән дә, кеше итеп танырга, күрергә теләми! Дөрес, без университетларда укымадык, укый-яза белмибез, затлы кибетләрдән киенмибез, рестораннарда тукланмыйбыз, әмма без дә – кеше! Безнең җаныбыз, күңелебез, хәтеребез бар! Без дә ярата, хыяллана, өметләнә һәм бәхетле була беләбез!..

Т у к с а н . Мин ышанам, син үз максатыңа ирешәчәксең һәм җиңүче булачаксың! Чөнки син чын бурлак, Гаяз!

Г а й ш ә . Коткар мине, Гаяз! Мин ул сәүдәгәрләрнең берсе белән дә булырга теләмим. Ни Измаилен, ни Габдулласын – берсен дә күрәсем килми!

Г а я з . Син хәзер минеке инде, Гайшә! Мин сине берсенә дә бирмим!

*О л а н саташа башлый.*

О л а н . Утрау!.. Бәхет утравы!.. Минем шунда барасым килә! Анда җылы!.. Рәхәт!.. Ак кошлар оча!..

Т у к с а н . Тәне ут булып яна. Әле бала гына бит бу. Өлкәннәр белән янәшә басып, баржа тартып барды, әле салкын суга ничә тапкыр егылды...

Г а я з . Нишләтәбез инде аны?..

Т у к с а н . Моннан ерак түгел генә балыкчылар йорты булырга тиеш. Аның миче дә бар иде. Тәнен скипидар белән ышкырмын... Без шунда барыйк әле...

Г а я з . Барыгыз... Сезгә Әстерханга кире кайтырга кирәк...

*Туксан белән Олан китә. Гайшә белән Гаяз икәү генә кала.*

Г а й ш ә . Мин кечкенә вакытта әнием миңа гел Аллаһы Тәгаләгә дога кылырга кирәк дип өйрәтә иде. Үзе дә һәрчак догада булды! Шуңа күрә без бик бәхетле яшәдек! Ул бер көн калдырмыйча көненә ничәшәр тапкыр догалар укый иде. Аңа карап, мин дә, үскәч, әниемнең бөтен догаларын өйрәнермен дип хыялландым. Тик аннары әнием нигәдер догаларын көн саен укымый башлады һәм... гаиләбезнең түгәрәк

бәхете кителде... Мин бер генә дога да белмим шул, Гаяз..

*Гаяз кинәт кенә сикереп тора да шишкарьның элмәген киеп, баржаны бар көченә тарта башлый.*

Г а й ш ә . Нишләвең бу, Гаяз?!

Г а я з . Мин бу баржаны Казанга берүзем тартып кайтам! Мин булдырам! Мин көчле! Бу баржа Казанда булырга тиеш!

*Гаяз бар көченә тырыша, авыртудан улый-үкси, әмма баржа урыныннан да селкенми.*

Г а й ш ә . Гаяз, тукта! Син үзеңне бетерәсең! Баржа комга terәлгән, үзең күрәсең бит!

Г а я з . Мин аны үзем генә сөйрәп чыгарам! Үзем! Берүзем!

Г а й ш ә . Ялварып сорыйм, тукта, зинһар!..

*Гаяз баржаны кузгатырга омтылып, әле бик озак тарта, тик аның тырышлыгы юкка. Ул хәлсезләнеп, җиргә ава. Гайшә аның янына утыра, чәчләреннән сыйпый.*

Г а й ш ә . Мин баржаны Идел буйлап берүзе тартып барырга риза булган ирне очратырмын дип хыялланмаган да идем хәтта. Син – минем батырым, син – минем героем, пәһлеванам, Гаяз! Мин сине хәзер беркемгә дә бирмим инде, һәрчак янәшәңдә булам... Гаяз! Мин әниемнең догаларын искә төшерә башладым бит! Тик мин аларны күңелдән генә укыйм, яме... Йә сүзләрендә ялгышырмын, ә син көләрсең... Бер дә миннән көлүеңне теләмим...

*Гаяз белән Гайшә кочаклашып утыра. Гайшә күңелдән генә догаларын укый. Гаяз әкрен генә тора да шалашка таба китә. Аш табагын ала да яр буена барып, андагы азыкны суга агыза.*

Г а й ш ә . Син нишлисең, Гаяз?..

Г а я з . Без ашатырга тиеш аны.

Г а й ш ә . Кемне, Гаяз?

Г а я з . Балык-Ана Байгалны… Безгә бары тик ул гына ярдәм итә ала.

*Ул арада караңгы да төшә башлый. Күк йөзендә мираж күренә.*

Г а й ш ә . Гаяз, карале! Тагын мираж балкый! Нинди матурлык!..

Г а я з . Тагын бер бурлак җаны теге дөньяга күчте...

Г а й ш ә . Аларның җаны ул утрауга ничек элә гә соң?

Г а я з . Балык-Ана Байгал аларны утрауга кадәр озата бара.

*Алар әсәрләнеп, миражны күзәтә башлыйлар. Мираж әкренләп юкка чыга.*
*Гаяз үз уйларына чумып утыра. Кинәт әкрен генә көйли башлый.*

Г а й ш ә . Нәрсә булды, Гаяз?.. Нишлисең?

Г а я з . Мин җырлыйм, Гайшә… Бу – минем яраткан җырым.

*Яр буенда И з м а и л б ә й. Өстендә җылы тун, башында кеш бүреге.*

И з м а и л б ә й . Тагын мираж күрдегезме? Сәер кешеләр сез, әллә нинди әкиятләргә ышанасыз.

Г а я з . Син ник килдең, Измаил бәй?.. Без монда, товар белән баржага беркем кагылмый, курыкмагыз.

И з м а и л б ә й . Мин барысын

да беләм, Гаяз. Туй турында да, аракы турында да, баржаның комда ятуын да беләм.

Г а я з . Уен әле төгәлләнмәгән, Измаил бәй.

И з м а и л б ә й . Мин беләм, син гайрәтле кеше, Гаяз. Онытма, мин дә кайчандыр бурлак булдым. Мең бурлак килсә дә, бу баржаны комнан кузгата алмаячак.

Г а я з . Мин әйттем бит, уен әле төгәлләнмәгән.

И з м а и л б ә й . Ярар ла, оныт ул уенны. Мин синең яныңа кешеләрчә сөйләшергә килдем, Гаяз.

Г а я з . Тыңлыйм сине, Измаил бәй.

И з м а и л б ә й . Бир миңа аны... Мин бу кызый – Гайшә турында әйтәм. Нигә кирәк ул сиңа? Нәрсә бирә аласың син аңа? Аның язмышы болай да катлаулы. Ул минем белән бәхетле булачак. Ул яхшы йортта, затлы тормышта яшәячәк, үз хезмәтчеләре булыр. Чит илләргә ял итәргә барыр, матур, затлы киемнәр кияр. Дөрес, мин яшь түгел инде, тик миндә гайрәт-көч ташып тора әле. Синең белән юкка чыга бит ул, Гаяз. Син бер генә күз сал әле аңа, шушы бер ай эчендә ул кемгә әйләнде. Тагын бер айдан ул пычрак, дорфа мужик кыяфәтенә керәчәк бит!

Г а й ш ә . Мин беркайчан да синеке булмаячакмын, Измаил бәй!

И з м а и л б ә й . Син миңа бик тә кирәк, Гайшә. Мин сине гомерем буе көттем. Минем беркайчан да өйләнгәнем булмады. Син теге вакытта Габдулла белән пристаньга килгәч, миндә үзем дә белмәгән, элек һич кичермәгән хисләр уянды. Мәхәббәт шул була, күрәсең... Һәм тагын бер бик сәер хис – кешеләр аны көнчелек дип атый... Әйе, мин сине Габдулладан көнләдем. Бик тә-бик тә минем хатыным булуыңны телим, Гайшә... Мин бу җир йөзендә коточкыч ялгызмын. Ярдәм итегез миңа. Мин сиңа түлим, күп итеп түлим, Гаяз! Нигә кирәк ул сиңа?! Ул бит сөйрәлчек, фахишә! Син әле яшь, Гаяз, үзеңә яхшы яр табарсың! Телисеңме, мин сиңа үзем кызлар табып бирәм, татар авылыннан саф, гөнаһсыз, чиста кыз алып кайтып бирәм!

Г а я з . Гайшә әйтте бит инде үзенең җавабын, Измаил бәй...

И з м а и л б ә й . Сез мине бөтенләй дә белмисез икән әле.

Г а я з . Кит, Измаил бәй…

И з м а и л б ә й . Мин бер нәрсәне аңлый алмыйм. Гап-гади бурлак күрә торган миражны ник мин күрмим соң? Һич башыма сыймый... Онытмагыз, мин үз гомеремдә бары тик игелекле эшләр генә эшлим һәм минем һәр адымым гадел!

*Измаил бәй китә. Пауза.*

Г а я з . Мин бу кешедән бик тә куркам. Аның бер генә сүзенә дә ышанырга ярамый...

Г а й ш ә . Су күтәрелә башлады, Гаяз, күрәсеңме?

Г а я з . Туксан бабай барлык елгалар да Иделгә коя дип кабатларга ярата иде. Ул елгалар агудан туктый, бөтен чишмәләр берьюлы кибеп китә алмый бит инде. Су һичшиксез күтәрелергә тиеш!

*Гаяз яр буена бара, тезләнеп, дога кыла.*

Г а я з . Йа Илаһым, бар галәмне бар итүчем... Сиңа эндәшә торган дөрес сүзләр белмим шул мин... Әмма шуны яхшы беләм: син мине ишетергә тиеш, чөнки мин бурлак... Идел буенда япа-ялгызы калган бурлак... Күримче могҗизаңны!..

Бары тик син генә миңа ярдәм итә аласың, мин синең ярдәмгә лаекмын дип уйлыйм. Беркайчан да юлымнан кире борылмадым, гомерем буе үз баржамны тарттым... комлыкта да, сайлыкта да, салкында да, эсседә дә, агымга-җилгә каршы да тарттым да тарттым... чөнки бу минем язмышым, тәкъдирем, күрәчәгем. Мин һәрчак ярлы булдым, әмма гадел булып кала белдем. Дөрес, минем хаталарым да бар, ләкин мине хаталанмаска өйрәтергә ни әтием, ни әнием, ни белемем булмады. Мин барысына да шушы елгада өйрәндем... Мин ышанам, кем дә булса, кайчан да булса минем турында, минем кебекләр хакында китап язар. Әмма бу китапның ахыры яхшы тәгәлләнсен өчен мин Казанга кайтып җитәргә тиешмен. Могҗизаң күрсәтче, йа Илаһым. Китапны яртысы гына язылган килеш ябарга ирек куйма. Могҗизаң булдыр! Балык-Ана Байгалны чакыра күр бирегә. Бар гәүдәсе белән елганы буып, суны күтәрсен. Шул чагында бурлаклар да кире килер һәм без баржабызны Казанга кайтарып җиткерә алырбыз! Мин көтәм, могҗизаңны көтәм, йа Илаһым!

*Елга буена өч ж а н д а р м килеп чыга. Алар Гаяз янына киләләр.*

Ж а н д а р м . Гатин Гаяз?.. Туган елы-көне – 1811 елның 12 апреле?..

Г а я з . Әйе, бу мин…

Ж а н д а р м . Син кулга алынасың.

Г а я з . Ни өчен?

Ж а н д а р м . Син сөргеннән качып йөрисең, дигән мәгълүмат бар.

Г а я з . Сезнең хакыгыз юк. Мин – казанлы!

Ж а н д а р м . Бездә утырырсың, без Казанга синең хакта сорау җибәрербез. Шул вакытта барысы да ачыкланыр. Киттек!

Г а й ш ә . Нәрсә кирәк аларга, Гаяз?

Г а я з . Моннан беркая да китмә! Көт мине! Мине көт, Гайшә!

Ж а н д а р м . Әйдә, әйдә, тизрәк бул. Көтә ул сине!.. Көтә!..

Ж а н д а р м . Бәлки, кызыйны үзебез белән алыргадыр? Бигрәк чибәр!

Ж а н д а р м . Кушылмаган!

Ж а н д а р м . Ә мин алыр идем! Их!..

*Жандарм Гаязны алып китә. Гайшә яр буенда үзе генә кала. Ул елый.*

Г а й ш ә . Әнием!.. Нигә мин шундый бәхетсез икән, әнием?.. Әйт әле миңа, нигә?..

*Г а й ш ә бөгәрләнеп ята, үксү-үксү йокыга китә. Күпмедер вакыт уза. Яр буенда И з м а и л б ә й күренә. Кулында кыйммәтле, затлы тун. Ул йоклап яткан Г а й ш ә янына килә, аңа озак кына карап тора, өстенә тунны ташлый. Гайшә уянып китә.*

И з м а и л б ә й . Бурлакларга беркайчан да ышанма, бер сүзенә дә ышанма! Габдуллага да ышанма, бик хәйләкәр ул! Тегендә яр өстендә минем карета тора. Мин сине шунда көтәм. Әстерханга китәбез. Үз өең булыр. Син иректә. Бүгеннән синең яңа тормыш башлана. Мин сине яр өстендә көтәм, Гайшә... Ышан миңа, бу тормышта могҗизалар булмый. Бары тик уен, зур уен гына бар.

*Измаил бәй китә. Гайшә тора, тунны җирәнеп кенә, читкә ташлый. Баржага таба атлый.*

Г а й ш ә . Су күтәрелде… Аллаһы Тәгалә безнең догаларны ишетте, Гаяз! *(Кычкыра)* Әй, Измаил бәй! Син могҗизалар булмый, дидең. Менә бит ул могҗиза! Иделдә су күтәрелде! *(Трап буйлап, баржага күтәрелә, үзе шул бер үк җөмләне кабатлый.)* Барлык елгалар да Иделгә коя, барлык елгалар да Иделгә коя, барлык елгалар да Иделгә коя...

*Г а й ш ә палубага күтәрелә, артык зур булмаган бер якорь табып ала. Якорьның арканын муенына урый, якорьны кулына тота. Якорь тоткан килеш бортка менә, Идел киңлекләренә карый.*

Г а й ш ә . Әни, әнием... Тиздән без бергә булырбыз. Мин эти дә синең белән бергәдер дип уйлыйм. Бик сагындым сезне. Мин ашыгам... Сезнең яныгызга ашыгам...

*Гайшә якорьны елгага ташларга омтыла. Ярда Т у к с а н белән О л а н пәйда була.*

Т у к с а н . Гайшә!.. Гайшә, нәрсә эшлисең анда?

*Г а й ш ә борттан палубага төшә, якорьны куя, ашыга-ашыга муеныннан арканны сүтә. Т у к с а н белән О л а н баржага күтәрелә. Алар кочаклашалар.*

Т у к с а н . Нәрсә эшләвең бу, кызым?..

Г а й ш ә *(яшь аралаш)*. Юк, юк, барысы да яхшы, Туксан бабай! Күрәсезме, Иделдә су күтәрелде! Без Гаяз белән дога укып ялвардык! Аллаһы Тәгалә безне ишетте! Без дога кылырга өйрәндек, Туксан бабай! Син дөрес әйткәнсең, барлык елгалар да Иделгә коя! Карагыз әле, күпме су! Хәзер инде Казанга да барып җитәргә була!

Т у к с а н . Гайшә, ә Гаяз?..

Г а й ш ә . Аны жандармнар алып киттеләр, качкын каторжан, диделәр...

Т у к с а н . Бик начар булган бу. Без Гаязсыз Казанга барып җитә алмыйбыз.

Г а й ш ә . Ул миңа монда көтеп торырга кушты.

Т у к с а н . Димәк, бергә көтәбез. Ул киләм дигән икән, киләчәк. Аны көтәбез.

Г а й ш ә *(Оланга)*. Олан, акыллым, син авырыйсың бит!..

Т у к с а н . Мин аны ике көн скипидар белән удым. Әзрәк аңына килүгә, сикереп торды да баржага барырга кирәк, ди! Баржаны Казанга илтергә кирәк, ди! Чын бурлак булып тора!

Г а й ш ә *(Оланны коча)*. Тартабыз, Олан! Тартабыз баржабызны! Казанга ерак калмады инде!..

О л а н . Без сиңа кыздырган балык алып килдек, Гайшә апа! Безне балыкчылар сыйлады! Бик тәмле балык!..

Г а й ш ә . Рәхмәт, алтыным! Бик зур рәхмәт!

*Ярда Г а б д у л л а күренә. Гайшә, Туксан һәм Олан баржадан ярга төшәләр.*

Г а й ш ә *(ачу белән)*. Сиңа нәрсә кирәк, Габдулла әфәнде?

Г а б д у л л а . Ачуланма, Гайшә! Мин сезгә яхшы ният белән килдем.

Г а й ш ә . Сиңа нәрсә калган монда, Габдулла әфәнде! Бөтен бурлаклар качып бетте! Гаязны алып киттеләр!

Г а б д у л л а . Бу юл миңа күп нәрсәнең асылын аңларга булышты, күземне ачты, Гайшә! Мин хәзер бөтенләй башка Габдулла!

Г а й ш ә . Син нәрсә аңлый аласың соң?! Син бит сәүдәгәр, сатлык җан, уеңда бары тик акча гына, бар хыялың байлык турында! Менә алар, укымаган, надан бурлаклар, бу дөньяны сиңа караганда күбрәк беләләр, күбрәк аңлый!

Г а б д у л л а . Мин бурлакларның йөрәге ярылып үлә дип ишеттем... Бурлакларның йөрәкләре нигә шартлап ярылганын аңладым!.. Чөнки бурлаклар бу баржаны гына өстерәмиләр, аның белән бергә елганың үзен дә, Балык-Анасы Байгалны да, барлык корабларны, көймәләрне дә, башка бурлакларны да үз җилкәләрендә йөртәләр. Аларны гына түгел, бурлаклар алар бөтен елга ярларын, андагы шәһәрләре, авыллары, пристаньнары белән бергә күтәреп йөртәләр икән! Боларны гына да түгел әле: бурлаклар урманнарны, кырларны, тауларны, исән һәм үлгән кешеләрне йөртәләр. Бурлаклар бар дөньяны үз җилкәләрендә ташыйлар икән бит! Аларның йөрәкләре шуңарга, чыдамыйча, шартлый икән күкрәкләрендә...

Г а й ш ә . Син гел матур сөйли белдең, Габдулла әфәнде! Мин сиңа ышанмыйм!

Г а б д у л л а . Әнә тегендә, ярга карагыз әле!

Т у к с а н . Бу нинди кешеләр, Габдулла әфәнде?

Г а б д у л л а . Болар безнең бурлаклар!

Т у к с а н . Алар коточкыч күп икән!

Г а б д у л л а . Мин трактирлардан, урамнардан, кырлар-урманнардан барлык ирләрне, хатын-кызларны җыйдым! Безгә баржаны сөйрәргә кирәк! Аны Казанга алып кайтып җиткерергә!

*Яр буенда бер көтү б у р л а к л а р пәйда була. Алар шактый күп. Алар арасында ят йөзләр – таныш түгел ир-ат, хатын-кызлар бар. Шау-шу, кычкырыш. Бурлаклар элмәкләрне киеп-киеп карый. Ш а м и л ә яр буенда яткан тунны күреп ала, аны киеп карый.*

Ш а м и л ә . О, тун! Әле өр-яңа! Бу бит синеке түгел!

*Шамилә тунны иңнәренә сала, кылана. Көлеш, шау-шу.*

– Ике-өч көннән Казанга кайтып җитәбез!

– Түләсеннәр генә!

– Безгә берни түгел бу!

Т у к с а н . Мин нигәдер Буранны күрмим! Сез аны кайдадыр югалтып калдырдыгызмы?

Э ш п а й . Буран үлде! Үтерделәр аны! Ат караклары белән сугыша башлады! Менә шулар аны суйды да инде!

Т у к с а н . Бик кызганыч! Яхшы бурлак иде, башкисәр булса да!

П у я н . Ә Гаяз кайда? Шишкарьдан башка без ничек баржаны алып барырбыз?

Г а б д у л л а . Карагыз әле, әнә килә сезнең Гаязыгыз! Аңардан башка нәрсә эшләп булсын инде?!.

*Ярда Г а я з күренә. Гайшә аның каршысына йөгерә, кочаклап ала.*

Г а й ш ә . Гаяз, сөйгәнем минем! Син иректә, сине чыгарганнар!

Г а я з . Мин үзем дә белмим, кемдер минем өчен зур акчалар түләгән.

Г а й ш ә . Нәрсә диделәр ул жандармнар? Син чыннан да качкын каторжанмы, Гаяз?

Г а я з . Әйе, дөрес, Гайшә... Мин

ат урладым. Үзем өчен түгел, әтием өчен. Әти гел үзенең аты турында хыялланды. Ул бик ярлы иде, ат алырлык акчасы булмады. Гомере буе ат караучы булып эшләде, соңгы тиеннәрен санады. Әгәр әти үлеп китсә, хыялы чынга ашмый кала бит дип уйладым. Һәм ат урлаучыларга кушылып киттем... Сөргенгә сөрелүемне үзем дә сизми калдым. Аннары качтым. Аннары Әстерхан, Измаил бәй, ә калганын үзең дә беләсең... Казанда миңа ачылган җинаять эше ята.

*Бурлаклар сөенә, Гаязны кочып алалар.*

Т у к с а н . Кара, Гаяз, су ничек яхшы күтәрелде. Баржа йөзеп тора, юлга кузгалсак та була!

Г а я з . Юлга, туганнар! Без юлда булырга тиеш! Казанга кул сузымы кадәр генә калды! Кем баса румпельгә?

Т у к с а н . Үзем басам, Гаяз, мин күнеккән инде аңа!..

*Туксан һәм берничә бурлак палубага күтәрелә. Туксан румпельне төзәтә, Бурлаклар җилкәнне күтәрә. Калганнар элмәкләрен кия. Төркем башында Гаяз. Аның янында Гайшә. Аннары Шамилә, матур туннан. Габдулла да элмәк киеп кырыйга баса. Җыр яңгырый. Җилкәннәр җил белән тула. Канатлар тартыла. Баржа әкрен генә юлга кузгала.*

**Тугызынчы күренеш**

*Өч атна вакыт узган. Чын-чынлап кыш җиткән. «Монамах» баржасы бозга каткан килеш Казан каршында туктап калган. Баржа ак бәс белән капланган. Баржадагы трап бозга төшерелгән. Бөтен б у р л а к л а р баржа янында, бозда басып торалар. Г а б д у л л а да алар белән. Бу юлда аларның киемнәре бик тузган, искергән. Кешеләр үзләре дә арганнар, өшәнгәннәр, телләрен көчкә әйләндереп, әкрен генә сөйләшәләр. Салкыннан тешләре тешкә бәрелә. Бурлаклар көчкә атлап йөриләр.*

Г а я з *(салкыннан туңган, калтырый торган тавыш белән)*. Менә ул, туган калам Казан, кул сузымы гына... Без кайтып җитәбез... Бурлаклар! Юлга! Торыгыз! Күп калмады инде! Бераз гына барасы.. Туксан бабай, тот румпельне!

Т у к с а н . Бары берничә көн җитмәде, берничә көн...

Г а я з . Безне анда кешеләр көтә... Без ничек тә барып җитәргә тиешбез... Без бит бурлаклар!.. Гайшә, Ходайга ялвар, догаларыңны исеңә төшер!

Т у к с а н . Гел-гел могҗиза булып тормый инде, Гаяз... Хәтта Балык-Ана Байгал да булыша алмаячак безгә... Уң як ярга китәргә кирәк, югыйсә катып үләрбез...

Г а я з . Казан сул як ярда бит, Туксан бабай!

Т у к с а н . Сул якта боз бик юка, ә Казан каршында кары эреп ачылган җирләр... Анда бармыйбыз...

*О л а н боз өстеннән әкрен генә йөри, аяк астыннан нәрсәдер карый, күзәтә.*

О л а н . Анда боз астында зур балык... Бик зур балык, Туксан бабай…

Т у к с а н . Бу Байгал... Ул килгән... Димәк, әле уен бетмәгән... Нәрсәдер булырга тиеш...

*Боз өстеннән И з м а и л б ә й белән М ө с л и м килә.*

Измаил бәй. Йә, нәрсә, бурлаклар, оттырдыгыз бит бу уенны! Шулай түгелме, Габдулла әфәнде?! Син дә оттырдың, Гаяз!

Гаяз. Юк, Измаил бәй, уен әле тәмамланмаган…

Измаил бәй. Көлдермә инде мине, Гаяз! Баржа бозга катты! Нәрсә эшли аласың син хәзер?! Иделдәге бозны эретәсеңме? Хәтта Балык-Ана Байгал да булыша алмаячак сезгә хәзер!

Гаяз. Уен әле тәмамланмаган, товар Казанда булачак...

*Гаяз әкрен генә трап буйлап палубага күтәрелә, трюмны ача, аннан берничә капчык, мичкәне ала...*

Гаяз. Бурлаклар!.. Баржаны бушатыгыз!.. Товарны боз буйлап ташыйбыз!... Товар Казанда булырга тиеш!..

*Гаяз капчыкларны, мичкәләрне бозга бушата.*

Измаил бәй. Син юкка тырышасың, Гаяз! Тукта! Бу баржада бернинди товар да юк!

Габдулла. Ничек аңларга моны, Измаил бәй?! Ничек инде юк?! Нәрсә сөйрәп кайттык соң алайса без?!

Измаил бәй. Капчыкларда гадәти елга комы, мичкәләрдә балчык, тартмаларда – ташлар...

Габдулла. Нәрсә дигән сүз бу, Измаил бәй?!

*Гаяз ялгызы гына баржаны бушатуын дәвам итә. Габдулла пычак алып капчыкларны кисә, мичкәләрне һәм тартмаларны ача башлый. Анда чыннан да – ком, балчык, таш. Габдулла өметсезлектән, әрнүдән кычкыра. Берничә бурлак торып, Габдулла янына килә.*

Измаил бәй *(тыныч тавыш белән)*. Мин башта ук әйттем бит, Габдулла әфәнде, уен була, бары зур уен була, дип. Барлык товарлар да олаулар белән Иделнең сул ярыннан китте. Син оныттыңмы әллә, Габдулла әфәнде, мин бит ике ярда да яшим! Әстерхан – ул ике яр! Минем йөкләрем күптән Казанда инде. Казанны тергезер өчен Император миллион сум акча бүлеп бирде. Ул миллион минеке булачак! Шулай итеп, мин бу уенда җиңдем, Габдулла. Бу елганың хуҗасы мин!

Габдулла. Ә нәрсәгә кирәк булды бу ташлар, комнар?

Измаил бәй. Хәтерлисеңме, мин балачакта алтын тәңкәләр салынган чүлмәк янына беренче булып йөгереп баруым турында сөйләгән идем. Менә шул чүлмәккә мин беренче булып йөгереп барып җиттем! Үземнең авыру аякларым белән! Шул рәвешчә эти мине йөгерергә, сикерергә, агач башларына менәргә өйрәтте. Мин көчле, куәтле, курку белмәс кешегә әвереледем... Ә хәзер мин үзем кешеләр белән уйныйм. Ләкин мин сезгә изге эшләр эшлим! Мин сезне тере җанлы, азартлы кешеләргә әйләндерәм! Сез миңа рәхмәт әйтергә тиеш моның өчен!

Габдулла. Мин барысын да аңладым... Хәзер барысын да аңладым... Казанда янгын юкка гына булмаган.. Казанны яндырганнар...

Измаил бәй. Тормышта барысы да булырга мөмкин, Габдулла әфәнде.

*Габдулла кулына револьвер ала. Гаяз баржаны бушатуын дәвам итә.*

Измаил бәй. Син нәрсә, үтерергә җыенасыңмы әллә мине?!

Габдулла *(бурлакларга)*. Зинданга салыгыз үзен! Теге ярдан

жандарм чакыртырбыз! Тикшерсеннәр! Янгынны кем оештыруын тикшерсеннәр!

*Бурлаклар Измаил бәйне зинданга алып китеп ябалар.*

Г а й ш ә . Гаяз! Җитте, тукта! Син ишетмәдеңме әллә, капчыкларда бернинди иген дә юк! Без таш сөйрәгәнбез, ә икмәк түгел!

*Хәлсезләнгән Гаяз бозга ава. Габдулла Гайшә янына килә.*

Г а б д у л л а . Гайшә!.. Казанда синең фәхешханәң янып бетте. Син ирекле... Шәһәргә кайта аласың.

Г а й ш ә . Син минем өчен зур акчалар түләдең, Габдулла әфәнде. Акчаларың кызганыч түгелме?

Г а б д у л л а . Юк, Гайшә, акча кызганыч түгел. Ул зур уен иде. Сез бу бурлак белән минем күземне ачтыгыз... Хәзер миңа дөнья түгәрәк һәм төсле булып күренә. Моның өчен теләсә күпме түләргә дә риза. *(Гаязга)* Гаяз! Жандарм бинасы да янып бетте. Сиңа ачылган җинаять эшләре көлгә әйләнде. Сиңа куркырлык берни дә калмады...

Г а й ш ә . Хушыгыз, Габдулла әфәнде… Башка беркайчан да очрашмабыз дип өметләнәм...

*Җил улый. Бурлакларның муенындагы кыңгыраулар чыңлый. Гаяз әкрен генә тора да Гайшә янына килә, аны кочаклый, Алар икәү бергә Казанга таба китеп баралар.*

Т у к с а н . Китмә, Гаяз! Боз бик юка әле! Көт берничә көн! Тукта, Гаяз!

Г а я з . Мин өйгә кайтам… Хушыгыз, бурлаклар…

О л а н . Китмә, Гаяз абый! Китмә!..

*Гаяз белән Гайшә китә. Кинәт аларның аяк астында боз ярылып, алар икесе дә суга төшеп югалалар. Олан алар янына йөгермәкче була, Туксан карт аны көчкә тотып тора.*

О л а н *(кычкыра)*. Гаяз абый!.. Гаяз абый!..

**ЭПИЛОГ**

*Күк йөзен якты матур мираж каплап ала. Искиткеч матур утрау, җылы диңгез, аллы-гөлле чәчкәләр. Күк йөзендә ике аккош очып йөри.*


Г а й ш ә т а в ы ш ы . Гаяз, сөйгәнем, монда шул тиклем яхшы, рәхәт! Синең янымда мин бик бәхетлемен!

Г а я з т а в ы ш ы . Гайшә, монда килербез һәм һичшиксез бәхетле булырбыз дип әйткән идем бит мин сиңа!

Г а й ш ә т а в ы ш ы . Без хәзер гел бергә, мәңге бергә булырбыз, Гаяз!

Г а я з т а в ы ш ы . Беркайчан да аерылышмыйбыз, Гайшә! Килештекме?!

**Тәмам.**



Рафаил
Газизов

# ТУГАН ТЕЛЕМ – БОЛЫННАРЫҢ ТАҖЫ

## Язам

Җанның Кол Шәриф күк кылыч тотып,
Мәчет баскычына баскан чагы,
Курку дигән хиснең мине ташлап,
Дөнья аръягына качкан чагы.

Чөнки язам.
Гавам, Галәм, Вакыт
Күзен мөлдерәтеп карап тора.
Шигырьләрне яраларга ябам,
Канап торган халкым ярасына.

Мең-мең корбан биреп, азатлыкның
Гомерләрдән кыйммәт таңнарында,
Тәгәрәгән башлар бүкәннәрдән
Һәр яуланган шәһәр мәйданында.

Гыйбрәт алыр, куркыр, туктап калыр,
Кияр, диеп коллык камытларын, –
Өмет иткән дошман, ләкин белгән,
Мең кат белгән тагын ялгышканын.

Бүген бары зыялы юл белән
Белем алып, ныгып, казганып,
Көн-төн эшләп, мөстәкыйльлек яулау
Һәм яшәмәү сүзгә алданып.

Мең кат алдаганны күргәне бар,
Мең-меңнәрне корбан иткәне бар,

Рафаил ГАЗИЗОВ (1947) – *шагыйрь, прозаик; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни исемендәге әдәби премияләр лауреаты, Г.Х.Андерсен исемендәге Халыкара диплом иясе. «Җиләкле алан», «Бүләгем», «Ачык тәрәзәләр» һ.б. китаплар авторы. Мамадышта яши.*

Язмышына елан үргәне бар,
Биш гасырлык канлы үткәне бар.

Җанның Кол Шәриф күк кылыч тотып
Мәчет баскычына баскан чагы.
Язам. Куркуларның җанны ташлап,
Дөнья аръягына качкан чагы.

## Туган телем

Җирем матур кешеләре белән,
Чәчәкләре алар болынның.
Кеше яза көен
Яшәешне
Киләчәккә дәшкән җырының.

Кеше яза сүзен туган телдә,
Кадерле дә шуңа үз теле,
Туган тел ул һәрчак күңелеңдә
Тибеп тора
йөрәк шикелле.

Туган телдә һәркөн сөйләшәсең,
Туган телдә төшләр күрәсең,
Җанга рәхәт, тәнгә, каныңда да
Туган телең йөри, күрәсең.

Бишекләрне тирбәтүче тел ул,
Әни, диеп дәшкән сүзләрең,
Туган тел ул – дөнья гүзәллеген
Колачлаган газиз күзләрең.

Болын тулы чәчәк. Ул чәчәкләр
Туган телнең садә сүзләре,
Нинди гүзәл болын чәчәкләре,
Нәфис, күркәм, садә үзләре.

Туган телем – болыннарың таҗы,
Туган телем – хәят чишмәсе,
Халык гомеренең терек суы,
Киләчәкнең бәхет иртәсе.

## Йөрәк

Йөрәкләргә сызып үтте канат.
Яралы кош төште убылып.
Күкләр чатнады да җимерелде,
Җанны сагыш алды куырып.

Самолётлар сиңа егылып төшә,
Бата океанда йөзгән кораб,
Сиңа аксарга да, туктарга да
Ярамый шул, йөрәк, аңа карап.

Сине киллер мөшкесенә ала,
Караш – җәллад, караш – имансыз.
Яраласалар да, атсалар да,
Син эшләргә тиеш бер ялсыз.

Ятим бала белән тулы илләр,
Толлар белән тулы фатирлар,
Тормыш төбендәге җаннар белән
Тулган подвал, җимерек катерлар.

Сиңа гына сыеп бетми алар,
Син җылытыр идең барсын да,
Чөнки синең хисап тотасың бар
Намус, вөҗдан, Аллаһ каршында.

Шуңа, йөрәккәем, яшәвең дә
Бөек, батырлыкка бәрабәр.
Чөнки игелегең, изгелегең
Соң талпынып тибүгә кадәр.

## Әни

Тегү машинасы келтер-келтер –
Әни чалбар тегә энемә,
Ул машина чишмә кебек җырлап
Сөендергән иде мине дә.

Җиделе лампа балкытамы өйне,
Әллә әни үзе нур чәчә,
Өйләр якты була, көн шикелле,
Шул машина нидер сөйләсә.

Күлмәкләр дә, фәрештәләр кулы
Тигән кебек, тегелгән иде,
Бездән бигрәк газиз әниебез
Иксез-чиксез сөенгән иде.

Нинди генә кием текмәде лә,
Инәсенә саплап гомерне,
Яңа күлмәк белән өебездән
Ятимлекләр себереп түгелде.

Меридиан, параллельләр сызып,
Киемнәрнең йөгерек җөенә,
Син Җир шарын яшәткәнсең, әни,
Планетаны нәни өеңдә.

Йә, келтерәт әле машинаңны,
Алып керим, сөртеп тузанын,
Сөйләп бирсен Зингер машинасы
Гомеркәйнең ничек узганын.

Ул сөйләсен, гасыр сыйган аңа,
Машинага сыйган Җир шары,
Ә син, Әни – Галәм Әниседер,
Ул машина гына нибары...

## Мизгел

Мизгелләрнең ялын эләктердем,
Ите белән купты еллары,
Шул мизгелләр инде гомеремнең
Каннар аша туган таңнары.

Мизгелләрнең ялын эләктердем,
Сыртларында минем йөрәктер,
Мизгелләрне иярләгән кеше
Бер гасырга берәү кирәктер.

Мизгелләрнең ялын эләктердем,
Куш аяклап типте мизгелләр,
Дага кадаклары кадаклаудан
Теткәләнеп бетте күңелләр.

Дөньяның бар күгәреге белән
Чәрдәкләнгән чакта хисләрем,
Туган якның бөек мизгелләрен –
Умырзаяларын иснәдем.

Мизгелләрнең ялын эләктердем,
Мизгел – тәүге язгы күкрәүдер,
Яшәүләрем – кызлар иркәләнеп
Шашкан чакта туган тетрәүдер.

Шул мизгелләр хуҗа тормышыма,
Яшәүләрем – мизгел ялында,
Атлантидаларны терелтерлек,
Помпейларның көлен эретерлек,
Бар дөньяны Хаҗга йөретерлек
Мизгел чәбәләнә җанымда.

## Атлар

Йомшак ирен белән уч төпләрен
Иркәләве истә атларның,
Алар китте, калды йөгән элгән
Боҗралары гына капканың.

Колын чапкан болын – гүзәл әкият,
Тояк тиеп чыңлый чәчәкләр,
Кирмән тауларының түбәләре
Чәчәкләрдән тезгән чәкчәкләр!

Авыр чакта, хәсрәт сарган чакта
Акрын гына килеп яныңа,
Йә әле, дип, мин дә бар әле, дип,
Күмеп мәрхәмәтле ялына

Басып тора иде янәшәдә,
Күзләрендә аңлау, акыл бар,
Синең йөрәгеңә сабырлыкны
Сыза торган зирәк такыл бар.


Бергә терелдек без, кайгыларны,
Шатлыкларны бергә кичердек,
Без атларга инеш суы түгел,
Гомеребез сутын эчердек.

Исәпләнде тормыш атлар белән,
Ни эшләгән, кая барылган,
Без тууга авыл чирәменә
Тәгәрәдек атлар ялыннан.

Атлар кереп бара офыкларга,
Яши алар хәзер хәтердә,
Шигырь булып кешни, чаба, дулый,
Тыпырчына, юырта бәгырьдә.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Кәрим
Кара

# БИЕК БӘХЕТ ТАУЛАРЫ

ПОВЕСТЬ

Эссе июль аеның бер төнендә йоклый алмый газапланып, киң караватында бәргәләнгән Рәзиләнең башына көтелмәгән сәер уй килде: «Хәйбүшне кайтып күрергә кирәк!» Болай да иләс-миләс кенә яткан хатынның йокысы сыпырып алгандай юкка чыкты. Үз уйлары үзенә кызык булып китте, көлемсерәп, үз кичерешләренә хәйран калып ята бирде. Хәйбүш кем, имеш, хәзер аның өчен: искән җил, язгы сулар булып аккан былтыр яуган кар, күптән онытылган адәм. Кайчандыр ир кисәге булган икән, ди, йә шуннан, үпкән-кочкан – җилгә очкан, диләрме әле? Хәйбүш, Хәйбулла, кайдан искә килеп төште соң әле ул? Исемен дә телгә аласы килми. Хәйбулла... Каян тапканнар диген андый котсыз, борынгы исемне. «Хәйбулла, Хәйбулла, койрык таксаң ат була», – дип, гел ирештерерләр иде үзен, күзен дә ачырмыйлар иде мәктәптә укыган елларда. Хәер, әле дә шул Хәйбүш булып кала бирәдер, тамчы да үзгәрмәгәндер... Рәзиләнең күз алдына бакыр чәчле, йөзен сипкел баскан, колгадай озын ирнең кыяфәте килеп басты. Ә кайчандыр Рәзилә шуның белән гаилә корырга маташкан булды бит әле, хәтта бала тапты. Ул каршы стена буендагы диванда мыш-мыш килеп йоклап яткан кызына күз төшереп алды. Юк, Хәйбүшнеке түгел ул, Рәзиләнеке генә, тик үзенеке генә. Аллага шөкер, тузан бөртеге кадәр дә йокмаган кызына килделе-киттеле теге җөмәйдән.

И язмыш, ничек кенә уйнамый кеше гомерләре белән. Рәзиләгә тиң егет идемени инде Хәйбүш? Чарасыздан ризалашты ул, артыннан күләгә сыман калмый тагылып йөргән, ике сүзне бергә кушып әйтергә батырлыгы җитмәгән, күзләрен мөлдерәтеп караудан узмаган шул егет кисәгенә.

Рәзилә абыйсында үсте. Әниләре, мәрхүмә, тол хатын «балаларым, балаларым», дип өзгәләнеп, хәленнән килмәстәй йөкләргә дә җигелеп, дөнья йөген сөйрәргә талпынды, талпынды да кырык яше тулар-тулмастан, йөгереп йөргән җиреннән кабергә кереп ятты, мескенкәй. Алай да тырышып-тырмашып, балаларын аякка бастырып өлгергән иде, бер Рәзилә

---

Кәрим КАРА (1956) – *прозаик; «Без әнкәйнең йөрәгеннән чыктык», «Җиләкле алан» исемле китаплар авторы. Яшел Үзәндә яши.*

генә балалыктан чыкмый кала дип, зар елады соңгы көннәрендә. Марат абыйсына: «Ризалыгымны аласың килсә, кеше ит сеңелкәшеңне, кыз бала бит ул, назлы җан. Сез, егетләр, ничек тә көн күрерсез, эшләрсез дә ашарсыз, ә кыз кешегә әти-әнисез бигрәк авыр, тәрәк бул сеңлеңә. Мин аннан сезне карап кына ятармын, әгәр дә рәнҗетсәң, риза-бәхил түгелмен», – дип, күзләре йомылганчы ялынды. Марат абыйсы нәрсә, үз абыйсы бит, «Рәзиләкәй, сеңелкәш», – дип кенә торды да соң, мәгәр җиңгәсе торганы бер аждаһа иде инде, аңа тиң башка дөньяда юктыр. Икейөзлелегә хәттин ашкан иде үзенең, абыйсы булганда ал да гөл, гел елмая, чөкердәп сөйләшеп кенә тора, эчеңә-бавырыңа кереп бара. Абыйсы өйдә генә торамыни, гел эштә, иртә китә, кич кайта, берни сизми дә, белми дә. Ул юкта утлар чәчә инде җиңгәсе, ни эшләсәң, шуны килештерми, нәрсә әйтсәң – ул ярамый, бетмәс-төкәнмәс йомышларын өеп кенә тора: абзардагы маллар да Рәзиләнең җилкәсендә, өй дә чиста булсын, балаларын бак... Кырык төрле мәшәкать тапты, ат урынына җикте үсмер кыз баланы. Тешләрен кысып түзде Рәзилә, абыйсына әләкләшеп йөрмәде.

Шуңа да мәктәпне тәмамлау белән бу тәмугтан котылу ягын карады. Әллә нинди югары уку йортлары турында хыялланмады, күршедә урнашкан шәһәрчектәге техникумга барып керде. Әллә күпме профессияләргә өйрәттеләр аны, бухгалтер да, секретарь-машинистка, фермер да, имеш, анда укыганнар. Ике ел шунда белем эстәгәннән соң, диплом алып, авылга кайтты. Барып, баш төртер урыны юк, җиңгә кешенең отыры шайтаны котырган чагы, укыганы бушка – эш буласы юк.

Бар дөньясы дөбердәп җимерелеп барган еллар, һәркемнең үз кайгысы – кайгы. Ни дисәң дә, яшьлек бит әле ул, каннар кайнаган чак, күңел мәхәббәт хакында хыяллана, киләчәк матур-матур төсләргә манчылып күзаллана. Рәзилә булган кадәре киенеп-ясанып, клубка йөри, яшьтәшләре белән шаяра-көлә, капка төбендә егетләр белән торгалый. Аерып кына, күңел кылларын чиерткәне юк арада, шул Хәйбулла йөри инде тагылып, кая барса, аңа тап була. Тегене мыскыллап, төрлечә сүзләр сөйләп, көлә-көлә хәлләре бетә Рәзиләнең ахирәтләре белән. Күңел ачалар шулай, тегесе ник күтәрелеп, каршы бер сүз әйтсен? Сокланып карый да ката, әйтерсең, фәрештә аның каршында.

Ә Рәзилә һич тә фәрештәләр затыннан түгел иде. Соңгы елларда җиңгәсенә бирешеп тормады ул, үз-үзен якларга өйрәнде, теге бер сүз әйтсә, унны җавап кайтарды, шактый чарланды. Җиңгәсе дә арага ирен кертмәде, акылы җитте, бетмәс-төкәнмәс көрәш ике арада гына барды. Тагы бер ягы бар иде җиңгәсенең: авыл хатыннарына Рәзиләне хурлапмы хурлады, әллә нинди уйдырмалар сөйләп бетерде. Әнә шунысы бигрәк тә җен ачуларын чыгара иде инде кызның. Бер көнне ахирәтләре аңа җиңгәсенең тагын бер гайбәтен җиткерделәр.

– Безнекенең бигрәк килеш-килбәте юк инде. Шуңа бер егет тә карамый үзенә. Килеп күренәләр дә якыннанрак белгәч югалалар. Карт кыз булып утырып калыр инде, гомер кияү тапмас, – дип, бар авылга чәчкән, имеш, яраткан җиңгәсе. Абыйсы өйдә юк чакны туры китереп иплән кенә сөйләшеп карарга булды Рәзилә. Аңлый торган кешемени, күтәрелеп-бәрелергә тотынды, әйтмәгән сүзе калмады җиңгәсенең.

– Дөресен әйттем! Дөресе шул: торганы белән ирдәүкәсең, гомер ирсез утырырсың. Турысын әйткән туганына ярамаган, ди, йөрәгеңне яндырамыни дөреслек? – дип чатнап торды җиңгәсе.

– Теләсәм, иртәгәдән кияүгә чыгам, миңа күз салганнарның чуты юк, – дип әйтте дә салды кыз үзе дә сизмәстән. Җиңгәсенә шул җитә калды. Авызларын кыйшатып көлгән булды:

– Уф, үтерә, кайдан килгән сиңа кияү? Сантый егетләр дә юк шикелле безнең авылда, әнә, теге гомер өйләнә алмый, авыл урамнарын киләп-сарып йөргән гарип Нурмый соратса гына инде, – дип мыскыллаган булды.

Әллә нәрсә булды Рәзилә белән, башы буталды, мин-минлеге шашынды, үз-үзен тыя алмастай халәткә килеп ярсыды. Кичне чак көтеп алды ул. Музыка уйный башлагач, яшьләр, әкренләп, клубка җыелдылар, Хәйбулла да күренде. Арадан бер кыз, гадәттәгечә, көлкегә борып, егеткә нindидер сүз кушкан иде, Рәзилә кырт кисте:

– Нәрсә бәйләндегез әле шуңа? Ул кемнән ким?

Ахирәтләре шым булдылар, аларга гына баш булырга булдыра Рәзилә. Шунда ук ул Хәйбуллага таба атлады.

– Нәрсә кызлардан качып, читтә генә торасың? Әйдә әле бер урамны әйләник, сиңа әйтә торган сүзләрем бар минем, – дип, тегене култыклап ук алды. Шатлыктан сулуы капкан егет, бер агарды, бер кызарды, чәч төпләренә кадәр тирләп чыкты, шулай да үзендә атлап китәргә көч тапты.

Сөйләшми-эндәшми, киң урам буйлап атладылар. Каршы очраганнар бу уты чыгып торган кыз белән чандыр гәүдәсе иелеп төшкән егетнең парлап атлауларына гаҗәпләнеп карап узды. Авызын яба белмәгән Рәзилә дә тынып калган иде. Ничегрәк сүз башларга да, ничегрәк куркытмый гына ышандырырга үз сүзләренә бу мокытны, дип баш вата иде кыз. Шулай авыл читенә үк чыгып киттеләр алар. Кешеләр ишетмәслек ара китүләренә инанганнан соң, Рәзилә туктады да Хәйбуллага таба борылып басты, нәзек бармакларын егетнең иңнәренә салды, күзләренә туп-туры карап:

– Хәйбулла, мин сиңа ошыйммы? – дип сораган булды иркә-назлы тавыш белән. Әлбәттә, егет нәрсәдер дип җавап бирер хәлдә түгел иде. Иңбашына кагылган кулларның кайнарлыгы аның табаннарына кадәр төшкән иде, бәрхеттәй тавыштан мие томаланды, авыз эче кипте, теле аңкавына ябышты. Атабыз, дисәләр дә, телен әйләндереп нәрсәдер әйтә алмас иде ул бу мизгелдә. Адәм ышанмас хәл бит, төн йокыларыннан мәхрүм иткән кыз үзе – Рәзилә аның белән авыл урамыннан парлап үтте, менә әле сихри карашлары белән аны арбый, куллары белән кагыла. Йа Хода, өнме бу, төшме?

Егетнең кичерешләрен якынча чамалый иде Рәзилә. Ошата ул Рәзиләне, нәрсә аны сорап торырга? Җавап та көтәсе түгел әле, югалып калгандыр. Бераз һушына килсен. Ышандырырлык итеп сөйләргә кирәк, Рәзиләнең һәр әйткән сүзенә ризалашып кына торырлык хәлгә килсен.

– Хәйбуллакаем, беләсеңме нәрсә әйтәсем килә минем сиңа? Мин сиңа кияүгә чыгарга риза. Син өйләнер идеңме миңа?

– Мин... син... миңа... алдашасың... – дип, телгә килде егет, кипшенгән иреннәрен ялап.

– Юләркәй, нишләп алдашыйм, ди? Кияүгә чыгу хакында шулай шаярып

сөйләшмиләр инде. Гомергә бер була бит ул, – дип, һаман үзенекен тукыды Рәзилә.

– Ничек инде, мин синең янында кем? Ә син әнә нинди чибәр, акыллы, сөйкемле... Юктыр, юк... – дип хәйран калды егет. Ышанырлыкмыни, карап туймаслык кыз үзе башлап, аңа өйләнешү хакында сөйли, җавап көтә әле...

– Менә инде, ник алай үзеңне башкалардан түбән куясың әле? Син кемнән ким? Бер дигән егетсең, мин сиңа ышанып, мине үз итәр, саклар, яклар, гөрләтеп, дөнья күтәрбез дип ризалык бирәм дә... – дип, тәмам үзе дә ышанып, сандугач булып сайрады Рәзилә.

– Рәзилә! Мин синең өчен утка да... үзең беләсең бит инде, күптәннән яратам мин сине. Тик син булганга көннәр якты миңа, синең хактагы уйлар иң ләззәтлесе...

– Тик бер шартым бар, Хәйбуллакаем, шуңа риза булсаң гына мин синеке, – дип, шартларын саный башлады кыз.

– Шарт?.. Анысы нәрсә тагы? Нинди шарт икән ул, – дип, тәмам төшенкелеккә бирелде егет. Мәңге шулай бу тормышта: бәхет кошы килеп кунды дип шатланырга өлгерми дә каласың, оча да китә. Чираттагы шаяртуы гына булган инде бу тиктормас кызның. Ахирәтләренә шулай кызык иттем дип сөйләргә генә кәмит куйгандыр.

– Иртәгә үк язылышабыз, никах укытабыз! Шуңа риза булсаң, башкарып чыга алсаң, мин риза!

Мизгел эчендә мең төрле уй үтте егетнең башыннан. Иртәгә үк? Ул менә шушы минутта, төн уртасында никах укытырга теләр иде дә соң, әти-әнисе ничек карар моңа? Әллә күпме чыгымнар чыгачак, шактый гына акча кирәк булачак, каян табарга? Аның бит әле өстенә кияргә рәтле-башлы костюмы да юк, ә иртәгә үк өстәл түрендә кияү булып утырасы кеше. Тегесен-монысын алырга район үзәген урамый булмас, ярты көн вакытың шунда узачак, ә кем никах укыр? Белер-белмәс әбиләрдән укытып булмас бит инде, ышанычлы, укыган ир заты кирәк. Кемнәрне чакырырга өстәл янына, ә Рәзиләнең абыйлары ризалашырлармы, ничек карарлар?

– Иртәгә икән, иртәгә. Син ничек телисең – шулай булыр, – дигәнен үзе дә сизми калды ул уйларына уралып.

– Хәйбуллакаем, җаным, – дип, кыз тыпырдап алды, аяк очларына басып, чия иреннәре белән егетне чуп-чуп үпте, кочагына сыенды. Монысы артыграк иде, кәнишне, чак аягында басып кала алды егет. Үз гомерендә беренче тапкыр кызлар иреннәренең тәмен, кызлар тәненең исерткеч назын тойды ул, һәм кем иде әле кызы да!..

Алдагы көн үтә мәшәкатьле булды. Рәзилә елап, үпкәләп, тиргәшеп, алдаштырып, иркәләнеп, кырык фигыльгә кереп, абыйларын үзенең яшь кәләш икәнлегенә ышандырды. Хәйбулла турында сөйләп торасы да түгел. Бер көн эчендә суырылып, кара янып чыкса чыкты, көтү кайтканда, аларның зур якларында күршеләрдән җыештырылган өстәлләр буйлатып сый-нигъмәтләрдән сыгылып торган бай табын әзерләнгән иде, ә түрдә, көзге астында, яңа костюмда үзен уңайсыз сизеп, яшь кияү Хәйбулла, аның янында балкып, минут саен уң якта урнашкан җиңгәсенә «күрденме?» дигән җиңүле карашлар ташлаган яшь кәләш Рәзилә утыра иде.

Гомумән, кичә күңелле үтте, кунаклар яшьләргә бәхет тели-тели

ашадылар-эчтеләр, җырладылар-биеделәр, никахны да ышанычлы, күрше авылның белемле олпат гәүдәле мулласы укыды. Рәзилә үз сүзен сүз итте; җиңгәсе телсез калган иде. Яшьләр авылда озак тормадылар, район үзәгенә барып урнаштылар. Хәйбуллага эш тиз табылды, алтын куллы эретеп ябыштыручыны урындагы автосервиска алдылар. Вакытлыча яшәп тору өчен торак та бүлделәр. Кайчандыр тегү мастерское булган ике катлы таш бинаның зур гына бер бүлмәсе буш тора икән. Бүлмәдә юынгычтан башка бернәрсә дә юк иде дә соң, баш өстендә кыек булгач ярап калды.

Рәзилә борынын югары тотып, элекке укыганы буенча берәр бүлмәдә язгалап-сызгалап утырырга эш эзләп караган иде дә, барып чыкмады, бер эшкуарның шәхси кибетенә сатучы булып урнашты. Көн артыннан көн үтте, шыксыз бүлмәләренә бер төрле ямь керде кебек, урын-җирләре булды, хәленнән килгәнчә бизәде Рәзилә үз куышларын. Бер-берсенә берегеп киткән төсле булдылар, Хәйбуллага икенче төрле, үзенеке итеп карый башлады яшь киләш. Ә Хәйбулла турында әйтәсе дә юк: атлап түгел, очып кына йөрде. Рәзиләсенең авызына гына карап торды, акчаны да шактый гына кайтара иде. Рәзиләнең теләге буенча, тәмәкесен ташлады, эчеп ямьсезләнгәне булмады.

Бары бер тапкыр исерек килеш күрде ирен Рәзилә. Сәбәбе дә юк кына кебек иде. Яшь киләш беренче төннән үк авырга калды. Моны белгәч тә, Хәйбулла түшәмгә сикерде, сөйгәнен өрмәгән җиргә утыртмады, кулына бер эш тидерми башлады. Кемдер шулай шатланды, ә Рәзилә үзе, мәсәлән, уйга калды. Нәрсә эшләргә? Алдагы тормыш ничек булачагы томанга төренгән төсле, билгесез, яхшы якка бер үзгәрешләр дә көтелми. Алган акчалары тамактан, кием-салымнан артмый. Гомер бакый шул таш капчыктан башлары чыкмас микәнни? Картайганчы көннәр буена прилавка артында торырга язганмы? Ир дигән булып, гаилә көтәм дип яшәү шундый була микәнни ул? Бала башка бәла генә булмасмы? Төрлечә уйлады да Рәзилә, ашыкмаска булып, абортка барды.

Дөньядагы ике хатын-кызның берсе аның аша үткән, телгә алып сөйләрлек нәрсәсе бар инде, ә менә сүз арасында Хәйбуллага бу хакта әйткән иде, таш булып катты теге. Башын иеп, сүзсез-нисез генә алдындагы чәен чөмерде дә, борын астыннан нәрсәдер мыгырдап чыгып китте. Соң гына, күрше-тирәләр йоклап беткәч, алпан-тилпән басып исереп кайтып керде. Йа Хода, кеше үзгәрсә үзгәрә икән, озын буена карагач кына төсмерләде Рәзилә Хәйбулла икәнен: йөзе көл сипкән төсле булган, сипкелләре дә югалган төсле, күзләре зур булып ачылганнар, муендагы төере туктамый аска-өскә йөгереп кенә тора. Керде дә бу киеме-ние белән урын өстенә лап итеп барып утырды. Гомер булмаганны, күмер булып кабынып китте Рәзилә. Җилтерәтеп, тегене ишек төбендәге ләгәнгә сөйрәде. Ачуын алды да соң, туйганчы тиргәде, аның тавышыннан күрше бүлмәләрдә утлары кабаттан кабынды. Ник бер сүз эндәшсен адәм актыгы, чөңкәеп утырды да шул ишек төбендә, нәүмизләнеп, Рәзиләгә карап катты, мөлдерәп күз яшьләре коела үзенең күзләреннән. Битләре буйлап агып төшәләр дә буып куйган шарфына сеңеп югала торалар. Холкы сәер икән дә бу ир кисәгенең, ныграк эчсә елый торган гадәте бар икән. Аның көен көйләп тормады яшь хатын,

туйганчы, эче бушап калганчы тиргәде дә тиргәде тегене, утны сүндереп, рәхәтләнеп ятып йоклады.

Икенче көнне берни булмагандай, Хәйбулла торып, чәй кайнатып эчте дә эшенә китте, Рәзилә дә башкача ул турыда сүз кузгатмады. Хәйбулла һаман хатынын әллә кем итеп күрде, ә менә Рәзилә тыштан сиздермәсә дә, уйлары белән бөтенләй башка дөньяда яши иде. Нәрсә әйтсәләр әйтсеннәр, Рәзиләгә тиң тормыш түгел иде бу. Рәзилә үзе яхшы, матур, күңелле тормышка лаек. Ә нигә? Чибәрлеге бар, акыл өлкәсендә читтә калмаган, кешеләр белән сөйләшергә маһир, кирәк булса сатып җибәрер, үҗәтлеге дә җитәрлек. Нәрсә эшләп ята соң әле ул монда, нәрсә бәйләп тота аны? Кайда киноларда күрсәткән, китапларда язылган өзелеп сөюләр, күңел җилкендергән вакыйгалар, күңелгә якын, күп акча ала торган эш, матур-матур киемнәр, урап чыккысыз фатир? Санап чыкканнар барысы да бар бит ул әйләнә-тирә дөньяда, яшиләр бит әнә кешеләр. Монда кул кушырып утыра торган булсаң үтәр-китәр гомер. Һәр кеше үз бәхетен үзе яуларга, көрәшергә тиеш. Әллә Хәйбулланы шәһәргә тартып караргамы? «Анда икенче мөмкинлекләр. Шул тартмада гомеребез үтәрме, әйдә, башкалага барып урнашабыз, сине кушкуллап каршы алачаклар, мин дә юньлерәк эш табармын. Бәлки, фатир да юнәтербез, анда бөтенләй икенче тормыш», – дип игәли башлады ул ирен форсат чыккан саен. Беренче тапкыр Хәйбулласы аның сүзләрен күтәреп алмады. «Монда яңа өй салабыз, – дип, үзенекен каерды. – Менә җәйгә бераз акча туплап, авылда бурасын бурыйбыз да көзгә алып килеп күтәрәбез. Калган өлешен әкренләп үзем эшләп чыгам. Әллә кайларга барып, бәхет эзлисе түгел. Әти-әни дә картайганнар инде минем, ничек аларны ташлап китәсең?..»

Язлар җиткәч, кар сулары гөрләвекләр булып акканда, Рәзиләнең күңеле бигрәк иләсләнде. Алда нindидер икенче тормыш көтә икән аны дип, үз-үзен ышандырды ул. Гөлт итеп торган шәһәр утлары, матур киенгән кешеләр, урап чыккысыз кибетләр, выжт-выжт чапкан чит ил машиналары, кулларына чәчкәләр тоткан нәзакәтле ир-атлар күз алдыннан китмәде. Өйдә тәмам холыксызланды, ашарга пешерсә пешерде, пешермәсә – юк. Юк йомышны бар итеп, гел урам киләпләде, ире белән аерым йоклый башлады. Ялкыткан иде аны бу ир кисәге, гомер бәхет күрәчәге юк аның белән. Менә хәзер тимерне кызуында сугып, үзгәртсә үзгәртеп кала язмышын, икеләнеп калса, мәңгегә мүкләнеп утырачак шушында.

Көннәрдән бер көнне ныклы карарга килеп, ул эштән яңа кайтып кергән Хәйбуллага ярып салды:

– Без башка бергә яши алмыйбыз, мин синнән аерылам!..

Тезләнепләр ялынып карады Хәйбулласы, шәһәргә китәргә дә риза булып бетте, ләкин Рәзиләнең хыялындагы шәһәрдә иренә урын каралмаган иде. Үз сүзен сүз итәргә гадәтләнгән Рәзилә эшне кызу тотты. Авылдан абыйлары килеп үгетләделәр, каената белән каенана: «Тормышта төрлечә була, түз бераз, җайланыр барысы да», – дип нәсихәтләп карадылар, очраган таныш-белеш, ахирәтләр тел шартлаттылар. Нык торды киребеткән Рәзилә, гел бер сүзне кабатлады: «Без холыкларыбыз белән туры килмибез, иң яхшысы – аерылышу».

Тәвәккәлләгән – таш ярыр, диләрме әле? Шомыртлар ак чәчкәләргә

күмелеп утырганда, яшь хатын ике кулына ике юл сумкасы тотып, шәһәргә бара торган автобуска кереп утырды. Күңеле җырлый иде аның. Тәки теләгенә ирешүте бит, әнә нинди гүзәл үзгәрешләр көтә аны алда!

Әлбәттә, болар барысы кысыр шатлыклар иде. Кочак җәеп каршы алган кеше булмады аны. Башта чыбык очы бер туганнарына барып, башын төртте. Ике бүлмәле фатирда ул гаилә үзе дә очын-очка ялгап гомер кичерә иде. Үсмер уллары беренче минуттан ук Рәзиләне күралмады, кайда барып утырса, йөзен җыерды, ни эшкә алынса да, «дерёвня» дип, авыз кутәреп көлә торган булды. Гаилә башлыгы эчәргә һәвәс булып чыкты. Һәр салмыш көнендә икенче бүлмәдә хатынын битәрләде: «Нәрсә эшләп бездә җан асрый бу килмешәк? Мин аның тамагын туйдырыр өчен бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр көч түгәмме? Әйт яхшылап, башка урын тапсын. Түземлегем бетсә, арт шәрифләренә тибеп, баскычтан очырам мин аны, күр дә тор».

Ара ишекне ябып әрепләшсәләр дә, барысын да ишетеп, җаны өзгәләнә иде Рәзиләнең. Анысы бер булса, тагын бер кайгысы бар иде әле: шәһәргә китмәстән алда үзенең авырга узганын сизгән иде. «Ярар инде, баргач төшертермен әле. Анда больницалар адым саен», – дип, җиңел генә уйлап килгән иде. Серен хуҗабикәгә чиште, теге кулларын җәеп җибәрде. Бушлайга хәзер төшермиләр дә, шәһәрдә пропискасы юк, аны нинди больница кабул итәр, бердәнбер юл – түләп. Андый акчалар Рәзиләдә юк иде. Көннәр буена эш эзләде яшь хатын, яшәр урын эзләде. «Әллә кире кайтып китимме икән?» – дигән уй да килгәләде башына бик авыр чакларда. Хәйбулласы берсүзсез кабул итәр иде, анысына ышана, башкаларның йөзенә ничек күренерсең, ояты ни тора.

Тешләрен кысып, күз яшьләре белән юынып, үҗәтләнеп, үз юлыннан атлады ул. Бар икән Аллаһы Тәгалә, көтмәгәндә, яшәр урын-җир дә, эшләргә эшен дә тапты ул. Ул урын ташландык яшь балаларны карый торган приют иде. Монда әлеккән ятимнәрне аякланганчы, бераз тернәкләндереп, интернатка озатканчы шулай карыйлар икән. Мөлаем гына йөзле татар баш табиб Рәзиләгә балалар палаталары янындагы ике метрлык әйберләр кую бүлмәсендә яшәргә рөхсәт итте. «Карават, тумбочка куярбыз, балаларга да һәрчак күз-колак булырсың, кирәк чакта башка санитарларны алыштырырсың, тамагың да балалар белән бергә булыр. Хезмәт хакы тиеннәр генә инде, анысына, бигайбә. Калсаң, иртәгәдән эшкә», – дип, яшәү тәртибен аңлатты. Риза булмыймы соң инде Рәзилә, шундый оҗмахтай урынга! Эштән курыкмый ул, җимертеп эшләр, вакытлыча гына бит барысы да. Эшли башласа, башка мөмкинлекләр эзләр, эзләгән табар, диләр.

Канатланып, яңа урынга күченде ул, җиң сызганып, эшкә алынды. Эш җитәрлек булып чыкты: яңа туганнарыннан алып өч яшькә кадәр булган балалар белән ике палата шыплап тулган иде. Шуларның асларын алыштырып, тамакларын туйдырып, елаганнарын юатып, уйнаганнарын уйнатып, кичкә кадәр җеп өзәрлек тә хәле калмый иде Рәзиләнең. Йокларга яткач та әле тавыш бирсәләр сикереп тора, дежур санитарларга булыша.

Әнә шулай көн-төн чабып, үз кайгысын күз уңыннан ычкындырган булып чыкты. Бераз ипкә килгәч, эш хакы алып, больницага барды. «Соңга калгансың, күгәрченкәем, телисеңме, теләмисеңме, табарга туры килер.

Анализларың яхшы, яшь чакта табып кал. Уңышлар сиңа», – дип, өметен өзделәр. Нәрсә булып бетәрен азагына кадәр уйламастан, тагын эшкә чумды, аны тагын балалар тавышы басты.

Бердәнбер көнне баш табиб аның түгәрәкләнгән гәүдәсенә карап, гаҗәпкә калды.

– Монысы нинди яңалык тагын? Кайчан табарга тиешсең? Син әле гинекологта исәптә дә тормыйсыңмы? Немедленно күренергә, декретный отпуск оформить итәргә! Ул нинди хәл, эш урынында балалап ятарга уйлыйсыңмы? – дип, пыр туздЫ. Рәзиләнең коты очты, урамга куалап чыгарып җибәрсәләр, бу хәлдә кая барыр ул?

Хатын хуҗасының аягына егылды, күз яшьләренә төелеп, барыр җире юклыгын әйтте, үз бүлмәсендә калдыруларын үтенде. Ярый әле баш табиб сирәк очрый торган изге күңелле затлардан иде, аны аңлады, калырга рөхсәт итте, әмма бүгеннән үк белгечкә күренергә кушты. Кош тоткандай шатланды Рәзилә, баласын күтәреп кайтыр куышы булачак аның, урамда калмас.

Бу сөйләшүләрдән соң әллә ай үттеме, Рәзилә авырлыгы өч килодан артык, калын тавышлы, елак кыз тапты. Дежурдан буш булган таныш санитар хатыннар аны таксида больницадан приютка күчереп куйдылар. Декрет вакыты, әле ярамый, дип тормады әни кеше, бераз хәл алгач та, үз баласын, ятимнәр арасына кушып, тагын эшкә тотынды. Башкалар әйтеп-әйтеп карадылар да кул селтәделәр. Өч ел гомерләре үтте әни белән баланың шушы зар йортында. Өч ел яшь гомерен сарыф итте шушында. Ләкин тик ятмады, һаман өметенә омтылды, бер тапкыр аның өчен генә күк капусы ачылачагына ышана иде ул.

Шәһәр җирендә иң авырткан җир, әлбәттә, торак мәсьәләсе. Үзеңнең фатирың булса – син кеше. Алда эшне үзгәртергә, шәхси тормышны кайгыртырга йөзләгән мөмкинлекләр ачыла. Ничек тә фатирлы булырга бар көчен салды Рәзилә. Фәрештәгә тиң баш табиб җәлли иде яшь хатынны, һәм ул мөмкинлекләреннән файдаланып, ничек тә аңа яшәр урын табарга тырышты. Төрле түрәләр каршында бу сорауны күтәреп чыкты, югарыда утырганнарга рәсми хатлар аша мөрәҗәгать итте, депутат буларак, вәкаләтләреннән файдаланды. Баш табибның да, Рәзиләнең дә тырышлыклары бушка китмәде, өч ел дигәндә Рәзиләгә гаиләлеләр тулай торагыннан фатир бирделәр. Бу авыр заманнарда бушлай фатир ала алуына бергә эшләгән ахирәтләре ышанмый аптырадылар, бот чаптылар. Ничә елга беренче тапкыр үзен чын-чынлап бәхетле итеп сизде Рәзилә. Менә бу буяу исләре аңкытып торган зур тәрәзәле иркен фатир аныкы бит, аның мөлкәте. Менә ачкычлары кулында, менә ордер. Ә ничек якты, иркен, тын алулары җиңеләеп китә хәтта. Аерым кухня, аерым туалет, ванна, кечкенә булса да коридоры да бар. Ә зур бүлмәсен иңләп аяклар арый. Менә монда ул диван алып куяр, бу ягында чит илнең стенкасы торыр, идәндә буеннан-буена зур келәм, люстра – бәллүрдән, почмакта зур телевизор. О, монда әллә ниләр тутырырга була әле! Мондый шатлыкларны, бары үзе яңа фатир алып караган кеше генә аңлый аладыр...

Ике-өч айдан ничә еллар җелекне суырган тәмуг казаныннан Рәзилә бөтенләйгә китте. Яңа эше кеше көнләшерлек иде: нефть-газ чыгару идарәсе баш инженерының секретаре. Анысыннан башка тагы ике-өч вазифа тактылар

әле яшь белгечкә, эш хакын да юмарт билгеләделәр, оешма бай иде. Ел үткәндә, Рәзилә танымаслык булып үзгәрде; өстенә соңгы модага ияреп тегелгән киемнәр (бу эшкә күчкәч тә ул ширпотребны бик өнәми башлаган иде), килешле прическа, күзләрендә наянлык. Үз-үзенең хакын белү чаткылары ялтырый, атлап китүләре подиумда йөргән кызларныкыннан һич ким түгел. Кем әйтер бу хатын кайчандыр авылда тирес каерып үскән дип?

Үз-үзен карады Рәзилә, аэробика белән дә шөгыльләнде, көзге алды бизәнү-төзәнү әйберләре белән тулды, диетага утырды. Хәзер инде шәхси тормышны җайга салу, үз тиңен табу аның тормыш мәгънәсенә әйләнде. Беренче ирешкәннәрен ул алдагы көннәргә трамплин дип кенә фараз йөртте.

Башта хатын планканы бик югарыдан куйды. Булачак хәләл җефетен укыган, карьера ясаган, иномарка руле артында утырган, акчаны исәпләми тоткан, Рәзилә өчен үләргә әзер торган, артистлар кебек чибәр, мәһабәт гәүдәле ир-ат итеп күз алдына китерде. Шундый затның үзен назлауларын тоеп, төшләрендә саташып уянды. Эш урынында һәр үткән-сүткән ир-атны үзенең хыяллары белән чагыштырды. Очрады андыйлар, бер караудан баш әйләнерлекләре белән дә танышкалады Рәзилә, үз җәтмәсенә эләктерергә омтылышлар ясап карады. Игътибарлы, зыялы, белемле, ихтирамлы, Рәзиләнең корбаны булырга тиешле кандидат, аңа сокланып, гомер ишетмәгән комплиментлар яудырды, чәчәкләр бүләк итте, рестораннарга чакырды. Авыл мокытлары төсле тупас кыланмады, бер-ике күрешүгә чишендерергә талпынмады, киресенчә, үзенең тиңе итеп күрде, фикерләре белән уртаклашты, тыңлап, түзеп утырырлык булмаган ниндидер симфоник концертларга, ничә карасаң да, аңлаешлы рәсем тапмаслык модернистик күргәзмәләргә йөртте. Кыйммәтле презентлар ташыды, мәхәббәттә аңлашты. Инде бу минеке, дип тәмам ышанып, Рәзилә аның белән бергә төннәр үткәрде, тәмле пешеренеп, эштән соң кунакка килгәнен көтте.

Ни гаҗәп, аралашулар шуннан ары узмады, өйләнү турында сүз бөтенләй чыкмады. Гаҗиз калган Рәзилә үзе башлап, сүз кузгатып карады. Син миңа ошыйсың, үзең дә миңа сөю сүзләре сөйлисең, бер-беребезне җитәрлек дәрәҗәдә белдек тә шикелле, нигә безгә бергә яшәмәскә, гаилә кормаска? Мин, мәсәлән, риза дигәнрәк кармаклар салып карады Рәзилә. «Өйләнү» сүзеннән куркып, «кандидат» эзсез югалмады, очрашулар дәвам итте, әмма дә ләкин ул өзелеп яратса да, Рәзиләгә бүгеннән өйләнә алмый икән. Ник дисәң, әле аның гаиләсе бар: хатыны, баласы, ничә еллар туплаган малы... Хатынының әтисе белән бер оешмада эшли, аның кул астында. Бер-бер хәл була калса, иртәгәдән аны урыныннан очыралар, шундыйрак шактый ышандырырлык сәбәпләр табылды. Шулай да Рәзиләне өзелеп ярата икән, күрми-очрашмый тора алмый, гел аның хакында уйлый. Иң яхшысы – араларны өзмик, ә бәлки, кайчандыр, малай үскәч, үзе ныклап аякка баскач, бабай тиешле кеше пенсиягә киткәч, кавышырлар да алар, әлбәттә, кавышырлар... Артына егылып китә язды Рәзилә андый аңлашулардан, булачак кавышулардан. Өстәл тулы сый-нигъмәтләрдән дә авыз иттермичә, пыр туздырып куалап чыгарды бәдбәхетне.

Сөяркә булып кына яшәргә аның планнарында юк иде. Инде акыллырак булырмын, кемнең кем икәнен аңлап, сак кыланырмын дип сүз бирсә дә, тегеңә охшашлар белән тагын берничә тапкыр авызын пешерде әле ул. Ләкин

алдына алганын куя торган хатынмы соң Рәзилә? Отыры чаяланып кырык төрле юллар аша үз тиңен эзләде ул. Ахирәтләренең таныш ир-атларын күзләде, игъланнар бирде, күңел ачу урыннарына ауга йөрде, танышу клубларын айкады. Бер ир белән берничә ай бергә яшәп карады. Миша урыс иде, анысы киртә булмады, кем әйтмешли, «үгез булмагае, чурт булсын, балаларга сөт булсын», дигәндәй, яхшы кеше икән, нинди милләттән булуы мөһим түгел.

Очраштыргалап, бер-берсен күзәтеп йөргәндә, Миша тыныч, басынкы кеше булып күренде, начар гадәтләре юк, эчми-тартмый. Рәзиләне чын-чынлап ошата булса кирәк. Машинасы юк-югын, яшь бара, машиналыны эзләп, карт карчыкка әйләнүең дә бар. Тәвәккәлләде хатын, бар шартын җиренә җиткереп, тагын бер кат кияүгә чыкты. Өрфия ак туй күлмәге киде, ахирәтләренә баш аша кулындагы чәчәкләр гөлләмәсен ыргытты. Янәсе, инде мин эзләгәнемне таптым, кайсыгызга чират?

Мишаның өч бүлмәле фатиры бар иде, анысы да уңай тәэсир иткән иде хатынга. Кызым үсеп килә, үзенең аерым бүлмәсе булыр, иркендә яшәрбез дип фараз йөрткән иде. Мишаның туйларында гына беренче кабат күренеп калган, комы коелып беткән әнисе яңа җиргә яшьләргә ияреп килде. «Это наша фамильная квартира, твой отец, земля ему пухом, потом и кровью достал ее. Мне недолго осталось, последние дни хочу проводить здесь», – дип шәрран ярды тешләре коелып беткән кыямәт карачкысы. Басынкы холыклы Миша: «Әлбәттә, әни, әлбәттә, бу өйдә иң кадерле кеше син булырсың», – дип шатланып, ризалыгын белдерде.

«Бәхетеңне сыер сөзсә, көтү көткән акчаңны да ала алмассың», диләрме әле? Үзе баш, үзе түш булып өйрәнгән Рәзилә карчык белән сыеша алмады. Тазалыгы чамалы булса да, зәһәре җитәрлек калган икән әле теге кортканың. Юк кына нәрсәдән һәркөн өйдә тавыш купты, мескен Миша ике арада яраргa тырышып бәргәләнде. Рәзилә күзаллаган бәхетле гаилә тормышы түгел иде инде бу. Чираттагы даулашулардан соң ул, әйберләрен төяп, кызын җитәкләп, үз фатирына кайтып китте. Ярый сатып өлгермәгән иде, мәгәр, клиентлар эзли башлаган иде бит инде, урамда торып каласылар икән. Миша мин дә калмыйм, сезнең белән барам, дип кызган иде дә, тиз тынычландырды Рәзилә. Бәләкәй генә бүлмәдә өрлектәй ирне карап ятарга башына тай типкәнме әллә аның?

Әллә Хәйбулланың рәнҗүләре каты булганмы, үз тиңен таба алмый җәфаланды Рәзилә. Үзенең язмышына бераз күнегә дә төшкән иде инде. Ярый әле кызы бар, янда тере җан, икәүләшеп тә, бик матур яшәп яталар әле. Миланасы укуга сәләтле булып чыкты (Рәзилә шәһәрчә яңгырасын дип, кызына шундый исем куштырган иде), гел «дүрт» тә «биш» төяп кайтты мәктәптән, менә шатлык әни кешегә. Энәдән-җептән киендерде газизен Рәзилә, өстәп, әле музыка мәктәбендә укытты. Үз җаена тәгәрәде шулай гомер йомгагы.

Һәм көтмәгәндә, менә бу хыялый уй башына килүе аны әсәрләндереп җибәрде. Хәйбулла ничек яшәп ята икән анда? Ниемә кирәге бар, ялгап торган җепләр күптәннән шартлап өзелгәннәр, күпме вакыт үткән, сулар аккан.

Ләкин бу уйлар аңа икенче көнне дә чат ябыштылар, тынычлык бирмәделәр.

Чынлап та, ничек яшәп яткан була икән беренче «мәхәббәт»? Өй салганмы икән, әллә авылларына кире кайтып киткәнме? Өйләнгәнме, хатыны нindirәк, Рәзилә белән чагыштырырлыкмы? Балалары бардыр, бәлки, үзенең тагын бер кызы үсеп килгәнен белми дә бит әле ул мүкләк. Күрсә, нәрсә эшләгән булыр иде икән? Авылдагы авыр тормыш изә кешене, картайгандыр, мөгаен, чәчләре чаларгандыр. Ә менә Рәзилә, Аллага шөкер, һаман кызларга биргесез әле. Бигрәк юньсез, җөмәй иде шул Хәйбулласы, артыннан эзләп килеп, Рәзиләне тапкан булса, әллә бөтенләй башка юллардан китәр иде язмышлары. Алай начар яшәмәделәр бит алар, бер-берсенә берегеп киткәннәр кебек иде, яшь чак бит, сөйгән-сөелгән дә булганнардыр. Икесе арасында гына булган искә алырлык, күңелне кузгатырлык вакыйгалар бар иде ул, бар...

Шулай хәтер сандыгын актарып, төшкә тиклем йөрде дә Рәзилә, өйләдән соң хуҗасына гариза тотып керде. «Киләсе атна башыннан ике көнгә отгул бирегез, кисәк кенә кайтып килергә кирәк иде, хәбәр алдым», – дип, үз гозерен әйтте. Күптәннән бергә эшләгән хуҗа берсүзсез ризалыгын бирде, хәерле юл теләп озатып калды. Гомер булмаганны, ашкынып, өенә кайтты Рәзилә, каяндыр килеп эләккән җыр кисәген көйләп, шыплап тутырылган кием шкафын актарырга тотынды. Ни гаҗәп, күңеле күтәрелгән иде аның, гел елмаясы, сөйләшәсе килеп кенә тора иде. Соң гына кайтып кергән Миланасы да әнисендә ниндидер үзгәрешләр булганын сиземләп алды, нечкә куллары белән әнисенең муенына килеп сарылды.

– Кайда җыенасың, ма? Берәрсе кунакка чакырдымы әллә? Матур күлмәкләреңне таратып салгансың...

– Барам инде, барам. Сер әлегә. Әйт әле, кызым, кайсы ныграк килешә миңа?

– Барысы да килешә, син үзең матур. Менә бу зәңгәре миңа бигрәк тә ошый. Йә әйт инде, зинһар, кая барасың?

– Чистый сагыз булдың. Ярар, әйтсәм әйтим инде. Үземнең дә тел кычытып кына тора. Беренчедән, мин үзем генә түгел, синең белән икәүләп барабыз, икенчедән, бер тапкыр да булганың юк синең анда. Авылга, абыйларың янына кайтып киләбез.

– Авылга? Абыйларга... Минем аларны бөтенләй күргәнем дә юк шул, минем кебек балалары бармы аларның? Ә кайчан?

– Иртәгә барып билет алып куярбыз. Йә ярар, бар, утырып аша, өстеңне алыштыр. Аннан соң синең дә киемнәрне карарбыз...

Кызы риза булып, кухняга атлады, ә Рәзилә кулындагы күлмәген тоткан килеш тынып калды. Әйтмәсәң дә, бала үз туганнары турында берни дә белми бит, ә Рәзилә үзе беләме соң? Ничек чыгып китте, шул килеш югалды. Баштарак мескен булып күренәсе килмәде алар каршында, соңыннан гаилә коргач парлап кайтырбыз дип уйлады. Кызын җитәкләп, ялгыз башы кайтып керсә, җиңгәсенең авыз кыйшайтып: «Ә кияү тиешле кеше, кызыңның әтисе кайда соң?» – дип соравыннан курыкты. Көн артыннан көн үтте, унике ел үтеп киткән. Башка да сыярлык түгел. Йә ярар, үткәннәргә үкенеп утырасы түгел, менә кайтырга җыена бит, соң булса да, уң булсын. Кемнеңдер кырын карашлары да куркытмый инде аны, ул хәзер икенче Рәзилә, керфеге дә селкенмәс.

Дулкынланып, юлга җыенып, кич үтте. Нәрсәләр алыйм, ничек

киеним, дип, кырык фигыльгә керде ул. Күргәннәр-таныганнар белеп торсыннар, алар каршына үз тормышыннан канәгать, бәхетле яшәгән ханым килә. Көнләшеп карап калсыннар, онытa алмый, соңыннан да ешеш телгә алсыннар. Нәрсә уйлаптыр, алмаш киемнәр дә аласы итте Рәзилә, белмәссең, ике-өч көнгә тукталырга туры килер...

Ял көне дә мәшәкатьле булды, әниле-кызлы кичкә кадәр шәһәр урамнарын айкадылар. Автовокзалга барып, автобуска билет алып куйдылар, супермаркетка кереп, туганнарына бүләкләр сайладылар. Рәзилә матурлык салонына кереп, яңа прическа, педикюр, маникюр ясатты. Мәш килделәр. Көч-хәл белән кайтып егылгач, тамакларына ашадылар да яту ягын карадылар. Арулары да җиткән, автобус та авыл тарафына бик иртә кузгала иде.

Иртән Милананың йокысы туймаган иде, салонга кереп утыргач та, әнисенең иңбашына башын терәп, йоклап та китте. Рәзилә тәрәзәдән күзләрен алмыйча таныш кырларны күзәтте. Бигрәк тә үзсүзле шул ул, юк сәбәпләрне бар итеп, ничә еллар кайтмый йөргән булды, туганнарны шулай онытырга ярыймы соң инде?..

Күршедә утырган киң гәүдәле, чәчен кыска гына итеп алдырган, яхшы киенгән бер ир-ат гел аңа карап килгәнен чамалап алды Рәзилә. Ирләрнең игътибары, соклanулары бөтен хатын-кызның да күңеленә май булып ята. Кирәксә-кирәкмәсә чәчләрен төзәткәләде ул, уч хәтле көзгесен алып, битен-йөзен сыйпады, иреннәренең иннеген яңартты. Күршесенең тәмам түземлеге төкәнде, ничек тә бу чибәр хатынны үзенә җәлеп итәргә кыбырсыды. Ниһаять, батырланып китеп, вакыт сораган булды, кайларга барасыз, дип кызыксынды. Рәзилә авыз йомып утырмады, сүз артыннан сүз ялгана торды. Исеме Мансур икән, инженер, Шпицберген утравына йөреп эшли, имеш, безнекеләрнең ташкүмер чыгару шахталары бар икән анда, эш хакы ярыйсы, долларлар белән түлиләр. Вахтасына өч йөз меңгә җитеп ала. Бу зур акчалар турында ишеткәч, Рәзиләнең колаклары торды, тигез, матур тешләрен ялтыратып, иргә сынап карап алды. Алай ярыйсы гына күренә, Рәзиләдән чак кына олырак булыр, әмма нык, төптән таза, йөзгә дә сөйкемле генә.

Автобус шофёры пассажирларга капкалап алырга, йомышларын үтәргә юл читендәге кафе буена туктатканда, бөтенләй үз күреп, Рәзиләнең артыннан бер тотам калмый ияреп йөрде яңа танышы. Хатынның тормышы хакында сорашты. Шәһәрдә яшәгәннәрен белгәч, бөтенләй балкып китте. Үзе хакында да сөйләп алды. Ә мин бит сезгә күрше урамда гына яшим, диде, яңа, зур фатир сатып алган идем, гараж янәшәдә генә, чит ил внедорожнигы минем, «Хаммер». Менә чак эштән кайткан идем, ямь тапмыйм ялгызыма. Авылга энекәшләргә китеп барышым. Машинага да утырып йөрисем килми, автобуста, ичмасам, кешеләр арасында. Анысына хәзер сөенеп бушый алмыйм, сезне очратмаган булыр идем, дип теленә салынды.

– Ә нигә ялгыз, тормыш иптәшегез, балаларыгыз бардыр бит бу яшькә җиткәч? – дип кызыксынды Рәзилә. Аучы дәрте кузгалган иде анда.

– Эш шунда шул: гаиләм юк минем. Әлегә кадәр өйләнгәнем булмады. Яшермим, булды танышлар, берсе белән дә артык якынаеп китмәдек. Язмышмы, ялгышмы, дигәндәй. Ошаганы очрамагандыр, күрәсең. Ә менә сез бөтенләй икенче, күктән төшкән фәрештәгә тиң... Ничә еллар күрше

урамнарда яшәп, бер тапкыр да очрашмаганбыз икән, жәл миңа хәзер төшеп калырга. Ә сез кайчан кире кайтасыз? Бәлки, шәһәрдә очрашырбыз, аралашырбыз. Телефон номерыгызны бирегез әле миңа, бәлки, өй адресын да яшермәссез. Без инде бала-чага түгел, мин чын күңелдән... – дип ялынып, адресын язып алды да, әйберләрен алып төшеп тә калды. Озак кул болгап торды әле ул автобус артыннан. Милана кызыксынып куйды:

– Ул нинди күп сөйли торган абый булды соң? Синнән күзләрен аерып ала алмый. Безнең шәһәрдә яшим, диме? Әллә безгә кунакка килергә булды инде?

– Күршеңдә утырган кеше белән юлда сөйләшәсең инде ул. Күп булыр андыйлар, – дип көлде дә куйды Рәзилә. Шулай да эченнән генә, туры килә калса, аралашып карарга уйлап куйды.

Аларга да барып җитәргә күп калмаган иде. Юлга алган бутербродларын ашап, минералка эчәргә өлгерделәр, автобус район үзәгенә якынлашты. Этенә-төртенә таралышкан кешеләр арасында кызы белән басып калды Рәзилә. Гаҗәпләнеп, таныш та, ят та булган җирләргә күз йөгертте. Кайда булган урамга егылырга торган ике катлы агач өйләр, агач тротуарлар, ерып чыккысыз җыелып яткан сулар? Бөтен җирдә асфальт түшәлгән, чәчәк клумбалары, агачлар, ак кирпечтән зур универмаг, почта, банк тезелеп киткәннәр, юл аша сырлап эшләнгән биек манаралы мәчет төзеп куйганнар, велосипедлар да күренми урамда, тыз-быз кыйммәтле машиналар чаба, кешеләр дә яхшы киенгән. Үзгәргән район үзәге, үзгәргән, кечкенә шәһәрчеккә әйләнгән. Кызы түземсезләнеп, аптырап басып торган әнисенең җиңеннән тарткалады:

– Кая барабыз, ма? Кайда яшиләр абыйлар?

Чынлап та, кая барырга, ничек эзләп табарга ул йөзек кашына тиң Хәйбулланы? Әллә бар, әллә юк Хәйбулла? Рәзилә эшләгән кибет кайсы тирәдәрәк икән? Бергә эшләгән ахирәтләреннән берәрсе булса да калгандыр бит. Алар белә дә белә инде Хәйбулланың кайда яшәгәнен, мондый җирдә барысы бер-берсен беләләр, хәбәрдар булалар.

Тирә-ягына каранып, Рәзилә кызы белән элекке эш урынының кайдалыгын чамаларга тырышты, урам буйлап өскәрәк үттеләр. Әлбәттә, аларның кибете урынында юк иде, анда кемдер ике катлы коттедж төзеп куйган, арырак базар мәйданы икән. Башы эшләде Рәзиләнең, кире килеп, ул универмагның пыяла ишекләрен ачып керде, яшь кенә бер кыздан сорыйсы итте.

– Сеңлем, миңа бер сатучы кирәк иде, Индира исемле, минем белән яшьтәш хатын. Зират буендагы урамда яши торган иде.

– Индира апамы? Ул бит хәзер сатучылыктан китте, әнә юл аша пенсионный фондта утыра, бухгалтер шикелле. Зират буе урамында яши, әгәр дә шуның хакында сорашсагыз...

Эзләп тапты Рәзилә, өстәл артында кәгазьләргә күмелеп утырган, тулыланып киткән ахирәте алдына килеп басты.

– Сезгә кем кирәк? Ни йомыш? – диде теге, танымыйча, кырыс кына.

– Индира дигән кыз кирәк иде миңа. Яле, ипләбрәк кара, кем мин? – диде Рәзилә, наянланып.

– Абау, үләм, – дип, авызын каплап карап катты ахирәте һәм кинәт сикереп торды. – Рәзилә, чукынчык, син бит бу!

Ике ахирәт көлә-елый, бер-берсен кочакладылар. Ашыгып-кабаланып, хәл-әхвәл сорашырга тотындылар, ышана алмый кабат-кабат караштылар.

– Әйкәем, гомер танымас идем яныңнан узып китсәм. Вәт шәһәр нишләтә кешене, кино артисткаларына охшап торасың, ахирәткәем, кыеп карарлык түгел. Бу синең кызыңмы, әтисен кая калдырдыгыз? Кунакка, авылга, абыйларгамы? – дип туктамый сөйләде ахирәте. Шул арада аның аркасыннан сөйде, киемнәрен чеметкәләп карады. Милананы үзенә тартып алып, киң күкрәгенә кысарга өлгерде.

– Әйе, кунакка кайтуыбыз. Ә син бер дә үзгәрмәгәнсең, йөзең дә шул килеш, тик бераз ит кунган, – дип алдашты Рәзилә, ахирәтенең шәлперәйгән гәүдәсенә карап.

– И, үзгәрмәгән кая, әбигә әйләндем инде, ирдән уңмадым, ахирәткәем, бик пырдымсыз, холыксыз бер нәрсә, эчеп алса бөтенләй кешелеген югалта, тавыш-гауга, тиргәш-талаш. Балалар чирләшеп беттеләр, кечкенәсендә йөрәк чире, диләр. Сөйләсәң күп инде, үзеңнең хәлләрең ничек соң, нигә бер кайтып та әйләнмисең? Әллә бик еракка киттеңме? Эшлисеңме, гаиләң бармы, иптәшең кая соң, нигә парлашып кайтмадыгыз? – дип, хатын-кызларга хас кызыксыну белән тезде генә сорауларны ахирәте. Сүзне озайтмады Рәзилә, нигә һәркем алдында йөрәгеңне ачып салырга?

– Кызым белән генә кайтырга уйладым шул. Беләсеңме, Индира, мин сине ник эзләп таптым? Хәйбулла хакында берәр нәрсә белмисеңме, мондамы икән ул?

– Менә сиңа, мич башыннан төшкәч, здрастуй. Нигә кирәк булды әле ул сиңа? Үзең чыгып качтың да...

– Кирәк инде. Бер кәгазьгә култамгасын куйдырырга иде, – дип, куык очырды Рәзилә, үзе уңайсызланып китте, бит очларына алсулык йөгерде.

– Сирәкләп очраткалыйм мин аны, бер-беребезгә баш кагып үтәбез, ә тукталып сөйләшеп торганыбыз юк. Өйләнде ул, соңлап кына, яңа өй салды шикелле. Бер-ике ел элек район гәзитләрендә фотосын да бастырып чыгарганнар иде, яхшы эшли дип мактап, һаман элекке эшендә, ахрысы. Тукта әле, менә икенче катта эшләгән бер хатын шул тирәдә яши, ул беләдер. Мин очып кына менеп төшим әле, ә сез урнашыгыз, хәл алыгыз, мин хәзер, – дип чыгып югалды. Озак та үтмәде кулына бер кәгазь кисәге тотып килеп керде.

– Менә, улица Победы, 16. Минем чамалавым буенча шактый ерак кына.

Кәгазьне кулына алгач та, Рәзилә китәргә җыена башлады.

– Кара әле, Рәзиләкәем, күргән кебек тә булмадым, эш вакыты туры килде. Иркенләп очрашасы иде бит, үткәннәрне искә алып, бер гөрләшеп-сөйләшеп утырыр идек. Кил безгә дә, монда сугылсаң, эштән сорап та китәм инде мин. Ут алырга кергән кебек кенә булды бит... – дип өтәләнде ахирәте.

– Керермен, керермен, булабыз әле без монда, йә, ярар, рәхмәт сиңа, күрешербез әле, – дип, чыгу ягын карады хатын.

Сумкаларын күтәреп, алар юл читенә чыгып бастылар, үткән-сүткән машиналарның берсен туктатып, кәгазьне суздылар.

– Була ул, – диде яшь кенә егет, бар тешләрен күрсәтеп елмаеп. – Бер йөзлекне җәлләмәсәгез, апа, җил уйнатып алып барып куям.

– Риза, – диде Рәзилә, авыр сумкаларын күтәреп тәпиләп йөрмәсләр бит инде.

Машина зәңгәр төсле сайдинг белән тышланган өй янына килеп туктады. Егеткә акча түләп төшкәч тә, Рәзилә нишләптер югалып калды. Әллә кермәскәме, кире борылып китәргәме? Хатыны ничек кабул итәр, кем дип таныштырыр үзен? Хәйбулланың беренче хатыны икәнен белгәч, уклау алып куалап чыгарса, оятыңнан җир тишегенә керердәй булырсың. Хәйбулла өйдә була калса, аңа нәрсә дип әйтер, ник килгәнен ничек аңлатыр? Менә искә төшеп киттең дә, түзәр әмәл калмады, бер күрәсе килде үзеңне, диярме? Милана хакында әйтергәме, юкмы? Йә, ярар, нәрсә диләр әле, «войнa план покажет», диләрме? Килгәч керергә инде, нәрсә сөйләргә сүз табылыр әле, күз күрер. Карар да Хәйбуллага, чыгар да китәр, кояш баеганчы үз авылына кайтып җитә ала әле ул, бик тә булмаса, әлеге кебек берәр частникны яллар.

Тәвәккәлләп, Рәзилә тимер торба баганалар утыртып эшләнгән капкага табан атлады. Аларны ишек төбенә чыгып ук каршы алдылар. Тулы гәүдәле, сөйкемле генә бер хатын чәчәкләргә уралган кирпеч сукмак аша каршы атлады.

– Әйдүк, үтегез, тәрәзә аша карыйм,ниндидер таныш түгел кешеләр капка төбендә таптаналар. Алып керим дип чыгып килүем иде. Эттән дә куркалар безнең. – Ул, борылып, өргән эткә кычкырып куйды. – Нельзя, Полкан, кер ояңа...

Өчәүләп, өйгә үттеләр.

– Кем дип әйтергә дә белмим. Әйдә узыгыз, утырыгыз әле. Безнең як кешеләренә охшамагансыз, ерактан киләсездер, сумкаларыгыз да зур күренә. Көне эссе бүген, тамагыгыз кипкәндер, хәзер чәй куеп җибәрәм, әйдә теге бүлмәгә үтегез әле, – дип йөгереп торды хуҗабикә. Стенага эленгән көзге каршында, бит-башларын, киемнәрен рәткә китереп, зур бүлмәгә үттеләр, әниле-кызлы йомшак диванга барып утырдылар.

– Мин Хәйбулланың авылдашы. Менә юл төшкәндә күреп чыгыйк дигән идем, – дип әйтергә кирәк тапты Рәзилә, үзе кызыксынып, өй эчен күзәтте. Өй җиһазлары матур, килешле генә күренде, стенка, келәмнәр, идән буйлап сузылып яткан зур палас, компьютер, музыкаль үзәк, зур телевизор, тәрәзәләрдә шау чәчкәле шторалар, барысы да бар, кырыйда ишек – йокы бүлмәседер...

– Тамагыгыз да ачкандыр, йомырка булса да кыздырып алыйм әле, кыяр турыйм, хәзер аш та пешеп чыга да соң, – дип, үзенекен сөйләп, ике арада керә-чыга йөрде хуҗабикә. – Кыяр күп быел, җиләк-җимеш тә, авылга кайткач җыеп рәхәтләнерсез әле. Мин үзем Арчадан, укытырга җибәргәннәр иде. Хәйбулла белән танышып киттем дә төпләнеп калдым шунда. Ир кайда, хатын – шунда инде ул. Ә шулай да сезнең авылга еш кайтып йөргәч, мин барысын да беләм. Сез кемнәрнең туганнары буласыз соң?

Ике ут арасында калды Рәзилә. Сүзне ерактан, уратып-уратып башлаган булды.

– Мин күптәннән чыгып киткән идем инде авылдан. Үзем дә танымыймдыр хәзерге яшьләрне. Ә Хәйбулланың әти-әнисе исәннәрме соң? – дип, сүзне икенчегә борды.

– Исәннәр, рәхмәт төшкерләре, теттереп, дөнья көтәләр. Һаман мал карыйлар, кош-корт тоталар, бара калсак, төяп кайтаралар. Әллә

туганнарымы Хәйбуллаларның, кызыгыз... – дип тагын сораша башлаган иде дә тәрәзәгә күз төшерде, ахрысы. – Әнә үзе кайтып та килә. Малайларны да кереп алган, миңа эш калдырмаган, – дип хәбәр салды. Рәзилә нишләргә белми, югалып калды. Ул арада аяк тавышлары ишетелде.

– Кунаклар бар, – дип, яңалык хәбәр итте керүчеләргә хуҗабикә.

Узышмактан йөгерешеп, дүрт-биш яшьләрдәге ике малай чабып керделәр, бер читтә туктап, Рәзиләләргә карап тора башладылар. Ишек чаршавы чыжылдады, йөрәге ярсып типкән Рәзилә күтәрелеп карарга батырчылык итте. Аның каршында киң бәдәнле, мыек үстереп җибәргән, каратут йөзле Хәйбулла басып тора иде. Гаепле елмаеп, Рәзилә урыныннан кузгалды. Бөтенләй ят ир аның каршында, җирдә нык басып торган, үз-үзенең бәясен белгән, алдагы көннәргә ышанычлы караган, тормышның тәмен белгән- тойган, очраган каршылыкларны җиңә алган кешегә охшаган иде бу ир. Кая киткән ул белгән Хәйбулла?

– Рәзилә?... – дип аптырап карады ир. Кара син аны, тавышы да үзгәреп, калынаеп, чын ирләрчә булып киткән. – Рәзилә... Нинди җилләр ташлады? Суга баткан таш төсле юкка чыккан идең дә син...

Кызыксынып, хуҗабикә ишектән башын сузды.

– Таныш бул Наилә, бу минем беренче хатыным Рәзилә...

– Шулаймыни-и? – дип, бөтенләй бүлмәгә үк кереп басты теге. – Тагын бер кат исәнмесез. Әйтәм мин аны, кызының күзләре нәкъ синеке, үз-үзен тотышлары да сиңа охшап тора. Туганнарыдыр дигән шик кергән иде. Кан ничек тарта... Коеп куйган кебек...

– Нинди кыз? – дип дертләп китте Хәйбулла. – Ә, монда кыз да бармыни әле? – дип, дәү кулларын сузды. – Исәнме, исемең ничек?

– Милана.

– Юк, юк, – дип кызара-бүртенеп тавышын күтәрде Рәзилә ике арага кереп. – Нинди охшашлык? Ул минем кызым, аның әтисе бар. Кайдан башыгызга килә андый уйдырмалар... Гомумән, без монда очраклы гына, автобуска кадәр вакыт бар, күреп чыгыйк әле дигән идем. Борчыган булсак, гафу итәрсез. Без кузгалабыз инде, вакыт та бара...

– Ничек инде алай, бер чынаяк чәй дә эчмичә... – дип югалып калды хуҗабикә.

– Тынычлан, Рәзилә, беркем бер сүз әйтми. Чәй эчәбез әле, аннан машина белән үзем төшереп куярмын. Вакыт та бар әле, шәһәргә соңгысы ничәдә китә? – дип, хатынына таба борылды ул.

– Шәһәргә түгел, авылга шикелле... – дип икеләнеп калды хатыны.

– Юк, юк, шәһәргә, без авылда булдык инде, бетереп әйтмәдем генә мин... – дип, кире сөйләде Рәзилә.

– Ә шулай да чәй эчәбез әле, кул югыч теге якта. Кайда, әнисе, әзерме анда синең?

Карышып торуны кирәк тапмады Рәзилә, өстәл артына барып утырды. Шактый күңелсез табын булды ул.

– Ә мин сине теге чакта күпме эзләдем, – дип, үткәннәрне искә алды Хәйбулла. – Башкалада бер-ике ай яшәп-эшләп тә булаштым әле! Эштән буш арада урам буйлыйм, кибетләрне айкыйм. Син бит сатучы булып эшләп киткән идең, бәлки, тагын шул эшенә урнашкандыр, дим... Өметләр өзелгәч

кайтып киттем. Йә, ничек яшисең, Рәзилә, тормышыңнан канәгатьсеңме, эзли торгач очрадыңмы бәхет тауларына?

– Очрадым, таптым, – дип, кыска гына җаваплар бирде, ризыкка кагылмыйча, буш чәй чөмереп утырган Рәзилә. – Яхшы яшим, барысы әйбәт...

– Кызың да үсеп җиткән икән инде, – дип, Миланадан күзен алмады Хәйбулла. – Әтисе кем соң? Ничек укыйсың, Милана?

– Яхшы укый, әтисе дә яхшы кеше, – дип, чак тыелып утырды Рәзилә.

Ниһаять, бу мең газапка тиң чәй эчүләр тәмамланды. Рәзилә чыгарга ашыкты, кызын кабаландырды. Хәйбулла сүзсез генә алар артыннан иярде. Машинага кереп утыргач, Хәйбулла, кызын кочаклап, почмакка сеңгән Рәзиләгә карап, авыр сулап алды.

– Их Рәзиләкәй, оныта башлагач, тагын кузгаттың иске яраларны. Бүгенге тормышымнан да ризамын алай. Наиләгә сүз юк, ярарга тырыша, әнә нинди бөркеттәй малайларым үсеп килә. Дөньям җитеш, эштә кадерне беләләр. Ну да ләкин... Эх-х... Мин яраттым бит сине, Рәзилә. Балта чаптың сөю тамырларына, әле дә әрниләр, сызлыйлар. Язмыштыр, күрәсең...

Рәзилә эндәшмәде, кайчандыр кочагында иркәләнгән ирнең киң җилкәсен карап, иреннәрен канатканчы тешләп барды. Күз яшьләренә ирек бирүдән курыкты. Мескен булып күренәсе килми иде аның. Вокзалга җиткәч тә, сүз ялганмады. Ярый автобус озак көттермәде.


Яна иде йөрәге Рәзиләнең, ни сәбәптән дигәндә, үзе дә өзеп кенә әйтә алмас иде, мәгәр сулкылдый иде йөрәге, әрни иде. Өстәп, кызы бәйләнеп кайтты. Әнисенә сыенды да сорау артыннан сорау яудырды:

– Ма, нигә алдаштың син? Авылга нигә бармадык без? Бу абыйга син кияүгә чыккан идеңме? Ә теге бәләкәй малайлар чынлап та миңа охшап калганнар шикелле. Ә минем чын әтием кем иде ул, нинди иде? Авариядә үлгән дип сөйли идең дә, ә нигә аның берәр фотосы да калмадымыни? Мин аңа охшаганмынмы?

Мөлдерәмә тулышкан Рәзилә бу сорауларга җавап бирерлек хәлдә түгел иде.

– Син минем кызым. Ә калганы турында кайткач сөйләшербез, яме? Йокларга тырыш, кызым, көне буе йөреп арыгансыңдыр, йокла...

Тәмам аруы җиткәндер, озак та үтмәде, әнисенең алдына капланып йоклап китте бала. Ә Рәзилә тагын тәрәзәдән күзен ала алмады. Их, йөгерәсе иде әнә шул иксез-чиксез яланнар буйлап, берни уйламый, иркә кыз булып, уйнаклап йөгерәсе иде, бар җирне яңгыратып: «Хәйбулла-а... Хәйбулла-а...» – дип кычкырасы иде. Ишетер иде микән, йөгереп килер идеме икән, сулуы кабып каршына, кулларына күтәреп алып, зыр әйләндереп: «Мин сине яратам, Рәзилә. Я-ра-та-ам!» – дип, аңа кушылып аваз салыр идеме икән?..



Марсель
Бакиров

# ҖАНЫМ ӘРНЕР ЯШӘП ТУЙМАГАНГА...

## Нигә сыкрый күңел?

*Кешенең үлгәннән соң да*
*өч көнлек эше кала...*

Олы яшьтәгеләр аңлар мине,
Гаепләсә – яшьләр гаепләр.
Чөнки сүзем – үлем белән бәйле,
Әманәтем калсын, дим, мәгәр.

Мин китәрмен. Тиздән туксан миңа.
Җир астыннан юл юк бер киткәч.
Мәшәкатем төшәр башкаларга,
Ыгы-зыгы тынар – эш беткәч.

Тына алмас бары җаным гына,
Җан-рух үлми, дию хак булса.
Гүрдә генә ял итәрмен диеп,
Әйтә идем дә бит гел, юкса.

Җаным әрнер яшәп туймаганга,
Эшем калганына бүленеп,
Эштә яну – яшәешем булды,
Яшәдем гел эшкә күмелеп.

Үлчәп булмый еллар саны белән,
Таулар сыман өелеп эш кала.
Ниятләрне тиздән әҗәл кисәр –
Шуңа сыкрый күңел, эч яна.

Мәгарәдә белем эстәп яткан
Әбүгалисина – гаян ир.

Марсель БАКИРОВ (1933) – *шагыйрь, галим, әдәбиятчы, фольклорчы, тюрколог; Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Кол Гали исемендәге халыкара премия лауреаты. Борынгы төркиләр, татар фольклоры һәм поэзия турындагы фәнни хезмәтләр авторы. Казанда яши.*

Безнең өчен китап-мирасханә –
Булды еллар буе шундый җир.

Чорлар күмгән тирән катламнарда
Энә белән кое казыдым.
Эзенә төштем ерак бабамнарның,
Чоңгылларда маяк кабыздым.

Тик сүтелми кала ахыргача
Үзем җыйган серләр йомгагы.
Без – фанатик могиканнар киткәч,
Тамчыдан күл ясар кем тагы?!

«После нас хоть потоп» түгел миңа –
Газиз халкым булсын гомерле!
Җәһилият мәңге капламасын
Нурлы аяз милли күгемне.

## Кеше һәм табигать

Һомо Сапиенс. Кемнәр генә белми,
Инсаният шуннан яралган.
Тәрәккыят, ягъни алгарыш та
Шул кадими чордан юл алган.

Мәҗүси чор, дибез, ә ул чорның
Булган хәтта үзгә бер ягы,
Кеше табигатьтән аерылмаган
Һәм үз итеп сөйгән дөньяны.

Күк йә балчык, яки хайван белән
Бәйләгән ул килеп чыгышын.
Алласы да булган Кояш йә Ай,
Серләр тулы булган тормышы.

Шәфкать көткән бары табигатьтән
Җирсуб[1] булган аңа туган ил.
Умай-ана – үрчем алиһәсе,
Табынган һәр көчкә кеше гел.

Алу өчен бирә белү кирәк –
Үрчем-уңыш бәйле шуңарга.
Табигатьне таламаган кеше,
Корбан биргән җиргә, суларга.

Алтынчы төр тойгы көчле булган,
Натура[2] – культ булып саналган.
Билгесезлек аңа шөбһә салган,
Гүзәллекне күреп таң калган.

Тәрәккыят кенә һәр нәрсәнең
Астын өскә бутап бетергән.
Мәдәният шүтне[3] тетеп салган,
Инсаният, гүя тилергән.

Тилермәгән, ул – масайган бары,
Тойган инсан үзен хуҗа дип.
Табигатьне җиңдем, буйсындырдым,
Мин кодрәтле, горур шуңа, дип.

Кеше сансыз сер иясе булгач
Марска да инде юл кыска.
Айга менә, гүя ындыр арты,
Ракеталар гизә космоста.

Әмма җирдә күрелмәгән мәхшәр,
Колак ишетмәгән гарасат.
Әллә күкнең төбе тишелдеме?
Туфан купты инде ничә кат?

Ул гынамы, җирдә өермәләр
Бөтерелә, күккә тоташып.
Җир убыла, ташлар җимерелә,
Янар таулар ата ут ташып.

Йә, шушымы табигатьне җиңү,
Шапырыну мин баш, хуҗа дип?!
Үз урыныңны таны, и мәхлук җан,
Йөрмә табигатьне узам, дип.

---

[1] Җирсуб (борынгы төркичә) – җир-су белән бәйле туган төбәк; миф буенча урталыктагы дөньяның төркиләрне яклаучы баш алласы.
[2] Натура (латинча) – табигать.
[3] Шүт (борынгы төркичә) – табигать.

Бабалардан калган әманәткә
Син, асылда, иттең хыянәт.
Бозык һава, тозлы чишмә суы –
Шул түгелме җирдә кыямәт?!

Рәнҗетелгән җир-су үч алачак
Җуйганга без изге берлекне.
Табигатьне болай кадерсезләү,
И кешелек, бу соң хөрлекме?

Саклыйм дисәң, инсан, бишегеңне
Татулашу лазем, бел шуны –
Үзара һәм Җир-Анабыз белән,
Һәм сакларга өйрән Җир-Суны!

## Анабыз Ай-Ва[4] турында риваяти баллада

**1**

Бәлки чындыр, бәлки мифтыр,
Шундый хәл булган, диләр,
Матриархатлык дәвере
Башкача узган, диләр.

Анабыз Ай-Ваны Тәңре
Тәү башлап яралткан[5], ди,
Яралгач ул бар дөньяны
Үзенә караткан, ди.

Сылу буен-сынын күреп –
Таулар аңа баш игән,
Җилләр чәчләрен тараган,
Кояш йөзләрен сөйгән,

Сулар, кочып, тәнен юган,
Үләннәр булган келәм,
Ташлар булып – таш эрегән
Ул аяк басу белән.

Әмма табигать дөньясы
Булса да җанга якын,
Күңеленә нидер җитмәгән,
Кальбен ялмаган ялкын.

Сораган ул Күк-Тәңредән:
– Ялгыз мин, сыкрый йөрәк,
Бергәләп тормыш көтәргә
Миңа бер иптәш кирәк.

Тәңре гозерен үтәгән –
Яралткан, ди, дәү Елан,
Тора башлаганнар болар
Ир белән хатын сыман.

Беркөн кара тавыш чыккан –
Елан моңа ыргылган.
Җитез Ай-ва аны шундук
Болгап, читкә томырган.

Гаҗәп, Еланның кабыгы
Калган Ай-Ва кулында.
Һәм ул бүтән беркайчан да
Очрамаган юлында.

Шуннан бирле Елан заты
Яши, ди, читтә качып,
Кабыгын сала, ди, һәр ел,
Чагам дип йөрми шашып.

**2**

Ай-Ва кабат ялгыз калган.
Ямансу. Хәле мөшкел.
Үз тиңем булсын иде, дип,
Йөрәге җилкенгән гел.

Янә Тәңрегә дәшкән ул:
– Илаһым, хәлемне бел,
Аерылыштык Елан белән,
Табылмады уртак тел.

Тәңре бу юлы пар итеп
Җибәргән, ди, Арыслан.
– Иң көчле зат белән, дигән,
Кавышасың, горурлан!

Яшәп киткәннәр. Арыслан
Патша күк тоткан үзен.
Ачуы чыкса – кып-кызыл
Кан баса икән күзен.

Ул гынамы, бер кычкырса,
Бөтен җиһан дерелди,
Ыржая казык тешләре,
Ай-Ва нишләргә белми.

[4] Ай-Ва – Библиядәге Адәмнең хатыны Ева, хәдисләрдәге Һаува намы белән тиңдәш һәм аваздаш исем. Ул Алгы Азиядәге балчыктан яралган иң беренче хатын-кыз турындагы борынгы мифта сакланып калган. Шул ук мифта Адәмгә тәңгәл исем – Ай-Атам. Төрки бабаларыбызның теле һәм төрки кавемнең яралган регионы да – Алгы Азия, яисә Якын Көнчыгыш дип исәпләнелә.
[5] Яралту – биредә барлыкка китерү мәгънәсендә.

Түзгән-түзгән дә гүзәл зат:
– Тай, йолкыш мәче! – дигән,
Койрыгын урап тоткан да
Шәпләп кирәген биргән.

Йоннары калган коелып,
Туналган күк тиресе.
Бары сакланган, ди, яллы
Муен-күкрәк турысы.

Шуннан бирле гәүдәсенә
Озын йон чыкмас булган,
Ай-Вага якын килергә
Ул бүтән кыймас булган.

**3**

Ай-Ва янә парсыз калган,
Йөрәге телгәләнгән,
Ялгызы иза чигүдән
Үзәге өзгәләнгән.

Өмет баглап, өченче кат
Тәңрегә ул сүз каткан.
– Үз ишем булса иде, – дип,
Күккә багып, җан аткан.

Теләге гарешкә җиткәч,
Тәңре кылган әмерен.
Ирештергән җир йөзенә
Яралтып, тиң әҗерен.

Җәнлек түгел, Ай-Ва сыман
Булган ул Адәм заты.
Исем-җисем туры килә –
Ай-Атам икән аты.

Чагам дип ысылдамаган,
Сыртын да кабартмаган.
Кояш астында көнозын
Кызынып та ятмаган.

Таң белән бергә уянып,
Табигатькә юл тоткан,
Һәр манзарага сокланып,
Могҗиза вә сер тапкан.

Сокланган ул Ай-Вага да.
Тик итагать сакланган,
Иялнә төшсен диеп,
Янына да ятмаган.

Ай-Вабыз соң хатынмыни
Итмәсә үзенекен?!
– Ир була белмисең, – диеп,
Тавыш күтәргән беркөн.

Шуннан Ай-Атам күтәреп,
Түш астына салган, ди,
Кысып-кочып үпкән чакта
Ай-Ва һуштан язган, ди.

Ике гашыйк кавышканда,
Табигать тынып калган.
Шул мизгелдә җир йөзендә
Тәү сөешү яралган.

Анабыз Ай-Ва шатланып,
Сөрән салган җиһанга:
– Ишем таптым! Баш булу хуп
Ир-атка – Ай-Атамга.

Ул баш булсын, ә мин – муен,
Җайга торырмын, дигән,
Кирәк чакта уңай якка
Үзен борырмын, дигән.

Гаилә шулай яралган,
Ямь биргән аңа ана.
Сөешкәч, туа башлаган
Бала артыннан бала.

Ана кальбен биләп алган
Мәхәббәт, шәфкатьлелек;
Шул хисләрне кавеменә
Тараткан, шифа кебек.

Бар кешелекнең әнкәсе
Икән Ай-Ва анабыз.
Аңа бөек тәхет итеп,
Шигъри һәйкәл салабыз.



Илсөяр
Иксанова

# МАТӘМ

хикәя

Халык. Халык шактый җыелган иде. Әхтәм уйлаганча, дөресрәге, Әхтәм теләгәнчә үк булмаса да, шактый. Әнә, койма тирәсендәге агач күләгәсендә төркем-төркем авыл кешеләре җыелып тора. Әнә, Гафиятнең йорты каршында туктаган автобус күләгәсенә Казаннан кайткан сәнгать әһелләре чүмәшкән. Шунда ук ишекләрен ачып куйган берничә җиңел машина да бар. Әхтәмгә, мөгаен, аларга кушылырга кирәктер инде. Тик... Ул тирәдәге беркемне дә күрәсе, сөйләшәсе килми. Аларның нәрсә сөйләгәннәрен болай да чамалый. Һәркем Гафият белән никадәр якын булуын, аның аңа биргән бәясен күпертеп-күпертеп сөйлидер. Гадәттә, танылган шәхесне озатканда шулай була. «Ул миңа болай диде...», «Ул мине югары бәяләде», «Без аның белән...»

Кешесе күп булмаса да, автобусның зурысын алганнар тагын. Хәер, эссесе тынга каба торган җәй челләсе икәнлекне исәпләсәң, кешесе алай аз да түгелдер. Шулай да Әхтәм күбрәк булыр дип көткән иде. Дуслары күп иде бит Гафиятнең. Артык озын булмаган гомер юлында югалтып бетергән икән... Бетергән. Бетергәнен белә бит инде Әхтәм. Нигә аптыраган була? Әле күптән түгел генә, соңгы күрешүләренең берсендә, үзе үк әйтте бит: «Дуслардан бер син калдың, син генә чын дус булгансың икән», – диде.

Гомер буена юлдаш булып барган чын дуслар күп булмый икән шул. Әхтәмнең үзенең кеме калды? Гафият. Әйе, бердәнбер ул булган икән. Ә бит алар гел-гел күрешеп, аралашып та яшәмәделәр. Берара бөтенләй

---

* Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсында «Хикәя» номинациясендә 3 урын алган әсәр.

---

Илсөяр ИКСАНОВА (1966) – *шагыйрә; С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Кырык кыл» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

ераклашкан кебек иде. Соңгы вакытта гына кабат студент елларындагыча якынайдылар. Дуслык сынавын икәү генә кичә алганнар иде.

Студент елларында алар өч дус булды: Әхтәм, Гафият, Атлас. Атлас... Ефәк егет! Килер микән? Килә алыр микән? Оялмыйча... Һе, авыр хәлдә ул хәзер, ә?! Килми калса, биләгән вазифасы ирек бирми. Килсә... Ни йөзе белән? Урынбасарын җибәрер микән? Анысы да инде... Ни дияр? «Талантлы рәссамыбызны югалттык», – дияр инде. Төче сүзләр сөйләр. Кадерен белмәдек, димәс. Ә, бәлки, дияр... Эштән сөреп чыгардык, куып җибәрдек, канатларын кистек, дип әйтә алмас. Дөресен Әхтәм әйтер. Сүзләрен уйлады инде. Кеше кадерен исән чагында белергә кирәклеген әйтер. Ә хәзер... Хәзер Гафияткә инде барыбер. Барыбер микән? Монысын тәгаен генә берәү дә әйтә алмый. Җан барысын да күреп тора, диләр бит. Имеш... Бәлки, чынлап та...

– Әле берәр сәгатьсез кайтмаслар, бар, наный, өйгә кереп утырып тор. Башыңа эссе сугар.

Чирмеш хатынына тартым йөзле апа... Апамы, әбиме? Олы яшьтәге хатын-кыз инде.

– Рәхмәт, күләгәдә түзәрлек.

– Озак бит әле. Өйдә җарау. И-и-и, нинди өй җиткергән иде бит. Үз куллары белән.

Апа кеше чөеп бәйләгән яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп алгандай итте.

– Сез... Гафиятнең...

– Күршесе. Күрше апасы мин. Син... үзең...

– Дусты.

– И-и-и, дуслары күп иде инде.

Бердәнбер! Юк, апага әйтеп тормады. Нишләптер, күренекле кешенең дуслары күп була дип беләләр. Ә Гафият танылган кеше иде.

– Кайткан! Күрдеңме?

Күрше апасы янына килеп баскан чандыр хатын өй ягына ымлады.

– Ә шулмыни әле ул? Улмы, түгелме, дип караган идем аны.

Әхтәм дә, ирексездән, хатыннар ым каккан якка күз ташлады. Җете кызыл чалбар кигән озынча гәүдәле ханым «Opel» машинасыннан ниндидер төргәкләр алып маташа иде.

– Кайтучылар булыр инде хәзер. Өй бар бит. Машина...

– Өй дип... Моңа берни эләкмәс, язылышмаган бугай алар. Просто, туры килгәндә торганнар инде шунда...

Чандырның сүзен Күрше апа бүлде:

– Торганнар дип... Соңгы арада монда да кайткалап йөрде ул үзе. Язылышмаса ни! Кем белә аны, ир-атны җебегән вакытында үз җаена салып җибәрергә осталар була. Васыятьнамә яздырып куйган булса...

– Һе, булыр анысы! – Аркасын агачка терәп чүмәшкән ир-ат авыр сулап куйды. – Кызы бар бит әле моның. Закунный.

– Күренми әле кызы.

– Моргтан ул алып кайтасы, ди.

Кай арада җыелып өлгерде әле болар? Әхтәм белән Күрше апа икәү генә ышыкланып торган каен күләгәсендә бер көтү кеше иде инде. «Кызыл

ыштан» әллә кайчан өйгә кереп китте, мондагылар әле һаман аны тикшерә. Гафиятнең малын бүлә.

– Беренче хатыны да кайтыр микән?

Әһә, Гөларага да барып җиттеләр... «Кызыл ыштан»ны калдырып, инде аның сөякләрен саный башладылар.

Гөлара... Кайтам, диде. Юлда ул. Кайтып җитәргә тиеш. Ялга киткән булган. Кипрга. Барып ике көн үтүгә, шушы хәбәр. Әхтәм шалтыратканда белә иде инде. Зинһар, көтсеннәр, кайтып җитәм, диде.

Юк, Әхтәмнең Гөлара турында, Гафият белән аларның үзара мөнәсәбәтләре турында авылдашлар уйлап чыгарган уйдырмаларны тыңларлык көче юк иде. Шыпырт кына өйгә юнәлде.

Узган яздан бирле никадәр үзгәреш монда! Бакчасы да ялт иткән. Эшләп тә караган икән Гафият! Әле узган язда күтәргәннәр иде бураны. Өмә белән. Әхтәм дә кайтты. Көз җиткәч, Гафият тагын чакырган иде үзен. «Өйне түбә астына керттем, кайтып күр», – дип. Вакыт... Алдый безне вакыт. Куалый. Туктап, сулу алырга, якыннарың белән аралашырга, дөньяның матурлыгына сокланырга да ирек куймый. Хәер, вакыт микән, үзебез микән? Туктап торыйм, дисәң... Тукта, кара як-ягыңа. Багышла бер көнеңне якыннарыңа. Юк... Йөгерәбез. Менә... Туктады Гафият.

Тыштан җыйнак кына күренсә дә, өй эче шактый иркен иде. Нарат исе аңкып торган салкынча өйгә килеп кергәч, сулу киңәеп киткәндәй булды. Җәй челләсенә кысылган тын юллары ачылып китте.

Алгы якта кайнашкан берничә хатын-кыз Әхтәмне өй түренә озатты. Монда да күбрәк өлкән яшьтәге хатыннар җыелган. Кемдер диванда, кемдер дивар буена тезеп куелган урындыкларда утыра.Тавышларын басып кына гәпләшәләр. Болар белән кул биреп күрешеп чыгасы микән, дигән уеннан бүлеп, түрдәрәк урнашкан ике ир-ат Әхтәмне үзләре янына дәшеп алды. Хатын-кызлар белән баш кагып исәнләште дә ирләр янына узды Әхтәм. Алар белән кул биреп күреште. Күрешкәндә генә танып алды, ир-атларның берсе узган язда бергәләп өй күтәрешкән егет иде. Егет димәсәң... Кырыктан өстәдер инде. Күренеп тора, салырга ярата торган кеше. Күз төпләре шешенгән. Гәүдә дә салынып төшкән. Авыл җирендә, эчү хакына кешегә авыр эш эшләп йөрүче мәхлуклардан бу. Гафиятнең ерак туганы иде кебек. Икенчесе, пөхтә киенгәне, йөзенә сары сарганы... Әйе, әйе, Гафиятнең бертуган абыйсы. Шактыйдан теге чир белән интегә. Диагнозын белгәч, и, кайгырган иде Гафият. «Бердәнбер якын туганым... Инде ул да...» – дип. Ул исән әле. Ә Гафият...

Өй диварларына эленгән модернизм стилендәге картиналар Гафият булып сөйләп торалар иде. Әхтәмгә шулай тоелды. Әхтәмнең игътибары картиналарда икәнлеген күреп, абыйсы зәгыйфь тавыш белән әйтә куйды:

– Иллә дә оста төшерә иде бит ул рәсемне. Кеше дисәң, тач үзе. Табигать дисәң... Җил искәнне дә тоясың инде менә... Шул хәтлек чын итеп ясый. Ул атлар! Менә шул атларның холыкларына кадәр күрсәтә инде.

Соклану да, горурлану да, үкенү дә бар иде аның сүзләрендә. Ә иң көчлесе – яклау иде. Янәсе, карама син бу аңлаешсыз нәрсәләргә. Бу аның саташуы гына. Ул бит оста иде. Ясый белә иде. Саташты...

Саташты. Күпләр аны шулай дип уйлады шул. Күпләр аңламады. Аңлаучылар... Аңламаганга сабышты. Көнләште. Заманча сәнгать белән мавыгып киткән Гафият күпләргә аңлаешсыз тоелган әлеге юнәлешкә шундый тирән керде... Бу анык иде. Рух халәтен, яшәешкә, системага булган дәгъвасын шул юл белән әйтеп бирә алырына ышанды ул. Аның мөмкинлекләрен аңлады. Заманча сәнгатькә кагылышлы иң кызыклы, көчле күргәзмәләрнең кураторы да ул булды шәһәрдә. Тора-бара үзенең күргәзмәсен оештыру уе белән яна башлады.

– Күргәзмә залын карап, һәр картинаның урынын тәгаенләп чыктым. Шундый күргәзмә булачак! Эшләр артык күп кирәкми, әмма һәрберсе үз урынында... – дип, дулкынланып сөйләгән иде Әхтәмгә. Күзләре яна.Чып-чынлап бәхетле иде Гафият бу минутларда. Тик күргәзмә булмый калды. Аңа каршы чыгучылар табылды. Имеш, халык йөрмәячәк. Әле иртәрәк. Кем каршы чыкты диген? Атлас!!!

Югыйсә Атлас бу кәнәфиенә Гафият ярдәме белән утырды. Чираттагы корылтайда яңа рәис сайланырга тиеш иде.

– Атласның рәис буласы килә, – диде Гафият. – Яшьләр миңа тавыш бирсә, үтәчәкмен, ди.

Ә Гафиятнең яшьләр арасында дәрәҗә зур. Яраталар аны яшьләр. Ышаналар аңа. Атлас – карьерист, система кешесе. Яшьләр аңа тавыш бирергә ашкынып тормый.

– Ә үзең... нәрсә? – диде Әхтәм.

– Атлас булсын. Үзебезнең егет бит. Безгә шундый кеше кирәк. Өстәгеләргә сүзе үтә. Алайса, берлекнең дәрәҗәсе булмый, эш бармый. Яшьләргә дә шулай дип аңлаттым. Тик аларда яшьлек максимализмы көчле. Нишләрләр...

Үтте Атлас дус.

Әйе, алар өч дус иде. Институтта бергә укыдылар. Архитектор булырга. Арадан Әхтәм генә сайлаган һөнәренә тугры калды.

Гафият белән Атлас институтка сәнгать училищесыннан соң килделәр. Әхтәм Гафият белән ничектер бик тиз дуслашып китте. Ә Атлас... Беренче күрүдән үк ошатмады аны Әхтәм. Шома егет. Гафияткә тагылган үзе! Гафият дус иткәч, Әхтәм дә кире кага алмады. Студент елларын өч дус булып кичтеләр.

Укып бетергәч, юллар үзләреннән-үзләре аерылды. Гафият белән барыбер дә ниндидер эчке якынлык тотып торды. Ә соңгы өч елда бөтенләй якынаеп киттеләр. Гафиятнең бик авыр чоры иде.Үзе әйтмешли, Атлас күргәзмәгә «крест сукканнан» соң, сүзгә килеп, Гафиятне эшеннән дә алдырган иде. Әхтәм аны авылына кайтып тапты.

Эш телефоныннан «Гөлара әле бу!» дигәнне ишеткәч, аптырап киткән иде Әхтәм. Гөлара әле бу! Әйтерсең лә, кичә генә сөйләшкәннәр. Ике дистә ел күрешмәгән-белешмәгәннән соң, шулай гади генә... Гөлара әле бу.

– Гафиятне ишеттеңме?

– Юк, ни булган Гафияткә?

– Эшеннән куып чыгарган... Дусты. – «Дусты»н аерым басым ясап әйтте. Кайсы дусты икән дип икеләнер урын калдырмады. – Авылда ята,

ди, эшсез. Гөлназ, безнең кыз, кайтып килгән иде. Әхтәм, аңа синнән башка ярдәм итәр кеше юк.

Сөйләшә торгач белде, хан заманында аерылышкан булсалар да, Гөлара Гафиятнең тормышыннан хәбәрдар икән. Хәбәрдар булуы аңлашыла, уртак кызлары бар. Аерылышсалар да, бала бүлмәгәннәр, ике арада үскән кыз. Ә менә үзенең тормышын корган, күпләр кызыгырлык итеп яшәп яткан Гөлараның элекке ире өчен шулай борчылуын башына да китермәс иде Әхтәм. Башына китерергә... Ул турыда уйлаганы да булмады аның. Күптән узган хәлләр бит.

Соңгы курста укыганда йөреп китте Гафият Гөлара белән. Дискотекада танышканнар. Университетның тулай торагында. Кыз шунда чит телләр бүлегендә укый икән.

Матур иде Гөлара. Җыйнак кына, чандыр гына кыз. Күзләре... Күзләренең төсен хәтерләми Әхтәм. Елмаеп торганы гына истә. Әйе, әйе, күзләре гел елмаеп, ике бит алмасы янып тора иде. Матур кызларның җилбәзәк булып чыгу ихтималын да уйлады. Ә бу төпле, акыллы. Гафият үлеп гашыйк иде инде! Матур йөрделәр. Өйләнештеләр. Туйда шаһит итеп, Гафият Әхтәмне сайлады. Сиздермәскә тырышса да, Атласның мин-минлегенә тиде бу.

Өйләнештеләр. Аннан аерылышканнар. Ул турыда Әхтәм уртак танышлары аша гына ишетте. Тормыш һәркайсын үз юлы белән алып киткән иде. Әхтәм кечкенә генә шәһәрдә шактый зур кеше – баш архитектор. Гафият Казанда. Талантлы рәссам, Күргәзмәләр залында эшли. Атлас министрлыкта кечкенә генә булса да түрә. Соңыннан бер очрашканда сөйләде Гафият: «Үземдә булды гаеп, – диде. – Гөлара беркая китмәс кебек иде. Ул бит инде минеке. Гөлназ бар. Башка гөлләр дә булды минем тирәдә. Сокландырдылар. Читтән генә сокланасы килмәде...

Ә Гөлара молодец! Менә дигән итеп тормыш корды... Миннән башка. Чынлап әйтәм, шундый шәп кешегә чыккан. Малайлары бар. Гөлназның энесе... Ташбаш!»

Гафиятнең «Ташбаш»ны шулкадәр яратып әйтүенә гаҗәпләнде Әхтәм. Шулай да була микәнни? Чит ирдән, көндәшеннән булса да, Гөлара баласы бит! Гөлара да яраткан түгелме соң инде Гафиятен? Әллә бу Әхтәм аңлап бетерә алмаган нindидер башка мөнәсәбәтме?

... – Миннән алмаячак. Әхтәм, зинһар, үзем биреп торам, диген. Синең счётка күчерәм акчаны. Авылда бөтенләйгә кала алмас, хәзергә исә аңа шунда булу хәерле. Салсын өен.

Гөлара хаклы булып чыкты. Әхтәмнең ярдәменнән баш тартмады Гафият. Өен салды. Авылда гына да тора алмады.

«Шундый шәп бина таптым. Дөрес, ремонт кирәк анда. Анысын үзем эшлим. Алай әйбәтрәк тә әле, күргәзмәнең концепциясенә туры китереп, үземчә эшләячәкмен...»

Әй канатланган иде Гафият!

Бу аларның соңгы сөйләшүләре булды. Телефоннан.

– Кайтып җиттеләр! – Кемдер ишекне ачып, аваз салды. Өй эчендәгеләр дәррәү кузгалып, урамга ашыкты.Чыгып барганда гына абайлады Әхтәм, алгы якта мәетне юарга колаша әзерләп куйганнар икән.

Урамга чыккач та, мәетне алып кайтучылар арасыннан Гөлараны эзләде Әхтәм. Юк, күренми. Әнә, тыела алмый сулкылдаганы кызы булырга тиеш. Берәр җылы сүз әйтергә иде. Ничек? Ни дип?

Автобус янына килеп туктаган «Toyota»дан аксыл-көрән төстәге җәйге костюм кигән Атлас төште. Кайткан... Кайткан гынамы! Машинадан төшә-төшешкә дилбегәне үз кулына алды:

– Ишегалды ничек анда? Ишегалдына куярга кирәк! Хушлашу мәрәсимен шунда... Ничек юасы? Моргтан юып чыгармаганнармыни? Мин сөйләшкән идем бит... Аһ, чёрт! Вакыт... вакыт...

Атлас җил-җил атлап, өйгә таба китте. «Кызыл ыштан» аның тирәсендә әвәрә килә иде. Капка алдына килеп өелгән кешеләрнең өзек-төтек сөйләшүләреннән шуны аңлады Әхтәм, кызы: «Әтине үз өендә юып, кәфенләп, укытып, кешечә озатабыз», – дип, нык торган икән. Дөрес иткән. Гөлара да кайтып җитәргә тиеш икән.

– Күреп калырга теләүчеләр булса, керегез, югач күрсәтмиләр аннары...

Гафиятнең абыйсы шулай диюгә, халык этелә-төртелә, капка тирәсендә бөялеп алды. Аннары чиратка бастылар.

Әхтәм, читкәрәк китеп, Гөлараның номерын җыйды. «Абонент не доступен». Юлда, димәк. Кайтып җитәр.

Өйдән Атлас чыкты. Вәкарьлек! Атласның шәп кәчтүм-чалбарына карап, Әхтәм беренче танышкан чакларын исенә төшерде. Ул заманда бик тә модалы саналган, «Саручи базары»нда гына юнәтергә мөмкин булган көрән төстәге микровельвет чалбардан иде Атлас. Ул чалбар Гафиятнеке булып чыкты. Абыйсы Балтыйк буенда хезмәт иткән булган, шуннан алып кайткан икән.

Бәхилләшергә иң ахыргылардан булып, өйгә кереп барган Әхтәмне күреп, Атлас кулын сузды: «Да... Хәлләр...» Кулы тирләп чыккан иде. Үзе кабалана.

– Моргта юарга дип сөйләшкән идем бит. Мәетне... Озак тотарга ярамый. Бу эсседә тагын...

– Хафаланмагыз, вакыт бар әле, җәйге көн озын, кояш баеганчы күмәргә була... – Кайсыдыр беркатлысы Атласны юатып маташты.

– Гөлара кайтып килә! – диде Әхтәм.

– Кайтып килә! Кайтасы кешеләр кайткан инде! – Атласның нигәдер ачуы кабарды.

– Ул Кипрдан кайтып килә.

– Ну... Нишли инде кайтып? Хәзер... Нигә? Чёрт! Миңа да Мәскәүдән кунаклар килеп ята анда!

Әйе, синең эшләр мөһимрәк икән. Әйтәм җирле кабаланасың! Уйларына бирелеп, Әхтәм өйгә атлады.

Мәет тирәсендә берничә генә кеше иде: кызы, абыйсы, юантык хатын. Туганыдыр, мөгаен. Авылның мулласы – озынча битле өлкәнрәк абзый.

– Башка кеше калмадымы? – дип сорады мулла.

Юантык хатын мәетнең йөзен каплаган яулыкны ачты.

Гафият... Тыныч, җансыз, соргылт йөз. Битарафлык. Битарафлык сурәте

иде бу. Бу инде Гафият түгел. Гафият битараф була алмый. Бу минутта һич кенә дә зиһененә килергә тиеш булмаган уйлар чәбәләнеп алды Әхтәмнең башында. Әлеге уйлары өчен Гафиятнең туганнары алдында уңайсыз булып китте. Әхтәм ашыгып, ишеккә борылды. Аннан, туктап, кызының кулыннан алды.

– Әйбәт кеше иде әтиең...

«Кайгыңны уртаклашам» кебек шаблон җөмләне әйтә алмады. Бу сүзләр бик ясалма яңгырар кебек тоелды. Чынлыкта ул бит бу кыз баланың кайгысын җиңеләйтергә тели иде. Ихлас йөрәге белән тели иде. Тик ничек? Гомумән, кешенең мондый кайгысын уртаклашып буламы? Юктыр. Һәр кеше аны үзе генә күтәрә. Үзенчә күтәрә...

Өйдән чыккач та, Әхтәм урамга, кешеләр ягына түгел, бакчага таба борылды. Төш вакыты авышып, көн сүрелә төшкән. Күкне урыны белән сизелер-сизелмәс кенә аксыл юка болыт челтәре каплаган.

– Гафу итегез, сезне Гафият Галиәкбәровның танышы, диделәр. Интервью бирә алмассызмы? – Янына килеп баскан яшь кенә кыз шулай дип сорады да, Әхтәмнең җавабын да көтеп тормастан: – Әйдәгез, йорт фонына басып карыйк, – дип әйдәкли дә башлады.

Интервью? Гафият турында әйтер сүзләре бар Әхтәмнең. Уйлап куйган сүзләре бар.

– Сез башта үзегез белән таныштырырсыз, аннан аның турында сөйләрсез. Хәзер, Атлас Азатович сөйләп бетерә дә...

Әхтәм кыз ымлаган якка күз атты. Атлас бик олпат рәвештә, вәкарь белән интервью биреп маташа иде.

– Ә... Атлас Азатович сөйләгәч...

– Әйе, алар иң якын дуслар булганнар икән бит. Ну... Сез дә үз фикерегезне әйтә аласыз.

Журналист кыз, шунда гына торыгыз, дигән ым кагып, интервью алучылар янына китте. Шунда торды Әхтәм... Тик әйләнеп килүче булмады.

Юып бетерделәр. Пөхтәләп төрелгән мәетне ишегалды уртасына куйдылар. Хушлашу мәрәсиме башланды. Атлас алып бара.

– Җәмәгать, без бүген бик якын, кадерле дустыбызны соңгы юлга озатабыз. Кызының, туганнарының, якыннарының... – Атлас туганнарыннан читтәрәк басып торган «Кызыл ыштан»га күз атып алды, – авыр кайгысын уртаклашабыз. Миңа бу сүзләрне сөйләве икеләтә авыр. Берлек рәисе буларак, мин талантлы рәссамыбызны югалту хисен кичерәм. Алай гына да түгел, мин иң якын дустымны югалттым. Без Гафият Галимович белән гомер буена аерылгысыз дуслар булдык. Училище, институт еллары... Бергә укыдык. Сәнгать дөньясында бергә хезмәт иттек. Мин аның иҗат эшчәнлеген һәрдаим күз уңымда тоттым. Талантын бәяли белдем. Талантлы иде ул! Әле зур хыяллары бар иде. Зур хыяллар белән яшәде. Без аның зур шәхси күргәзмәсен әзерли идек. Менә шул күргәзмәсен әзерләгәндә... Чын иҗат кешеләренә хас булганча, Икар шикелле янып үлде!

«Икар»ның артыграк китүен үзе дә чамалады бугай, бераз төртелеп торды. Аннан тамак кырып, дәвам итте:

– Барыгызга да мәгълүм, күргәзмә үтәчәк залны үзенчә күреп, үзенчә бизәгәндә, түшәмне дә үзенчә оформлять итәргә теләп... Шул биеклектән егылып төшеп... – Атлас тавышына хәвеф-хәтәрле аһәңнәр кушты: – геройларча һәлак булды. Бәхил бул, дустыбыз, без сине онытмабыз. Тыныч йокла! – Атлас бер тын башын иеп торды. – Без шундый шәхесне озатырга кырык эшебезне кырык якка ташлап кайттык. Хәзер сүзне Мәдәният министрлыгыннан килгән вәкилгә бирәм.

«Вәкил» Гафиятнең кем икәнлеген күз алдына да китерә алмаган кеше иде. Татарча белгән бердәнбер сүзе булгангадыр, ул чыгышын «Исәнмесез!» дип башлады. Аннан бик нык гафу үтенеп, русчага күчте. Мондый очракта әйтелергә тиеш булган, ятланган берничә җөмләсен җиткергәннән соң, үтә олы вазифа башкарган кыяфәттә, Атлас янына барып басты. Атлас:

– Мәрхүмнең туганнары арасыннан сүз әйтүче булырмы? – дип, Гафиятнең абыйсы белән кызы ягына күз ташлады. Аның тавышыннан, күзләреннән, әйтеп тормасагыз да ярар, дигән теләге сизелеп тора иде. Тик...

– Әйе, мин әйтми кала алмыйм, – диде кызы һәм алгарак чыгып басты.

Гөлназдан соң сүз алырга өметләнеп, Әхтәм дә селкенеп куйды. Әмма...

– Яхшы, кызын тыңлыйк та, бу соңгы чыгыш булыр, аннан җеназа намазын укырбыз. Артык озакка китә, – дип кисеп тә куйды Атлас.

Сүзен әйтә алмый калуына күңеленнән көенсә дә, Гөлназны тыңлагач, мин теләгәнне әйтте инде дип, үзен юатудан башка чара тапмады Әхтәм. Әйе, әтисенең нинди олы талант булуын, ләкин аны аңламауларын, бәяләмәүләрен ачынып әйтте кызы. Йөрәге белән әрнеп әйтте.

Җеназа намазына бастылар.

Гөлара. Гөлара юк бит әле һаман...

Авыл мулласы күңелгә ятышлы мәкам белән укыды. Җиренә җиткереп, шактый озак укыды. Әхтәм Атласның борсалануын сизеп торды.

Инде кузгалып китәләр дигәндә... «Әнием!» – Гөлназның тавышы барысын шып туктатты. Түбәсенә сарылы-каралы шакмак утыртылган таксидан төшкән сылу гәүдәле хатын Гөлназны кочып алды. Ике күзеннән чишмә төсле яшь ага... Ә күзләре елмая иде... Чынлап та шулаймы соң? Әхтәмгә генә шулай күрендеме?

Өлгерде! Әхтәм җиңел сулап куйды. Гөлара салмак, әмма ышанычлы адымнар белән мәет янына килде.

– Соңгарак калдың шул, кызым. Кулың белән кагыла күрмә инде, тәһарәтен бозарсың. – Авыл мулласы, сакчы фәрештә кебек, мәет белән Гөлара арасына басты.

– Рәхмәт! Рәхмәт барыгызга да...

Гөлараның әкрен генә чыккан тавышын барысы да ишетте. Халык тын да алмый аны күзәтә иде бу мизгелдә.

– Гафият... – Хатын мәеткә кагылмый гына, өстеннән кулы белән сыйпап узгандай итте. – Гафият!

Шул бер сүзгә барысы да салынган иде: ярату да, үкенү дә, кызгану да, әрнү дә... Чын, ихлас хисләр салынган иде.

Атлас килеп, Гөларага нидер әйтмәкче булды. Хатын аны тыңлап тормастан, кызын кочагына алып, читкәрәк китеп басты.

– Әйдәгез, кузгалдык, – дип, дилбегәне тагын үз кулына алды Атлас. Колашаны күтәрделәр. Алга бер яктан – Атлас, икенче яктан Әхтәм басты. Берничә йортны үткәч, Атласны урынбасары алмаштырды. Алдан килешенеп куелган булган, күрәсең. Җеназа артыннан әкрен генә «Toyota» да барган икән, Атлас тиз генә машинага чумды. Автомобиль зур тизлек белән авылдан чыгып китте.

Дустын иңенә салып, соңгы юлга озата барганда, Әхтәм моннан күп еллар элек булган бер мәрәсимне исенә төшерде.

90 нчы еллар иде. Җинаятьчел төркемнәр баш калкыткан вакыт. Казан бүленеп беткән: «Халева», «Тяп-ляп», «Перваклар», «Җилка»... Әхтәм яшәгән йорттагы күрше малаен да төркемдә дип сөйләшәләр. Карап торышка юаш кына, ипле генә күренгән шул егеткә йорттагылар шүрләп карый, аның белән очрашмаска тырыша иде. Туры килгәндә, үзе һәркайсы белән кул биреп күрешә. Әхтәм белән дә юллары кисешкәләде. Күрешә. Артык сөйләшми, аяк очына карап кына үтеп китә...

Аттылар аны. Үзләренең йорты янында. Аттылар. Аннан җыйнаулашып җирләделәр... Күршеләренең күбесе, фатирларыннан борын төртергә дә куркып, тәрәз пәрдәләре артыннан гына карап торды. Бөтен Казан төркемнәре җыелган иде бугай. Ул машина! Гаишниклар юлларны ябып торды хәтта. Җеназаны күтәреп киткәндә, юлларга роза таҗлары сиптеләр. Ул кып-кызыл роза таҗлары, аңны сискәндереп, берничә көн буена юлда түшәлеп ятты. Күршеләр әле бик озак чыш-пыш килде:

– Теге баш булып йөргән юаны... Шул аттырган икән...

– Кит аннан! Шул бит инде мәрхүмнең әнисенә пачка белән акча биргән, ди.

– Алганмы?

– Алмый нишләсен! Алмый ярамый, ди. Аларның закон шулай икән.

– Аллам сакласын! Балаңны үтергән кешедән...

– Нишлисең... Үзләре үтерә, үзләре җирли...

Шушы вакыйганың шомлы хатирәсе дусты Гафиятне иңенә салып барган Әхтәмне зиратка кадәр озата килде. Үзләре үтерә, үзләре җирли... Ул нигәдер үзен дә шушы процессия эчендә кебек хис итте...

Гафиятне җиргә иңдереп, халык таралып беткәннән соң, төне буена иркенләп яварга әзерләнгән болыт куерып, зират өстенә килә иде...



*Фәрдилә Яр (1982) – (Фәрдилә Яруллина) Кукмара районы Вахит авылы кызы. Янил урта мәктәбен тәмамлагач, ул тормышын Казанның педагогика көллияте белән бәйли. Әүвәл шушында белем ала, аннан читтән торып, Татар дәүләт гуманитар педагогика университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый да үзе белем алган көллияткә эшкә урнаша. Альберт атлы егет белән гаилә корып, бүген алар Азалия белән Алмаз исемле игез бала тәрбиялиләр.*

*Фәрдилә диңгезгә, тауларга гашыйк, сәяхәт итәргә ярата. Бу гашыйклык аның иҗатында да чагылыш таба. Аның шигырьләренә тормышчан фәлсәфә, нечкә тоемлау һәм халыкчан гадилек хас дияр идем мин. Иҗатының дәвамлы булуын телик!*

Фәрдилә
Яр

# ӨМЕТ ТАМА ҖАННЫ КУАНДЫРЫП…

***

Этләр улый…
Аларның да бабалары бүре булган…
Әллә нәрсә шомландыра күңелемне
Ә бит, юкса, күктә бары ак ай тулган…

Ай тулганда, әллә сагыш,
Әллә каргыш уяна да күңелемдә
Йокым ала…
Бабам каны тынгы тапмый тыпырчына,
Кавемемә тагын кемдер богау сала…

## Очкын

Баш очыңда соңгы йолдыз сүнеп,
Ай тотылып, кояш югалганда,
Соңгы шәмең эреп, утсыз калып,
Караңгылык аша юл алганда –
Очкын янар җанда, бик тирәндә
Һәм яктыртыр бөтен жиһаныңны.
Ул – күрсәтер сиңа маяк кебек,
Гомерләрең буе җыйганыңны.
Яшерергә хәтта теләсәң дә,
Аермачык булып җәйрәр бар да,
Син аңларсың нинди маллар төяп,
Киткәнеңне шунда, каршы ярга…

## Дөнья

Дөнья бит ул ак-каралар белән,
Яхшы-яман белән чикләнми…
Яманның да була яхшы ягы,
Яхшыдан да булмый шикләнми…

Намус дигән маяк булса җанда –
Тәрбиянең шулдыр олысы.
Мең бүләктән кадерлерәк кайчак
Кемнәрнеңдер күңел җылысы…

Мәхәббәтнең төсе төрле-төрле,
Нәфрәт кенә кара коелган.
Ничек яшәсәң дә, кабер ташка
Тик ике сан бары уелган…

Матурлыкның нуры җанга дәва
Ямьсезләрнең керле гамәле.
Бер яхшыга бер яманмы җирдә?
Әллә күбрәк микән яманы?

***

Күз яшемне күргәннәр аз,
Синең хәтта күргәнең юк.
Мескен итеп күрсәтерлек
Әрсез, ямьсез күлмәгем юк.

Чирле чагым күргәннәр аз,
Чирдән башым чыкмаса да…

Чыраемны сытып йөрмим,
Тормыш кат-кат тукмаса да…

Җүләрләнеп сөйгәнемне
Белүчеләр санлы гына.
Йөзем ачык һәркемгә дә
Ача алмыйм җанны гына…

## Ялгышма

Түбә кыегыннан тамган тамчы,
Яз дип уйлап, зинһар, ялгышма!
Керфегемнән тамган елмаюны
Син күтәреп алма ялгыш та…

Язга таба кояш якты була
Һәм алдалый иләс күңелне,

Чегән кызы кебек карашыма
Корбан итә күрмә үзеңне…

Язда туган җаным, язның ише –
Мәңге китмәс кебек җилкенә…
Тик ышана күрмә сүзләремә,
Күңелем бары язгы җил генә…

***

Диңгез ярларында кояш бата
Диңгез ярларында гамь башка…
Йөрәктәге сөю ярасыдай,
Җуелмаслык эзләр һәр ташта…

Мин яшәүдән туя алмагандай,
Диңгездән дә туя алмамын.

Исерәмен аның кочагында,
Офыгында дөрләп янамын.

Бу сөюем үтә торган түгел,
Үтә торган түгел бу ялкын.
Офык чигендәге кояш кебек
Ул бик ерак, әмма бик якын…

***

Йокысыз ятканда төн ката
Хәтергә ияреп, уй кайта.
Шул хәтер кадерсез уйларны
Уйната, тузгыта, уята…

Ә төннең күзләре үтәли каезлап,
Бәгырьнең төбеннән зар эзли…
Һәм таба!
Ут каба җаныңа, төн яна –
Төн гүя хөкемдар дөньяга.
Ул – казый, ул – хуҗа уйларга…

## Куаныч

Яңгыр юган тәрәзләргә сагыш иңә
Күзгә җилнең салкын сулышында…
Яфракларга кунып бәргәләнә,
Урын тапмый җаным елышырга…

Тоник тәрәзләрдә кояш уйный,
Пәрәвезләр җебен нурландырып…
Килер язда шытар бөреләрдән
Өмет тама җанны куандырып…

## Манзара

Сурәтен төшерде ак айның
Җәйге төн тын диңгез өстенә.
Дулкыннар тибрәлде таң калып,
Илаһи матурлык көченә.

Сурәтен төшерде кояшның,
Таң килеп төннәргә алмашка.
Диңгезне бизәгән яктыдан
Ак томан сузылды кояшка.

***


Офыкның читендә баеган кояшның
Диңгездә җуелган мизгелен
Бер күрер өчен дә
Мин кабат туарга әзермен…

Син мине җүләр дип тиргәмә,
Аңлатып интекмә дөньяны!
Бар гамең онытып, йотылып,
Офыкка карале нибары…

***

Парктагы ялгыз утыргычта
Китап кына укып утырасы
Килгән көннәр була…
Тик, йә яңгыр ява, йә җил чыга,
Мин яшәгән бу ил
Тоташ күздән тора…

Яр буенда кояш баеганны
Карар өчен генә каһвә алып,
Утырыйммы дисәм,
Моның өчен оҗмах кирәклеге
Искә төшә – «диңгез» дигән…
Ә мин әле исә…
Мин – Казанда икән…



Рашат
Низами

# КЕЛӘМДӘ ОЧРАШУ

хикәя

Пассажир поездының Казан вокзалыннан кузгалып китүенә дә байтак вакыт узды инде. Егәрле поезд әкияттәге киң күкрәкле баһадир сыман алга йөгерүен дәвам итә. Аның артыннан елтыр тасмадай сузылып, тигез ритм белән тукылдап, рельслар артка таба шуыша.

Сентябрь урталары бу. Табигать әбиләр чуагына керергә җыена булса кирәк, юл читендә чагылып-чагылып киткән ак каеннар тезмәсендә саргая башлаган яфраклар учламы шәйләнә. Кояш нурлары астында алар әкияти бер күренеш, көтелмәгән тәэссорат булып, хәтер почмагына сеңеп кала. Кешеләрне, бигрәк тә шәхси бакчачыларны мул уңышы белән сөендерә белгән сентябрь ае, ни әйтсәң дә, табигатьнең иң күркәм, иң юмарт чагы.

Бу сәфәрендә уйчан йөзле Айбулатның күңеле нигәдер ялгызлыкка сусаган иде. Шуңа да ул, ялынып-ялварып дигәндәй, мөлаем кассир кыздан билетны ялгызак купедан бирүен сорады. Бәхетенә – сораганы мач килде. Юкса, вагондаш булып, елак баласы белән хатын-кыз таифәсе эләксә, көенү катыш буталчык уйлар җәтмәсеннән арына алмыйча җәфаланырсың. Ә инде күп сүзле ир-ат заты каршыңда утырып, юк-барны сораша, ләчтит сата башласамы – күңел тынычлыгыңның чәлпәрәмә киләсен көт тә тор. Юл йөргәне бар, төрлесен күргәне-очратканы бар Айбулатның...

Кич җитте. Вагонда утлар кабынды. Хәзер инде купе тәрәзәсе аша җете ачык сурәтләрне күрермен, димә, анда тоташ караңгылык. Сураеп баскан электр баганасы утлары гына тәрәзә пыяласында чагылып-чагылып китә. Кайчак билгесез ерак почмакларда авыл утлары җемелдәве күзгә ташлана. Урыны-урыны белән озын япма бөркәнгән кара күләгәләр вагонга ышкылып кала шикелле. Тышта төпсез караңгылык.

Күзәтүләреннән туктап, тәрәзәнең дерматин пәрдәсен кинәт аска шудырып төшерде егет. Бу мизгелдә әйтерсең лә караңгылык дигәнең вакытның теге ягында кыл урталай бүленеп, киселеп калды. Үз-үзең белән сөйләшү, уй-фикерләрне тәртипкә китерү – үзе бер күңелле форсат, җан тынычлыгы бирә торган үзгә юаныч иде. Ыгы-зыгылы, матавыклы вакытларда мондый юаныч кешеләрдән ерак йөри ләбаса.

Егет иң элек үзенә читтән карап, бәя бирергә, ирексездән, «Мин кем?..» дигән сорауга җавап эзләргә теләде бугай бу минутларда. Хыялларының чынга ашуы түгелмени бу? Югары уку йортын тәмамлады, татарча көрәш буенча үз авырлыгында Казан чемпионы булды. «Динамо» спорт сараенда югары профессионал әзерлек узды. Спорт остасы дигән мактаулы исем йөртә. Ун ярышның тугызында – җиңүче. 25 яшьлек егет өчен вак-төяк казаныш түгел болар. Мактаулардан өстен кала белде ул, эреләнеп-масаеп йөрмәде. Үзенең спорт карьерасы башланып килүен искиткеч тыйнаклык белән сизенгән хәлдә яши бирде, авыр күнегүләрдә үзен чыныктырды, алгы көрәшләргә әзерләде.

Инде менә алда – яңа очрашу!

Алдан хәбәр бирделәр, келәмдә Игорь Краснов дигән көрәшче белән очрашачак икән ул. Екатеринбург егете. Калган мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә. Димәк, бу бәйге беренче тапкыр очрашулары сыйфатында узачак икән.

Менә шушы «беренче» дигән сүз бик нык уйландыра иде Айбулатны. Игорь... Игорь... Краснов дигән фамилиясе дә тач туры килә... Очраклы хәлме бу, әллә исем-фамилиясенең туры килүе генә микән? Моңа кистереп кенә җавап бирү мөмкин түгел иде, билгеле. Сәгате җиткәч, вакыт күрсәтер, Алла боерса.

Ә шулай да уйланырга, гөман кылырга урын бар...

Менә шушы җирендә Айбулат күңелендә хатирәләр дулкыны йөгереп узды... Шахмат тактасындагы фигуралардай, берәм-берәм, мәктәп еллары күз алдына килеп басты.

...Бишенче класска укырга килгән чаклары иде. 1 сентябрь иртәсе бит, ул көнне Казан каласының барлык мәктәпләре аллы-гөлле чәчәк букетларына күмелгән булгандыр, мөгаен. Тантаналы линейкадан соң беренче классның «пингвин»нары да, өлкән классның инде егетлеккә таба атлаган яшүсмерләре дә парталар артына утырды.

Айбулат атлы малайны үзенә күрә зур «яңалык» көтеп тора иде: аны Игорь дигән яңа малай белән партадаш итеп бергә утырттылар. Класс җитәкчесе яңа укучы белән болай дип таныштырды:

– Сезнең белән бергә класста яңа укучы Игорь Краснов укыячак. Әтисе – хәрби офицер. Алар Казанга Оренбург ягыннан күченеп килгәннәр. Бергәләп, дус һәм тату яшәгез.

Игорь бик тыйнак малай булып чыкты, әтием офицер дип кәпрәеп, борын чөеп йөрмәде. Ул елларда, бигрәк тә совет чорында, хәрбиләрне бер гарнизоннан икенчесенә «күчереп» йөртүләр, урын алмаштыру табигый хәл иде шикелле. Традиция хәзер дә саклана булса кирәк. Ни өчен шундый «рокировка» сәясәте? Югары командование, күрәсең, бер урында мүкләнеп, сөрсеп ятмасыннар, тамыр җибәрмәсеннәр, дип фикер йөртәдер. Әнә бит – Красновлар гаиләсен дә, Чечняда канлы сугыш башлангач, Казаннан Кавказдагы хәрби частьларның берсенә – чираттагы озын-озак сәфәргә юлладылар.

Шулай итеп, Айбулат белән Игорьның дуслыгы, партадашлыгы, бергәләп татарча көрәш секциясенә йөрүләре әллә ни озакка сузылмады. Язмыш, тормыш агышының калейдоскоптай үзгәреп торуы алга таба аларның сукмакларын, бәлки бөтенләйгәдер, аерды.

Ә моңа кадәр менә нәрсә...

Әйе, аңа кадәр менә мондыйрак күңелсез бер вакыйга булган иде. Дәресләр тәмамлангач та, ниндидер сәбәп белән, класста кизү торган Айбулат мәктәп бинасыннан урамга соңарыбрак чыкты. Йөз-ике йөз метр чамасы җирне узды микән, күрде – стадион кырыендагы чирәмлектә өч укучы малай әүмәкләшә! Ни булган, нәрсә бүлешә болар? Яннарына йөгереп килеп җитсә – шаклар катты: параллель класстагы ике малай аның партадашы Игорьны җиргә егып салганнар да йодрыклары белән дөмбәслиләр!

Айбулат, озак уйлап тормастан, минуты-секунды белән тегеләр өстенә яшь карчыгадай ташланды! Берсен бер якка, икенчесен икенче якка тәгәрәтеп җибәрде. Тегеләр көтелмәгән бу хәлдән тәмам югалып калдылар. Әйтер сүзләре, тотлыга-тотлыга, бугазларында төртелде бугай. Игорь да төшеп калганнардан түгел икән, берсенең авыз-борыны канга баткан...

– Кагыласы булмагыз! Ул минем классташым...

Айбулатның кисәк яңгыраган бу таләпчән сүзләре тегеләрне бик тиз игә китерде, чирәмлектә яткан сумкаларын эләктереп, табан ялтыраттылар.

– Рәхмәт... – диде Игорь, кыенсынып кына. Аның да борыныннан ике тамчы кан чәчрәп чыккан иде.

– Дусларны ярдәмнән ташламыйлар, – дип кенә әйтә алды Айбулат.

Менә шундыйрак хәлләр булган иде ул чакта. Бактың исә теге малайлар, икәүләшеп, Игорьдан акча бирүен таләп иткәннәр икән. Ә ул менә җебеп калмаган, каршылык күрсәткән, үзара дөмбәсләшергә керешкәннәр...

Игорьларның гаиләсе, җылы якка киткән кошлар кебек, йомшак климатлы Кавказ якларына күченеп китте. Адрес алмашырга ничектер вакыт та, җай да булмады бугай. Классташлык гомере нибары бер ел чамасы дәвам итте дә, язмыш кушуы буенча, аралар бөтенләйгә өзелде...

Теге малайлар бигрәкләр дә эгоист, алдакчы, тар күңелле булып чыкты шул. Менә сиңа мә, авыз-борыны җимерелгәне, укытучысына Игорь мине кыйнады, дип әләкләгән икән. Бу уңайдан класс җитәкчесе – рус теле укытучысы Игорьны классташлары каршына бастырып, болай дип ачуланды:

– Твой поступок мы осуждаем, Краснов! За такое поведение ты долго будешь краснеть.

Игорьны ул чакта бары тик партадашы Айбулат Мөхәммәтов кына яклап чыкты, чөнки чын дөреслекне ул гына яхшы белә иде.

Хәтердә калган бу вакыйга ни өчендер күңелдә әнә шулай тирбәлеш алды бу минутларда. Поезд коридорында тукталышка хас шыбырдау, ыгы-зыгы авазлары ишетелде. Шулчак йомшак кына итеп, купе ишеген шакыдылар. Ачты ишекне. Анда студент кыяфәтле, кулына сумка тоткан яшь бер егет басып тора иде. Исәнләштеләр. Айбулатның иң өске шүрлеккә куелган спорт киемнәре белән дыңгычлап тутырылган симез биштәр капчыгы янына төнге пассажирның юка сумкасы да менеп кунаклады. Яңа юлдашы күп сөйләшми торганрак егеткә охшаган иде. Айбулат үзе дә сүз куертып торуны кирәк санамады. Кайбер станцияләрдә кыска тукталыш ясый-ясый, поезд алга барамы-бара – тагын нәрсә кирәк Ходайның мосафир бәндәләренә...

Айбулат беләзегендәге сәгатенә күз төшереп алды – төнге унбер тулып килә икән инде. «Иртәгә җитди ярышлар көтә, йокларга, ял итәргә кирәк», – дигән уй күңеленнән йөгереп узды. Икенче катта хәстәрләп җәелгән

урын-җир аны байтактан бирле көтеп тора лабаса. Сикереп менеп, казна мендәренә башын төртте дә йокыга сабышты ул.

Ә тышта, бик биектә җемелдәшеп һәм иренеп кенә, сентябрь йолдызлары җирдәге төнге тормышны сүзсез генә күзәтәләр иде бугай...

* * *

Уянып китеп, түбәнге катка текәлеп караса, исе китте – студент егет кайсыдыр станциядә төшеп калган булса кирәк, урыны буш, шүрлеккә куелган сумкасы да күренми. «Шушы кадәр дә таза йокы булса булыр икән...» – дип, үз-үзенә сөйләнеп, купе идәненә сикереп төште Айбулат.

Проводник китергән иртәнге чәйне эчкәннән соң, озак та үтмәстән, поезд Екатеринбургның борынгырак стильдәге вокзалына килеп туктады. Айбулатның башында һаман бер чама уйлар өере бөтерелә иде: «Чынлап та классташы Игорь белән очрашыр микәнни ул бүген? Кайда диген әле – келәмдә бит. Бәлки, Игорь дигәнең бөтенләй икенче бер егеттер?.. Азмыни тормышта фамилияләрнең тәңгәл килү очраклары?»

Иртәнге сәгать унда Россия күләмендә татарча көрәш ярышлары башланачак. Заманча төзелгән спорт комплексы. Шуның кыл уртасында көрәшүләр кызачак түгәрәк мәйданчыклар әзерләп куелган. Зал тамашачылар белән шыплап тулган. Хөкемдарлар, комментаторлар, телевидение операторларының игътибары «аучы» комарлыгы белән келәм уртасына төбәлгән: бер генә мизгелне дә күз уңыннан ычкындырырга ярамый дигәнне аңлата бу. Әйе, ни булса – шул булыр бүгенге көрәш-тартыш мәйданында.

Ни гаҗәп: беренчеләрдән булып, келәмгә Екатеринбург һәм Казан егетләре чакырылды. Менә, ниһаять, көрәш тамашасын алып баручы, кулындагы микрофонын уйнатып, ике көндәш спортчы белән таныштыра башлады:

– Зәңгәр почмакта... Айбулат Мөхәммәтов.

– Кызыл почмакта... Игорь Краснов.

Шулкадәрле туры килүен кара син – Игорь исемле көрәшченең фамилиясе дә кызылдан, сөлгесе дә кызыл. Зал тулы тамашачылар да бу тәңгәллекне сизделәр булса кирәк, гөрләтеп кул чаптылар... Таблода – ике спортчының да сурәте һәм соңгы нәтиҗәләре урын алган. Көчләр тигез кебек. Ләкин спортның бу төрендә фараз кылу, гөман итүләр бик четерекле нәрсә, анда көтелмәгән хәлләр, акланмаган өметләр булырга да бик мөмкин – моны истән чыгармаска кирәк.

Айбулат дулкынланмаска тырышты. Аның каршында – еракган Игорьга охшаган да, охшамаган да кебегрәк егет басып тора иде. Ни әйтсәң дә, мәктәп елларындагы танышлыктан соң унөч ел вакыт сизелми генә узып та киткән бит. Шулай шул: вакыт җил кебек исә дә урманнар артына китеп югала. Ә кешеләр хәят киңлегендә яши, сулый, үз дөньясын кора. Кемнәрдер күпләр көнләшерлек уңышларга ирешә, кемнәрдер – ни үкенеч – тайгак юлга басып, тормыш арбасыннан мәтәлеп төшә. Язмышлар гамәл дәфтәренә әнә шулай төрлечә языла шул...

Зал тутырып, рампаның көлтә-көлтә төсле утлары уйный. Алар җитез кайчы канатлары кебек көрәш мәйданчыгын да турап-турап узалар. Менә, ниһаять, төсле утлар уйнавы тукталды, зур прожектор келәмне көн яктысы белән сугарды.

Хәлиткеч мизгел җитте: хөкемдар ике якта басып торган ике көрәшчене кулы белән ымлап, уртага, үзе янына чакырды. Мускуллары уйнап торган егетләр хәзер инде бер-берсен якыннан үтәли күрәләр иде...

Шыгрым тулы зал берзаман гаҗәпләнүдән тып-тын калды: чөнки гомер булмаганны ике көндәш егет, туганнарча җылы кочаклашып, башларын бер-берсенең иңенә куеп, бермәл тып-тын басып тордылар! Әйе, алар – элеккеге классташлар – байтак еллар үтсә дә, бер-берсен тиз таныды! Игорь әллә ни үзгәрмәгән дә кебек: бала чактагыча терекөмештәй җемелдәп торган күзләр, тупыйк борын... Аларның бер-беренә үз исемнәре белән эндәшүе, аркаларын кагулары күпне күргән судья агайны да сискәндереп җибәрде бугай. Гадәттә, көрәшкә чыккан көндәшләр иң әүвәл җете күз белән бер-берсен «ашый» торганнар иде, ә болар...

Әлеге аңлашылып бетмәс күренештән тын калган зал бер мәлне кинәт шартлады! Кызганмыйча икесенә дә көчле алкыш яудырдылар...

Келәм – кәнфитләнеп, вакыт үткәрә торган урын түгел. Һәр икесе дә тиз арада үз-үзен кулга алдылар.

Ниһаять, ныклы, ләкин саңгырау гына кыңгырау авазы яңгырады!

Көрәш, тартыш, көчләрне һәм осталыгыңны сынап карау тамашасы башланды. Көрәш яратучы тамашачылар игътибар итми калмаганнардыр: Игорьның киң җилкәсе, калын муены көчле спортчы булуы турында сөйли иде. Ләкин Айбулат та төшеп калганнардан түгел – аның беләк мускулларына чаклы чүлмәктәй кабарып тора. Димәк, көчләләр очрашуы булачак икән бу. Тамашачылар нәкъ менә шуны көтә.

Беренче тартыш. Ул разведка төсендәрәк, ягъни бер-береңнең йөрешен, алымнарын, техник әзерлеген барлау кебегрәк барды шикелле. Ләкин алга таба билгә салган сөлгеләр ныграк кысыла барды. Икесенең дә гәүдәләре сыгылмалы, йөрешләре саллы. Сөлге белән йолкып, бер-берсенең көчен дә, алымнарын да сынамакта болар. Максатлары – көндәшен ничек тә аркага салу, шушы форсатны ничек тә кулдан ычкындырмау. Икесенең дә беренче ыргымнары очко алудан узмады. Алга таба ни булыр – хәзергә моны берәү дә әйтә алмастыр, мөгаен.

Акрынлап, үзара тартышу көчәйде. Картина шундыйрак төс ала бара: бер-берсеннән уздырып, әле билдән йолкыйлар, әле үзләре белгән осталык белән артка таба чигенү ягын да чамалыйлар. Үзара дусларча елмаю белән башланып киткән көрәш инде җитди чырайларга алышынган иде. Чөнки «кем-кемне?» дигән сорау ике егетнең күңелендә дә, залның электрланган гөмбәзендә дә сүнмәс очкыннар рәвешендә эленеп тора иде.

Игорь көрәш мәйданында үзен шактый иркен хис итә. Салмак яисә кискен хәрәкәтләрен оста ясый, көтелмәгән һөҗүм ясаулардан да куркып тормый. Аның каравы, Айбулат хәйләкәр йөрешләр ясый. Көрәштә аның үзе генә белгән төп принцибы бар: һәрбер хәрәкәтең адреслы һәм нәтиҗәле булырга тиеш.

Аларның көрәш-тартышын, арсеналларында булган чараларны тамашачылар үз күзләре белән күреп торды, егетләргә теләктәшлек итте.

Көрәш әнә шундыйрак рухта дәвам итте. Зал, уен агымына ияреп, умарта күчедәй кайный, көчле кул чабулар дулкын-дулкын булып, стадион диварларына килеп бәрелә дә кире кайтарылып төшә. Судья исә аларның

көрәшен искиткеч төгәллек белән күзәтә, кул хәрәкәтләре белән аларга теләктәшлек итә.

Игорьның чираттагы һөҗүме уңышлы булып чыкты. Алагаем селтәнү белән ул Айбулатны келәм читенә ыргытты, өстәмә очко алды.

Айбулат та җавапсыз калмады: шунда ук көндәшен келәмгә тәгәрәтте. Екатеринбург егете җитез генә торып басты, сөлгесен алга суздны.

...Ниһаять, көрәшнең соңгы минутлары чишелешкә таба бара! Көчләр тигез дисәк тә, нәкъ менә шушы минутларда җиңүче ачыкланырга мөмкин. Шунлыктан үзара тартышу кызганнан-кыза барды, егетләр тәмам тирләп чыкты, маңгай тирләре тере тамчылар булып, як-якка чәчри иде...

Айбулат, соңгы алымны кулланырга вакыт дип уйлады һәм хәлиткеч форсат эзләде. Исәбе болай иде: көндәшенең билен сөлгесе белән ныклап эләктергәннән соң, гәүдәсенең бөтен авырлыгы белән кинәт кенә аска таба чүгәләп тартылып, Игорьны күтәреп алу. Нәкъ шулай эшләде дә. Аннары ул егетне, сул якка таба алагаем селтәп, аркасына салды...

Игорь аркасына ауган җиреннән аягына торып басты. Җиңүче – Казан егете Айбулат Мөхәммәтов! Айбулат иң әүвәле Игорьның уң кулын югары күтәреп, аның профессиональ осталыгын искәртергә онытмады, әлбәттә. Шуннан соң бик нык итеп янә кочаклаштылар. Аларның һәр икесе дә ихластан егетләрчә елмая иделәр. Аңлаган кешегә бу елмаю – сабыйларның керсез-гөнаһсыз елмаюына тиң иде. «Кеше кайчан матур була? Елмайган чагында...» дип, бер акыл иясе бик тә дөрес әйткән. Әлеге самими күренеш шушы хакыйкатьнең ифрат дөрес икәнлеген тормыштагы яңа бер мисал белән раслады.

Тамашачылар белән тулы зал, егетләрнең искитмәле күркәм көрәшенә рәхмәтен белдерү йөзеннән, гөрләтеп кул чапты!

Чү! Алдагы рәтләрнең берсеннән гөрнәдирдәй ике егет калкып чыкты да ашыгып, келәмгә таба юнәлде. Аларның хәрәкәте, үз-үзләрен тотышы бер дә яхшыга охшамаган, йөз-чырайларыннан ук усаллык төсмерләре бөркелеп тора иде. Болар буза куптарырга, бәхәс-мазар оештырырга ният кылган иде булса кирәк. Валлаһи шулай! Сирәк булса да, көрәш ярышларында андый хәлләр булгалый. Алай-болай кирәге чыкса дип, Айбулат йодрыкларын йомарлады.

Игорьның җанатарлары келәм уртасына кереп басты. Аларның ни кыланырга, нинди җәнҗал куптарырга җыенуларын берәү дә белми иде, билгеле. Ә менә Игорь үзе вакыйганың ничек төенләнүен бик вакытлы һәм дөрес сиземләде булса кирәк. Ни әйтсәң дә, ике якның әзерлекле командасы да бар бит әле бу залда.

Игорьның җанатарларына әйтер сүзе, әмере бик кискен булды:

– Кагылмагыз! Ул минем классташым!

Алар – кайчандыр ике сыйныфташ, кочаклашып, көрәш мәйданчыгыннан акрын гына залга таба кузгалдылар...

– Ә хәзер безгә чәй эчәргә кайтабыз... Чәйгә! – Игорь, ихлас бер караш һәм ышаныч беләнерактагы-якын классташына әнә шул сүзләрне пышылдады.

# ЕРАККА КИТЕП КАРАП

Кайсы гына каләм иясеннән сорасаң да, иҗат юлының «Казан утлары» журналында басылып чыгудан башлануын әйтер... Бу табигый да. Үзенең багланышы, юнәлешләре һәм таләпләре иң югары биеклеккә куелган басмада чыгуы – һәр каләм иясенең милли әдәби, мәдәни мәйданда тәүге имтихан тотуы бит ул. Имтиханны әзерлексез генә үтеп булмый шул... Төрле газета-журналларда дистә еллар шигырьләрен бастырып килгән, нәшриятларда китаплары чыгып, радио-телевидениедә җырлары яңгырап та, «Казан утлары»нда бер генә әсәре дә басылмаган авторлар белән очрашканым булды... Аларны һич кенә дә кимсетеп, гаепләп әйтүем түгел. Әмма, әдәби иҗатка җитлеккәнлек, өлгергәнлек таныклыгын, әйткәнемчә, «Казан утлары»нда имтихан тотканнан соң гына алып була... Имтиханны һәркем үзенчә тота...

Халкыбызда «Кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлыйсың», дигән бик тә мәгънәле әйтем бар. Әгәр дә ки, ул арбага мең еллык мәдәниятебез, әдәбиятыбызның асыл мәрҗәннәре, бай мирасы төялгән икән, һәм ул бүгенге көндә шул нигездә олуг бер халыкның рухи алгарышына юнәлеш тота икән, нигә әле шул арбага, фәкать шул арбага гына утырмаска?!

Моннан йөз ел элек гамәлгә куелган «Безнең юл», илдәге вазгыятькә карап, исем-атамаларын үзгәртә-үзгәртә, «Яңалиф», «Атака», «Совет әдәбияты», «Казан утлары» булып, безнең көннәргә килеп җитте... Ул дәүләт тарафыннан гамәлгә куелып, әдәби-нәфис, иҗтимагый, сәяси миссияне үтәргә, бердәнбер идеологиягә хезмәт итәргә дучар иде... Бу яктан караганда, ул чыннан да чикләнгән кысаларга күнү, яңа хуҗаларның арбасына утыру буладыр... Әмма «Безнең юл»ның – безнең милли әдәбиятыбыз, мәдәниятебезнең алгарыш юлы – рухи елъязмасы булганлыгына бернинди шик юк...

*«Адәм баласы үткәннәре белән яши, / киләчәге бары хыялда»*, дип язган идем кайчандыр... *«Һәр яңаны эзләп табабызмы, / табып югалттыкмы күптәннән, / Киләчәккә узып барабызмы, / кайтып киләбезме үткәннән?»* – дип тә сорау куелган икән... «Казан утлары» журналына баш мөхәррир булып билгеләнгәч, аңарчы ике елга якын «Мирас» журналын кабаттан гамәлләштерү вазифалары белән мәшгуль көннәрдә әлеге «Үткәннәр һәм Киләчәк» турындагы уй-фикерләр тагы да дәррәү уянып киттеләр. Редакциянең эш бүлмәләрендәге төрледән-төрле тартмалар, шкафларда журналларның беренче саннарыннан алып бүгенгәчә сакланган-тупланган 1000нән артык нөсхәсе – 300гә якын шыплап тулган томнарын күреп хәйран калган идем... Кысылып тыгызланган һәр журнал битләрен актарганда, бүлмәгә шул чорларның һавасы, исе тарала. Авторларның йөз-кыяфәтләре җанланып. каршыңа килеп баса... Туксан биш елда өч имля алыштырып, репрессияләргә дучар ителеп, ничәмә-ничә күченүләр үтеп тә, бер генә санын да югалтмаган тере, исән-сау журнал бит ул.

2006 елда үзенең 1000 нче саны басылып чыгу уңаеннан редакция хезмәткәрләре бар иткән «Сүнмәс утлар балкышы» кулыма килеп керү белән өстәл китабыма әверелде. Никадәрле ният ныклыгы, рухи кодрәт иясе булырга кирәк шундый зур хезмәтне башкарып чыгу өчен. Бу эшкә айлар буе төн йокламый әлеге томнар тавын күчергән, төпсез төбеннән энҗе-мәрҗәннәрен табып чыгарган тынгысыз каләмдәшебез Рәфикъ Юныс кына алынуына ышана аласың бүген. Алга таба китеп, тагы да шуны әйтим, журналыбызның 95 еллыгын үткәрү ниятенә кереп йөргәндә, Рәфикъ абый «Сүнмәс

утлар балкышы»ның дәвамын, яңа басмасын әзерләргә кереште... Әлеге томнарның киләчәк язмышына беребез дә битараф түгел. Аларның шундый ук тулы саннары Республика китапханәсендә дә саклануын телә идем... Үзебезнең кысан бүлмәләрдән киңрәк мәйданга чыгару – «Казан утлары» музее өчен өстәмә бүлмә бирүләрен сорап та күп мәртәбәләр мөрәҗәгать иттем... Журналның 1100нче саны басылып чыгу, инде әйтеп үткән 95 еллыгын республика күләмендә билгеләп үтәргә дигән теләкләребез дә хыялда гына калды... Моны ничек аңларга?.. Үткән-беткән – җилгә очкан дипме?.. Заманабызның олуг шагыйре Мөдәррис Әгъләмнең «Үз хәлеңне анык белү өчен еракка китеп кара», дигән гыйбарәсе һәммәбезгә таныш... Шагыйрьнең әлеге сөале – ирешкәннәреңне чит-ятларның күз-карашы аша чагыштырып карарга чакыруы түгел, ә иң беренче нәүбәттә, бүгенге хәлеңә, вазгыятькә ерак бабаларың ирешкән, яулаган биеклекләрдән торып карарга, үткәндәге бөекләрнең эшен үрнәк итәргә, ялгышларыннан гыйбрәт алырга, гаепләре, гөнаһлары булса, ярлыкау сорарга, тәүбәгә килергә кирәк дигән нәсыйхәт ләбаса.

* * *

«Еракка китеп кара» гыйбарәсенең турыдан-туры мәгънәсе дә безнең өчен бик әһәмиятле...

Халыкара төрки телле мәдәниятләрнең «ТЮРКСОЙ» оешмасы ел саен бер илдә төрки телле әдәби журналларның форумын үткәреп килә. Дистә еллар буе үткәрелгән бу җыенда «Казан утлары» үзенең эчтәлеге, сыйфаты, милли әдәбиятларның барышына тәэсире, йогынтысы, әдәбият фәненең куелышы белән иң югары бәяләргә лаек булды. 2017 елгы форум Казакъстанның рухи башкаласы статусын алган Төркестан каласында үтте. Анда кардәш әдәби журналларның баш мөхәррирләре бертавыштан Төрки телле әдәбиятларның «Ел язучысы» дип, журналыбызда үзенең даһи әсәре «Тукайча татар кодексы»н бөтен дөньяга чыгарган татар шагыйре Зиннур Мансуровны сайладылар.

Шул ук елны профессор Мостафа Өнәр чакыруы белән Төркиянең Измир шәһәрендәге Мәрмәрә университетының татар әдәбияты кафедрасы галимнәре һәм аспирантлары белән очрашырга насыйп булды. Андагы кафедра китапханәсе киштәләрендә «Казан утлары», «Мирас» һәм башка журналларның күп еллардан тупланган саннарын күреп, тагы да хәйран калдым. Мостафа бәй Өнәр аларның Татарстанның Милли китапханәсе тарафыннан даими җибәрелеп торуын әйтте.

– Татар әдәбияты – төрки телле әдәбиятлар мәйданында иң алдынгы әдәбият! Татар шагыйрьләре дөнья күләм мәйданда ат уйната, – дип бәяләде ул. Үземнең бер сәгать буе татар шагыйрьләренең шигырьләрен яттан (укуымны) сөйләвемне аның сүзләрен дәлилләү, дип үсендерде. Бүген еш кына, хәзер милли әдәбиятыбыз торгынлык кичерә, дигән сүзләр ишетергә туры килә... Мин моның белән элек тә килешмәдем, хәзер дә килешмим. Олы бер халыкның әдәби, мәдәни барышына 5-10 елда дөнья күргән әсәрләргә генә карап, бәя бирү дөрес түгел. Төп бәяне вакыт үзе бирә... Гәрчә соңгы 5-10 елда журналыбызда басылган роман, бәян, поэмаларның кайсысын торгынлык хилафларында гаепләп булыр икән? Үзем мөхәррирлек иткән дүрт елда журналда урын алган 18 роман, 39 бәян, 8 поэма, йөзләрчә шигырь, хикәяләргә карата да: «Нәкъ безнеңчә милли, моңлы көй» дип әйтә алам. Аеруча прозабыздагы сан һәм сыйфатның уңай үзгәрешләрен күрү, тану, бәяләү зарур... Атап үтелгән сандагы әсәрләрне бер генә кардәш әдәби журналларда да күргәнем булмады... «Наш современник», «Дружба народов», «Мир» һ.б. журналларда роман, повестьлар «журнал версиясе» дип кыскартылып, реклама рәвешендә генә тәкъдим ителә бит. Танылган тарихчы әдипләребез Р.Батулланың «Мур кырылышы», «Ил башы», Ф.Бәйрәмованың «Һиҗрәт», В.Имамовның «Карабәк», И.Гыйләҗевнең «Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядәге татар әсирләре», Х.Галидәннең «Патша

солдаты Әхмәтнасир», Н.Яһудинның «Атлы казаклар», Ф.Садриевның «Тургай», М.Әмирхановның «Бибимәмдүдә», М.Галиевнең «Тимә – яшәсен», К.Кәримовның «Тургайлы болытлар», Ә.Моталлаповның «Гамь», Д.Салиховның «Чукрак», Н.Гыйматдинованың «Нурулла», А.Әхмәтгалиеваның «Таллы күлдә былбыл бар» роман-бәяннары, Ф.Гыйззәтуллинаның «Илаһилык вә даһилык», Ә.Рәшитовның «Мөхәммәт», Р.Харисның «Уба», Р.Шәриповның «Биш алма», «Җомга» поэмалары, Р.Фәйзуллин, Р.Гаташ, З.Мансуров, Р.Вәлиев, Г.Морат, Т.Галиуллин, Д.Заһидуллина, З.Хәким, Р.Рахман, Р.Корбан, Г.Гыйльманов, В.Нуриев, Р.Галиуллин, Р.Шаһиев, С.Шәмси, Ф.Хуҗин, А.Юнысова, Р.Ханнанов, Р.Мөхәммәтшиннарның әсәрләрендә нәфис сүз сәнгатенең күркәм төсләрен күрәбез түгелме? Галимнәребезнең дистәләрчә фәнни язмаларын бүгенге көн милли әдәбиятыбызның сулышын, йөрәк тибешен чагылдырган иҗади казанышлар дип бәяләргә кирәк...

Журналыбыз тәрҗемә әдәбиятка да ишекләрен киң ачты. Галим, прозаик Р.Галиуллин рус язучысы А.Егинның күләмле «Үзбәк хан», Чиләбедә яшәп, рус телендә иҗат итүче Рөстәм Вәлиевның бөек Тукаебызга багышлап язган «Дөнья гаме» романнарын, тәнкыйтьче шагыйрь Мөдәррис Вәлиев атаклы Чыңгыз Айтматовның «Чыңгызханның ак болыты» кыйссасын редакциябезнең мөрәҗәгате-соравы буенча тәрҗемә итеп бастырдылар. Әйткәнемчә, үзем мөхәррир буларак укып, үз иткән әсәрләрне генә искә алдым. Исемнәрен атамаган каләмдәшләрем, зинһар, гафу итә күрегез. Дистәләрчә шагыйрьләребезнең, шул исәптән үземнең иҗатыма кагылганнарына башка бер форсат-җай чыгып тукталырбыз әле...

«Еракка китеп кара» гыйбарәсен тагы да бер яңа мәгънәдә, ерак киләчәкне күздә тотып фаразлау да өметсезлеккә урын калдырмас дип уйлыйм... Соңгы елларда әдәбиятыбызга килеп, «Казан утлары»нда өлгергәнлек таныклыгы алган һәм алачак дистәләрчә яшь талант ияләренең иҗаты «еракка» җитәчәгенә шундый ышаныч белән карарга этәрә... Милли мәгарифебез дә газиз ана телебезне саклау, үстерүнең яңа мөмкинлекләрен ачар, халкыбызның милли үзаңы, бердәм мәдәни, әдәби мохитнең тараюына чик куяр дип ышанам... Глобаль дөньяның да уңай алшартлары табылып тора бит. Республикабызның Милли китапханәсе иң беренчеләрдән булып, үзенең тулы фондын цифрлаштыруга керешкән иде... Бер ел дигәндә, үзендә сакланган «Казан утлары»ның барлык томнарын электрон кулланышына күчереп тә куйды... Дөньяның биш кыйтгасында яшәүче һәркем санаулы минутлар эчендә аның йөз еллык мирасы белән дә, бүгенге хәзинәләре белән дә танышу мөмкинлегенә ия. Мең рәхмәт аларга... Милли ана телебезнең киләчәк язмышында Республикабыз җитәкчелегенең игътибары, дәүләти җаваплылыгы конкрет эшләр белән артуын әйтер идем... Иң мөһиме, «Казан утлары» редакциясе, үз эшләренең осталары булган яшьләребез ерак киләчәкне якынайту теләгендә яшиләр, хезмәт куялар, иҗат итәләр...

Журналыбызның олуг юбилее – язучылар, әдәбиятчыларның гына түгел, ә дөньяның биш кыйтгасына таралган дистә миллионлы татар халкының да бәйрәме. Тагы да бергә булырга, бердәм булырга язсын!

**Илфак ИБРАҺИМОВ**

# «БУ БИТ – АКАДЕМИК БАСМА!..»

«Казан утлары» журналындагы (2020 ел, 1 нче сан) «Кызыл кара белән» рубрикасында Рамил Ханнановның «Чи утын муртая...» дигән язмасын укыгач, «Бер өтернең кеше үтерү яки аның гомерен саклап калу очракларын онытмыйк», дигән җөмләсе байтак хатирәләрне уятты.

Минзәлә педагогика училищесында татар теле һәм әдәбияты дәресләрен Мөхәммәт абый Гарифуллиннан укыдым. Мөхәммәт абый тирән белемле, үзенең фәнен яратып, җиренә җиткереп укыта белүче, бик пөхтә, шул ук вакытта пөхтәлекне укучыларыннан да таләп итүче, олпат шәхес иде. Сугышка кадәр үк Казан педагогика институтында талантлы шагыйрьләр Сибгат Хәким, Хабра Рахманнар белән бергә укыганлыгын, Минзәләгә хәрби курсларга укырга килгән шагыйрь Муса Җәлил белән берничә тапкыр очрашуларын искә ала. Шигырьләр ярата. Классик шагыйрьләрнең әсәрләрен яттан укып, мисаллар китерә, үзе белән булган төрле вакыйгаларны сөйләп көлдерә... Кыскасы, педагог белән студент арасында бернинди киртәләр юк, гүя без – аның яшьтәшләре. Гомумән, ул елларда педучилищедагы өлкән яшьтәге ир укытучыларыбызның барысы да диярлек авыр фронт юлларын үткәнгәме, ә өлкән яшьтәге хатын-кыз мөгаллимәләребез тыл газапларын кичергәнгәме – бик шәфкатьлеләр, алардан үзгә бер җылылык, мәрхәмәт бөркелеп тора иде.

Мөхәммәт абый Гарифуллин «Казан утлары» журналының даими һәм бик таләпчән укучысы булып та истә калды. Редакция белән бәхәскә кереп, хатлар яза, җибәрер алдыннан аларны почеркы матур булган студентыннан күчертә, хәер, аның үзенең дә язуы гаҗәеп матур иде. Ак шигырь язучы шагыйрьләрне пыр туздырып тәнкыйтьли... Кыскасы, «Казан утлары» журналы аның өчен (безнең өчен дә булып чыга бит инде) дәреслек вазифасын да үти иде. Әйтик, еш кына, журналның билгеләп килгән урынын ачып, диктант яздырта, аларны өлкән курстагылардан тикшертә, билгеләрне дә алардан куйдырта торган иде. Сүз уңаеннан әйтеп үтим, шундый, ягъни эшен ышанып тапшыра торган, яраткан студентларының берсе, бүгенге көндә 17 китап авторы, бик яхшы балалар шагыйре, соңгы елларда «Ак калфак» оешмасы үткәргән әдәби конкурслар җиңүчесе – Сарманнан Вәсимә Хәйруллина-Талипова. Аның, Мөхәммәт абый Гарифуллин юлламасы белән җибәрелеп, педучилищеда укыган вакытта ук «Казан утлары», «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә») журналларында шигырьләре басыла башлаган иде.

Ә без әле бөредә... Бер төркемдә, бергә укыган сабакташым, еллар үткәч, Түбән Кама газетасын үзенең лирик парчалары белән бизәячәк Рәшит Рәхимов белән Мөхәммәт абыйның «Шигърият» түгәрәгенә йөри башладык. Күп тә үтми ул безгә Минзәлә турында җыр тексты язып килергә кушты. Җыр текстының шигырьдән нәрсәләр белән аерылуын әйтте. Бу эшне ул, түгәрәккә йөрүчеләргә генә түгел, үзе укыткан һәр төркемгә кушкан икән. Шулай итеп, шигырьләр бик күп җыелган. Гадәтенчә, шигырьләрне башта яраткан төркеменә – Вәсимәләргә тикшерткән. Ул төркемдә булачак композитор Рәис Нәгыймовның да укуын әйтеп үтим. Калганнарын тагын кемнәр белән сайлаганнардыр, белмим, әмма минем «Ямьле безнең Минзәләбез» тексты, җырга яраклы дип табылган. Һәм аңа, ул елларда училищебызда мөгаллимлек иткән композитор Әнвәр Бакиров көй язган иде. Мин ноталарын күргәнче үк,

Мөхәммәт абый Гарифуллин аны «Социалистик Татарстан» газетасына җибәреп, бастырып чыгарды. Шундый игелекле гамәлләре белән укытучыбыз үзенә карата чиксез мәхәббәт тәрбияләде. Табигый ки, «Казан утлары» журналына да. Иманым камил, бүгенге көндә аның студентлары арасында журналны алдырмаган мөгаллимнәр юктыр.

Беркөнне укытучыбыз дәрескә үзенә бөтенләй дә охшамаган уйчан йөз белән килеп керде. Баш кагып кына исәнләште, кул ишарәсе белән генә утырырга кушты. Аерылгысыз дусты «Казан утлары» журналы белән кара төстәге папкасын өстәлгә куйды да, акбур алып, класс тактасына: «Атарга ярамый калдырырга» дип, тип-тигез итеп язып куйды. Һәм, безгә борылып, «Рәшит, чык, өтерне кайда куясың?» – дип, кулындагы акбурын сабакташыбызга сузды. Рәшит чыгып, берничә секундмы, минутмы тактадагы сүзләргә текәлеп карап торганнан соң, «ярамый» сүзеннән соң өтер, «калдырырга» сүзеннән соң өндәү билгесе куйды. Мөхәммәт абыйның йөзе дәррәү яктырып, балкып китте, Рәшитне башыннан сыпырып, кочагына алды, ә тегесе тыелгысыз күз яше белән елый башлады. Аңа без дә кушылдык. Укытучыбыз, классыбыз белән яшь коеп утыруыбызга бик гаҗәпләнде. Чөнки Рәшитебезнең әле генә әнисен җирләп килүен белми иде... Аннан соң үзе дә сулкылдый язып: бу юньсез җөмләне тикшертеп, кәефеңне кырдыммы әллә дип курыктым, диде. Шәкертен тынычландыргач, үзе белән алып кергән журналның кәгазь кыстырган битен ачып, минем алга куйды. Карандаш белән астына сызылган урынга бармагы белән төртеп: «Хәзер син менә бу җөмләне укы», – диде. Күрсәтелгән юлны эчтән генә укыдым да, берни аңламыйча аңа күтәрелеп карадым. Инде шигырьне тулысынча укы, диде ул. Кычкырып укы, башкалар да ишетсен...

1962-63 еллар иде шикелле. Журналның ничәнче саны, шигырьнең авторы кем? Истә калмаган. Ә менә мәгънәсе яшәү белән үлем арасында ук булмаса да, бик сәер, ике ноктадан соң тезелеп киткән тиңдәш кисәкләр «очты-очты арбалар очты, очты-очты каргалар очты» кебегрәк. Һәм аларның алда әйтелгән фикер белән берниндидә уртаклыгы юк сыман иде. «Менә монда өтер яки сызык сорала, монда да шул ук хәл, ә биредә тулы бер яки ике юл төшеп калган булырга тиеш», диде Мөхәммәт абый, авыр сулап. Хәер, бу юллар әллә ничә өтер, әллә ничә сызык куйсаң да, йөрәккә барып җитә торган нәрсәләр түгел... Аннан ачынып, журналны өскә күтәреп: «Бу бит – академик басма!.. Каләм язганны балта белән дә юнып алып булмый, исегездә калсын!» – диде.

Чал чәчле мөгаллимемне күз алдына китерәм дә, бүгенге көндә газета-журналларны аның кебек сүзен сүзгә укып, фикерләрен укучылары, студентлары белән дә бүлешеп, иншалар яздыртып, әсәрне рольләргә бүлеп укытып, дәрес бирүче укытучылар күп микән дип уйлап куям.

«Казан утлары» журналының – «Совет әдәбияты» булып чыккан елларын искә төшерсәк, безнең гаиләгә, әткәй сугыштан кайткачтыр дип исәплим, даими килеп торды ул. Тышлыгының төсе башта куе, караңгырак зәңгәр төстә. Кытыршырак тышлыгын бармак белән сыпыргаласаң, кечкенә генә йомычкалар да кубып төшә иде. Шул вакытта башыма: «кәгазьне агачтан ясыйлар диюләре хак икән», дигән уй килүен хәтерлим. Андый кәгазьнең соры төстәгесенә кибеттә сабын, кильки кебек әйберләр төреп бирәләр иде ул елларда.


Әткәй, язучыларга мөкиббән киткән кеше. Бигрәк тә фронтовик язучыларга. Сибгат Хәкимнең «Дуга» поэмасын, үзе дә шул җирләрдә сугышканга күрәдер, еш искә ала иде. Кияве Фаил Шәфигуллинны да «Әдип» кенә дип йөргәнен язганым да бар... Кич җитеп, яктысы бөтен өйгә төшсен өчен кучкар башына куелган җиделе лампа яктысында дәресләрне әзерләп бетергәч, журналдагы әткәй сайлаган әсәрне кычкырып уку башлана. Башта әнкәй укый. Аннан: «Мә, менә монда калдым, авызым кипте», – дип, журналны әткәйгә бирә. Әткәй укый. Алга таба, ул вакытта күрше авылдагы урта мәктәпкә йөреп укучы абыем дәвам итә. Без – вак-төякләр – фәкать тыңлаучылар.

Еш кына күршедәге туганыбыз тиешле Зөһрә апа да безнең белән тыңлый. Зөһрә апа гади колхозчы, гомере буе колхозда сыер сауды, сарыклар да карады, әмма бервакытта да вакытлы матбугаттан аерылмады. Район газетасы, «Ватаным Татарстан» («Социалистик Татарстан») аның хыянәтсез «дуслары» булды. «Совет әдәбияты»н исә, йә безгә килеп тыңлый, йә булмаса алып китеп укый иде. Әмма тыңлаган вакытта шул кадәр бирелеп китә, һич кенә дә тыныч кына утыра алмый, «Ярамай да!» (еш әйтә торган сүзе) дип, кулларын чәбәкләп куя яки башкача мөнәсәбәтен белдерә иде. 1968 ел микән, һәрхәлдә Минзәләгә китәсе елыммы, әллә укый гына башлаган вакытыммы, Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» повесте чыкты. Автор хәтта әткәй өчен дә яңа әдип. Ул, күрәсең, башта повестька күз йөртеп чыккандыр дип уйлыйм, Зөһрә апаны да чакырырга кушуы шуның өчен булгандыр... Укыйбыз да тукталып көләбез, укыйбыз да көләбез. Әнкәй исә, нәрсәнедерраслап яки ни дә булса өстәп куя. Ул да шундый ук авыр елларда укып, яңарак кына ачылган Минзәлә педучилищесының икенче чыгарылышы укучысы булган мөгаллимә. Әсәрдәге «Гитлер тегермәненә чүмечләп су кою» Зөһрә апаны бөтенләй чыгырыннан чыгарды... Кыскасы, журналның бу саны, авылдашлар арасында кулдан-кулга йөреп, тәмам таушалып бетте. Ә «Казан утлары» журналының укылганнарын исә, билләренә бау бәйләп, чормага менгерә торды. Хәлбуки, әткәй безнең өчен махсус: «Яшь ленинчы», «Ялкын», «Пионерская правда», «Костёр» ише балалар матбугатын ел саен яздырса да, күңел ни өчендер, хисле, озаклап, тәмләп укый торган җитлеккән әсәрләр тели иде. Ә андыйлар, билгеле, «Совет әдәбияты»нда... Шулай итеп, беравык чорма минем өчен менә дигән уку залына әйләнде. Шунда менеп, «Без – кырык беренче ел балалары»н тагын бер кат укыдым. КДУда Фазыл Туйкин турындагы диплом эшемне Мөхәммәт Мәһдиев җитәкчелегендә яздым.

«Казан утлары» журналының минем язмышымдагы тагын бер чагылышы – Фаил Шәфигуллин белән кушылуыбызда. 1967 елда мин Казанга килеп, Фаил белән танышып, очрашып йөри генә башлаган көннәрнең берсендә ул миңа «Казан утлары» журналын бүләк итте. Анда Фаилнең теләсә-нинди кызны гашыйк итәрлек бик матур портреты белән шигырьләре чыккан иде...

Ә үземнең «Казан утлары»нда басыла башлавыма килгәндә, ул – 1977 елда булды. Фәрваз абый Миңнуллин Фазыл Туйкин турындагы диплом эшемне кыскартып, журнал варианты итеп эшләргә кушты. Ул «Илебез – кадерле җиребез!» дигән исем белән шул елның 6 нчы санында дөнья күрде. Мондый саллы журналда язмаңмы, шигырeңме чыгу, билгеле, зур дәрәҗә! Алга таба каләмеңне ныграк чарларга, ешрак кулга алырга этәргеч бирүче көч ул! Шулай итеп, бик еш булмаса да заказ белән язылган интервьюлар, очеркларым, поэма, шигырьләрем журналда басыла башлады. Бүгенге көндә мин язучының вакытлы матбугаттан, беренче чиратта, «Казан утлары» журналыннан башка яшәвен күз алдына да китерә алмыйм. Әмма шактыебызның мөмкинлекләре чикле, басмалар кыйммәт, гонорарлар юк дәрәҗәсендә. Соңгы елларда журналның, иганәчеләр табып, төрледән-төрле конкурслар үткәрүе, үз тирәсендәге даирәне җанландыруы – бик күркәм гамәл.

**Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА**



*Равил Фәйзуллин. «Казан утлары» журналының 1989-2013 еллардагы баш мөхәррире.*



*Илфак Ибраһимов. «Казан утлары» журналының 2013-2018 еллардагы баш мөхәррире.*



*«Казан утлары» журналы редакциясе коллективы. Беренче рәттә (сулдан уңга): Гөлзадә Бәйрәмова, Марс Шабаев, Равил Фәйзуллин (баш мөхәррир), Шамил Маннапов, Тәслимә Сибгатуллина, Шаһинур Мостафин; басып торалар – Тәүфикъ Әйди, Камил Сәгъдәтшин, Лилия Гатауллина, Мансур Вәлиев,  Флёра Сабирова, Наис Гамбәр, Флёра Гафурова, Рәмис Гәрәев, Тәгъзимә Шиһабиева, Рәдиф Гаташ. 1997 ел.*



*«Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары, шагыйрь Рәфикъ Юныс галим, РФ Дәүләт Думасы депутаты Фатих Сибагатуллин белән әңгәмә кора. 2013 ел.*



*Язучы Фәрит Гыйльми (1943-1993). Бу айда аңа 75 яшь тулган булыр иде.*




*Г.Камал театрында «Казан утлары» журналының 70 еллык юбилеена багышланган тантаналы кичәдән зал күренеше. 1992 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# ЯРАЛЫ ХӘТЕР, МИЛЛИ СҮЗ КИТАБЫ

## ШАГЫЙРЬ ЛӘИС ЗӨЛКАРНӘЙГӘ – 60 ЯШЬ

Ләис Зөлкарнәй шигырьгә иртә, бик иртә килде һәм сирәкләребездә генә була алганча өлгереп килде: Зөлфәт, Ркаил Зәйдулла, Луиза Янсуар, Лилия Гыйбадуллиналар кебек... Менә аның 15-17 яшьләрендә язган шигырь юллары: аларда бәйгеләргә омтылган яшьлекнең сурәте ләбаса!




*Бу бәйгенең йолалары*
*Бабамнардан калганча,*
*Дәрман белән дәрәҗәсе*
*Йөрәк сайлап алганча.*
*Соң көнгәчә шушы бәйге*
*Соң көнгәчә – тантана.*
*Йолдызларга бәрелә аваз:*
*– На, бахбай! На, на-на-на!*

Яки менә нинди кичерешләр белән яна яшь шагыйрь:

*Давыл тынды диеп уйламагыз,*
*Тояк тавышлары тынса да.*
*Давыл аты*
*алга ыргыла ул*
*Аяклары шартлап сынса да!*

Шул ук вакытта Ләистә бик яшьли милли Гамь, тарихилык ярылып ята иде. Балбал турындагы шигыре ничек бетә, игътибар итик әле: *«...иңнәрендә Тарих. / Яралы яки: / «Ачы тәҗрибәләр мирас миңа – / Яшим кебек борын-борыннан: / Әче тәм ул китми... / – Сагаеп, мин яңа гасырларга орынам...»* – ди Ләис. Ышандыра да! Шунда ук «Бүре сугу» шигыре... Ат өстендә инде көче дә беткән, әмма солы-осталыгы сакланган сиксән яшьлек татар карты... Ул бүрене сугып үтергән чукмарын тоткан килеш иярдә үлә! Шундый ук милли баллада дип «Гармунчы бабай» шигыренә карата да әйтә алабыз. Хәер, укучы минем фикерне аңлагандыр дим, мисаллар җитеп торсын.

Болар – Ләиснең мәктәп баласы чагында, әле университетка кергәнче язган һәм без «Казан утлары»на сорап алган шигырьләре. Хатында яшь шагыйрь, үзе кебек үк яшь талантның Чуваш илендә яшәп, язышып торуын белгәч (Ркаил Зәйдулла иде ул!) сөенеп, мин җибәргән яшьтәшенең шигырьләре белән танышкач, менә ни дип яза: «Теге телепередачаны күрдем. Шигыремне сезнең авыздан ишетү зур куаныч булды миңа. Башкаларныкы да (сүз «Казан утлары»ндагы яшьләр иҗаты турында бара! – Р.Г.)). ...Ркаил дуска хат язармын, дим. Аны көрәшкә чакырам, таза билле көрәшчегә охшый ул!» Бу – 1979 елның беренче мартында язылган. Бүген инде алар күптән университет тәмамлап, шигърият университетларын да үтеп, үсеп, илгә, халыкка киң танылган шагыйрьләр дип әйтә алабыз. Ркаил энебез әнә, гөрләтеп, юбилей кичәләрен уздыра, иҗаты турында күп мәкаләләр чыга тора. Тиздән Ләисебезнең дә (ул апрель башында туган!) зур, мөбарәк бәйрәме. Шул уңайдан языла бу ашыгыч

сызмалар – каләмдәшемне, якташымны котлап, хисләр дә ашыгып агыла. Шигърият өчен горурлык хисләре... һәм кулыма яңа гына кергән «Узганны кабатлау» исемле яңа китабы өчен шатлык халәте... Әйе, әйе, юбилеена чыккан Ләиснең зур, 527 битлек китабы белән танышудан соңгы кичерешләр бу язмамда! Гадәти генә китап түгел бу, шикләнми әйтәм, шигъриятта гаҗәеп бер вакыйга да! Ул шагыйрьнең бик кызыклы кереш сүзе белән ачыла: «Мин – Нугай йорты егете... 1380 елларда Алтын Урда ханы Туктамыш, Кырым, Төньяк Кавказ, Җаек далаларыннан 200 меңләп Алтын Урда татарын Чулман, Ык, Агыйдел, Сөн буйларына күчереп утырта. (Ихтыярсыз, моны укыгач, В.Имамовның «Карабәк» романы, Х.Сарьянның Илеш ягы халкына «Без Гәрәй хан угланнары» дип язган нәсере хәтергә килә. Шул ук Илеш ягы Сеңрән авылы тумасы галим Ә.Мөхәммәдиевнең бу төбәкне Һун (Сөн) заманнарына бәйләп, нумизматика (акчалар) һәм Туран язуы турындагы хезмәтләре искә төшә. Ләис тә тарихилыкны тирән кичереп, хәтта сабый аңы белән үк кабул итә! – Р.Г.) Менә ни яза шагыйребез: «1974 елда археологик тикшерү өчен Уфадан килеп, казу эшләре булып узды. Ярты меңләп җәсәд табылды: иң тирән казылмалар бу тирәне 1-2 меңенче (безнең эрага кадәр!) елларда ук торак итүне сөйли. Ә иң өстәге катлау: тәртипсез җирләнгәннәр; богауланган куллары белән баласын кочкан бер сөлтәр әле дә хәтеремдә – бала башында (!) ук тырпаеп тора иде. Бу җәсәдләр Алтын Урда чорыннан булырга тиеш...» Шунда ук Ык буе авыллары, Нугай тавы... Соңгы елларда күп әдипләр каләме белән мәшһүр булып киткән Чатыр тау, Чатырау, Чатра дип атала ул. Риваятьләргә караганда Сөембикәгә бәйле Сөен(дек) авылы... Аннан – шагыйрьнең үз авылы Саскүл, укыган җире – Куштирәк... Ык буендагы Тымытыклар, Сарлылар. Шулай, «Ык сулаган» Ләисебез бу җирләрнең дастаннарын, әкиятләрен, риваятьләрен җанына сеңдереп, Түләкләр, Идегәйләр рухын тоеп, тарихи коллизияләрне тирән аңлап үскән шагыйребез. Менә нинди җирлектә туган икән бу китап! Берничә бүлеккә бүленеп, үзендә «Алтын Урда», «Нугай урдасы», «Идегәй итеге» кебек күләмле шигъри бәяннар дә, халыкның үзеннән килгән риваятьләр, кыйссалар, уен-әйтешләр, җырлы вакыйгалар, үзе язганча илаһият, мозаика, притчалар (безнеңчә, бу русча әйтелешле жанрны Б.Урманче язган, хикаят дип билгеләү дөрес булыр иде. Яки хикмәтле кыйсса! – Р.Г.), бәет, мәрсия, лирик чигенешләр, элегияләр һ.б. керә. Хәтта мәҗүсият дигән жанр да бар!

Һәммә шигъри әсәр изге бер максатка – халыкның мең яралы Милли хәтерен уятып, олуг Гамь белән яшәү кирәклеген раслауга юнәлтелгән. Һәр бүлек йә бүлекчә, шигырь ялгау алдыннан «Идегәй» дастанының үлемсез юллары тезелә, Тукай, Дәрдемәнд кебек шагыйрьләрдән бу зур бинаның шамаилләре кебек хикмәтле тәҗрибә сүзләре китерелә. Әмма бу китап – бүленмәс, бербөтен Рух китабы, Моң дастаны, Тарихи аң дәреслеге талант, көч, белем, эрудиция, интуиция белән тудырылган һәм, әлбәттә, укучыдан да тирән аңлап, кушылып, илаһым, бар икән әле millions бездә Милли хәтерне йөртүчеләр! – дигән тойгы уятып, тетрәтергә тиешле күптән көтелгән бер басма! Бу иң бөек байлыгыбыз – Туган тел, Милли Сүзнең бер фокуска җыелып, гүя ки бер илаһи гомумиләштерү аша раушан көзгедә чагылышы! Укыйк без аны, дусларым, өйрәник һәм Милли Сүзнең, Тарихи хәтернең табигый кушылып, безнең хыялларга, омтылышларга бер һәйкәл булуына инаныйк! Бу китапны укыганда, күз алдыма дөнья әдәбиятының тетрәткән, яшьлектә эзен калдырган, үз халкының күңел дөньясын тулы ача алган мәгълүм китаплары килде: «Гомум кешелек җыры» (П.Неруда), «Үлән яфраклары» (У.Уитмен), «Инсан манзарасы» (Н.Хикмәт) һ.б. Мондый рухтагы басмалардан Р.Рахманның «Мең чакрымга мең чакрым» китабы, Г.Сәлимнең фәлсәфи-пантеистик характердагы бердәнбер шигырьләр җыйнамасы хәтергә килә. Әмма без аларга тиешенчә игътибар бирмәдек кебек.

Ләиснең бу китабы нигезендә «Идегәй» дастаны, дидек. Шулай ук ул үзенең рухи эзләнүләрендә классик шагыйрьләребез казанышларына да таяна, Кол Гали, Акмулла, Дәрдемәнд, Тукай, Бабич, Такташ, Туфан, Исәнбәт, Хәкимнәрнең афоризмдай тирән

мәгънәле сүзләре дә, замандаш абыйлары М.Әгъләм, Зөлфәт эзләре дә ят түгел шагыйрьгә. Әмма, безнең карашка Ләис бу бабта барыннан да бигрәк «Орчык җыры», «Болгар» авторы Роберт Әхмәтҗан мәктәбенә таяна: шул ук бар дөнья белән сөйләшә алу, эрудиция көче, өслүбе, бай ритмикасы белән ул остазы казанышларын үстерә, диясе килә. Абыйсы Фәиз Зөлкарнәй дәресләренә дә тугры калган, аның фикри, шигъри хатирәсен дә олылый белә ул.

Тагын бер әһәмияткә ия нәрсә: Ләис Зөлкарнәйнең шигъри ритмикасы, көе, моңы көчле булу. Тел ягыннан гаҗәеп халыкчан, төрле сурәт-чараларга бай булу белән бергә шигырь эчендә үк рифмалашып, аллитерация белән аһәңле шигырьләр күп аңарда. Моның сере – әлбәттә, үзенең рухи дөньясының заман, чорлар, бүгенге белән ярашыр, тәңгәл килер музыкасын – ритмын булдыруда! «Слушайте музыку революции!» дисә Блок, Такташыбыз исә «Шагыйрь композитор булырга тиеш!» дигән таләп куя. Ягъни бөтен бер әсәр композиция ягыннан да камил аһәңле, музыка таләп иткәнчә төгәл, хәтта ки моңлы, үтемле булсын! Моның өчен, беренче чиратта, Туган тел могҗизасын тою, куллана алу, Сүз кадерен саклау кирәк. «Изге кан, изге сөт»не сакларга!

*Киләсе көн агырга*
*Без барабыз, ул килмәс!*

– дигән сүзләрдә дә Н.Исәнбәт безгә җомак-табышкан калдырган, ди Ләис. Ә үзенең китап атамасы? «Узганны кабатлау» – ни ул? Трагедиянең фарска әйләнүеме? Әллә, шәкерт дәрес өйрәнгәндәй, милли аң тарихын, ятлагандай кабатларга чакырамы Ләис? Аның бит әле:

*Йә Иблискә табын,*
*Йә Ләискә,*
*Хәл ит инде, хәл ит, ниһаять!*

– дип өзгәләнүләре бар. Югыйсә Иблисләр тантана итәр чорлар килер дип кисәтәме? Кырык ел буе язылган бу китап! Гаҗәбе: 15-17 яшьтә язганнары яңа гасыр иҗаты белән нык берегеп, яраша.

*Баштан ашсын ләззәт, утлы газап,*
*Янсын бәгырь, көл калсын тәннән.*
*Безнең өчен шушы дөнья – оҗмах,*
*Шушы дөнья – утлы җәһәннәм!*

Моны шагыйрь, мөгаен, үз буыны исеменнән дә язгандыр: 80 нче елларда университетта татар филологиясе факультетында булачак әдипләр күп булды. Әйе, Газинур, Ркаил, Ләбиб, Рифә, Нәбирә, Фирүзә һәм Фәйрүзә, Гөлзадә, Дания, Илсөяр, Йолдызлар бергә иде. Аннары әдәбиятка тагын шундый талантлы буыннарны биреп калдырды инде мәрхүм татар факультетыбыз. Луизалар, янә Йолдыз, Ландыш, Ленар Шәех, Рифат Сәлах, Рөстәм Галиуллин, Лилия Гыйбадуллиналар, Булат Ибраһимнар... Эльвира, Резедалар, Фәнилләр...

Күп исемнәрне хәтердән кичерә-кичерә, газиз факультетыбызны сагынып язам бу нәсеремне. Быел 60 яшен билгеләүче хөрмәтле әдипләребез әнә шул милли факультетның җаны, даны иде шул. Ләис тә шундый шагыйребез. Котлыйбыз!

**Рәдиф ГАТАШ,**
*Татарстанның халык шагыйре,*
*журналның элеккеге бүлек мөхәррире.*

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ НИ ХӘЛДӘ?

*(Әдәби әсәрләр бәйгесеннән соң уйланулар)*

2021 ел татар әдәбияты, мәдәнияте белән кызыксынучылар, үзләре дә каләм тибрәткәннәр өчен гаять мөһим һәм олы бер вакыйга ягыннан үзенчәлекле булды: Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан игълан ителгән татар телендәге әдәби әсәрләр конкурсы зур активлык белән узды. Бәйге татар әдәбиятының торышы, билгеле һәм яшь авторлар, аерым әсәрләр – гомумән алганда, татар әдәбияты хакында фикер алышуларга сәбәп булды. Татар әдәбиятының сөйләшү объектына әйләнүе үзе үк конкурсның кирәклеге, файдасы турында сөйли.

Чөнки милли әдәбият – бер халыкның мәдәни югарылыгын билгеләүче төп күрсәткечләрнең берсе. Бу җәһәттән без бай әдәби мирасыбыз белән горурланабыз. Әмма бүген әдәбиятыбызның торышы ни хәлдә, башка халыклар өчен дә кызыклы булырлык заманча әсәрләр языламы? Мең еллык тарихы булган, үзенчәлекле милли традицияләрдә гаҗәеп кызыклы әсәрләр тудырган татар әдәбиятының XXI гасырда дөнья әдәбияты мәйданында лаеклы урын били алмавының сәбәпләре нидә? Гомумән, әдәбиятыбыз нинди юлдан китәргә тиеш, аның үсеш мөмкинлекләре ничегрәк? Бәйге шушы сорауларга күпмедер күләмдә җавап бирергә ярдәм итте. Дөрес, бу очракта мин бәйгегә килгән проза әсәрләре мисалында гына фикер йөртә алам.

Беренче сораудан башлыйк. Бүгенге татар әдәбиятында дөнья әдәбияты мәйданына тәкъдим итәрлек әсәрләр бар. Әмма күп түгел. Мәсәлән, сорауны башкачарак: хикәя, повесть һәм роман жанрында беренче 3 урынны яулаган әсәрләрнең күпмесен башка телләргә тәрҗемә итү кирәк дип саныйсыз, дип куйсалар, мин ике дип җавап бирер идем. Хикәя номинациясендә беренче урынны алган «Лаләләр» һәм роман номинациясенең фавориты – «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..»

Шул ук вакытта, әйтик, «15 романның күпмесен «Казан утлары» журналында бастырырга мөмкин» дип сораганда, 7 дип җавап бирәм. Бәйгегә килгән текстларның яртысы бу.

Инде шушы саннарны шәрехләп карыйк (әлбәттә, бу төрле кешедә төрлечә булырга мөмкин). Минем карашымча, татар әдәбиятында көч-куәт бар, әмма дөнья әдәбияты мәйданына чыгар өчен осталык җитенкерәми.

Шушыңа бәйле, тагын да алгарак күз ташлап, «Нишләп лаеклы әсәрләр киң мәйданга чыга алмый, әдәбиятыбызны дөньяга таныту өчен нәрсә эшләргә?» – дигән сорауга да җавап биреп карарга кирәктер.

Аерым бер язучыларның иҗатын дөнья әдәбияты мәйданына тәкъдим итү – ул шәхси эш кенә була алмый. Мәсәлән, күпмилләтле совет әдәбиятында яңалык булачак күп кенә сыйфатлар башлап, Әмирхан Еники иҗатында борынлый. Кызганыч, үз вакытында татар әдәби җәмәгатьчелеге республика җитәкчелеге ярдәмендә Әмирхан Еники иҗатын шундый югарылыкта популярлаштыра алмаган. 5-10 ел уза – башка милләт язучылары иҗатында да әлеге сыйфатлар күренә, аларның әсәрләре рус теленә, башка телләргә тәрҗемә ителә. Нәкъ менә без сүз алып бара торган конкурслар тәрҗемә өчен тәкъдим ителә торган әсәрләрне сайларга ярдәм итә ала.

Инде бәйгенең минем өчен гаҗәп тоелган кайбер нәтиҗәләре турында да сөйләшергә кирәктер.

Беренчесе – әдәби барышта үзгәрешләрне әйдәп бару позициясенең хикәядән – романга күчүе.

Кече эпик жанр буларак, хикәя әдәбиятта заман алып килгән яңалыкларга иң сизгерләрдән санала. Татар әдәбиятының зур үзгәрешләр кичергән вакытларын: XX йөз башы, 1920-1930 еллар чиген, 1960 еллар башын, 1990 елларны искә төшергәндә, нәкъ менә хикәяләрнең тәҗрибә-экспериментлар үзәгенә куелуын, эпосның барлык жанрларына әйдаман булуын күрсәтергә кирәк. Кызганычка күрә, конкурска килгән хикәяләр арасында яңалыкның азлыгы күзгә ташланды. Бу очракта мин тематик яңалыкны гына түгел, образ тудыру, сәнгати эшләнеш ягыннан әдәбиятта алга китешне дә күздә тотам.

Әлбәттә, беренче урынны алган хикәя – Р.Мөхәммәтшинның «Лаләләр» әсәре бу яктан аерылып тора. Кечкенә жанр булуга карамастан, анда ике вакыт – ике тарих тергезелгән. Хәзергесе – Татарстан делегациясенең Бохарага Мәрҗани хәзрәтләре истәлеген мәңгеләштерү нияте белән сәяхәтен сөйләсә, үткән – XIX гасырда Аллаһка омтылган йөрәк кайнарлыгын кушып, шәкертнең рәсем төшерүе; боларны исә сәяхәттән алсу чәчкә алып кайтырга вәгъдә иткән хикәяләүченең шәкерт төшергән рәсемне табуы үзара тоташтыра. Әкияти алсу чәчкә символы, үз чиратында, гомумбилгеле мотив – күп халыкларның фольклорындагы бәхет-мәхәббәт турында хыялланган кече кызның әтисеннән сораган бүләге белән ассоциацияләшә. Аннары, хакыйкатьне (бигрәк тә Мәрҗани шәхесен аңларга омтылу, аның каберен зыярәт итү белән янәшә), кешенең үз күңелендәге билгесез омтылыш-алгысынуны табу булып та аңлашыла ала. Һәркем үзе теләгән текстны «укый» торган постмодернистик әсәрнең сере дә шунда. Моның белән генә чикләнмичә, хикәягә хәзрәт образының иллюзор төстә кертелүе (ул да хикәя ахырында реаль шәхестән – хыялда туган символга әверелә) яңадан-яңа мотивларга юл күрсәтә: илаһи мәхәббәтнең серенә төшенгән хәзрәт – кеше рухын бер баскычтан икенче югарырак халәткә озатучы ярдәмче, сәбәп рәвешен ала; ул сәнгатьнең гаҗәеп көчен раслаучы да; кеше аңы танып белә алмаслык, әмма аны үзгәртүче язмыш, тәкъдир дә. Бохараның борынгылыкта сакланган кайнарлыгын – татар тарихындагы җимереп, кабат корылган һәйкәлләрнең салкынлыгы белән чагыштыруда иҗтимагый эчтәлекле тәнкыйть калкулана. Хикәяләүче күңеленә оялаган «функционер» һәм алсу чәчәк эзләүче «шәкерт-шагыйрь» – бер холыкка берләшергә дучар ителгән инь һәм янь, бер яшәешнең ике ягы хакындагы фәлсәфә булып аңлашыла.

Кызганычка күрә, мондый тирәнлек бәйгегә килгән башка хикәяләрдә күзәтелми. Интертекстуальлек алымы кулланылганда да, ул яңа дәрәҗәдәге эчтәлек тудырмый. Әйтик, «Тукай» хикәясе 136 елдан соң Тукайны терелтә: Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестен, шушы фантастик мотивны кабатлаган башка әсәрләрне искә төшерә, хикәяләүче-герой ярдәмендә бүгенге тормышның күп кенә тискәре яклары тәнкыйтьләнә. Сатирик бәяне алга чыгарса да, хикәягә заман әдәбиятына хас уен җитми, инде әдәбиятыбызда булганны тагын бер кат кабатлау килеп чыга.

Кабатлау дигәннән, хәтта урын алган хикәяләрдән «Тиле»не охшаш темага язылган күп кенә әсәрләр (әйтик, Батулланың «Ике җүләр» повесте) белән чагыштырганда да, элегрәк иҗат ителгән текстларның күпкә тәэсирлерәк, фикри тирәнрәк булуы күренер. Бу очракта хикәянең бәйгегә тәкъдим ителгән әсәрләр арасында гына узуын искәртү мәслихәт булыр.

Тагын бер мисал – «Соңгы ветеран» хикәясе Гарифның җиңү көнендә совет солдатларының батырлыгы турында истәлекләр сөйләп йөрүен тергезә. Чынлыкта сугыш вакытында концлагерьда утырган картның хатирәләрендә исә хурлыклы истәлекләр калка. Бу мотив М.Мәһдиевтә бар, анда матур һәм әдәби итеп сурәтләнгән. Аның белән чагыштырганда, хикәя натуралистик ялангач тоела.

Бәйгегә килгән хикәяләргә тулаем күз ташлаганда, иң беренче чиратта, аларда татар хикәясенең традицион арынып бетә алмый торган сыйфаты – публицистик

башлангычның алга чыгуын әйтергә кирәк. «Үксез бала бәхете», «Коммунизм кыры», «Якын дус», «Ак үрдәк», «Киселгән бәхет», «Алар кем дә, мин кем?» һ.б. текстларда бу шулай. Алар хикәя белән публицистика арасында калганнар.

Мондый хикәяләрнең күбесе нәсихәт бирүгә корылган: «Саттылар», «Мәхәббәткә рөхсәт сорамыйлар...», «Дөнья – куласа», «Җуелмас эз», «Зимагур» һ.б. Нәсихәт бирү, билгеле ки, тормышны акка-карага аеруга китерә (әйтик, соңгы хикәядә мондый капма-каршылык матди-рухи кыйммәтләргә мөнәсәбәт мәсьәләсендә туа).

Шул ук вакытта бу кимчелекнең гомумән татар әдәбиятына хас икәнлеген, газета-журналларыбызда басыла торган яки китап булып чыккан җыентыклардагы күпчелек хикәяләрнең шуннан котыла алмавын әйтергә кирәк. Аның сәбәбе – татар әдәбиятында мәгърифәтчелекнең соң формалашып, XX гасыр башы яңарышына да, совет әдәбиятына да йогынты ясавында булса кирәк.

Бу сыйфат авторларның прозаик, хикәяче буларак осталыгы җитмәүдән дә килә. Аерым бер очракларда текстлар ашыгып эшләнгән, уйлап бетерелмәгән дигән тәэсир калдыра. Мәсәлән, «Көянтә» хикәясе, әйтерсең лә, шушы бәйге өчен язылган: анда милли традиция-гадәтләрнең кадере, аларны киләсе буынга тапшыру мөһимлеге үзәккә куела. Йә булмаса «Җан тартмаса, кан тарта» хикәясендә ялгыз яшәүче Габдулла бабайның (улы шәһәргә киткән, авылны оныткан) оныгы Илгизнең янына күчеп кайтуы – бик матур күренеш, әмма ышандырырлык итеп тасвирланмаган. Һәр ике хикәядә дә кеше образларының эшләнеп бетмәве күзәтелә. Аерым бер очракларда авторның ни әйтергә теләве, хикәясен ни өчен язганлыгы («Дала буйлап икәү бара» һ.б.) аңлашылмый.

Тагын бер зур кимчелек – вакыйгаларны сөйләп чыгу белән чикләнү. Мәсәлән, «Хатирә» хикәясе әдәбиятта, кино-сәхнә сәнгатендә очрый торган сюжетка язылган: Хатирә әби 1941 елны искә төшерә. Ире Абдулвәли сугышка китә, үлем хәбәре килә. Хатирә Җамалетдин исемле егеткә гашыйк була, өйләнешәләр, 5 кыз, 1 малай үстерәләр. Әсирлек җәфаларын кичеп, Абдулвәли кайта. Автор тарафыннан, сугыш булмаса, Хатирә башка кешегә кияүгә чыкмас иде дигән фикер ассызыклана. Әмма төп героиняның кичерешләре һәм гамәлләре дә мотивлаштырылмый; әсәрдәге барлык геройлар да – яхшы кешеләр; төп фаҗигаләрнең сәбәбе исә сугыш дигән «очраклылыкта» булып чыга. Бу урында, шиксез, психологизм алымын куллану хикәяне «эшләп бетерергә» ярдәм итә алыр иде. Шушы ук сүзләрне «Әни сөйләгән хикәя», «Бакча карагы» кебек текстларга карата да кабатларга мөмкин.

Бу яктан, урын алган хикәя – И.Иксанованың «Матәм» хикәясен телгә алырга мөмкин. Шактый авыр тәэсир калдыра торган әсәр талантлы рәссам Гафиятне күмү вакыйгасын сурәтли. Талантлы шәхескә исән чагында сәнгатьтә юл бирмәгән Атлас озатуны оештырып йөри. Язучы безнең җәмгыятьтә талантлы кешеләргә мөмкинлекләр чикләнүгә игътибар итә. Шушы проблематика фонында тирән психологизм, хәтта лиризм дулкынында эшләнгән ике образ – Гафиятнең хатыны, кызы образларының яңалыгы һәм бөтенлеге әсәрнең эмоциональ тәэсирлелеген тәэмин итә.

Соңгы елларда повесть, роман жанрларында күзәтелә торган телесериаллар йогынтысы хикәягә дә килеп кагылганлык турында да әйтергә кирәктер. «И чабата, чабата...» хикәясендә, мәсәлән, сугыш вакытында Әннүрәләрнең өенә килеп кергән әсир итальянлы Энрике илче булып Казанга килә, кызга өйләнә. Әлеге матур әкият укыла, әмма ышандырмый. «Бер сәгать гомер», «Сатлыкҗан» кебек әсәрләр дә шулай.

Хикәя жанры турындагы фикерләрне повестьларга карата да кабатларга мөмкин: күп кенә текстларда тормышта очрый торган хәлләрне сөйләп чыгу өстенлек итә, сайлап алынган вакыйгалар типиклаштырылмый («Урланган бәхет»). Бер яки берничә кеше тарихын яки бер гаилә тарихын сөйләп чыгу – гайре табигый ситуацияләр тудыру төсен ала, аерым вакыйгалар ышандырмый башлый («Бәхет бар ул дөньяда...», «Өч дус»). Әйтик, югары бәяләнгән «Бәхет бар ул дөньяда...» повесте төрле буыннар

тарихын бергә тоташтыра, кызыклы, укыла. Шул ук вакытта үткәнне сурәтләүдә – фаҗигалелек күбәеп китә, хәзергене идеаллаштыру бар.

Еш кына сюжет үстерелеше телесериалларны искә төшерә. Публицистик башлангычның көчле булуы повестьларның жанр төре ягыннан тарихи-публицистик («Хыянәткә – кыямәт»), иҗтимагый-публицистик («Үзәккә үткән онытылмас балачак хатирәләре») яки бер лейтмотив тирәсенә тупланып җитмәгән таркау истәлекләр кебек («Яшә, авылым!») килеп чыгуына китерә. Повесть жанрында әсәрне җыеп торган концептуаль нигез булмау язучының нәрсә әйтергә теләгәнлеген күрергә мөмкинлек бирми («Атылган йолдыз», «Соңлап килгән сөю», «Без югалткан көннәр» һ.б.). Повестьлар арасында массачыл әдәбият булып чыккан аерым текстлар да булды («Кыз балага сүз әйтмәгез»).

Шунысы кызык: повесть жанрында характерлар тудыру ягыннан отышлы, кызыклы текстлар юк түгел («Мәк чәчәге», «Моңсыз җыр» һ.б.), болар әле укучыларга тәкъдим ителерләр. Алар мисалында беренче урыннарны алган әсәрләр белән чагыштырганда, әсәр проблематикасының сайлыгын күрсәтергә мөмкин.

Әдәби эшләнешендә кимчелекләр шактый булып та, урын алган повестьлар арасына «Исемлек»нең эләгүе – экспертларның текстта яңалык булуны таләп итүе белән бәйле. Шактый таркау булса да, әсәр татар әдәбияты өчен яңа тоелган, агым буйлап баручы заман героен тәкъдим итә, бер-берсенә охшамаган кеше образлары аша җәмгыять сурәтен тергезергә омтыла.

Аерым бер очракларда текстларны татар әдәбиятындагы шундый материалга элегрәк иҗат ителгән әсәрләр белән янәшә кую мәҗбүрияте туа. Әйтик, югары бәяләнгән повестьларның берсе – «Үтте инде» әбинең истәлек дәфтәрләрендә сакланган вакыйгаларны тергезә: сугыш алдыннан ятим кызның Казан–Бөгелмә тимер юлын салырга баруы, Бөек Ватан сугышы башлангач, Мәскәү янына окоп казырга озатылу, торф чыгаруда эшләү, авылдагы ачлык, авыр хезмәт һ.б. Ирексездән Н.Фәттахның «Кырык дүртнең май аенда» (1965) повесте хәтергә төшә. Әмма ике әсәрне чагыштыру бәйгедә катнашкан повесть файдасына түгел.

«Эшләнеп бетмәү» ягыннан, мин шәхсән проблематик яңалыгы өчен югары бәяләнеп тә, әсәрнең драматург кулы белән язылуы сәбәпле, беренче өчлеккә кермәгән тагын бер повестька тукталып, аны билгеләп үтәсем килә: «Җиләк пешкән чагында» ул. Кайчандыр авылдан Себергә сөрелгән Закир нигезендә яшәп ятучы Габбасларга – өен-ихатасын таләп итеп, Закир карт үзе кайтып төшә! Шулай төенләнгән сюжет уйландырырлык. Анда постсовет дәверенең иң зур проблемаларыннан булган тәүбә – кешеләрнең бер-берсе алдында, хакимиятнең язмышлары сындырылганнар алдында, дәүләтнең тулы бер халык-милләт алдында гафу үтенү мәсьәләсе әле татар әдәбиятында күзәтелмәгән дәрәҗәдә колачлы, тирән итеп куела. Сюжеты – кызыклы, геройлар – характерлар итеп эшләнгән  текст, нигездә, диалоглардан тора. Әмма бу әсәр – бәлки, драма буларак, яки повесть итеп эшләп-редакцияләп, татар укучысына җиткерелергә лаек.

Бәйгедә икенче урынны алган психологик повестьтагы читтән йогынты ясап, кеше холкы-характерының гына түгел, аңының  үзгәреше һәм аңастына (подсознание) үтеп кереп, анда үзгә күзаллаулар китереп чыгару омтылышын күзәтү (М.Кәбировның «Тик син генә» повесте) татар әдәбияты өчен яңа бер күренеш хасил итә. Автор үзенең әсәрен «альтернатив тарих» дип бәяли. Монда Илнур исемле яшь егетнең – коралга тотыну тарихы сөйләнә. Егетнең гаиләсе, гаиләдә җылылыкның җитәрлек булмавы бер сукмак хасил итә. Илнурның, гаделсезлекләр белән очрашып, шуларны җиңәргә көчле дуслар табуы, шуларның аны үтерүче-зомби ясавы тагын бер тарих булып оеша. Автор егетнең балаларга атмавын аның аңастында сакланган мәрхәмәтлелек-җылылык тудырган дулкынның җиңеп чыгуы белән аңлата. Илнурның үзенең һәм Ләйләнең үлеменә китергән фаҗиганең соңгы өлеше аеруча кешенең психологиясен анализларга

омтылып язылган. Джон, Остаз кебек геройлар – үтерүче ясауны яшьләргә тормышны яхшы якка үзгәртү теләге белән бәйләп аңлату юлы тапканнар. Алар җәмгыятьне тетрәндерерлек вакыйга булганда гына, кеше уяначак, тормышны яхшырту өчен нидер эшләячәк дип ышандыралар. Автор исә сурәтләү осталыгы ярдәмендә укучы игътибарын шушы тарихтан «ычкындырмый», аның каләме ахырга кадәр укучысын әдәби киеренкелектә тотып торырга сәләтле.

Повестьта «телесериаллар эзе» үзен сиздерә, тормышны ике капма-каршы чиккә аеру ышандырып бетерми. Башта – барысы да караңгы һәм кара булып, шул исәптән, әти-әниләр образы да тискәре сурәтләнә. Аннары – болар явызлыкны җиңәрлек көч дәрәҗәсенә куела. Шулай булса да, психологизм, психоанализның татар әдәбиятында үсү юлы булуы бәхәссез.

Роман жанрында бәйгегә тәкъдим ителгән иң кызыклы әсәрләр дә психологизм алымы кулланып, образларның тип дәрәҗәсендә эшләнүе, фәлсәфи-фикри тирәнлек белән аерылып торалар.

Беренче урынны яулаган әсәрнең бәйгедәге башка текстлардан шунда ук аерылып алга чыгуын күрсәтергә кирәк. Зөлфәт Хәкимнең «Бер сәгатьтә ничә мизгел бар?..» романы ул. Әсәр тормышны вакыт ягыннан ике катламга аера: хәзерге – 2014 елны Хәйдәр исемле ирнең, яман чир, лейкемия диагнозы белән, Германиядәге Мюльхайм-ан-дер Рур шәһәрчегендә урнашкан «Панмедика» клиникасына дәваланырга килүе, терелеп кайтып китүе; һәм Бөек Ватан сугышы көннәре, 1944 елның августында Украина территориясендә – Хәйдәрнең әтисе Гарипов Самат белән әсир радист Ортвин Мейерның (Берлинда, Шаритэ клиникасында табиб булган Винфрид Мейерның әтисенең) язмыш җепләре кисешкән вакыт ике төп сюжет җебе булып сузыла.

Алман радистын тиешле оешма вәкилләренә илтеп тапшыру бурычы йөкләнгән Самат белән әсир Ортвин арасындагы мөнәсәбәтләр үсештә сурәтләнүе белән кызык. Әсирне дошман санаудан – кеше итеп карауга кадәр ара узып, Самат аны ирекке җибәрә, Ортвин да солдатны сатмый. Сәбәп – кешеләрнең янәшә булганда, бер-берсен яхшырак аңлавында да, әмма язучы моны шушы кыска гына вакыт аралыгында Саматның, Света исемле кызга гашыйк булып, олы мәхәббәт кичерүе белән аңлата. Нәкъ менә шушы, һәркемгә дә насыйп булмый торган, олы хис, якты, бәхетле мизгелләр кичерү егетне дә үзгәртә, бу хистән миллионлаган кеше сокланып тыңларлык җыр да, акыллы-затлы балалар да туа.

Язучы әлеге тарихны: «Әтисе Самат белән Винфриднең әтисе Ортвин да бер-берсен сугышта үлемнән коткарганнар дип әйтергә була... Димәк, тикмәгә түгел...» – дип бәяли, тикмәгә булмавын Хәйдәрнең Германиядә гомере сакланып калу мисалында дәлилли.

Романның фәлсәфи эчтәлеге тирән: бу – Зөлфәт Хәким иҗатына хас күренеш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья – вәхши, әмма анда бер нәрсә дә очраклы түгел. Вәхши дөньяда мәхәббәт бәхетле булырга ярдәм итә, ярата белгән кеше үтерми, ди прозаик. Шактый бәхәсле нәтиҗәләргә китерә торган мотивлар да табыла текстта. Бәхетле мизгелләрнең – гомердән кадерлерәк икәнлеге, яки сугышларда җиңүгә караганда үз-үзеңне җиңүнең авыррак булуы – шундыйлардан.

Тагын бер роман – Равил Сабырның «Фәхрине үтереп ташладылар»ы – шулай ук күпкатламлы, укучы төрле текстлар таба ала торган постмодернистик әсәр. Анда детектив кануннары буенча сузылган җинаять һәм җәза сюжетын да, совет һәм постсовет җәмгыятенең кешене – «корбан итүен» сөйләгән сызыкны да, шәхси мәнфәгатьләрне кайгыртып, милләткә хыянәт итүне дә күрергә була. Шуның белән бергә, Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романындагы кебек үк, бу әсәрдә дә төп геройлар – гаепләнүчеләр Галимҗан, Хамис, Илгизәр, Диләрәнең 20 еллык тормышларын искә төшерү вакытында тормыштагы хәл-халәткә анализ ясала, бәя бирелә. Алар аерым бер кеше булудан туктап, җәмгыятьтәге катламнарның (интеллигенция, эшмәкәр, органнарда хезмәт итүче, җилбәзәк хатын) типик вәкилләре

рәвешендә аңлашыла башлый. Шулар һәм Кадыйр, Зөлмәт образлары ярдәмендә язучы җәмгыятьтә төрмә законнары урнашуга игътибар юнәлтә. Шул ук законнар буенча геройларга җәза бирә.

Бер үк вакытта әсәрдә язучы үзенең геройлары белән дә, укучы белән дә катлаулы уен кора. Төп геройларны берләштергән «Шаяннар һәм тапкырлар клубы» да, Кадыйрның туган көнендә һәр герой уйнаган уен да, төрмәдән азат ителгәч, Кадыйрның элекке дуслары белән уены да, Зөлмәтнең уены да – шуның өлешләре. Язучының мондый уен-роман белән ни әйтергә теләгәнен дә һәр укучы үзенчә ачыклый ала, ачыкларга тиеш була.

Романнар бәйгесендә әле каләм тибрәтә генә башлаган язучының урын алуы – гаҗәеп күренеш. Сүз «Казан утлары» журналында басыла башлаган «Буа» романы белән игътибарны үзенә җәлеп иткән Фирдүс Гыймалтдиновның «Үзбәк хан» тарихи романы турында бара. Роман укыла, автор тарихи вакыйгаларны күз алдына килеп басарлык характерлар, психологик ситуацияләр рәвешендә тергезә. Әмма мәгълүм тарихи вакыйга-күренешләрне сөйләп бару да шактый зур урын алып тора. Бу очракта, романдагы сюжетларның Үзбәк хан тормышыннан гомумбилгеле тарихи материаллар чикләреннән чыкмавы әсәрнең традицион, классик тарихи роман булуын тәэмин итә. Гомумән, классик тарихи романнар вакыты узды дип санасам да, авторның язу куәсенә, тасвирлау мөмкинлекләренә карап, аны бәйгенең җиңүчеләре исемлегенә кертү кирәклеге бәхәссез.

Бәйгегә килгән романнар арасында тарихи темаларга мөрәҗәгать иткән башка әсәрләр дә булды. Аерым алганда, Болгар чорына алып киткән «Яугирә», Сафа-Гәрәй ханның Казан тәхетенә утыруын үзәккә алган, гүзәл дөнья сурәте тудырган «Шәһри Казан кыйссасы» әсәрләре дә укучыны кызыксындырырлык булып чыккан. Алар әле «Казан утлары» журналы битләрендә укучыга тәкъдим ителерләр дип уйлыйм.

Хәзерге яки совет чорына караган вакыйгалар үзәккә алынган текстларда да еш кына тарихи экскурслар ясала («Казан серләре» (роман-поэма), «Килер бер көн...» (Татар бәхете). (Роман-татар) һ.б.).

Шуңа күрә классик тарихи романнар вакыты узды дип санавым турындагы фикерне бераз аңлатып китү кирәктер.

Мәгълүм ки, XX-XXI гасырлар чиге татар әдәбиятында тарихи романнар күпләп язылды, әдипләребез мәшһүр Н.Фәттахның «җиңел кулы» белән салынган юлдан Казан ханлыгы тарихын да, ераграк гасырларны да әдәбият мәйданына менгерделәр. Шул ук вакытта әдәби тәнкыйть тарафыннан, әлеге күренешне хуплау белән бергә, татар тарихи романнарының әдәби эшләнеше ягыннан заман әдәбиятына түгел, XIX гасырлар дөнья әдәбиятына йөз тотуы, публицистика белән фәнни башлангычның көчле икәнлеге дә, еш булмаса да әйтелә. Әлбәттә, тарихи романнар, аларның әһәмияте турында сүз алып барганда, бигрәк тә, милли үзаңны ныгыту ягыннан гаять үтемле, тәэсирле булуын  ассызыкларга кирәк. Шул ук вакытта заман укучысы, яшь буын тарихи материаллар һәм аларга үзенчәлекле караш белән әдәбият аша да таныша алсын өчен әлеге материалның яңа формаларга «төрелгән», заманча булуы сорала.

Заманча матур әдәбиятта тарихи материал ничек кулланылырга тиеш соң дигән сорау туганда, иң билгелеләрдән, казакъ прозаигы Рәхимҗан Отарбаевның «Чыңгыз ханның елавы» («Плач Чингис-хана», 2016) повестен, азәрбайҗан язучылары Эльчинның «Баш» («Голова», 2017) яки Камал Абдулланың «Сихерчеләр үзәнлеге» («Долина кудесников», 2016) романнарын мисалга китерү дә җитәдер. Әлеге әсәрләр тарихи материалны файдалануның яңа бер юлын: романтизмнан – модернизмга һәм постмодернизмга күчүнең текстлар эчтәлеген һәм фәлсәфи, һәм сәнгати яктан гаять киңәйтүен күрсәтә.

Бәйгегә килгән романнар арасында якын тарихка мөрәҗәгать итеп, тематик планда кызыклы гына әсәр тудыруга мисаллар да юк түгел. «Әлмирәнең хәтере ачыла» –

шундыйлардан. «Зөләйха күзләрен ача» исеме белән интертекстуаль бәйләнешкә игътибар итмәгәндә дә, романда милләтара никахлар, мондый никахта татар кызына мөнәсәбәт мәсьәләсенең моңа кадәр әдәбиятыбызда күтәрелмәгән дәрәҗәдә куелышын әйтергә кирәк. Өлешчә постколониаль элементлар белән баетылган текстта совет илендә татарларга мөнәсәбәт мәсьәләсенә дә шактый саллы кагылып узыла. Теле русчадан тәрҗемә кебегрәк булып, структур яктан төрлелек (бигрәк тә аерым вакыйгалар җентекле сурәтләнеп тә, аерым берләр – әйтеп кенә үтелү) күзәтелсә дә, яхшы редактура узганда, роман журнал вариантында укучыга кызык булыр иде дип исәплим.

Роман жанрында да сюжет-проблематика тарлыгы үзен сиздерә, еш кына кеше ышанмаслык хәлләр белән артыграк мавыгып китү түгелме бу дигән сораулар да туа («Сихри божра», «Кичерү юк» һ.б.). Ни гаҗәп: роман жанрында да кеше тарихлары белән чикләнү – повесть материалыннан роман оештырырга тырышу да күзәтелә («Ачылмаган сер», «Сыналу» һ.б.).

Нәтиҗәләр ясаганда, бәйгенең башка көтелмәгән нәтиҗәләре дә күренә. Әйтик, соңгы 20-30 елда без татар әдәбиятында иң олы кимчелек буларак үткән турында, авыл тормышы сөйләүне күрсәтә килдек. Бәйгегә килгән әсәрләр хәлнең үзгәргәнлеген хәбәр итә: хәзерге тормыш, шәһәр тормышы да, яшьләрне кызыксындырган мәсьәләләр дә ят түгел икән милли сүз сәнгатебезгә.

Әмма татар әдәбиятына хас әйтелә килгән гомуми кимчелекләр бүген дә калку: тормышчан булмаган, әкият калыбындагы сюжетлар белән мавыгу (яхшы-яман каршылыгы, яхшылык җиңеп чыга); тематик тарлык; әсәрләрдәге кеше концепциясенең заманыбызга туры килмәве; публицистик һәм дидактик башлангычның көчле булуы, ситуацияләрнең ясалмалылыгы, образларның берьяклылыгы; язма сөйләмнең татарча матур телдән ерак торуы...

Инде әдәбиятыбыз нинди юлдан китәргә тиеш дигән сорауга да җавап биреп карыйк. Шиксез, һәр әдәбият нindидер дәрәҗәдә, күпмедер күләмдә артта калып булса да, дөнья әдәбияты үтә торган юлны уза. Алай гына да түгел: алдынгы булырга теләгән милли сүз сәнгатеннән дөнья әдәбияты белән бер дулкында булырга омтылу таләп ителә. Тарихка карасак, безнең милли әдәбиятыбыз – традицияләрне яңарта алуы, узганның табышларын-казанышларын яңа шартларда яңача куллана белүе белән көчле! (Дөнья әдәбиятында өр-яңа сукмаклар салу белән мавыккан әдәбиятлар да юк түгел). Димәк, гомум яңалыкларны үз традицияләребезгә җайлаштыру юлы мөһимдер.

Шул ук вакытта мондый бәйгенең оештырылуы, уздырылуы хуплауга һәм мактауга лаек. Әлбәттә, эш барышында ук Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү мәсьәләсе дә, оештыру ягыннан кайбер тәкъдимнәр дә жюри тарафыннан әйтелә барды. Аларга өстәп, мин тагын бер номинация – әдәби тәнкыйть номинациясен кертү кирәк дип санавымны да ишеттерергә телим. Чөнки милли әдәбиятның үсеш кыйбласын аның әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйте билгели. Әдәби җәмәгатьчелектә татар сүз сәнгате язмышы турында борчылу көчен киметмичә, тагын да шундый ук колачлы әдәби бәйге оештырып, анда сыйфат ягыннан үзгәреш кичергән әсәрләр белән горурланырга, аларны дөнья әдәбияты мәйданында күрергә язсын иде.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы.*

# АБАГАЛАР ЧӘЧӘК АТСА...

Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры «Абага алмасы ачы була» (Р.Сабыр) спектаклен кабат сәхнәгә менгерде. Кабат дим, чөнки берничә ел дәвамында уйналмый торган иде ул.

Безнең ил халкы – абагалар бүген булмаса, иртәгә чәчәк атар дип ышанып, гомер буе өметләнеп яши белгән халык. Талантлы режиссёр Фаил Ибраһимов куйган драма мондый өметнең өреп кабартылган шар гына икәнен исбатлап күрсәтә. Кеше – еш кына бүтәннәр кулындагы пыяла уенчык. Кемдер башкалар язмышы белән уйнаудан тәм таба, уенчыкның челпәрәмә килүен күреп ләззәтләнә. «Бүтәннәр» һәм «кемдер» дигәнебез аерым кеше дә, тулы бер дәүләт тә булырга мөмкин. Спектакльнең сюжет сызыгын берничә җөмләгә сыйдырып бетерергә була: 86 яшенә кадәр паспортсыз яшәгән Насыйбулла (өлкән Насыйбулланы – Татарстанның атказанган артисты Рафил Сәгъдуллин, яшь Насыйбулланы Винер Фәйзуллин уйный) янына яшь егет Айбулатны (Фирдүс Сафин) журналист кызыксынуы алып килгән. Ничек инде ул безнең дәүләттә – кәгазь кисәгеннән башка сине кешегә дә санамаган җәмгыятьтә паспорт хәтле паспортсыз яшәргә мөмкин?!

Төп герой Насыйбулланың язмышка әллә ни дәгъвасы юк: аның сөйгән яры белән гаилә корып, үз авылында тыныч, матур гомер кичерәсе килә. Кыска гына гомер юлын шул бәхеткә төренеп үтәргә тели. Әмма аны урап алган тирәлек, ул яшәгән дәүләт бу теләкне күпсенә. Хәер, бер аның гынамы? Меңләгән, миллионлаган Насыйбуллалар кул сузымындагы мондый бәхеткә өметләнә алмый. Алар ымсынып көткән абага чәчәген генә түгел, абага алмаларын да авызга капмаслык итеп агулап куячакларын беләләр… Драма тарихи сабак бирерлек бай мәгълүматны үз эченә сыйдырган. Дәһшәтле утыз җиденче еллар, шәхес культы, яла-ялган корбаны булган бик күпләр инде мәңгелеккә китеп барган. Алар сөйләргә өлгермәгәнне бүгенге буынга язучылар, шагыйрьләр, драматурглар җиткерә.

«Кеше» һәм «бәхет» төшенчәләре арасында һәрвакыт өченче берәү була. Насыйбулла белән аның сөйгәне Гөлия арасында – кара йөрәкле, көнчел Тахау (Равил Гыйләҗев, Марсель Мөсәвиров). Аның бер капчык онны Насыйбуллаларның мунча түбәсенә китереп куюы гөнаһсыз егетне ун елга Себер якларына озата. Әле нинди маддә белән – илле тугызынчы! Бу исә – бандитизм өчен дигән сүз. Урлашкан өчен бер ел бирергә дигән маддә, Сталин кушуы буенча, совет суды тарафыннан инде бөтенләй кулланылмый икән…

Насыйбулланың яшь чагы артист Винер Фәйзуллин тарафыннан шактый тәвәккәл, кыю, имәндәй нык холыклы итеп бирелә. Төрмә камерасында аның бау әзерләп куйганын белгәч, имәннәрне дә егып салырлык көчләр барлыгына ышанып, сискәнеп китәсең. Гомумән, сәхнәдә Колыма лагеренең барагы сурәтләнгән күренеш бер генә тамашачыны да битараф калдырмый. Бирредә тормышның үз фәлсәфәсе, үз законы. Насыйбулла белән очрашкан Большой Татарин кушаматлы каракны да (Татарстанның халык артисты Рәфыйк Каюмов), сәяси тоткын буларак утырган Низамны да (Рәзил Фәхретдинов) иң беренче чиратта «төрмәдәш» булу түгел, үзләренең бер каннан, бер җаннан – татар икәнлекләрен аңлау берләштерә. Аларның әңгәмәсендә янә тормышның ачы хакыйкате чагыла. Большой Татарин авызыннан яңгыраган сүзләр совет хөкүмәте төзелгәч кылынган гамәлләргә хөкем карары булып яңгырый. Егерменче еллардагы продразверстка, авыл

халкының соңгы икмәген кычкыртып талау, коточкыч ачлыкның кешеләрне бер-берсен ашау дәрәҗәсенә җиткерүе – әнкәсенең үз баласын тураклап, соңыннан акылдан язуы турында сөйләгән карак: «Үз халкын болай җәберләгән дәүләтнең киләчәге юк!» – дип нәтиҗә ясый. Ә бит халык ил башлыкларының – «патша»ларның гуманизмына ышана, бу кабахәтлекләрдән алар бихәбәрдер, белсәләр, юл куймаслар иде, дип фикер йөртә. Әнә бит, Насыйбулла да, Низам да Сталинга хат язып, дөреслек хакында хәбәр итмәкче… Ә бит шушы ук Низам да, аның кулак тамгасы сугылган əти-əнисе дә утызынчы елларда ук Сталин әмере белән Себергә сөрелгән, «халык дошманы» дигән ярлык та патша боерыгы белән тагылмаган… Әлеге дәүләттә кеше язмышы бөҗәкнекеннән артык аерылмый. Әлеге фикер Комарик кушаматлы тоткынны сурәтләгәндә дә, ачык ярылып ята. Әти-әнисе ачлыктан үлгән баланы приютка китергәч, аңа Иван Комарик дигән өр-яңа исем бирәләр – әнисе Камәр исемле булган икән… Сүз уңаеннан, бу рольне башкарган Руслан Ибраһимов, образның исемен җисеменә туры китереп, бик оста башкарып чыкты. Төрмә шулпасын шактый авыз иткән, черки урынына безелдәп торган, кызу канлы, кирәк чакта яраклашырга да, үзен якларга да өйрәнгән мәрхәмәтсез, әмма бик кызганыч яшь егетне кыска гына күренешләрдә менә дигән итеп күрсәтә алды. Бүген дә балалар йортында, урамда тәрбияләнгән меңләгән яшүсмернең язмышы, ни кызганыч, Комарик язмышыннан күпкә аерылмый. Теге яки бу сәбәп белән ата-ана җылысыннан мәхрүм калган балалар беркемгә дә, шул исәптән, дәүләткә дә кирәкми…

Кайтып, күзенә күренгәнче Насыйбулласын көткән Гөлия (Индира Маликова) – сабыр татар хатынының бер үрнәге. «Шулай насыйп булгандыр инде, Насыйбулла». Шушы бер җөмләгә хатынның унөч ел буе тешен кысып, ирен көтүе дә, нарасыеның ачтан үлү хәсрәтен эчкә йотуы да, Тахау кебекләр алдында тезләнмичә яши белүе дә сыеп беткән. Шулай, кемнәрдер якты коммунизмга ышанып, икенчеләр Аллаһы Тәгаләнең язганы дип, гомер кичерә. Хәтта ата карак Большой Татарин да: «Бар нәрсә Аллаһы Тәгалә кодрәтендә! Син үз тормышыңа үзең хуҗа түгел. Совет власте да хуҗа түгел аңа!» – дип фикер йөртә.

Авыл советы рәисе Локман (Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Инсаф Фәхретдинов) исә үз кыйбласын үзе дә аңламаган ир буларак тасвирлана. Насыйбулла авызыннан без аның чучка асрап сатуын, әмма үзе ашамавын («гөнаһ була!») беләбез. Бабайны паспортлы итү артыннан да Локман йөри, карчыкларның пенсиясен арттыру өчен дә ул йөгерә. Ул – уңай сыйфатлары да, тискәреләре дә җитәрлек булган гап-гади җир кешесе, без яшәгән системаның чираттагы корбаны. Авыл советы рәисенең ике сүзнең берсендә «замглавы Лариса Мирзагитовна» дип кабатлап торуына игътибар итү җитә – югарыдан нинди әмер бирелсә, Локман кебекләр аны үтәү өчен җирдән шуышырга әзер. Бүген дә эреле-ваклы түрәләрнең һәрберсе үз кәнәфие өчен җан калтырап тора, алар янәшәдә гади кешеләр барлыгын, гадәттә, сайлаулар алдыннан гына искә төшерә. Табаннарын яларга әзер әнчекләре дә гомер бакый булган, бар һәм булачак та. Тахау – шундыйларның бер мисалы. Автор тарафыннан ул кешелексез, шул ук вакытта ялган идеологиягә алданган бәхетсез бер җан иясе итеп бирелә. Аның кебекләр кемнедер яратырга сәләтсез; башкалар бәхетеннән көнләшү, хөсетлек аларның үзләрен дә бәхетсез итә. Мәсәлән, Тахау – гомер буе Насыйбулла артыннан күзәтеп, аның һәр гамәлен тиешле урынга җиткереп яшәгән, үз тормышына күз салырга вакыты да, җае да булмаган адәм актыгы. Картлык көнендә аның бер куанычы да юк. «Балаларының да җүне булмады… Үзе авыл көтүлегеннән ерак китә алмады, авылдан бер дә чыкмады», – ди Насыйбулла аның турында. Шунысы куркыныч: безнең милләттә Тахау кебекләрнең бетәсе, «татар башын татар ашар» дигән мәкальнең үз көчен югалтасы юктыр, ахры. Тарих тәгәрмәче бертуктаусыз хәрәкәттә, гел әйләнеп тора. Үткәннәрдән гыйбрәт алыр өчен алар турында дөресен белү кирәк бит әле. Мәктәптә укытылган тарих дәреслекләре дә, китаплар да, без карап үскән кинофильмнар да матур ялган белән өретелеп, дөньяның ике төскә генә – ак һәм карага бүленүен генә тасвирлап килде. Чит илләр, фашизм, капитализм – кара, совет

кешесе, совет иле – ак төсләргә төренгән иде. Бөек Ватан сугышы китергән фаҗигаләр турында да белергә тиеш булганны гына белдек. Ә бит совет сугышчылары арасында Насыйбулла кебек «туган авылым, әнием, Гөлиям өчен» дип, ут эченә керүчеләр дә; бер-берсен чәнчеп үтерергә әзер уголовниклар да; командирларның акылсыз боерыгы аркасында күрәләтә үлемгә баруын ачык аңлаган хәлдә дә «За Родину!» дип, атакага күтәрелгән Большой Татарин кебекләр дә җитәрлек... Яраланган Насыйбулла өчен сугыш немец концлагеренда дәвам итә. Биредә инде җан асрау, яшәү, ачтан үлмәү өчен көрәш. Аннан соң – «сатлыкҗаннарны» колач җәеп көтеп торган ватан төрмәләре. Совет төрмәсендәге җәзалау ысуллары Насыйбулланы гына түгел, бик күпләрне тез чүктерә. Ул инде какшамас, кыю, имәндәй Насыйбулла түгел, теләсә нинди гаепне үз өстенә алырга әзер, ул кыйналган, сындырылган… «Без права выезда» дигән кәгазь белән авылга кайтып төшкән Насыйбулланың тәнендә чыкмаган җаны гына бар. Ирнең бөтен теләге – үз гомерен тынычлап яшәп бетерергә ирек бирсеннәр, аңа тимәсеннәр генә. Ләкин бу җәмгыятьтә шәхси иреккә урын юк. Мөмкин булса, һәркемнең күпме һава сулавына кадәр исәпләп торырлар иде. «Теләсә кайсы дәүләт – ул кешене изү өчен төзелгән система», – ди Равил Сабырның төп герое. Әлеге фикер әсәрнең буеннан-буена сузылып, автор шуны расларга тырыша да инде.

Насыйбулланың немец концлагеренда тарихи шәхес, Көнчыгыш министрлыгы хезмәткәре, профессор Әхмәт Тимер (Татарстанның халык артисты Булат Сәлахов) белән очрашу күренешендә, татарның туган иле кайда дигән сорауга җавап эзләнелә. Әхмәт Тимернең: «Татарның Казан ханлыгы булган, СССР төзелгәч, яһүд большевиклары, татарның «т» хәрефен дә калдырмыйча, кырып бетерүне максат итте», – дип, Насыйбулланы Идел-Урал легионына язылырга кыставы бернинди нәтиҗә бирми. Насыйбулла өчен дәүләтнең ничек аталуы мөһим түгел, патшаның кем булуында да аерма юк, ул мең дә беренче кат үз сүзен тәкрарлый: «Нимес төзеп биргән республика Мәскәү төзегәненнән нәрсәсе белән аерылсын? Кирәкми миңа бернинди суверенитет да, фашизм да, коммунизм да, капитализм да кирәкми, берсе дә кирәкми. Минем тынычлап яшисем килә!»

Әмма җәмгыятьтә яшәп, җәмгыятьтән азат булу мөмкин түгел. Кешелек ялган сәгатьтән үк яхшылык һәм явызлык, хакимнәр һәм коллар булган. Адәм баласының үз тормышы белән генә яшәргә хыяллануы – утопия. Насыйбулла да, «бүген минем Җиңү көне!» дип, ничек кенә өметләнмәсен, абагалар чәчәк атмый, атмый…

Яшь журналистның спектакль азагында төп геройдан хат аша кичерү соравы, бөтен җәмгыять исеменнән гафу үтенүе тамашачыны кырыс тормыш чынбарлыгы белән күзгә-күз очраштыра. Без бит кино, спектакль, хикәя-повестьларның якты төсләр белән, оптимистик рухта тәмамлануына күнеккән. Биредә исә әкияти романтикага урын юк: кеше – башкалар кулында уенчык, корбан. Әлеге кануннан беркем дә ташлама өмет итә алмый; максатыма ирешәм дип хыялланган Айбулат үзе дә – чираттагы корбан. Ул әзерләгән язмасын матбугатта бастыра алмый, шул рәвешле безнең илдә җиңүчеләр юклыгына үзе дә инана шикелле… Ә бит аның «Безнең ил үзгәрергә тиеш. Үзгәртәчәкбез без аны!» дигән сүзләренә шулкадәр ышанасы килгән иде…

Әсәрне сәхнәләштергән Чаллы театры артистларының бар күңел җылысын биреп уйнавы, режиссёрның олы хезмәте, отышлы сайланган музыка, яңа сәхнәнең бизәлеш һәм ут мөмкинлекләре – болар барысы бербөтен тәшкил итеп, театр коллективының да, авторның да уртак уңышы булып тора. Фаил Ибраһимов, гадәттәгечә, үз югарылыгында – аның символик образлары беркайчан беркемне битараф калдырмый. Спектакльнең башыннан азагына кадәр сәхнә өстендә эленеп торган рәшәткә – адәм баласының кылдан нечкә, кылычтан үткен гомер юлын теләсә кайсы мизгелдә өзәргә әзер балта булып күзаллана. Ә кеше абага чәчәге һәм бәхет турында хыяллана…

**Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА**

# «ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТОРМЫШ ҺӘМ ИҖАТ ХРОНИКАСЫ ӨЧЕН МАТЕРИАЛЛАР»

*2021 ел ахырында мәшһүр шагыйребезнең тормыш юлын-иҗатын җентекле тергезеп, бүгенге көнгә билгеле барлык мәгълүматларны күздән кичереп язылган, «Габдулла Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы өчен материаллар» дигән 3 томлык зур хезмәт дөнья күрде. Татар һәм рус телләрендә әзерләнгән бу басма – Тукайны өйрәнү фәненең бүгенге көнгә иң олы казанышы, аның Мәскәүдә Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык уздырган конкурста иң яхшы фәнни проект буларак, беренче урынны яулавы моны тагын бер тапкыр раслый. Журнал укучыларына әлеге басмага, гомумән, Г.Тукайны, татар әдәбиятын өйрәнү һәм популярлаштыруга кагылышлы уйлануларны туплаган язма тәкъдим итәбез.*

Үзенең «Уянгач беренче эшем» дигән соңгы мәкаләсендә Г.Тукай «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын энәсендән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле», дип язган. Әйе, һәр халык милли әдәбияты хәзинәсенең җәүһәрләрен тәшкил иткән шагыйрь-әдипләр тормышын тәфсилләп өйрәнергә, Тукай әйтмешли, «энәсендән җебенә кадәр» тикшерергә тырыша.

Бу эш төрле халыкларда төрле вакытта башлана. Русларның әдәбият фәнендә моның беренче үрнәкләре XIX гасыр ахырында күренә: матбугатта башлап «Хронологическая канва для биографии Грибоедова» (1889) – танылган рус язучысының тормыш юлын билгеле бер тәртиптә актырткан хезмәт пәйда була, аннары башка язучыларны шушы рәвешле өйрәнүгә юл ачыла.

Бу төр хезмәтләр биографик жанрдагы язмалардан аерылып тора: нигез итеп «вакыт» төшенчәсе алына, ягъни әдип тормышында булган вакыйгалар вакыт агымына бәйле тергезелә (димәк, бу очракта иң әһәмиятлесе – мөмкин кадәр төгәллек белән әдип тормышында булган вакыйгаларны ачыклау һәм аларны хронологик тәртиптә урнаштыру). XX гасырда русларда мондый хезмәтләр «летопись жизни и творчества» («тормыш һәм иҗат елъязмасы») дип йөртелә башлый. Бу жанрда язылган биографияләр аз түгел: укучыларга А.С. Пушкин, И.С. Тургенев, Н.А. Некрасов, Л.Н. Толстой, Ф.М. Достоевский, Н. Лесковның елъязмалары мәгълүм. XXI гасыр башында Мәскәү Дөнья әдәбияты институты (ИМЛИ) галимнәре өч китаптан торган «Хроника жизни и творчества А.С. Пушкина» исемле басма әзерләделәр (гәрчә үзләре «хроника»ның «елъязма»дан аермалы сыйфатларын күрсәтсәләр дә, алар принципиаль түгел: хроника мәдәни контекстка игътибарның күбрәк булуы белән генә үзенчәлекле).

Татарларда «елъязма» яки «хроника» жанрында язылган хезмәтләр таралыш алмаган. Бу ни өчен шулайдыр – әйтүе кыен. Дөрес, XX гасырда әдәбиятчылар тарафыннан әдипләребезнең тормыш һәм иҗат елъязмаларын булдыру өчен адымнар ясалган. 1960 елларда Сәгыйть Исәнбаевның «Габдулла Тукайның тормышы һәм





иҗат хроникасы» дигән хезмәт өстендә эшләгәне мәгълүм, ләкин башлаган эшне тәмамларга өлгермичә, 1972 елны әдәбиятчы вафат була. Бирредә шуны да өстәргә кирәк: аның Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (ТӘҺСИ) Язма мирас үзәгендә саклана торган архивында Ибраһим Нуруллинның әлеге «Хроника»га нисбәтле рецензиясе бар. Олпат галимебез бу хезмәтнең әһәмиятен күрсәтсә дә (Ибраһим ага «Тукай хроникасы» турында «Тукайны яраткан һәрбер кешенең өстәлендә торырга тиешле китап ул», дип яза), үз бәяләмәсендә С.Исәнбаев кулъязмасындагы шактый күп кимчелекләрне билгели. Аларның иң зурысы – хезмәтнең «хроника» таләпләренә туры килмәве, ягъни вакыйгаларны даталарга бәйле тезү принцибыннан тайпылу. Бәлки, шуңа күрә дә С.Исәнбаев хезмәте дөнья күрмәгәндер – анысын хәзер төгәл әйтеп булмас.

Бу өлкәдә Тукайның тормышы һәм иҗатына бәйле икенче тәҗрибә XXI гасыр башында ясала. 2003 елда Татарстан китап нәшриятында «Габдулла Тукай. Тормыш һәм иҗат елъязмасы» исемле китап басылып чыга (төзүчеләр – ТӘҺСИ галимнәре Ә.Алиева һәм Ф.Ибраһимова). Бу хезмәттә хроникага хас төзелеш принцибы (вакыйгаларны мөмкин кадәр даталарга бәйле тезү) саклanса да, кимчелекләре дә юк түгел. Аларның иң күренә торганы – вакыйгаларның азлыгы. Мисал өчен, 1898 елга нисбәтле – бер, 1899 елга – өч, 1900 елга – ике, 1901 елга бер вакыйга күрсәтелгән. Бу инде, Тукай үзе әйтмешли, шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын «әнәсендән җебенә кадәр» тикшерүдән шактый ерак тора.

Ничек генә булмасын, хәзерге көндә без бер генә татар язучысының да иҗатына һәм тормышына бәйле «елъязма», яки «хроника» жанрында язылган хезмәт белән мактана алмыйбыз. Шул ук вакытта әлеге жанрның отышлы яклары бар: хроника, башка биографик хикәяләүләр белән чагыштырганда, бары тик даталарга бәйле фактларга нигезләнгән булырга тиеш. Бу очракта укучыга әдипнең тормышындагы хәлләргә субъектив караш тагылмый, фәкать фактик мәгълүмат бирелә (фәлән көнне әдип фәлән җиргә барган, фәлән кеше белән очрашкан, фәлән вакыйгаларда катнашкан һ.б.). Гади укучыга бу төр нарратив, бәлки, кызык та булмас, ләкин объективлык өчен бик мөһим.

Татар әдәбият белемендә истәлек жанры зур урын алган. XX гасыр дәвамында Г.Тукай шәхесенә бәйле берничә истәлекләр җыентыклары дөнья күрде (әдәбият сөючеләргә алар мәгълүм, шуңа күрә бирредә исемнәрен телгә алу артык булыр). Боларның әһәмиятен инкяр итмичә, шуны да искәртергә кирәк: истәлек – субъектив жанр, аларга гына таянып, «бу хәл әдипнең тормышында шул вакытта, шул рәвешле булган» дип раслау мөмкин түгел. Истәлекләр фәкать төрле архивларда табылган документларда теркәлгән фактлар белән чагыштырганда, хакыйкый төс ала (верификацияләнә). Сүз дә юк, истәлек-ядкярләрнең үз кыйммәте бар: субъектив булуларына карамастан, алар әдипләребез тормыш сәхифәләрендәге вакыйгаларга ачыклык кертәләр, шул ук вакытта шәхеснең психологиясе, дөньяга карашы, гадәтләре һ.б. турында мәгълүмат бирәләр.

Узган ел ахырында дөнья күргән өч томлык «Габдулла Тукайның тормыш һәм




иҗат хроникасы өчен материаллар» басмасы югарыда әйтелгән вазгыятьне күздә тотып эшләнде. Баштан ук әйтергә кирәк: бу хезмәтне чын мәгънәсендә «хроника» дип әйтү дөрес булмас (шуңа күрә аны әзерләүчеләр «хроника өчен материаллар» дип атаганнар). Дөресрәге, бу хезмәт – «биография» һәм «хроника» сыйфатларын берләштерә. «Ни өчен «хроника» гына түгел?» дигән сорауга җавап биргәндә, берничә мәсьәләне кузгатырга мәҗбүрбез.

«А.С. Пушкин тормыш һәм иҗат хроникасы» рәвешендә хезмәт булдыру өчен әлегә фәнни һәм мәдәни көч җитәрлек түгел. Шунысын да әйтергә кирәк: А.С. Пушкинның елъязмасын төзү ИМЛИдә 1938 елда башланып, аның беренче китабы унөч елдан соң, 1951 елны дөнья күрә. Бу эшнең дәвамы 1990 елларда кабат кузгатыла, һәм монда, шиксез, институтта Пушкин иҗатын өйрәнү өчен аерым сектор оештыру зур роль уйный. Кызганычка каршы, безнең фәнни оешмаларыбызда Г.Тукай секторы яки Г.Тукай комиссиясе дигән төркемнәр юк. Билгеле, андый фәнни берәмлекләрнең булмавы Тукай иҗатын фәнни яктан тикшерү өчен киртә дип әйтеп булмый – XX гасырда галимнәребезнең Г.Тукайга багышланган йөзләгән хезмәтләре моны ачык дәлилли. Ләкин зур фәнни проектларны башкарганда, аерым галимнәрнең көче генә җитми, фәнни коллективлар булу сорала.

Икенчедән, ТӘҺСИ галимнәре бу эшкә алынганда, аны чиста фәнни хезмәт итеп кенә түгел, бәлки, фәнни-популяр басма рәвешендә башкару максаты куелган иде. Шуңа күрә өч томлык галимнәр өчен генә түгел, гади укучыга да кызыклы һәм файдалы булсын дип эшләнде.

Өченчедән, китаплар ике телдә әзерләнгәннәр. Сер түгел, рус телле укучылар (биредә руслар гына түгел, башка милләт укучылары да күздә тотыла) татар әдәбиятыннан аз хәбәрдар. Мин җөмһүриятебездә яшәүчеләрдән бигрәк, чит төбәкләрдәге укучыларны күздә тотам. Аларның татар әдәбияты (шул исәптән, Тукай иҗаты) турында мәгълүматлары юк дәрәҗәсендә. Шуңа күрә соңгы вакытта Интернет аша таралган төрле сафсаталарга очрап (мисал өчен, Айдар Хөсәеновның Тукайның әдәби фейк булуы турында язып чыгуын китереп үтәргә мөмкин), бу сүзләргә ышанулары да ихтимал. Проектны ике телдә башкарганда, без шуны да күздә тоттык. Гомумән, әдипләребезнең рус телендә язылган биографияләре булу бик мөһим. 45 ел элек Мәскәүдә «Яшь гвардия» нәшриятында И.Нуруллинның «Тукай» китабы рус телендә чыкканнан бирле (китап «Атаклы шәхесләр тормышы» сериясендә 1977 елда басылды), башка хезмәтләр күренгәне юк.

Кемдер әйтергә мөмкин: «Хәзерге рус укучысы татар әдәбияты белән кызыксынмый, шуңа күрә дә рус телендә андый биографик хезмәтләр язылмый». Бу сүзләр нигезсез түгел: кызганычка каршы, милли әдәбиятларга игътибар кими. Үзәк тарафыннан бу эш Советлар Союзы чорындагыча системалы алып барылмый (гәрчә соңгы елларда бу мәсьәләдә федераль үзәкнең аерым эшләре күренә башлады: 2016 елдан милли әдәбиятларга ярдәм итүдә федераль программа эшли, бу программа кысаларында төрле чаралар уздырыла). Ләкин аңа карап, бу юнәлештә көтеп тору дөрес булмас. Иң беренче чиратта, рус телендә татар әдипләре һәм, гомумән, татар әдәбияты




турында хезмәтләр әзерләүдә үз көчебездән файдаланырга кирәк. Монда да проблемалар юк түгел: татар әдәбиятын әдәби яки фәнни өслүб белән рус телендә яктырта алучыларның саны бик аз, татар теленнән русчага иркен тәрҗемә кылучылар да санаулы. Ләкин көчебездән килгәнне эшләүдән башка юл юк.

Проектның идеясе турында да берничә сүз. Бу басманың һәрбер китабы үзәгендә, билгеле, Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты тора. Аларны яктыртканда, авторлар киң планда шул чор иҗтимагый, мәдәни, әдәби тормышына игътибар бирәләр: Г.Тукай эшләгән газета һәм журналлар (Уральскида К.Төхфәтуллин оештырган «Фикер», «Уклар», «Әл-гасыр әл-җәдит», Казандагы «Әл-ислах», «Яшен», «Аң», «Ялт-йолт»лар, аларның наширләре, мөхәррирләре, хезмәткәрләре), Г.Тукайның даирәсе (биредә аерым игътибар шагыйрьгә якын булган һәм аның шәхесенә, иҗатына тәэсир иткән иҗат әһелләренә бирелә: Ф.Әмирхан, Г.Камал, С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, Ә.Хәсәни, В.Бәхтияров һ.б.), Тукай белән бәйле урыннар (кунакханәләр, редакцияләр урнашкан биналар, китапханәләр, клублар, күңел ачу урыннары һ.б.), Г.Тукайның сәяхәтләре (Әстерханда, Уфада, Петербургта, Троицкида булган вакыйгалар, очрашулар, танышулар).

Вакыйгаларны яктыртканда, төрле чыганаклар кулланыла: архив материаллары, шагыйрьнең «Исемдә калганнар» автобиографиясе, юлъязмалары, хатлар, замандашларының истәлекләре. Төрле жанрдагы бу чыганаклар китапларның бүлекләрендә үрелеп бара, һәм мондый төзелеш укырга кызыксындыра. Бер үк вакыйга газетадагы игълан, кемнеңдер истәлеге, хаты аша бирелгәндә, укучы моны бер ноктадан гына түгел – төрле яктан, төрле кешеләр күзлегеннән кабул итәргә мөмкин. Бер мисал китерик.

Тукайның язучы һәм журналист Галиәсгар Гафуров (Чыгътай) белән үзара мөнәсәбәтләре киеренке булу мәгълүм. Мулла указыннан коры калмас өчен үзенең «Исабәт» хезмәтендәге фикерләреннән баш тарткан Чыгътайдан көлеп, Тукай 1910 елны «Мәҗрух указ» шигырен иҗат итә. Ләкин Ш.Шәрәф истәлекләренә караганда, вафатына кырык көн калган Тукай: «Яшьлек берлә әллә нәрсәләр язылган, кайсыбер шигырьләремне күрәсем дә килми, халыкның дини яки милли шогурларына (аңнарына) тукына торган нәрсәләрне бер дә яратмыйм, шуңарга күрә «Исабәт» чыгаручыга каршы да бер шигырь язып ташлаган идем», – дигән була. Күрәсең, бу шигырен язганда, Тукай Чыгътайның «указдан мәхрүм калырмын» дип тәүбәгә килүеннән генә көлмәгән – «Исабәт»тәге фикерләре белән килешмәгәнгә дә аны һөҗүм утына алган.

Проектның тагын бер үзенчәлеге – Тукай иҗатына һәм тормышына бәйле берьяклы карашлардан баш тарту. XX гасырда Тукайның тормыш һәм иҗат юлын яктырткан хезмәтләрнең күбесендә шул чор идеологиясенә буйсынган шәрехләүләр аз түгел. Әйтик, танылган тарих белгече Р. Нәфыйковның Тукайга багышланган хезмәтләрендә (мәсәлән, рус телендә чыккан «Тукай и его окружение»сендә) галим, төрледән-төрле фактлар табып, шагыйрьнең большевиклар хәрәкәтенә якын булуын күрсәтергә тырыша. Моның өчен зур хезмәт башкарылган, төрле архивлардагы документлар

өйрәнелеп, Тукай фәненә байтак кына яңа материаллар килеп кушылган. Шул ук вакытта бу фактлар арасында иң лаеклысы дип, Г.Тукайның большевиклар фиркасе тарафдарлары белән мөнәсәбәттә булуы күрсәтелгән.

Тагын бер мисал. Тукай биографиясе белән азмы-күпме таныш укучыларга мәгълүм: шагыйрьнең язмышында зур роль уйнаган кешеләрнең берсе – Уральскидагы җизнәсе Галиәсгар Госманов (ятим баланы үз йортына китертеп, ул аны Уральскидагы атаклы «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә бирә, русча да укыта). И.Нуруллинның «Атаклы кешеләр тормышы» сериясендә чыккан китабында Тукайның җизнәсе белән киеренке мөнәсәбәтләре телгә алына, бу каршылыкның нигезе буларак иҗтимагый сәбәпләр күрсәтелә (шактый хәлле сәүдәгәр тормышы белән яшәгән Г.Госманов, имеш, ятимлектә, нужа кичергән яшүсмер Тукай белән берничек тә уртак тел таба алмаган). Әйе, аерым истәлекләрдә, җизнәсе вафат булгач, яшүсмер Тукайның зур кайгы кичермәве искәртелә. Ләкин бу психологик яктан да аңлаешлы: кайчандыр үз атасы турында җизнәсеннән ишетелгән авыр сүзләр, билгеле, яшүсмернең йөрәгенә кадалмый калмаган.

«Хроника» китапларында андый шәрехләүләр дә китерелә, ләкин аларны авторлар укучыга бердәнбер хакыйкать дип тәкъдим итмичә, аерым бер караш төсендә телгә алалар һәм, төрле чыганакларга таянып, башка фикерләрне дә китерәләр. Гомумән, хезмәттә озак еллар яшәп килгән стереотиплардан баш тартырга омтылыш көчле. Мәсәлән, хәзер инде беркем дә, кадимчелек белән җәдитчелек мәсьәләсен тикшергәндә, кадими фикер йөртүчеләрне милләтнең алгарышына киртә салучылар дип кенә бәяләми. Ләкин Тукай биографияләрендә мондый бәя әле дә хөкем сөрә. Аерым очракларда (әйтик, «Бәян әл-хак» газетасын оештыручы Ә.Сәйдәшевкә мөнәсәбәтле) андый фикерләүгә нигез итеп нәкъ Тукай карашлары, сүзләре, язмалары алынган. Яңа басманың авторлары, Г.Тукайның абруена сүз тидермичә, субъектив шәрехләүләрдән баш тартып, фактларны, шул чорда яшәгән төрле шәхесләрнең фикерләрен китереп, укучыга бу хакта мөстәкыйль хөкем итәргә мөмкинлек бирәләр.

Чорның мәдәни тормышын күз алдына китерер өчен басманы әзерләүчеләр китапларга Тукай тормышы һәм иҗатына бәйле булган күптөрле фотосурәтләр урнаштырган.

Күзәтүебезне И.Нуруллинның «Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты хроникасы»на карата әйтелгән сүзләр белән башлаган идек. Әйе, 3 китаптан торган һәм зур көч куеп эшләнгән бу басма, олы галимебез әйтмешли: «Тукайны яраткан һәрбер кешенең өстәлендә торырга тиешле». Шуңа өметләнәбез.

**Марсель ИБРАҺИМОВ,**
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге фәнни хезмәткәре*

# ТУКАЙНЫҢ ЙӨЗ ЕЛЛЫГЫН ҮТКӘРГӘНДӘ

«Казан утлары» журналы редакциясе егетләре Камил Кәримов белән Вакыйф Нуриев эшләгән бүлмәгә кергән саен диварга эленгән зур фоторәсемгә күз төшермичә калмыйм. Могтәбәр язучыбыз, каләмдәш дустыбыз Марсель Галиев бүләк иткән әлеге фотодагы шәхесләрне кабат берәм-берәм, җентекләп, күздән кичерә-кичерә: «Кемнәр бар да кемнәр юк... Кара син, ә... Мондагыларның егермеләбе бакыйлыкка күчкән икән бит инде!» – дим. Аннары сурәт астындагы «Г.Тукайның 100 еллыгын Мәскәүдә бәйрәм итәргә килгән Татарстан делегациясе. Октябрь, 1986 ел.» дигән язуны укыйм да бераз аптырабрак калам: «Бу фотога төшкән чакта без кайда булдык икән соң? Камил Кәримов бар, Марсель Галиев, Роберт Миңнуллин бар... Ул вакытта без дә бардык бит Мәскәүгә. Нишләп монда Рөстәм Кутуй, Ркаил Зәйдулла юк? Рәфкать Кәрами дә күренми. Үземне әйтмим дә инде!» – дип, егетләргә карыйм. Әле фотосурәттәге үз кыяфәтенә, әле миңа карап алган Камил дус анык кына берни әйтә алмыйча тора. Вакыйф дус исә: «Монда минем бер катышым да юк!» – дигән сыман җилкәсен генә селкетеп ала...

Ахыр чиктә, мин: «Фото астына дөрес язылмаган. Бу делегация Мәскәүгә яз көне барган булырга тиеш һәм Тукай юбилеена түгел, ә Муса Җәлилнекенә! Герой-шагыйребезнең дә ул елны юбилее – 80 еллыгы иде бит!» – дип, фараз кылып, үземне юатам...

– Син әйткәнчә булырга да бик мөмкин! – ди Вакыйф дус.

Язманы әлеге фотосурәткә бәйләп, шулай башлавымның хикмәте бар.

Беркөнне Татарстан Язучылар берлегенең авторлар белән эшләү бүлеге җитәкчесе Марат Закир:

– «Безнең мирас» журналына барырдай язмалар булырга тиеш монда, – дип, кулыма папкалар белән шыплап тулган бер олы букча тоттырды.

– Ә нигә «Безнең мирас»ка гына! «Казан утлары» өчен дә материаллар булырга бик мөмкин! – дидем мин.

Өйгә кайтуга, беренче эш итеп, әлеге букчада казынырга тотындым һәм «Г.Тукайның 100 еллыгын уздыру» дип исемләнгән бер папкага юлыктым. Ул, тышлыктагы язудан ук күренгәнчә, мәшһүребез Г.Тукайның 100 еллыгына нисбәтле язмалардан, белешмәләрдән, хатлардан, планнардан, төрле исемлекләрдән гыйбарәт булып чыкты. Һәм, әлбәттә, әлеге кыйммәте әйтеп бетергесез байлык арасында бөек шагыйрьнең 100 еллыгын Мәскәүдә зурлап үткәргән чарага Казаннан кемнәр һәм кайчан баруы теркәлеп калган исемлек тә бар...

Озын сүзнең кыскасы, булган материалларны, документ-фәләнне бер тәртипкә салып, аларны үземнең аңлатмалар һәм искәрмәләр белән сезнең хозурыгызга җиткерергә булдым.

Гадәттә, зур чаралар план-проекттан, әллә ниткән комиссияләрдән, чутсыз исемлекләрдән һәм төрле оешма җитәкчеләренә язылган хатлардан башлана. Рәисе – Туфан Миңнуллин, сәркатибе – Рәис Даутов, әгъзалары Илдар Юзеев, Ибраһим Нуруллин, Мәҗит Рәфыйков, Равил Бохараев, Мөхәммәт Мәһдиев, Наип Ләисов, Рәфыйк Нәфыйков булган оештыру комиссиясе, иң беренче итеп, Г.Тукайның 100 еллыгына нисбәтле эш планына кичекмәстән башкарылырга тиешле түбәндәге чараларны теркәп куюны *(болар барысы да машинкада русча бастырылган. –* **Л.Л.***)* мәгъкуль күрә:



*Мәскәүгә Г.Тукайның тууына 100 тулуга багышланган кичәгә баручылар, дип ялгыш уйланылган, чынлыкта 1986 елның язында М.Җәлилнең тууына 80 ел тулуга багышланган кичәне үткәрергә дип, Мәскәүгә килеп төшкән «десант». Алгы рәттә (сулдан уңга): Рәшит Гобәйдуллин, Хәйдәр Бигичев, Георгий Ибушев, Владимир Ефимов, Рәис Даутов, Зилә Сөнгатуллина, Нур Әхмәдиев, Камил Кәримов, Вафирә Гыйззәтуллина, Ганс Сәйфуллин; арткы рәттә: Рәдиф Гаташ, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Гәрәй Рәхим, Туфан Миңнуллин, (...), Юрий Борисенко, Кыям Миңлебаев, Мәхмүт Хәсәнов, Ольга Стрельникова, Мөхәммәт Гәрәев, (...), (...),Мирсәет Сөнгатуллин, Римма Ибраһимова, Марсель Галиев, Марат Тажетдинов, Роберт Миңнуллин, Ринат Мөхәммәдиев, Әхәт Гаффар, Мөхәммәт Мәһдиев, Мәдинә Маликова, Тәлгат Йосыпов, Гариф Ахунов, Сәлам Алишев, Ренат Харис, Флүн Мусин, Рәшит Сабиров, Гомәр Бәширов, Рафаэль Билалов, (...), Әмирхан Еники, Рәфыйк Таҗетдинов. (Фото Марсель Галиев архивыннан алынды).*

1. Бәйрәмне мәдәният сарайларында, авыл мәдәният йортларында, китапханәләрдә, барлык мәктәпләрдә, һөнәри училищеларда, урта һәм махсус сәнгати уку йортларында (тематик кичәләр, күргәзмәләр, концертлар) уздыру;

2. Төрле нәшриятларда («Художественная литература» (11 табак), «Советский писатель» (10 табак), «Детская литература» (5 табак), «Малыш» (балалар өчен шигырьләр), «Современник» (поэмалар), «Советская Россия» («Шүрәле» поэмасы) Г.Тукай китапларын бастыру, бу эшләргә Евгений Винокуров, Владимир Соколов, Владимир Солоухин, Лариса Васильева, Белла Ахмадуллина, Алла Ахундова, Владимир Леонович, Лев Озеров, Николай Старшинов, Яков Козловский, Владимир Микушевич, Юнна Мориц кебек язучы-шагыйрьләрне һәм тәрҗемәчеләрне җәлеп итү;

3. «Сәхнә йолдызлары» концертын үткәрү (15-17 апрельдә);

4. Әдәбият һәм сәнгать әһелләреннән торган бригадаларны республикадагы шәһәр һәм районнарга җибәрү;

5. Бәйрәм барышын матбугатта яктырту, радиотелевидение аша тәкъдим итү;

6. Чакыру билетлары хәстәрләү һәм бәйрәм программалары төзү;

7. Иҗат берлекләренең бәйрәмдә катнашуы;

8. Митинг өчен мәйдан әзерләү;

9. Бәйрәмгә кунаклар чакыру;

10. Сату-алуны оештыру (буфет, китап һәм сувенирлар сату);

11. Чәчәкләр (кәрҗин белән дә) сатып алу;

12. Г.Тукай каберен һәм Г.Тукай һәйкәлләрен тәртипкә китерү;

13. Г.Тукай һәйкәлләренә чәчәкләр салу;

14. Казанда Г.Тукай музеен ачу (26 апрель, 1986 ел);

15. Кырлайга (Арча) бару һәм шигъри бәйрәм оештыру.

ЮНЕСКО карары белән «1986 ел – Г.Тукай елы» дип игълан ителде. Әлбәттә, мәшһүребезнең олуг юбилеен Казанда (26 апрельдә һәм 11-12 июньнәрдә), Кырлайда (26 апрельдә һәм 12 июньдә) һәм Мәскәүдә (14 октябрьдә) зурлап уздыру планлаштырыла. Шул ук вакытта, Г.Тукай туган көннәрдә, ягъни 23-26 апрельдә, Әлмәттә, Чаллыда (ул чакта Брежнев шәһәре), Уфада, Әстерханда *(РСФСР Язучылар*

*берлегенең Әстерхан өлкәсендәге оешмасы җитәкчесе А.И.Шадриннан, аның Әстерхан партия өлкә комитеты секретаре А.П.Гужвин белән сөйләшүе, аннан Тукай юбилеен Әстерханда уздырырга ризалык алуы, әмма апрельдә язгы чәчүгә һәм балык тотуга бәйле мәшәкатьләр күп булганлыктан, бәйрәмне июнь уртасына чигерүләре турында хат (11 апрельдә язылган) килә. ТАССР Язучылар берлеге рәисе Туфан Миңнуллин, 16 апрельдә кулына килеп кергән ул хатны урынбасары Ризван Хәмидкә юллап, түбәндәге сүзләрне язуны кирәк таба: «Ризванга. Күздән төшермик. Т.Миңнуллин. 16.04.1986.»* – **Л.Л.**), шулай ук Лениногорск каласында әдәбият көннәре уздырырга ниятләп торалар. Мәсәлән, ул вакытта Әлмәт язучылар оешмасы секретаре вазифасын башкарган Әхәт Гаффардан берлек рәисенә мондый эчтәлектәге хат (*10 апрельдә язылган ул хатка Т.Миңнуллин болай дип язып куйган: «Ризван, хәбәрләш. 15.04.1986.»* – **Л.Л.**) килә: «Туфан Абдуллович! Г.Тукайга багышланган тантанада катнашыр өчен Әлмәткә бер Казан шагыйрен командировкага җибәреп булмыймы? Горкомда шул теләк белдерелде. М.Җәлилгә багышланган тантаналы кичәдә Я.Мостафинның (*Җәмил Мостафин – совет язучысы, тәнкыйтьче, Башкортстанның Чишмә районы Яңа Усман авылы тумасы, ул елларда – «Литературная Россия» газетасының редколлегия әгъзасы, Әхәт Гаффар белән дус иде, 2021 елның 29 октябрендә туксан дүрт яшендә вафат булды.* – **Л.Л.**) сөйләвен бик ошатып калганнар иде. Сәлам белән, Әхәт Гаффар.» Шушы хаты белән бергә юлланган икенче кәгазьдә исә, Әлмәт төбәгендәге әдипләрнең дә, аерым алганда, Г.Афзал, Ә.Маликов, Э.Мөэминова, К.Булатова, И.Әхсәновларның, шулай ук Лениногорск, Бөгелмә, Сарман, Азнакай һәм Баулыда яшәп иҗат итүче каләм әһелләренең Тукай юбилеена әзерләнүләре хакында бәян ителә. Икенче биттә исеме телгә алынган Энҗе Мөэминованың хыял-уе башкачарак булган, күрәсең, ул Казанда узачак олы тантанада катнашырга теләге барлыгын сиздереп, 12 апрельдә язучылар башлыгына аерым хат юллый, хат белән бергә «Иң зур бүләгем» дигән яңа шигырен дә җибәрә:


*Кемне генә сокландырмас, шатландырмас*
*Яңа гына ачылып килгән сабый теле! –*
*Яңа табыш, ачыш сыман тоела бит*
*Аның башлап әйткән һәрбер яңа сүзе.*

*Оныгыма Ана Теле бүләк иттем,*
*Татарчалап: «Әти!» – диде, «Әни!» – диде.*
*«Әйт әле син, күбәләк, – дип,*
*Сөйләшик без бергәләп, – дип,*
*Бөтерчектәй бөтерелеп, биеп йөрде.*

*Әйтерсең лә, моңа кадәр бер кеше дә,*
*Беркайчан да андый матур сүз әйтмәгән,*
*Гөлчәчәктәй иреннәрен һичбер кем дә*
*Аның кебек матур итеп тибрәтмәгән!*

*Оныгыма Ана Теле бүләк иттем –*
*Ата-бабам бүләк иткән матур телне.*
*Ул да, димен, оныгына бүләк итсен*
*Минем шушы тиңдәше юк бүләгемне.*

*Оныгыма Ана Теле бүләк иттем –*
*Күңел түрен бизәп торыр матур гөлне:*
*Алтын, көмеш, җәүһәрләрдән кыйммәтләрәк*
*Тукай, Такташ, Җәлилләрне биргән телне.*



*Г.Тукайның 100 еллыгының Кырлайда узган тантанасында шагыйрь Наҗар Нәҗми чыгыш ясаган вакыт. Микрофоннар турысында Харис Әшрәфҗановны (КПСС өлкә комитеты инструкторы (1985-1989), Туфан Миңнуллинны (ул чакта – Татарстан Язучылар берлеге рәисе) һәм шагыйрь Равил Фәйзуллинны шәйләргә мөмкин. Уңнан беренче – КПСС өлкә комитеты секретаре Рәис Беляев, КПСС өлкә комитетының мәдәният бүлеге мөдире Дания Зарипова, башкорт язучысы Әхияр Хәкимов, композитор Нәҗип Җиһанов (Н.Нәҗми артында). 1986 ел. М.Шакирҗанов фотосы. (Фото Л.Лерон архивыннан алынды.)*

Чаллы (әйткәнемчә, ул чакта – Брежнев) язучылар оешмасы секретаре Ямаш Игәнәй дә, коллегасы Әхәт Гаффар шикелле, рәискә махсус хат юллап («Ризван, сиңа инде бу. М.Туфан. 15.04.1986.»), үзләренә Казаннан әдипләр, аерымлап әйткәндә, Г.Тукай премиясе лауреаты Илдар Юзеевны, Андерсен исемендәге Халыкара премия лауреаты Шәүкәт Галиевне, шагыйрьләр Рөстәм Мингалим һәм Роберт Миңнуллинны җибәрүләрен үтенә.

Лениногорск шәһәр партия комитеты секретаре (1985-1990), соңыннан «Татнефть»нең генераль директоры (1990-2013) булачак Шәфәгать Фәхразый улы Тәхәветдинов та рәис Т.Миңнуллинга шушы уңай белән мөрәҗәгать итә (1 апрель, 1986 ел): «23-26 апрельдә Лениногорск шәһәрендә һәм районында бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга багышланган әдәбият һәм сәнгать көннәре уздырылачак, – ди ул һәм язучылар башлыгыннан әлеге чарага Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары Ибраһим Нуруллин белән Илдар Юзеевны җибәрүдә ярдәм итүен үтенә. Хатка кемдер зәңгәр кара белән «И.Юзеев һәм Р.Мингалимов китә» дип язып куйган.

Бөтенләй чит өлкәдән – Свердловскидан килгән хат та кызыклы. РСФСР Язучылар берлегенә караган Свердловск өлкәсе язучылар оешмасы рәисе Л.Л.Сорокин 1986 елның 21 мартында юллаган ул хатта («т. Хамидуллину. М.Туфан. 28.03.1986.») мондый юллар бар: «1986 елның 12 апрелендә Лавров исемендәге Мәдәният сараенда Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган татарча кичә узачак. Ошбу кичәгә Тукай иҗатын өйрәнгән әдәбият белгечен һәм шагыйрь көтеп калабыз. Юл чыгымнарын Свердловск өлкәсе китап сөючеләр җәмгыяте (рәис урынбасары Нина Афанасьевна Репенко) түләячәк. Кунаклар каршылауда җаваплы кеше – Фәрит Ләбиб улы Шәңгәрәев». Свердловскига кемнәр барачагын рәис урынбасары Ризван Хәмидуллин, алдан ачыклаган булса кирәк, Разил Вәлиев һәм Рәис Даутов барачак, дип язып куйган.

Бу урында Уфадан – Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Әсгат Мирзаһитовтан (1977-1988 елларда әлеге вазифаны башкара) Туфан Миңнуллинга килгән телеграмманы теркәп кую урынлы булыр: «Вечер Тукая в Уфе состоится 26 апреля накануне будет научно теоретическая конференция просим командировать двух представителей = Мирзагитов.»

Уфага Башкортстанда туган ике шагыйрь – Рәдиф Гаташ (ул чакта Гатауллин әле) белән Әхсән Баян тәгаенләнә. Алга китеп булса да әйтим, 26 апрельдә Уфада Башкорт дәүләт филармониясе залында Г.Тукайның туууына 100 ел тулуга багышланган кичә була, аны халык шагыйре Мостай Кәрим ача, шагыйрь Равил Бикбай исә бөек шагыйрь

турында доклад ясый, башкорт шагыйрьләре Гыйлемдар Рамазанов, Абдулхак Игебаев, Газим Шафиков белән бергә Татарстаннан кунак булып килгән шагыйрьләр Әхсән Баян һәм Рәдиф Гатауллин Тукайга нисбәтле шигырьләрен укый. Бу хакта «Кызыл таң» газетасының 1986 елның 27 апрель санында (№100 (17250), якшәмбе) хәбәр басылып чыга. Газетаның соңгы битендә Рәдиф Гатауллинның өч шигыре дә дөнья күргән.

Форсаттан файдаланып, ТАССР Язучылар берлеге рәисе урынбасары Ризван Хәмидкә адресланган ике хатны (аларны ул вакытта Чиләбедә яшәп иҗат итүче шагыйрә Салисә Гәрәева язган) тулаем китерергә булдым. Беренче хат (1986 елның 20 апрелендә язылган), икенчесенә караганда, шактый кыска:

«Ризван дус!

Троицкида Тукай кичәсе үткәрү буенча эшне башлап җибәрдек. Афишалар, чакыру билетлары бастырырга бирелде. Иртәгә Троицкига разведкага (*әлеге сүзнең астына сызылган.* – **Л.Л.)** китәм. Рөстәм Вәлиев тә (*Рөстәм Шәвәли улы Вәлиев (1936) – Чиләбедә яшәп рус телендә иҗат итүче язучы, Тукай турында роман («Заботы света», 1986) авторы, СССР Язучылар берлеге әгъзасы.* – **Л.Л.**) булышачак. Троицкидан кайткач, хат язармын. Әлегә майның 25-30 арасында дип тәгаенләп торабыз. Тәфсилләп, кайткач, хат язармын. Троицкида кичә булачак, дип әзерләнә торыгыз.

Әлегә шул. Барыгызга да кайнар сәлам. Салисә.»

Икенче хатның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт:

«Ризван дус! Урал сәламнәре озатып калам.

Мин Тукай кичәсе буенча Троицкида булдым. Кичәне 30 майга билгеләдек. Үзгәреш була калса, хәбәр итәрбез. Киләсе кешеләр шул срокка әзерләнә торсын. Троицкидагы дуслар – краевед, ветеран партии и комсомола Мөҗип Вахитович Вахитов һәм тат(ар) библиотекасы хезмәткәрләре бик каты әзерләнәләр. Чакыру билеты, афиша бастырганнар. Минем зур афиша да әзер. Тукайның зур әйбәт портреты бар, карадык, яңартырга бирдек. Шәһәр культура йортында буласы кичә (кичке сәг(ать) 19да). Ә көндез – Тукай урамы бәйрәмен үткәрү турында сөйләштек горисполком белән. Килүче илчеләр моны да истә тотсыннар! Газетага да материал кирәк булыр («Вперёд», авыл өчен «Степная нива» чыга). Ул материалны газета өчен туры Троицкига Мөҗип Вахитовка (*адресы күрсәтелә.* – **Л.Л.**) җибәрсәгез әйбәт булыр иде.

Союз исеменнән хат язарбыз. Троицкида гос(тиница) булыр, диделәр. Чиләбедә дә кирәк булыр инде ул. Троицкига Чиләбедән автобус (2 сәг. 30 м.) һәм электричка бара. Сорауларыгыз булса, туры миңа өйгә шалтыратыгыз (*телефон номерын күрсәтә.* – **Л.Л.**).

Чиләбедә дә үткәрергә исәп. Без анысын Рөстәм (Вәлиев) белән көзгә дип планлаштырабыз, шәһәрнең берәр театрын сорарга исәп, язучылар да чакырырбыз яңадан. Анысына яңа хәбәрләшү булыр.

Тукай плакатлары Троицкида да (Вахитовта), миндә дә бар. Бу баруымда мин биб(лиоте)кага (ул революциягә кадәр үк эшләгән) татар класс(ик) язучыларының бер комплект портретларын бүләк иттем.

Биб(лиоте)ка әзерләнә. Алар 26 апрельдә бер кичә үткәрделәр инде – ген(ераль) репетиция.

Әлегә шул. Сораулар булса – адрес, телефон бар. Йә иртән, йә кич мине тотарга була. Казан хәбәрләрен бераз беләм – радио тыңлыйм, хатлар да килгәли.


Тормыш элеккечә. Эш муеннан.

Тагы ни дим? Барыгызга да сәлам, Май һәм Җиңү бәйрәмнәре белән котлыйм, сәламәтлек телим. Ихт(ирам) белән – Салисә.

R.S. Ризван дус! Бер үтенеч: әгәр Р.Даутов әзерләгән тат(ар) язучылары турындагы био-библ(иографи)к җыентык чыккан булса, берне миңа алып куй әле, яме.»

Әхәт Габдрахман улының да, Ананий Нестерович Маловның да (Ямаш Игәнәйнең чын исем-фамилиясе шулай), Шәфәгать Фәхразый улының да, Әсгат Мәсгут улының

да, хәтта Свердловск язучылар оешмасы секретаре Л.Л.Воронинның да, кыскасы, шундый рухтагы сорау белән мөрәҗәгать итүчеләрнең барысының да үтенечләре канәгатьләндерелгәндер, язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез Мәдинә Маликова, Разил Вәлиев (Троицкида), Рөстәм Мингалим, Мөхәммәт Мәһдиев (Уральскида), Рәдиф Гатауллин (Р.Гаташ), Илдар Юзеев (Уфада), янә Разил Вәлиев, Әдип Маликов (Әстерханда), Зиннур Мансуров (Мөхәммәт Мәһдиев белән бергә, 4-6 апрельдә) Тукайга нисбәтле сәфәрләрдә булып кайтканнардыр, дип ышанасы килә.


ПРАВИТЕЛЬСТВЕННАЯ ТЕЛЕГРАММА
МИНИСТЕРСТВО СВЯЗИ СССР
Для заметок адресата
ПРИЕМ 10 1610 мин.
Бланк № 339
Принял
ПЕРЕДАЧА: ПРАВИТЕЛЬСТВЕННАЯ КАЗАНЬ БАУМАНА 19 СОЮЗ ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ=
№ связи
Передал
АЛМА-АТА 91/2111 85 10 1505=
ДОРОГИЕ ДРУЗЬЯ ЗПТ ВАШИ КАЗАХСТАНСКИЕ КОЛЛЕГИ ПОЗДРАВЛЯЮТ ВАС ВСЮ ОБЩЕСТВЕННОСТЬ РЕСПУБЛИКИ БОЛЬШИМ ЛИТЕРАТУРНЫМ ПРАЗДНИКОМ ДЛЯ ВСЕХ НАРОДОВ СОВЕТСКОЙ СТРАНЫ ЮБИЛЕЕМ ВЫДАЮЩЕГОСЯ ТАТАРСКОГО ПОЭТА ГАБУЛЛЫ ТУКАЯ ВСК ТУКАЯ ЗПТ ТВОРИВШЕГО МНОГИЕ ПРОИЗВЕДЕНИЯ НА БЕРЕГУ УРАЛА ЗПТ КАЗАХСТАНЦЫ СЧИТАЮТ И ПЕВЦОМ НАШИХ СТЕПЕЙ И ГОР ЗПТ СКЛОНЯЮ ГОЛОВЫ ПЕРЕД ЕГО ТАЛАНТОМ ЗПТ ХРАНЯТ ЕГО КНИГИ КАК ВЕЛИКУЮ ДРАГОЦЕННОСТЬ НА САМОМ ПОЧЕТНОМ МЕСТЕ СВОИХ КНИЖНЫХ ПОЛОК ТЧК ЖЕЛАЕМ УСПЕХА ПРОВЕДЕНИИ ЮБИЛЕЙНЫХ МЕРОПРИЯТИЙ ЗПТ ТВОРЧЕСКИХ УСПЕХОВ ПОТОМКАМ ТУКАЯ ТАТАРСКИМ ПИСАТЕЛЯМ=ОЛЖАС СУЛЕЙМЕНОВ-

*Казакъстан Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре (1984-1992), атаклы «АЗиЯ» авторы, шагыйрь Олжас Сөләймановның Татарстан берлеге идарәсенә 1986 елның апрель урталарында юллаган телеграммасы.*

Бөек шагыйребезнең туган көне якынлаша. Төрле төбәкләрдән котлау телеграммалары, хатлар килә. Бер телеграмманы биредә искә алмый ярамас. Аны ул чакта Казакъстан Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре вазифасын башкарган атаклы «АЗиЯ» авторы, шагыйрь Олжас Сөләйманов юллаган: «Дорогие друзья, ваши Казахстанские коллеги поздравляют Вас, всю общественность республики большим литературным праздником для всех народов Советсой страны юбилеем выдающегося татарского поэта Габдуллы Тукая! Тукая, творившего многие произведения на берегу Урала, казахстанцы считают и певцом наших степей и гор, склоняют головы перед его талантом, хранят его книги как великую драгоценность на самом почётном месте своих книжных полок. Желаем успеха в проведении юбилейных мероприятий, творческих успехов потомкам Тукая татарским писателям = Олжас Сулейманов.»

Инде килеп, 1986 елның 26 апрелендә Казанда (Ирек мәйданы) – Тукай һәйкәле янында кемнәр шигырь укыячагын (яки укыганын ) да белеп узыйк: Сибгат Хәким (митингны ачып җибәрә), Нури Арслан, Хисам Камалов, Мөхәммәт Садри, Рәшит Гәрәй, Равил Фәйзуллин, Николай Беляев, Ренат Харис, Рәдиф Гатауллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Равил Бохараев, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев, Эльмира Шәрифуллина, Ркаил Зәйдуллин, Марат Акчурин, Башкортстаннан, Мари АССРдан, Чувашиядән һәм Удмуртиядән килгән кунаклар.

Ул елны Тукай премиясенә ике кеше – язучы Хисам Камал («Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» романнары өчен) һәм рәссам Виктор Куделькин (Татарстан сәнгать әһелләренә, шулай ук хезмәт алдынгыларына багышланган күпсанлы портретлары, картиналары өчен) лаек булды.

***

Казанда Тукай көнендә узган чарадан соң Кырлайдагы олы бәйрәмгә, тагы да дәртләнеп, ныклап әзерләнә башлыйлар. Бу вакытта инде минем Язучылар берлегендә Әдәби фонд директоры вазифасына керешкән чагым. Әзерлек эшләрендә күпмедер дәрәҗәдә мине дә катнаштырдылар.

Календарь план мондыйрак рухта иде:

9-10 июнь. Кунакларны каршы алу, аларны «Татарстан» һәм «Яшьләр үзәге» кунакханәләренә урнаштыру (җаваплы кешеләр – Р.Кәрами, Ә.Рәшит, Р.Әмирханов);

10 июнь. Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган күргәзмәдә булу (14.00-16.00, җаваплы – Ә.Тумашев, Т.Миңнуллин); Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия

театрына барып, «Без китәбез, сез каласыз» спектаклен карау (19.00-22.00, җаваплы – Ш.Закиров, Р.Хәмид, Ш.Асылгәрәев);

11 июнь. В.И.Ленин, А.С.Пушкин, Г.Тукай, М.Горький һәйкәлләренә чәчәкләр салу (10.00, җаваплы – Л.Космылина, Т.Миңнуллин); шәһәр буйлап экскурсия (11.00-13.00, җаваплы – Л.Космылина, Р.Хәмид); Г.Тукай музеен ачу (14.00-15.00, җаваплы – Ф.Зыятдинова, Р.Идиятуллин, О.Ермакова, Л.Вәлиева); Г.Тукайның 100 еллыгы уңаеннан әзерләнгән тантаналы җыелышта һәм концертта катнашу (17.00, М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасы, җаваплы – Ф.Зыятдинова, М.Таишев, Т.Миңнуллин, М.Таҗетдинов, И.Мәҗитов);

12 июнь. Арчага бару (8.30, җаваплы – М.Таишев, М.Хәбибуллин, Ш.Асылгәрәев); Тукай-Кырлайда кунакларны каршы алу (11.30, җаваплы – КПССның Арча район комитеты); Г.Тукайның 100 еллыгына багышланган шигърият бәйрәме (11.30-13.30, җаваплы – Д.Каюмов, Т.Миңнуллин, М.Таишев, М.Таҗетдинов);

13 июнь. «Г.Тукай һәм СССР халыклары әдәбиятларының үзара бәйләнеше, бербърсен баетуы» дигән темага Бөтенсоюз фәнни-гамәли конференциясе (9.30-18.00, СССР Фәннәр академиясенең конференц-залы, җаваплы – М.Зәкиев, Н.Юзиев).

Инде хәзер Тукайның олуг бәйрәменә кайлардан кемнәр килергә тиешлеген ачыклыйк. Башта, зурдан кубып, Георгий Марков (прозаик, КПСС ҮК әгъзасы, СССР Язучылар берлеге идарәсенең беренче секретаре, Социалистик Хезмәт Герое), Юрий Верченко (СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре, РСФСР Югары Советы депутаты), Сергей Михалков (шагыйрь, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, СССР Язучылар берлеге идарәсе секретаре, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое), Рәсүл Гамзатов (Дагстан АССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, СССР Верховный Советы президиумы әгъзасы, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое), Чыңгыз Айтматов (язучы, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое), Эдуард Межелайтис (шагыйрь, Ленин премиясе лауреаты), Евгений Евтушенко (шагыйрь, СССР Дәүләт премиясе лауреаты), Давыд Көгелтдинов (шагыйрь, СССР Дәүләт премиясе лауреаты) чакырырга ният ителгән иде. Тора-бара, килергә тиешле әдипләр алышынып бетеп, исемлек шушындый булды: Николай Доризо (шагыйрь, Мәскәү, аңа Т.Миңнуллин беркетелгән), Михаил Кошечкин (Мәскәү, Г.Ахунов, Е.Лисин беркетелгән), Мостай Кәрим (Башкортстан, Р.Харис беркетелгән), Әхияр Хәкимов (башкорт язучысы, Мәскәү, М.Мәһдиев, И.Хәйруллин беркетелгән), Вил Ганиев (тәрҗемәче, шагыйрь Әхмәт Ерикәй кияве, Мәскәү, Р.Мостафин беркетелгән), Нажар Нәҗми (шагыйрь, Башкортстан, Р.Фәйзуллин беркетелгән), Кадим Аралбаев (Башкортстан), Сергей Комиссаров, Марат Акчурин (тәрҗемәче, Мәскәү), Александар Горленко, Ямил (Җәмил) Мостафин (Мәскәү), Рувим Моран (тәрҗемәче, Мәскәү, Ә.Мушинский беркетелгән), Рөстәм Вәлиев (Чиләбе, Р.Гатауллин беркетелгән), Николай Рыбаков (Мари АССР, Ш.Галиев беркетелгән), Порфирий Афанасьев (Чувашия Язучылар берлеге рәисе), Абдулла Арипов (шагыйрь, Үзбәкстан, Р.Мингалимов белән Ә.Сафин беркетелгән), Адихан Шадрин (татар, Мордовиядә туган, Әстерхан өлкәсе Язучылар оешмасы секретаре, М.Галиев беркетелгән), Байнияз Каипназаров (шагыйрь, Каракалпакстан халык шагыйре, Каракалпакстан Язучылар берлеге рәисе), Каалеп Айн (Эстония), Василий Эндип (В.Антипов, Чувашия), Владимир Леонович (Кострома), Абдулхак Мусалов (Габделхак Хөснетдин улы Мусалов, рәссам, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Әстерхан өлкәсендәге Кызыл Яр авылында туган, Б.Урманче һәм Ә.Тумашев беркетелгән), Николай Бабоглу (гагауз язучысы, Молдовия), Абдылдажан Акматалиев (галим, Ч.Айтматов иҗаты буенча белгеч, И.Юзеев беркетелгән), Токен Абдрахманов (казакъ язучысы, Казакъстан, җаваплы Р.Мөхәммәдиев). Биредә шуны гына әйтә алам: әлеге исемлеккә кергән язучыларның күбесе, ниндидер сәбәпләр аркасында, юбилей тантанасында катнаша алмады. Кунакларның бер өлеше, аерым алганда, Н.Доризо, М.Кошечкин, М.Кәрим, Ә.Хәкимов, В.Ганиев, Н.Нәҗми,

Я.Мостафин, А.Арипов, Т.Абдрахманов, А.Акматалиев, Б.Каипназаров КПСС өлкә комитетының Зинин урамындагы кунакханәсенә урнаштырылды. Н.Нәҗминең каршы алучысы һәм озатып йөрүчесе итеп Равил Фәйзуллин билгеләнгән булса да, нишләптер, бу вазифаны мин фәкыйрегезгә башкарырга туры килде. Шуның өстенә, каракалпак шагыйре Б.Каипназаров (миндә аның култамгасы салынган китабы саклана) белән үзбәк шагыйре, Тукайның адашы Абдулла Ариповны (соңыннан ул Үзбәкстанның халык шагыйре булды, Үзбәкстан гимны авторы, 2016 елның 5 ноябрендә Хьюстон (АКШ) хастаханәләренең берсендә вафат булды), миндә култамгасы салынган китабы саклана) озатып йөрү дә миңа йөкләнде. Әлеге шәхесләр белән аралашу минем өчен, шәхсән, зур мәртәбә иде («Тукайлы хатирәләр» дигән язмамда – ул «Идел» журналында ике санда дөнья күрде – бу турыда тәфсилләп яздым).

Казан үзәгендә урнашкан «Татарстан» кунакханәсендә Р.Кәрами (штаб җитәкчесе), Ә.Рәшит (штаб җитәкчесе урынбасары), К.Кәримов, Р.Низамиев, Мөдәррис Вәлиев, З.Мансуров, Х.Гайнетдинов, Б.Сулимов (Вайнер), Р.Зәйдуллин, Л.Зөлкарнәев, Г.Садә, Аяз Хәсәнов, Р.Юнысов, Ә.Сәхәповтан торган махсус штаб (резервта – Х.Әюпов, Г.Моратов) булдырылды.

Тукай-Кырлайда һәм Кушлавычта узачак бәйрәм тантанасында катнашу өчен 37 язучыга чакыру җибәрелде. Биредә исемлекне тулысынча китерергә булдым: Н.Арсланов, Г.Ахунов, Г.Бәширов, Ә.Баянов (Ә.Баян), Р.Батуллин, Н.Беляев, Р.Гатауллин (Р.Гаташ), Ш.Галиев, Ә.Гаффаров, Н.Дәүләтшин (Н.Дәүли), Ә.Еникиев (Ә.Еники), Л.Ихсанова, Р.Кәрамиев (Р.Кәрами), Л.Леронов (Л.Лерон), Д.Маликов (Зөлфәт), М.Мәһдиев, М.Маликова, Р.Мингалимов, Т.Миңнуллин, Р.Миңнуллин, Р.Мостафин, Р.Мөхәммәдиев, Ә.Рәшитов (Ә.Рәшит), Р.Фәйзуллин, М.Хәбибуллин, С.Хәкимов (С.Хәким), Р.Хәмидуллин (Р.Хәмид), Р.Харисов (Р.Харис), И.Юзеев, Я.Игәнәй, яңадан өстәлгән язучылар – М.Галиев, Р.Ишморатов, Р.Ишморатова, Н.Орешина, Д.Вәлиев, А.Әхмәдуллин.

Инде Тукай-Кырлайдагы тантаналы шигъри митингта кемнәр чыгыш ясаячагын да ачыклап китик. Менә алар: С.Хәким (авыруы сәбәпле, ул бәйрәмдә катнаша алмады, тернәкләнә алмыйча, шул ук елның 3 августында вафат булды), М.Кәрим, М.Хөсәенов (Арча районы башкарма комитеты рәисе), Н.Доризо, Н.Арсланов, И.Юзеев, Х.Гәрәева (Тукай районы укытучылары исеменнән чыгыш ясарга тиеш), Р.Гатауллин, Н.Дәүли, Р.Харис, Айп Каалеп, Н.Нәҗми, В.Эндип, Г.Рәхим, Р.Мингалимов, Р.Моран, Б.Каипназаров, Р.Бикбаев, Р.Бохараев, А.Арипов, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин, Р.Вәлиева.

Шигъри бәйрәмгә халык бик күп килгән иде. Наҗар Нәҗмиләр белән бергә Тукай музеен караганым, митингта катнашучыларның чыгышын, Мәскәүдән килгән кунакларның бер өлеше (Ә.Хәкимов, Я.Мостафин, В.Ганиев) белән бергә, Сабан туендагы шикелле итеп, чирәмгә утырып тыңлаганым исемдә калган.

***

Мәскәүдә узасы олы тантанага әзерлек бер ел алдан башлана, дисәк, һич тә хата булмас.

М.Җәлилнең тууына 80 ел тулуга нисбәтле хатны тиз арада Г.Тукайныкына әйләндереп, төзәтеп, өстисен өстәп, башта ТАССР Язучылар берлеге рәисе Туфан Миңнуллин исеменнән әзерләнгән үтенеч-хатны җәһәт кенә КПСС өлкә комитеты секретаре Гомәр Усманов исеменә үзгәртеп, аны СССР Язучылар идарәсенең ул чактагы беренче секретаре Георгий Марковка юллыйлар. Русча язылган хатның эчтәлеге белән танышыйк: «Уважаемый Георгий Мокеевич! 26 апреля 1986 года исполняется 100 лет со дня рождения основоположника татарской реалистической литературы, великого поэта Габдуллы Тукая. Тукай еще в дореволюционные годы стал знаменем нации, всех тюркоязычных народов Востока. Он сыграл огромную

роль в обогащение национальной культуры достижениями и традициями передовой русской и мировой литературы.

Г.Тукай обладал многими высокими качествами поэта, человека и гражданина, которые и сегодня привлекает строителей коммунистического общества.

По характеру своего творчества, активной гражданской позиции и влиянию на умы современников и последующих поколений он занимает достойное место в ряду таких корифеев классической литературы нашей Родины, как Шевченко, Абай, Шота Руставели, Махтумкули и др.

Исходя из художественной ценности и общественного значения творчества и деятельности Г.Тукая, Татарский ОК КПСС ходатайствует перед вами, уважаемый Георгий Мокеевич, о создании Всесоюзной юбилейной комиссии и проведении юбилейного вечера поэта в Колонном зале Дома Союзов, чтобы 100-летие одного из виднейших классиков нашей многонациональной литературы получило поистине достойное звучание. Первый секретарь Татарского ОК КПСС Г.И.Усманов. (*Хат язылу вакыты күрсәтелмәгән. –* **Л.Л.**)

Кем әйтмешли, мәсьәлә уңай хәл ителгән булса кирәк, күпмедер вакыттан соң «Татар әдәбияты классигы Г.Тукайның 100 еллыгын үткәрү буенча Бөтенсоюз юбилей комиссиясе» оештырыла. Әлеге комиссиягә кемнәр кергән соң? Исемлекне сезнең хозурга тәкъдим итәм: М.А.Дудин (рәис), М.Х.Хәсәнов (рәис урынбасары), комиссия әгъзалары – Т.Ә.Әскәров, М.Н.Алексеев, С.А.Баруздин, Р.К.Беляев (*1935-1996, дәүләт эшлеклесе, 1984-1987 елларда КПСС өлкә комитеты секретаре. –* **Л.Л.**), Ю.В.Бондарев, Р.Р.Бохараев, Ю.Н.Верченко, Р.Г.Гамзатов, Е.А.Евтушенко, Э.Ю.Зимин, М.А.Ибраһимов, М.С.Кәримов (М.Кәрим), М.Д.Львов, Г.М.Марков, Т.А.Миңнуллин, С.В.Михалков, Б.И.Олейник, О.О.Сөләйманов, М.Танк (Евгений Иванович Скурко), У.Р.Умарбеков (Үлмәс Омәрбәков), С.Т.Хәкимов (С.Хәким), А.Б.Чаковский, Г.В.Родионов *(Г.Рәхим, җаваплы секретарь, 1980-1987 елларда РСФСР Язучылар берлеге идарәсендә Татарстан, Башкортстан, Чувашиянең әдәби консультанты, Урал һәм Идел буе төрки әдәбиятлар комиссиясенең җаваплы сәркатибе һәм РСФСР милли әдәбиятлар эше буенча баш консультант булып эшләгән чагы. –* **Л.Л.**).

Бәйрәм тантанасы 1986 елның 15 октябренә тәгаенләнә. Әлеге тантанага барырга тиешле язучыларның исемнәре ачыклана, поездга билетлар алына. 13 октябрьдә Казаннан кузгалучылар: Т.Миңнуллин (делегация житәкчесе), Р.Хәмид (аңа билет купега – 9 нчы урынга алынган), Р.Мингалим (10 урын), Я.Игәнәй (11 урын), М.Галиев (12 урын), Г.Бәширов (13 урын), Ә.Гаффар (14 урын), В.Нуруллин (15-16 урыннар, күрәсең, хатыны белән барган), Ә.Рәшитов (17 урын), Л.Леронов (Л.Лерон, 18 урын), Р.Кәрами (19 урын), Р.Зәйдуллин (Р.Зәйдулла, 20 урын), Р.Харисов (Р.Харис, 21 урын), Р.Кутуй (22 урын), Р.Якупов (23 урын), Р.Миңнуллин (24 урын). Берничә язучы икенче көнне 14 октябрьдә юлга чыга: Ә.Баянов (хатыны белән), Р.Мостафин (хатыны белән), Р.Даутов (хатыны белән). Исемлеккә М.Әгъләмов та кертелгән булган, әмма аның исем-фамилиясе сызылган.

Йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: бөек Тукаебызның юбилее, чын мәгънәсендә – тантаналы шартларда, һәркайда – Казанда, Тукай-Кырлай белән Кушлавычта, Мәскәүдә, шулай ук Татарстанның һәм Россиянең төрле төбәкләрендә зурлап үткәрелде.

**Ләбиб ЛЕРОН**

# БАКЫЙ УРМАНЧЕ ХАТИРӘЛӘРЕ

## Бутырка

1930 ел. Мәскәү. Зур Лобян урамында бик матур өйдә урынлашкан ЧК (ГПУ) эчке төрмәсендә (камера 3 булса кирәк, яхшы хәтеремдә калмаган, беренче кат тәрәзәләре капланган, бары көкне генә бераз төннәрен күрергә мөмкин иде) ярты елдан артык утырдым. Төннәрен яхшы йокласам да, кайчакта әнкәй мәрхүмәне искә төшереп, вакытында яшьлек мавыгулары белән тиешле хөрмәт, шәфкать, ардаклау күрсәтә алмаган булуыма көенеп, ачынып, төннәр буе егълый идем.

Сакчы ишектән озатып, даңгор-доңгыр йозакны бикләп куйгач, мин тирә-якны карадым. Бүлмә зур түгел иде. Барысы сигез тапчан. Бер-икесе буш иде. Шуларның берсендә мин ятачак. Түрдә, тәрәзә каршында тумба. Аның янындагы урында бер кеше мине күзәтеп утыра иде. Аның йөзеннән күренеп тора иде. Ул инде монда күптән утыра, шунлыктан аның урыны да иң түрдәге, хөрмәтле урын. Бу – Мәскәү политехник институты профессоры Николай Лапин (яхшы хәтеремдә калмаган, Панин булуы да мөмкин). Аның аяк очында инженер (гаскәри инженер булса кирәк) Кралеолин урыны. Болар янында озак торганнар хәтеремдә калмаган. Соңыннан да озак «утыручылар» без өчәү булдык, ахры. Башкалар инде, ягъни атлары исемдә калганнар, миннән соң кергән кешеләр булды. Болар арасында бер яшь егет Нельсен, үзенең әйтүенчә, алман-немец, бандит Закиров, Атласи угылы, тагы баласы белән бер татар бар иде. Погосов-Полгосян инженер, өлкән кеше. Абрамович Одессадан бер яһүд сәүдәгәре. Нельсен байтак вакыт булды. Миңа Максим Горькийның Капридагы (Италия) тормышын сөйләде. Профессор Лапин миннән алда байтак утырган булырга кирәк. Ул һаман бу камераның иң игътибарлысы булып күренә иде. Үзен бик сабыр, борчылусыз, бер төрле рухани халәттә тотты. Юкка борчылмый, допроска да бик тыныч кына китә һәм шулай тыныч кына кайтып кереп, урынына сабыр гына утыра иде. Бервакыт шулай да допростан кайткач булса кирәк: «Мин урыс – урыс халкы өчен хезмәт итәм, яшим. Урыс халкы булмаса, миңа гомернең булуы-булмавы бердәй», – дигән мәгънәдә җавап биргәнен сөйләде. Профессор 3 нче камерадан соң кая киткән, гомере ничек узган – Аллаһ белә. Ул һаман нинди хәлдә булса, шул сабырлык, тынычлыгын саклый алдымы икән?

Җир реформасы ясап йөргән аристократ Столыпин белән бу садә зыялы профессор арасында ниндидер уртаклык бар иде. Ләкин Николай Лапин гади чынбарлык булса, Столыпин реформаларын казганып йөргән, һәртөрле ситуациядә булган, шуңар карамастан, минем гомеремдә төрле һәм җанлы романтик эз калдырган бер белемсез (билгесез) кеше арасында аерма да зур иде. Шулай хәтеремдә урнашып калган.

Профессор миннән алдарак китте, аның тапчанына күчтем. Озак булганнардан берсе Грамолин иде. Аты исемдә калмаган. Бу да урта хәлле халыктан чыккан, чиновниклар гаиләсеннән чыккан булса кирәк. Урта дәрәҗәдәге инженер-техник зыялы. Допроска еш чакыралар иде. Бик борчылып кайта. Тикшерүче-әзерләүче следователь бик йомшак, яхшылыклы кеше дип сөйли иде. Тикшерүче үзе янында хатыны белән күрешүләр рөхсәт итеп, бүләкләр дә алып кайткалый

*Ахыры. Башы узган санда.*

иде. Яшь кызлары бар икән. Төнлә еш йокысыз ята иде. Кайвакыт кече кызы бүләк итеп җибәргән чигүле яулыкны битенә каплап, чынлап сыктап ятканын күргәләдем. Миңа да бик авыр була, мин дә егълый башлый идем. Грамолин Беренче герман сугышы чагында гаскәри хезмәттә булып, инглиз-америкaн гаскәри инженерлары белән дә күп очрашкан яшь гаскәри офицер булгандыр. Хәзер ул илленең йә бу ягында, йә теге ягында булырга охшый. Бик йончыган кеше. Мине Бутыркага озаткан чакта, февральләрдә булса кирәк, ул әле калган иде. Бутырканың ишегалдында прогулкада берничә тапкыр күрдем. Безнең камерада да аның белән катнаш эштә булган кешеләр бар икән. Аның одиночкада утырганын, күптән түгел уртак камерага күчерелгәнен сөйләделәр. Берничә көннән соң Грамолин прогулкада күренми башлады. Элекке иптәшләрнең берсе Грамолинны атканнарын әйтте. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун. Кем белә, нинди гаепләре булгандыр...

Камерада төнлә ут сүндерелми. Шунлыктан елаган кешене, үле кешенең битенә каплаган кечкенә генә яулыкны үбә-үбә үксеп егълавын күреп тору бик авыр икән.

## Казакъ даласы, Тургай сахрасы. 1942.

Шундый шакшылык, бет арасында нинди гаҗәп шигърият һәм моң, музыка! Әйе, гаҗәеп контрастлар. – Бу юлларны мин кайчандыр язып куйганмын.

Әлбәттә, сүз казакъ даласы, Тургай сахралары хакында бара. 1942 ел. Тургай каласы белән Кустанай арасында яман дала кышы башлангач, бер-ике генә өе кар көртеннән чолпаеп, чумышып[1] торган кышлак-саман өйләргә туктап, ял итеп, чәйләп чыгарга туры килде. Өе бик кечкенә, төрле чүпрәк-чапрактан ботарланып яткан җир идән, бер почмакта учак ягылган, нәрсәдер булынып-булынып кайный[2]. Ишек тирәсендә куй, кәҗә бәтиләре аналарының ябык имчәкләрен талыйлар. Урын табып утыргач ук, итек астыннан тәнгә бетләр үрмәли башлый, чиркандыра. Ләкин җылы бар. Чәй бар. Һәм тәмле, араматлы казакъ даласында гына дәмләнә торган чәй[3].

Шаламалар арасында думбра. Шәяхмәт берәр чынаяк чәй уртлагач, думбраны алып, әң сала[4] башлый – «Карлы таукай да карлы»... Гаҗәеп музыка, гаҗәеп моң.

Аннан соң думбраны безне озатып килә торган егеткә бирә, ул әң салмаса да, моңлы гына итеп, думбраны чиртә башлый. Бу музыка да тирән самимият, дала табигатенең киң тыйнак аһәңнәре белән садәчә ифадә ителгән[5] тойгылары. Гүя җил-җиләсләрдә җилпелдәгән чыңгыл уты[6] әкрен генә дулкынланып, дәрья дулкыннары шималь офыкларга таба юргалый. Шәяхмәт, акын Сараның «Сарымбәт»ен бик яратып җырлый[7]. Бер мәлле ул үзен дә Сара итеп хыял кыла. Аннан соң Корбан Газыйның Аксак куланын[8]. Бу гаҗәеп бер музыка әсәре. Бер тыңлаганда, Паганининиың хәрәкәтен искә төшерә. Бет-борчаларның чагуларын да онытасың.

«Сарин бөт»не бик тә дәртләнеп җырлый. Чыннан да җырларга сәләте бар. Сарынлык[9] ахыры, озын башкалардан нечкәдер, аерылып тору, шунлыктан иркәләнебрәк китү тойгысыдыр. Казак язучыларының күбесендә бу тойгы бар иде.

[1] Чолпаеп, чумышып – ямьсезләнеп, кибәтсезләнеп.
[2] Булынып-булынып кайный – парланып-парланып кайный.
[3] Дәмләнә торган чәй – татлы тәм бирә торган чәй.
[4] Думбраны алып, әң сала – думбраны алып, көй, мотив, җыр сала.
[5] Садәчә ифадә ителгән – гади аңлатылган.
[6] Җилпелдәгән чыңгыл уты – җилпелдәгән чәнечке уты.
[7] Сарының «Сәрембөт»ен бик яратып җырлый – бу урында казакъ халкынын хатын-кыз акын җырчыларыннан берсе, шагыйрә, думбрачы Сара Тастанбәк кызының (Тастанбекова (1853 – 1907) «Сарин бөт» ягъни «Сабырлык бетәр» җыры күздә тотыла кебек.
[8] Корбан Газыйның Аксак куланын – бу урында казакъ халкының композиторы, музыканты, думбрачысы, казакъның музыкаль мәдәнияте үсешенә зур өлеш керткән Кормангазый Сагырбайулы (1818 яки 1823 – 1889 яки 1896) күздә тотыла. Аксак куланын дигәндә, монда Аксак Тимернең «каешы», «бавы» күздә тотыла кебек.
[9] Сарынлык – җырчылык.

Мәсәлән, Сабит Мукан[10], Габид Мөсрәп[11] сарынлык тойгыларын яшермиләр иде. Сарынлык бигрәк хатын-кызга мөнәсәбәттә күренә. Сарынны хатын-кыз камарга[12], яратырга тиеш. Безнең сәяхәт чагында Шәяхмәт бу яктан да сарынлыкка булырач-кандидат булырга[13] теләге барын күргәзде.

Язарга теләгәнем, асылда, кыпчаклык иде. Шәяхмәт белән кыпчакларга таба бардык. Шәркый Казакъстан белән гарәби Казакъстан арасында аерма күренә. Иң әүвәл – ат җиһазы. Кыпчак иярләре үзенә аерым рәвештә чибәр, рус кавалериясенең ияре – кыпчак ияреннән алынган. Бу ияр һәм иярләү хакында аерым бер мәкалә язарга ниятем бар.

## «39» тамгасы белән[14] Мәскәүдән китү. 1949.

Мәскәүдән Алма-Атага. Владимировтан Алма-Атага кадәр билет алгач, Мәскәүнең Казан вокзалында кунак бүлмәләрендә кунып чыгарга «хакым» бар иде. Бер кич кундым. Мәскәүдә дә йөргәләп алдык. Алма-Атага юнәлдем.

Берничә еллардан бирле гомернең иң тыныч, хәвефсез көннәре поездда, пароходта йөргән көннәр булды. Монда үзенчә экстерриториялык. Әгәр куркыныч качкын, җинаятьче булмасаң, юлда  яхшы ук тыныч барасың. Әйләнәңдә бер хокуклы пассажирлар.

Алма-Атадан Мәскәүгә ул вакыт биш тәүлек юл иде. Шул биш тәүлек эчендә яхшы ук ял итеп ала идем. Бу юлы бигрәк тә. Паспортта «39» билгесе. Алма-Атага барып җитеп, мин отельгә урнаштым. Бу отельләрдә еш туктала торган булганнан, паспортны карамастан урнаштырдылар. Шулай мин берничә көннәр уздырып, сәнгать эшләре комитетыннан кирәкле кәгазьләрне алып, Әүлия-ата даласына юнәлергә булдым. Минем ат багар оста Картабай Атчабаровнең[15] (социалистик хезмәт герое) портретын язарга договорым бар иде. Шул портретны язу өчен Әүлия-ата даласына юнәлдем. Җамбол каласыннан машина белән барырга. Алма-Атадан Җамболга барганда, минем белән ике МГБ хезмәтчеләре барды. Рәсми формада. Җамболда кунак өенә дә бергә барып, үзләре белән мине хөкүмәт әһелләре урнаша торган бүлмәгә алып керделәр, хөрмәт күрсәттеләр. Бик уңгай булды. Далага китәр өчен кайдан машинага утырып китәргә икәнен дә өйрәттеләр. Поездда барган чакта аз-маз әңгәмә булды. Шул вакыт Мохтар Һәуэзовны һәм Урал Тансыкбаевны[16] искә алдылар. Аларның очрашуларын беркадәр шөбһә белән гаепләгән шикелле тонда. Башкача сүзләр булмады. Бик сөйкемле егетләр иде үзләре. Икесе дә урыслар.

Җамболда озак булмадым. Караханиларның калган хәрабәләрен һәм базарны барып күрдем. Шәһәрнең бакчасында сөргенгә җибәрелгән Ленинград сәнгать институтының студентын очраттым.

[10] Сабит Мукан – Сабит Муканов (1900 – 1973), казакъ, совет әдәбияты классигы, язучы-академик. Б.Урманче истәлекләре арасында Казакъстанда яшәгән якын танышлары хакында да истәлек язмалар шактый. Алар арасында С.Муканов та бар. «1941 елда Алма-Атада таныштык. Арабызда дустлык хасил булды. Төрле эшләрдә күмәкләштек. Татар культурасын, әдәбиятын яхшы белүчеләрдән».

[11] Габид Мөсрәп – Габид Мөсрапов (1902 – 1985), казакъ, совет язучысы, тәнкыйтьче, драматург, тәрҗемәче.

[12] Сарынны хатын-кыз камарга – җырны хатын-кызда теләк ирешергә, теләк уятырга.

[13] Сарынлыкка булырач-кандидат булырга – җырчылыкка беренче кандидат булырга.

[14] «39» тамгасы белән – СССРда репрессияләр дәверендә рәсми булмаган атама. «Минус 39» тамгасы сугылган паспорт буенча репрессияләнгән кешегә СССРның 39 зур шәһәрендә яшәргә рөхсәт ителмәгән. Беренче карар 1924 елда кабул ителгән. 1932 елда кабат карала. Сөргенгә җибәрелгәннәргә зур шәһәрдә яшәргә рөхсәт ителмәгән шәһәрләр саны тагын да арта.

[15] Картабай Атчабаровнең – Картабай Атчабаров (1882 – ?) Казакъстан республикасының Җамбул өлкәсе Талас районының Чкалов исемендәге колхозның ат заводының мөдире. 1948 елда социалистик хезмәт батыры исеме бирелгән. Туган авылы Ойык.

[16] Урал Тансыкбаевны – Урал Тансыкбай улы Тансыкбаев (1904 – 1974), совет, казакъ, үзбәк рәссамы, сценограф.

## Шәһид Әхмәдиев

Шәһид Гыймадетдин улы Әхмәдиев (1888 – 1930) – язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе. Б.Урманченың шәхси архивында сакланган язмалар арасында Ш.Әхмәдиев шәхесенә өстәмә материаллар бирерлек чыганаклар да бар. «1919 елда Казанда таныштык. Шәһид мәгариф бүлегенең татар мәктәпләрен караучы иде. Ул инде күренекле җәмәгать хадиме иде. Галимҗан Ибраһимов тирәсендәге «суллар»дан. 1920 елда «Кызыл шәрык» эшелоны белән Төркестанга китте. Ул эшелонның башлыгы булган яһүди Сафаров[17] урынбасары дәрәҗәсендә булмады микән? Сафаровны СЭС – энциклопедиядән карадым, исеме юк. Кызык: Троцкий[18] исеме дә юк. Бары троцкизм гына бар. Гаҗәп! Ул вакытта Сафаров бик җаваплы вазифалар белән Ленинның үзе тарафыннан күндерелгән иде. Бу төркемгә байтак татар зыялылары җыелган иде. Шәһид мине дә өндәгән иде, бармадым, укыйсым килде. Мәхмүт Бөдәйле[19], Гасыйм Мансуров[20], Солтанбик Әлмөхәммәтов. Болар арасында Казанның иң чибәр кызларыннан Маһирә Юнысова да бар иде. Маһирә экс-президент Мәмәт Бисеровка чыгып өйләнештеләр. Маһирәне Казанда 1919 елда еш очрата идем. Соңгы очратуым 1952 елда Сәмәрканд янында Сәчак кышлагында абыйсы Гали Юнысов өендә булды. Романтика! Бисеров Мәмәт (Мөхәммәдҗан) бабында Маһирә хакында язылды. Шәһид Әхмәдиев бик зур урыннарда, иң түрдәге урында булды дисәк тә ярый. Төркестан республикасының мәгариф комиссары. Ул вакыт җөмһүрияткә хәзерге Үзбәкстан, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Таҗикстан илләренең барысы да керә иде. Бохара әмирлеге, Дәште кыпчак ханнары хыял кыла алмаган бер империя, мәмләкәт. Әмма ул анда, әлбәттә, һични эшли алмады. Бу гаҗәп бер дәвер, никадәр мөмкинлекләрдән файдала[на] алу кодрәте юк иде бездә. 1921 ел. Ачлык фаҗигасе. Шәһид урынына Хуҗаев атлы бер казакъ утырды (монда үзбәк, совет дәүләте һәм фирка эшлеклесе Фәйзулла́ Гобәйдулла улы Хуҗа́ев (1896 – 1938) истә тотыла). Шәһидкә Казанга азык алып кайтыр өчен бер товарный вагон бирделәр. Аның янында янә берничә кеше бар иде. Гомәр Әлмөхәммәтов[21] белән Фатыйх Сәйфи-Казанлы[22] түгел микән. Мин дә үземнең җыйган азыкларым белән шул вагонга эләгеп кайтырга ният иткән идем. Кайсыдыр каршы булды. Казан тирәсендә ачлык-үлем игенен җыя иде. Шул вакыт Оренбургтан Хөсәения педагоглары, шулар арасында галиҗәнап Фатыйх Кәрими дә бар иде. Аларга да вагон булмады. Шыгрым тулы 3 нче класслы вагонда азапланып кайттылар. Юкса, Үзбәкстан халкы бүләге буларак, байтак азык алып кайтырлар иде. Шәһид Казанга кайткач та, һични эшли алмады. Инде чирле кеше иде.

## Аксёнов. 1975.

Мәрхүм Мәхмүд Бөдәйленең 80 яшь тутыру мөнәсәбәте илә аның өендә уздырылган кечкенә генә мәҗлестә Аксёнов Павел Васильевич та бар иде.

Ул да Сталин вәхшәте заманында концлагерьда булган кеше. Аңа кадәр Казан шәһәр советының башлыгы булып торган. Хәтере бик яхшы икән. Бергә утырган кешеләр хакында күп нәрсә сөйләде. Һади Атласи белән утырган. Аның фикерләрен һәм бигрәк кызыгы – лагерьның берсендә зур китапханә мөдире булып эшләгәнен сөйләгән. Бу Соловки[да] булса кирәк. Анда Беренче сугыш заманында инглизләр

[17] Яһүди Сафаров – монда нәсел җепләре әрмән һәм поляк нәселеннән рус революционеры, совет дәүләте һәм фирка эшлеклесе Георгий Иванович Сафаров (1891 – 1942) истә тотыла.

[18] Троцкий – рус революционеры, совет дәүләте һәм сәясәт эшлеклесе Лев Давидович Троцкий (Лейба Давидович Бронштейн) (1879 – 1940).

[19] Мәхмүт Бөдәйле – Мәхмүт Һади улы Бөдәйли (1895 – 1975, журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе.

[20] Гасыйм Мансуров – Гасыйм Гата улы Мансуров, (1894-1955) — дәүләт эшлеклесе, мөхәррир, мөгаллим. ТАССР Халык Комиссарлары советы рәисе урынбасары (1924).

[21] Гомәр Әлмөхәммәтов – монда дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Гомәр Камал улы Әлмөхәммәтов (1895 – 1937) истә тотыла.

[22] Фатыйх Сәйфи-Казанлы – бу урында язучы, журналист, педагог, иҗтимагый эшлекле Фатыйх Сәйфи-Казанлы (Мөхәммәтфатыйх Камалетдин улы Сәйфуллин (1888 – 1938) истә тотыла.

күп китап калдырып киткәннәр. Инглиз, француз, немец телләрендә. Һади абзый шул китапларны укып, тәртипкә китереп торган һәм «гомеремдә иң рәхәт үткәргән чагым шушы булды» дигән.

Яхъя Җәлал улы Алмаев белән дә Казан эчке төрмәсендә утырган Аксёнов. Яхъяны да, Һади абзыйны да бик яратып сөйләде. Яхъяны ниндидер эш белән лагерьдан китергәннәр. Ул Ухтинский кирпеч заводында эшләп торган. Яхъя һичкем белән хәбәрләшми, язышмый икән. Ләкин һаман бик ачык күңелле, төрле кызык нәрсәләр сөйли торган булган. Мәсәлән, бик кызык итеп, казны хәстәрләү турында лекция сөйләгән. Тик үзе, башкалар сыйларга тырышсалар да, төрмә паегыннан башка бернәрсә дә ашамый икән.

## Галимҗан Ибраһимов

1919 елда таныштык. Сәясәткә катнашты. Заманында бик кызыл булып, Кәшшаф Мохтаров идарәсенә каршы хәрәкәттә булды. Беренче хатыны Мәстүрә Фәйзуллина иде. Икенче – Зөләйха Мөхәммәдова, өченче – Галия[23](?)

Интриганы ярата иде. Фатих Әмирханны яман кыяфәттә сурәтли. Дустлары Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Шәһид Әхмәдиев шәкертләре, иярченнәре иде. Яшьләргә йогынты ясарга бик тырышты. Мөхәммәд Парсин аның тәрбиясендә үсте. Революция башында сул эсер, соңра коммунистлар партиясенә керә.

Пләтән төрмәсендә үлде. Сәнгатьтә сул булып, арабызда мөнакашәләр булды (сүз көрәштерү, бәхәс булды). Гомумән, яңалыкны сөючеләрдән. Ләкин хәреф (алфавит) мәсьәләсендә консерватор, гарәп графикасы тарафында булды.

## Лотфый Исхакый[24]

1921 нче елда булса кирәк таныштык (1923 тә түгелдер дип уйлыйм, 1922 дә мин язны Салтыкта уздырдым шикелле). Мәскәүдән Петербургка кечкенә бер сәяхәт ясадым. Ул вакыт ике институтта – сәнгать һәм шәрык телләре институтларында укый идем. Шәрык институтының директоры ул вакыт Габдулла ага Гыйсмәти[25] иде. Ул мәдрәсәдән командировка биреп, өстәвенә, берничә дустларына хатлар язып, миңа булышуларын үтенде.

Шуларның берсе Лотфый хәзрәт Исхакый иде. Икенчесе, Питерның алдынгы татар большевикларыннан элекке татар гәзитә һәм нәшриятлары тирәсендә әүвәл хәреф җыючы, соңыннан Мәскәүгә килеп, «Центриздат»та шәрык халыклары үзәк нәшриятында эшләде. Басма эшләрен яхшы белгән специалист булса кирәк.

Минем Питерны беренче тапкыр күрүем иде. Төннәр якты вакыт иде. Ул да миңа кызык булды.

Барудан төп максат: Эрмитаж һәм андагы сәнгать хәзинәләрен күреп кайту иде. Минем институттан алган кәгазьләрдә шундый хисап язылган булгандыр, ахры, Эрмитаж директоры Иосиф Орбели[26] мине бик ачык йөз белән каршы алды һәм Эрмитажның запасник саклык урыннарыннан да күрсәтеп йөрде.

Лотфый Исхакый ул вакыт Питер университетында фарсы һәм төрек телләре укыта иде. Исхакый Мисырда «Әзһәрия»дә[27] укып һәм Иран телле илләрдә сәяхәт итеп

[23] Мәстүрә Фәйзуллина иде. Икенче – Зөләйха Мөхәммәдова, өченче – Галия – Б.Урманче бу урында Мәстүрә Гыйльман кызы Фәйзуллина (? – 1978), икенче хатыны Гөлсем Мөхәммәдованы (1908 – 1988) һәм өченче хатыны Хәдичәне (Әпсәламова-Фәтхуллина (1893 – 1967)) күздә тота.

[24] Лотфый Исхакый – Лотфый Исхакый (1870 – 1925), дин эшлеклесе, XX гасырның 20 елларыннан мөһаҗирлеккә китә. Төркиядә вафат.

[25] Габдулла ага Гыйсмәти – Габдулла Төхфәт улы Гыйсмәти (Гыйсмәтуллин) (1883 – 1938), сәяси эшлекле, журналист.

[26] Иосиф Орбели – Иосиф Абгарович Орбели (1887 – 1961), шәрык белгече, һәм җәмәгать эшлеклесе. Б.Урманче Эрмитажда булган елда И.Орбели урта гасыр мөселман чыганаклары бүлегенең саклаучысы вазифасында була. 1934 – 1951 елларда – Эрмитажның директоры.

[27] Мисырда «Әзһәрия»дә... – Каһирәдә Әзһария дарелфөнүнендә – әл-Әзһар (әл-Җәмигъ әл-Әзһар) Каһирәдәге дини һәм дөньяви югары уку йорты. X гасырда шул исемдәге мәчет каршында оештырыла.

кайткан татар галимнәре арасында фарсы теленең иң осталарыннан исәпләнә иде. Ул вакыт мин моны белми идем, әлбәттә. Шуннан байтак еллар узгач кына аңладым. Хәтта фарсы телен яхшы белүче Ризаэддин Фәхреддин[28] дә кайвакыт Лотфый ага белән фарсы нөсхәләре хакында киңәш итешә торган булган.

Лотфый аганың өендә булдым. Исемдә келәмнәр күп булуы калган. Бигрәк тә идәндәге келәмнең бизәкләре бик оригиналь һәм дөя сурәтләре тукылган булуы аерым хәтердә калган. Бу – Гыйрак эше булса кирәк.

Лотфый ага үзе бик сөйкемле, гүзәл кыяфәтле кеше иде. Чәй тәкъдим итте, шул вакыт күрше бүлмәдән бер кеше чыкты, мине тәкъдим итте һәм миннән: «Бу кешене беләсезме, күргәнегез бармы? – дип сорады. Миннән «юк» җавабын алгач, Габдулла әфәнде, диде. Бу Габдулла әфәнде Габделбарый Баттал[29] булып чыкты. Бу серне шул вакытта ук Лотфый әфәнде үзе миңа ачты бугай. Габдулла ага Гыйсмәтинең хаты шуңар юл куйган булса кирәк. Гомумән, Гыйсмәти ага белән минем арада «дустлык» дип әйтерлек бер якын мөнәсәбәт бар иде.

Шул вакытта Габдулла (Габделбарый) Баттал Питер сәүдәгәрләренең ярдәме белән булса кирәк, Финляндиягә чыгып китә. Казанда калу аның өчен куркыныч булгандыр.

Бер җыелышта, (Казандамы, Мәскәүдәме) Гыйлемдар Баембәтовның[30] Г.Баттал адресына бик яман сүзләр әйткәне минем хәтеремдә калган. Баембәтов мәрхүм, шөбһәсез, чын күңел революционер, яхшы журналист, үткен сүз иясе, ләкин кыланышларында үлчәүсез, сүзләрендә чикләүсез иде. Шушы вакытта татар җәмәгатьчелегендә күренекле урын тоткан, Питерда татарча нәшрият белән шөгыльләнгән Галим әфәнде Максудов белән дә таныштым. Ул миңа Петербург мәчетен күрсәтте. Мәчет курасында бер павильон, икенче катында мәчетнең конкурс белән ясалган берничә проекты бар иде. Алар пыялалы кысалар эчендә, диварларга тыгылган хәлдә саклана иде.

Галим Максудов Касыйм морзаларыннан. Мәгърифәт иясе. Мөхтәрәм зат.

## Мирсәид Солтангалиев

Безне Соловкига җибәргән вакытта Бутырканың «вокзалында» Сәгыйть (Сүнчәләй) белән күрештек. Соловкида янә очраштык. Ул Кремль янындагы бер бинада склад мөдире булып эшли иде. Чәй эчтек. Шул вакыт Мирсәид (Солтангалиев) килеп керде. Бераз сөйләшеп утырдык.

Мирсәид белән элегрәк очрашканыбыз бар иде. Мәскәүдә (мин Мәскәүдә укыган чакта) Ирзиннар гаиләсе белән таныш идем. Мирза Ирзин кардәшләребездән иде. Аларның өендә күп вакыт студентларның күңел ачу кичәләре була иде. Мирсәиднең хатыны Фатыйма ханым ул кичәләрдә катнаша. Мирсәид кайвакыт күренгәләп кенә китә иде.

Ул түгәрәктә булучылардан хәтеремдә калганнары: ирләрдән Мирза, Исмәгыйль Хантимер, Кадыйр Хуҗаев, Мостафа Кастров, Габделхак Гобәйдуллин (сирәк), Бари Сөләйманов, Ибраһим Шахмәметов, кызлардан: Мәрьям Ашратова, Хәдичә Ирзина, Фатыйма Ирзина, Госман Акбулатов, Гариф Хөсәенов, җырлаучы.

Шулай ук Ибраһим абзый Карамышев өендә дә җыелгалый идек. Бу өйдәге булучылар башкарак. Карамышевлар өе Пятницкая урамында 25 номерлы йорт иде. Бу өйдә безнен халык күп тора иде. Зыя абзый Фәизов, Госман Албитков, Шамилләр, Әзһәр Шамил гаиләсе. Тагы бик күпләр.

Карамышевлардан Гали абзый, аның хатыны Әминә ханым безнең мәҗлесләрдә дә була иде.

[28] Ризаэддин Фәхреддин – Ризаэддин Фәхреддин улы Фәхреддин (Фәхретдинев) (1859 – 1936), мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе.

[29] Габделбарый Баттал – Габдулла Габделбари улы Сәетбаттал (Баттал) (1880 – 1969), татар әдибе, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе.

[30] Гыйлемдар Баембәтовның – Гыйлемдар Солтан улы Баембәтов (1886 – 1933), язучы, сәясәт эшлеклесе.

Бу мәҗлесләрдә һичберендә эчке булмады. Аны искә алучы да юк иде. Чәй, төрле бәлешләр, таба ашлары. Бөтен кызыгы: утырып, әңгәмә кылу һәм музыка, җыр. Ибраһим абзый һәм Фатыйма ханым безнең арада булмыйлар, ләкин берәү җырлаганда чыгып тыңлыйлар. Безнең арада яхшы җырлаучылар булды. Гариф Хөсәенов, Исмәгыйль Хантимер яхшы җырлыйлар иде. Мин дә җырлый идем. Гариф Карамышев (Ибраһим абзыйның улы, студент) пианинода уйный, мандолинада уйнаучылар бар иде.

Бу урында Мирсәид хакында сүз бара. Гомумән, Мәскәү дәверендәге гомергә аерым кайтырмын.

Мирсәид белән беренче күрешү 1919 елда – минем, Казан сәнгать мәктәбе шәкертләреннән берсе буларак, мөгаллимебез график Шикалов белән Мәскәүгә экскурсиягә барган чагымда булды.

Ул вакыт Мәскәүдә командировкада Микъдат Борындыков[31] белән, Рәүф Алмаев та миннән ерак түгел, дүртенче Дом Советта яшиләр иде. Аралашып тордык. Алар мине бер кичне Мирсәиднең каенэнесе Гали Ирзинның никах туена алып бардылар. Шул вакыт Мирсәидне күрдем, таныштык. Туй мәҗлесе эчкесез иде. Гаҗәп заман! Хәзер Мәскәүдә түгел, Татарстан авылларында да эчкесез туй ясамыйлар.

Микъдат ул вакыт Суфия ханыма (Ирзиннарның берсе) нишанлы иде. Кайткан вакытта әүвәл Суфияне озаттык. Шуннан соң Олы Татар урамыннан Садовая аркасына кадәр Кызыл мәйданны кичеп, җәяү кайттык. Кызыл мәйданнан татарча җырлап узып кара! Никадәр үзгәрде дөнья!

Мирсәид белән икенче очрашу 1920 елның көзендә – мәркәзи хәрби коллегиясе (центральная Мусульманская военная коллегия) Мәскәүгә, ПУРның Политуправлениесенең Шәрык бүлеге итеп күчерелгәч булган. Бу эшне башкаручы Мирсәид иде. Без килеп, Татар Тыкрыгындагы татар мәктәбенә барып төштек. Шуннан безне квартираларга урнаштыра башладылар. Безнең күбебез Ирзиннар өендә урнаштык. Мирсәид шушы өйнең бер канатында тора иде. Бу бит Мәскәүнең иң әшәдде[32] кризис заманы. Өй ягылмый. Җылыту юк. Шунда борыннан торган халык вакытлы кирпеч мичләр чыгарып (буржуйка) яшиләр. Бу тормышны аерым язарга кирәк.

1923 – 1924 еллар булса кирәк, Казаннан Фәйзуллин атлы бер егет килеп чыкты. Миңа аны Һади хат белән җибәргән иде. Ул Мирсәид белән очрашырга теләвен һәм минем шул очрашуны булдыруда ярдәм итүемне теләде. Мин аны Мирсәидкә барып әйттем кебек исемдә калган. Ләкин Мирсәид аның белән очрашырга теләмәде, ахры. Юныс Вәлидне җибәргән иде. Юныс белән сөйләштеләр. Мин яннарында булмадым.

Юныс чирли, тиздән шифаханәгә кергән. Шифаханәдә мин Юнысны барып күрдем. Хәле яман түгел иде. Шифаханәдә Мирсәидне дә очраттым кебек. Яхшы хәтеремдә калмаган. Шуннан озак тормастан, Юныс Вәлидев вафат булу хәбәрен ишеттем. Юныс Мәскәү зиратына күмелгәндер. Дөньяның мәшәкатьләре белән бу гаҗәп көчле рухлы кешене хәтердән чыгарган булганмын, ахры. Көенеч.

1925 елдан соң институтны тәмамлау һәм Казанга кайтып эшкә керешү кайгысы белән хафада булдым.

Казан сәнгать техникумында педагог һәм идарә эше мине баштанаяк биләгән иде. Шулай ук Мәскәү кордашларыннан Исмәгыйль Хантимер Казанга кайтып, Садово-Огородный техникумының уку эшләре мөдире һәм мөгаллиме булып, Кадыйр Хуҗаев авыл хуҗалыгы техникумында укыту эшләре мөдире (зав. уч.) һәм мөгаллим булып, Дәвер Яналиев мәгариф комиссариатында өлкән инспектор булып, Сөләйман Яналиев саулык комиссары, Рәүф Шахмәмәтов табиб булып, Илһамия ханым педагог эшендә, Хәмит Беркутов медицина факультетында укуын дәвам итә, Бари Сөләйманов Өфедә урнашкан иделәр.

[31] Микъдат Борындыков (1896 – 1965) – сәяси эшлекле.
[32] Иң әшәдде – бик каты, бик көчле.

Мәскәүгә барган чакларда мин күбрәк Зыя абзый Фәизовларда була идем. Әминә белән Рабыйга үсеп җиткәннәр иде. Шул вакытларның берсендә Мирсәид белән очрашып, ул мине озаттымы, әллә безнең юл туры килдеме, белмим, ләкин сәяси мәсьәләләр кузгалгандыр, ахры. Мин Казанда үземнең эштән бик разый идем. Эшем тыныч, халкыма хезмәт итәргә иркен юл куелган. Мин шул хәлдә эшләсәм, бик разый, Мәскәүдән кайткан башка иптәшләребез дә шулай ук, дип җавап бирдем. Ул игътираз итмәде.[33] Шул җаваптан канәгатьләнде кебек.

Онытканмын, 1925 елда булса кирәк, Илһамия ханым Богдановичлар өендә бер мәҗлестә күрешкән идек. Бу мәҗлестә Кырым яшьләреннән берничә кеше бар иде. Бу мәҗлескә Мирсәиднең ник чакырылганын мин аңлап бетермәдем. Күбрәк яшьләр иде. Илһамиянең биге Ягъкуп ага Богданович бу мәҗлестә булмады. Ирзиннардан Мирза һәм тагы кемдер бар иде. Исмәгыйль Хантимер, Кадыйр Хуҗаев бу мәҗлестә катнаштылар. Кырымлылардан берсе бик чибәр кыяфәтле студент, аның катында бер кырымлы туташ та бар иде.

Бу – Илһамия ханымның педагогия институтын тәмамлап, диплом алган вакыты булмадымы икән? Илһамия 1980 елда Казанда вафат булды. Иркемдә вакытта Мирсәидне соңгы күрүем шул урамда булды. Ләкин ул Казанга килеп йөргән һәм минем энем экономист Һади белән безнең квартирада күрешкән. Моны миңа Һади Соловкида вакытта әйтте. Мәскәүдә ГПУда миннән сораткан-тикшергән вакытта, Солтангалиев сездә, ягъни минем квартирада булдымы, дигән сорау булды. Һади безнең квартирада үзенә аерым бүлмә били иде. Солтангалиев эше белән кулга алынган тоткыннарны шимальга (Соловки лагерьларына) озаткан вакытта әүвәл Бутырканың «вокзалында» җыйдылар. Монда ул булмады, ахры, юкса күренгән булыр иде. Дөрест, Бутырканың шифаханәсе баскычында мин аны очраткан идем. Ул вакытта исәнләшмәдек тә. Шулай соңгы очратуым Соловкида Сәгыйть Сүнчәләйдә булды. Ул сүз арасында: «Мин синең турыда бернәрсә дә әйтмәдем...» – диде. Ягъни «синең кулга алынуыңда минем гаеп юк» дигәнне аңлатты. Чынлап та, Казан зыялыларыннан алынган кешеләрнең – алфавитны латинлаштыруга каршы петиция язылган «82 кешенең» алынуына сәбәп шул петиция булды, ахры. Әлбәттә, мәсьәлә катлаулырак, чуалчыграк, сәяси «чаралар» булса кирәк, кулга алынуның сәбәпләре караңгы.

Тагын онытканмын, Мәскәүгә барып йөргән чакларымның берсендә, 1928 микән, Шәрык институты залында Яңалиф мәсьәләсенә арналган (багышланган) бер җыелыш булды. Мәҗлесне Сталинның урынбасарларыннан Павлович дигән яһүди алып бара иде. Яңалифне бик яклаучы, патша заманында Казанда цензор булган Ашмарин да шул җыелышта, президиумда иде. Мирсәид Яңалифкә, ягъни латинизациягә каршы бик кайнар сүз әйтте. Аның ораторлык, сүз кодрәте көчле икәне билгеле. Ул латинизациянең татар-төрк халыкларының культурасына һич булышлык итмәячәге, киресенчә, аны артка чигерәчәге хакында күп дәлилләр китергәч, кулы белән Ашмаринга күрсәтеп: «Латинизация нужна вот этим бывшим царским чиновникам-миссионерам, они хорошо знают, что латинизация положит начало русификации тюркских народов, они бывшие миссионеры, страстно добиваются ликвидации старого алфавита», – диде. Павлович Мирсәидкә каршы сөйләп, бер-ике сүз әйтте. Ләкин Мирсәиднең сүзләре атылган уклар кебек иде. Ашмарин бер сүз дәшмәстән корышып утырды. Бу җыелыш һәм Мирсәиднең кайнар рәнҗү белән әйтелгән сүзләре минем күңелемдә онытылмас эз калдырды.

Бу – Мирсәиднең сәяси карьерасы төшеп барган чагы иде инде. Рәсми даирәләрдә Мирсәид тәкъдир ителми иде. Шуннан соң узып киткән ярты гасырда бу алфавит үзгәртүнең, латиннан соң славян алфавитына күчүнең нәтиҗәләре хәзер һәркемгә билгеле.

Мирсәиднең кыяфәте мәһабәт, күз карашы көчле, сүзе үткен, кискен, бераз гына

[33] Игътираз итмәде – бер каршы фикер әйтмәде.

карлыккан тамак тавышы белән сөйли иде. Әйткән сүзләре каты фәрман шикелле була иде. Шулай да үзенең йөзендә һаман көләчлек, аз гына елмаю сизелә иде. Коңгырт кара кучкыллы кавказ тукымасына охшаган, истә калырлык яхшы уймалы чырай. Йөз мускуллары дәртле, ирадисе[34] көчле булганлыгын күрсәтеп тора иде. Батыр кыяфәтле, үзен туры тота. Шунлыктан яхшы ук биек, озын буйлы булып күренә иде. Спорт белән шөгыльләнгәнме, юкмы, ләкин спортсмен кыяфәтендә, симез түгел, хәтта җадау бәдәнле дип әйтергә мөмкин. Җыйнак гәүдәле, сөйләве дә чәчән.

Солтангалиев кыпчак морзалары токымыннан (Төмәннәрдән булса кирәк). Мирсәиднең гыйльми сәләте ничек булгандыр, ләкин яхшы журналист, көчле сүзләүче иде.

Гарәпчә укый ала һәм гарәпчә язгалый да алган. Мәхмүт Бөдәйли аның Бутыркада вакытта кар өстендә гарәп телендә язган сүзләрен әйткән иде. Ләкин бу сүзләр хәтеремдә калмаган.

Ул теория кешесе түгел, практика кешесе булгандыр. Башка шартларда ул яхшы юлбашчы, атаман булыр иде. Төрек халыкларын оештыру фикерләрен чагылдырган бер сүзе исемдә калган. Төрек халыкларын оештыруда аның революциягә каршы сүзен мин ишетмәдем. «Союздагы төрек халыкларында кайсы ыру авангардта булса да ярый. Бер кабиләгә дә артыклык дәгъвасы булмаска тиеш» дигән сүзләре хәтеремдә калган.

Сәгыйть Сүнчәләйдә утырган чакта мин ничектер үземнең инглиз телен өйрәнүемне Соловкида да дәвам иттерүемне әйтеп куйган идем. Мирсәид урыныннан торып, минем кулларымны кысты. Соловкида вакытта бер шәхес бер үзбәкне хурлап җәберләргә керешкән, шулвакыт Мирсәид үзбәкне яклап, теге шәхесне кыйнаган. Бер штрих!

Мирсәидтән зарланган, аңарга рәнҗегән кешеләр, ягъни солтангалиевчелектә гаепләнеп, җәза алган кешеләр белән, табигый, сөйләшкәләргә туры килде. Шуларның берсе белән Соловкида таныштык: Фирдәүс (исемен белмим). Ул Казанда эшләгәннән соң, Шимали Кавказның бер өлкәсендә тыныч кына партия комитетында секретарь булып эшли иде. Мирсәид өстемә сөйләгән, шунлыктан камадылар дигән мәгънәдә сөйләде. Шәһәрнең исемен дә әйткән иде, хәтеремдә калмады, рәнҗүен белгертте. Микъдат Борындыков белән Мәхмүт Бөдәйли Мирсәидне провокатор дип атадылар. Һәрвакыт аңардан рәнҗеп сөйләделәр. Микъдатны Мирсәид белән очная ставкага чыгарганнар. Шунда Микъдат Мирсәидне бик каты сүккән. Мирсәид яман хәлдә иде кебек сөйләде. Кем булды ул кеше? Тарих кайчан да булса ачыклар. Микъдат белән дә, Мәхмүт белән дә мин гомеремдә күп очраштым. Алар хакында да бер яман фикер әйтергә урыным юк. Иманлы коммунистлар иде, шуның өстенә Мәхмүт актив Алласыз, дәһри иде. Мирсәиднең провокатор булуына да мин ышана алмыйм.

## Исмәгыйль Ситдыйк улы Хантимер

1982 дә 4 ноябрьдә Исмәгыйль Хантимер угылы Рөстәм белән килеп төште. Исмәгыйль минем иске дуслардан. Дус дигәннән, безнең дуслыкның бер китеге бар кебек сизелә иде. Юк, ышанычның там булмавыннан[35] түгел, кайсыдыр бер ноктада безнең зәвыклар бердәй булмавы, ахры. Берүк без үзара тәмам ышанычлы, иманлы дуслар идек. Теләгән һәрбер серне әйтергә хәзер – уртаклашырга шиксез, ләкин ни өчендер һәммәсен дә әйтеп бетерми идек кебек.

Мәсәлән, ул мәрхүмә Суфия Туишевага булган мәхәббәтен шушы очрашуда гына яхшылап сөйләде. Ул вакыттан инде бер гомер узган бит. Хәерле булсын!

Һәрхәлдә Исмәгыйль чын, намус, сәдәкать иясе[36]. 1929 елны ул миннән соң камалган иде. Лубянкада ул азрак утырган, ай ярым. Бутыркага күчерелеп, Әхмәд

[34] Ирадисе – ихтыяры.
[35] Там булмавыннан – тулы, төгәл булмавыннан
[36] Сәдәкать иясе – тугрылык, дуслык иясе.

Байтурсын ага[37], Сәгыйть Сүнчәләй[38] һәм Ханкирмән татарларыннан берәү белән бер камерада утырган, тәрәзәдән көндезге гизмә чагында[39] күрешкәли һәм төрле юллар белән бик сирәк кенә хат та язышкалый идек.

Мурманск лагеренда бер эшелонда барып төштек. Ләкин аны тиздән Соловкига җибәрделәр. Мин барганчы, аны Соловкидан чыгарганнар да инде. Өч ел лагерь алып, янә өч ел шимальга сөргенгә җибәрелеп, Архангельскида яшәгән. Һәм шунда сөргендә вакытта Леонтина Артуровна белән өйләнешкәннәр. Изольда кызы шунда туган.

Исмәгыйль бик сәләтле, тырыш, тирән белемле, җитди галим иде, дөресрәге, булып китте. Әгәр бу афәт булмаса, ул Казанның данын күтәрерлек бер галим булачак иде. Үкенеч!

Сөргендә вакытта ул гыйльми эшкә керешә. Аның сәләтен тиз тәкъдим итәләр һәм Коми республиканың АН СССР филиалына эшкә җәлеп итәләр. Махсус матбугатта һәм мәркәзи прессада ачык исеме кат-кат аталды. Исмәгыйльнең гомере күп татар галимнәренең гомеренә охшый. Ул «партия»гә кергән булса, аның уңышлары башкачарак тәкъдим ителеп, тормышы да җиңелрәк булыр иде.

Исмәгыйль 1898 елда, февральнең 5 ендә Саратов губернасы Сафарка авылында туган[40]. Миннән бер яшькә кечерәк. Авылны салучы Сафар бабай Пенза Алтулдан килеп утырган[41]. Исмәгыйльнең әнисенең атасы яхшы ук бай кеше булган. Яңача укыту чаралары күреп, Истамбулда белем алган Алушев атлы мөгаллимне чакыралар. Исмәгыйль яхшы укый, Коръәнне дөрес укый, яхшы ук гарәпчәгә өйрәнә. Үзе мөгаллим булырлык белем хасил иткән була.

Ләкин укуны дәвам итергә теләп, Казанга барып, Татарская учительская школага керергә омтыла. Бу 1914 елда. Школага алмыйлар. Урысча белем җитешми (шулай микән?). Акчасызлык, гидайлык, таныш иптәшләрендә туенып йөри. Шул вакыт, бәхеткә каршы, Казанга мәктәпкә алырга килгән Чәмәк-Ташкыч мулласына[42] моны юнәлдерәләр. Кием начар, яхшырак күренергә кирәк. Дуслары моңарга үзләреннән яхшырак киемнәрен биреп торалар. Мулла ярата мөгаллимне, ун сум авансны бирә. Ун сумга ул яхшы гына кием ала. 1914 – 1915 елларда Чәмәктә – мөгаллим. Язын бер 130 сум акчаны кесәгә салып, Казанга кайта. Казаннан авылга кайтырга туры килә, әтисе сугышта.

Өйдә хезмәтче кирәк. Бер ел авылда уздыра. 1916 елның көзендә янә Чәмәккә килеп, мөгаллимлек итә. 1917 ел февраль революциясен Чәмәктә каршы ала. Уку елы ахырына җиткезмәстән, Казанга килә һәм нинди шаукымнар беләндер Сафаркага кайта, ул вакыт әтисе Ситдыйк та гаскәрдән өйгә кайткан була.

Шуннан Исмәгыйльнең тормышында төрле борылышлар белән икенче дәвер башлана. 1917 елның маенда ул гаскәри хезмәткә алынып, конный пограничный полкта хезмәт итә башлады. Озак та узмастан, аны эскадронның сайлавы буенча Казанда вакыйг булган мөселман гаскәри шурага делегат итеп сайлап, шураның җыелышларында яхшы ук актив хәрәкәттә була. Бик кызыл булып китә, тагы хөррият ягында максималист, янә Сафарка. 1918 елда янә Аклар гаскәренә алынып, Иделдән чигенү башлана. Мангышлак, кышкы суыкта Хәзәр диңгез тирәсеннән әйләнеп, Хаҗитарханга кайталар, Аклар гаскәре Хәзәр диңгезе һәм Кавказ таулары эчендә таралып бетә, ахры, бу вакыйгаларны тәфсилләп сөйләргә яратмый Исмәгыйль.

[37] Әхмәд Байтурсын ага – Әхмәд Байтурсынов (1873 – 1938), дәүләт эшлеклесе, шагыйрь, галим.

[38] Сәгыйть Сүнчәләй – Сәгыйт Хәмидулла улы Сүнчәләй (1889 – 1937), шагыйрь, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе.

[39] Гизмә чагында – йөрү чагында.

[40] Саратов губернасы Сафарка авылында туган – бу урында хәзерге Саратов өлкәсе Дергачи районына караган Сафарка авылы күздә тотыла. 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәр Самара губернасының Новокузенски өязе Осиново-Гайски волостена кергән. 1859 елгы Россия империясе торак урыннары исемлегендә авыл Пенделке буларак теркәлгән.

[41] Пенза Алтулдан килеп утырган – бу урында Пенза губернасының Каменск районының Алты авыл, ягъни Мучали, Решетин, Кобылкин, Кутеев, Кикин, Телятин исемле татар авыллары күздә тотыла кебек.

[42] Чәмәк-Ташкыч мулласына – бу урында хәзерге Биектау районына караган Чәмәк авылы күздә тотыла кебек.

Ләкин даими күңелдә урнашкан теләк уку, белем алу, гыйлемгә үрмәләү, бу буталчык арасында белем алу кыен булуын аңлап, чит илләргә китү-ычкыну уе күңелен биләп ала. Ләкин ничек?

Хаҗитарханның үзендә университет ачылган. Шуның агрономия факультетына керергә хәзерләнә. Ул вакыт гали мәктәп ишекләре җиңел ачыла. 19 нчы ел. Аннан 1919 елның башында Мәскәүгә Голицынский курсларына күчерәләр[43] (ләкин монда ялгыш булуы мөмкин, 1921 елда түгел микән?).

1923 елда инде ул Тимирязев авыл хуҗалыгы академиясендә[44] укый. Шул вакытларда безнең танышлык бик якын була. Еш очрашалар. Мәскәүдәге татар-башкорт студентларының түгәрәге, Мәскәү яшьләре Ирзиннар[45], Карамышев[46], Кастровлар[47] белән аралаша (бу вакыт башка бер урында язылыр).

1926 елда Мәскәүдә укуын тәмамлап, Казанга кайта һәм эшкә керешә. Мәскәүдә вакытта Исмәгыйль, Мирсәед Солтангалиев белән очрашкан вакытларында, Мирсәедне берникадәр өметләндергән була, ахры. Мәсәлән, мәшһүр Царицынода[48] бер очрашуны Исмәгыйль исендә тота. Югарыда әйткәнчә, кайбер вакыйгаларны Исмәгыйль тәфсилләргә яратмый. Миңа кабатлап соравы уңайсыз булды. Минем уемча, аның яшерен серләре булуда түгел хикмәт, ул заманнарны аның искә төшерәсе килми. Мирсәед үзенең күрсәтүләрендә Исмәгыйльнең исемен атаган.

Шунлыктан Исмәгыйльгә Казанда Черек күлдә һәм Мәскәүдә ГПУның шәрык бүлеге мөдире Розенбергка[49] бер йөз (100) бит гарзы халь – показания язып бирергә туры килә.

Аны 1929 елның сентябрендә камыйлар. Ай ярым Черек күлдә утырганнан соң, Мәскәүгә Лубянкага күчерәләр. Казанда ул авыл хуҗалыгы техникумында, Кабан күленең аргы башында эшләде (Кадыйр Хуҗаев Садово-огородный техникумында[50] эшләде. Шулай ук авыл хуҗалыгы институтында[51] да дәресләр бирә иде). Исмәгыйль лагерьда өч ел булды. Аннан соң сөргендә Архангельскида. Анда агрономия эшләрендә булып, ахирел әмер Коми республикасы урталыгы Сыктывкарда Бөтенсоюз гыйльми академиясенең филиалында гыйльми хезмәттә була. Инде пенсиядә. Эшен дәвам иттерә. Күп гыйльми хезмәтләре бар. Бөтен союзда һәм чит илләрдә иң аталган галим. Исмәгыйльнең Көнчыгышка чигенә торган Ак гаскәрләр белән китеп, күп җәфалар

---

[43] Мәскәүгә Голицынский курсларына күчерәләр – Югары хатын-кызлар (Голицын) авыл хуҗалыгы курсы. 1908 елда княгина С.К. Голицына тарафыннан төзелә. 1922 елдан Петровски авыл хуҗалыгы академиясенә кушыла.

[44] Тимирязев авыл хуҗалыгы академиясендә – монда К.А.Тимирязов исемендәге Мәскәү авыл хуҗалыгы академиясе күздә тотыла. 1865 елда оештырыла. 1923 елдан К.А. Тимирязов исемен йөртә.

[45] Ирзин – монда миллионер-меценат, сәүдәгәр, Салих Йосып улы Ирзин (1833 – 1911) күздә тотыла. Чыгышы белән хәзерге Рязань өлкәсенең Әҗе авылыннан. Мәскәүдә яши, шунда җирләнә.

[46] Карамышев – Ибраһим Карамышев (1846 – 1954), Мәскәү сәүдәгәре. Б.Урманче Мәскәүдә укыган дәверендә Карамышевлар гаиләсе белән дә аралаша һәм алар хакында кыска гына хатирәсен язып калдыра. Югарыда язылган искәрмәдә Карамышевлар хакында тулырак мәгълүмат алырга мөмкин.

[47] Кастровлар – бу урында нәсел тамырлары Касыйм ханлыгыннан килгән танылган татар сәүдәгәре һәм меценат Әхмәт Хәйрулла улы, Мәскәү мәчетенең имам-хатыйбы вазифасын башкарган. Габдулла Шәмсетдин улы Кастров (1878 – 1937) күздә тотыла кебек. Б.Урманче хатирәләре арасында Кастровлар нәселеннән, скрипач Мостафа Кастров искә алына. Аның белән 1920 елда очрашуын яза һәм «Ханкирмән, мәшһүр Кастров мирзалардан» дип язган.

[48] Царицынода – монда хәзер Волгоград шәһәре истә тотыла.

[49] ГПУның шәрык бүлеге мөдире Розенбергка – бу урында 1921 елдан СССР дәүләт идарәсе хезмәткәре Альберт Петрович Розенберг (1893 – ?) күздә тотыла кебек.

[50] Садово-огородный техникумында – ТАССР төзелү белән бергә Татарстан Мәгариф комиссариаты республикада югары һәм һөнәри белем бирү йортлары ачуга, яшь совет дәүләте өчен кадрлар әзерләүгә игътибарны юнәлтә. Б.Урманче искә алган техникум 20 нче елларда ачыла һәм анда Урманченың Мәскәүдә укыган дәвердән үк якын дусларының берсе Кадыйр Хуҗаев укыта. К.Хуҗаев шул заман татар зыялылары кичергән язмыш – репрессияләр дәверен кичерә. К.Хуҗиев хакында ниндидер тулы мәгълүмат табу мөмкин булмады. Аның исеме белән Кәрим Сәгыйтьнең Фатих Әмирханның соңгы көннәрен тасвирлаган язмасында (Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар. 2 нче чыгарылыш, Казан, 2016) әдипнең хәлен белергә килүчеләр исемлегендә генә очрашабыз. Исемлектән күренгәнчә К.Хуҗиев әдипнең хәлен белергә дүрт тапкыр килгән.

[51] Авыл хуҗалыгы институтында – Казан авыл хуҗалыгы институтының тарихы 1919 елдан политехника институтының авыл хуҗалыгы факультетыннан башлана. 1995 елдан Казан авыл хуҗалыгы академиясе атамасы белән йөри.

күреп, Хаҗитарханга кайтып җитүе бик драматик шартларда булган. Аның Штулкерц фамилияле бер ак гаскәрине үлеменнән коткаруы хәйран бер вакыйга.

Штулкерц, Пулково обсерваториясендә[52] эшли торган булган, ахры, ахырында ул шунда кайтып тагын эшли башлаган.

## Һади Атласи

Һади Атласины Күл Черкендә 1906 елларда күрдем. Әткәйнең якын танышы иде. Татар мәдәнияте хәрәкәтендә бу затның үзенә хас бер урыны бар. Төгәл характер, төгәл сыйфат һәм үзенчә хәрәкәт итүче төгәл табигатьле кеше иде.

Тәне-бәдәне, рухани сыйфаты белән арыслан табигатьле.

Бервакыт Һади агадан сораган берәү: «Һади әфәнде, нигә сез болай сирәк язасыз, китаплар сирәк бастырасыз?» – дип сорагач, мәгълүм фарсы касыйдәсен искә төшереп, нәзыйрә ясап[53]: «Дуңгыз бик чагалы, бик күп дуңгыз үрчи, һәрберсе дуңгыз. Әмма арыслан елга бер генә балалый, ләкин баласы арыслан була», – дигән. Моны үзе сөйләмәдеме икән? Соловкида.

Сабый чактан, 1905 еллардан бирле күреп беләм. Буа шәһәрендә Нургали хәзрәт[54] мәдрәсәсендә укыган чагында әткәй белән яхшы таныш һәм фикердәш булып, безгә Черкенгә (Күл Черкене) кунак булып килеп йөри иде. Черкен сабантуйларында көрәшергә килеп, бик күп сөлгеләр ота, казана иде. Зариф Бәширинең[55] дә сабантуйларында яхшы гына көрәшүе хәтеремдә калган.

Ул вакыт XX гасырның беренче ун елында Буа мәдрәсәсендә яхшы ук оешкан бер революцион уртаклык булган. Боларның түр иясе Һади ага булган булса да гаҗәп түгел. Шул ук даирәдән билгеле журналист Шакир Мөхәммәдов[56] Оренбургта Хөсәен Ямашевка «Урал» гәзитәсен[57] чыгарыша. Шул ук даирәдән (Ш.Мөхәммәдовның каенэнесе булса кирәк) казамалык Фатыйх Садыйков[58] да Оренбургка китеп, анда сәяси хәрәкәттә гаепләнеп сөргенгә җибәрелә һәм Капалга[59] барып мөгаллимлек кыла. Капал Фатыйх дип мәшһүр иде. Бу Фатыйх әткәйнең бик якын дусты булган, әткәйнең үз сүзе.

1907 еллардан соң Һади ага Әлмәттә мулла булды һәм шунда яшәп, җитди рәвештә тарих, төрек-татар тарихы белән шөгыльләнеп, татар халкының иң игътибарлы, иң кодрәтле тарих галиме булып күтәрелде. 1906 елда Государственный Думага сайланып, анда «трудовик»лар фракциясендә[60] торды. Бу аны сурәтли торган бер штрих.

*Хатирәләрне басмага* **Зөфәр МӨХӘММӘТШИН** *әзерләде.*

---

[52] Штулкерц, Пулково обсерваториясендә – Россия фәннәр академиясенең төп астрономия обсерватория патша Николай I карары белән 1839 елның 19 августында ачыла. Әлеге обсерваториядә Б.Урманче искә алган астроном Пётр Григорьевич Штулькерц (1892 – 1937 елдан соң) да эшли. Ул 1917 елга кадәр Рус астрономия җәмгыяте әгъзасе булып торган.

[53] Нәзыйрә ясап – пародия ясап.

[54] Нургали хәзрәт – Нургали Хәсәнов (Нургали Хәсән әл-Буави) (1852 – 1919), дин белгече, җәмәгать эшлеклесе һәм педагог. Туган җире хәзерге Апас районы Морзалар авылыннан.

[55] Зариф Бәширинең – Зариф Шәрәфетдин улы Бәширов (Бәшири) (1888 – 1962), татар совет язучысы, шагыйрь, тәрҗемәче, публицист, этнограф һәм педагог.


[56] Шакир Мөхәммәдов – Шакир Мөхәммәтша улы Мөхәммәдов (1865 – 1923), язучы, нашир.

[57] Хөсәен Ямашевка «Урал» гәзитәсен – «Урал» газетасы Россиядә беренче социалистик газета. 1907 елның 4 гыйнварында татар большевигы Хөсән Миңһаҗетдин улы Ямашев (1882 - 1912) тырышлыгы белән Оренбургта нәшер ителә. Барлыгы 31 саны дөнья күреп, 1907 елнын апрелендә туктатыла.

[58] Фатыйх Садыйков – Фатыйх Садыйк улы Садыйков (1880 - ?), укытучы. Б.Урманче истәлекләре буенча 1905 – 1907 елгы революцион хәрәкәтендә катнашкан, социал-демократлар идеясенә якын торган. Урта Азиягә китә, Капал шәһәрендә укыта. Соңгы эш урыны Алма-Ата өлкәсенең Талдыкурганда укытучы булган. Сталин репрессиясе корбаны.

[59] Капалга – Алма-Ата өлкәсенең Акусук районына кергән авыл. 1847 елда нигез салынган.

[60] Государственный Думага сайланып, анда «трудовик»лар фракциясендә – патша Россиясе Дәүләт Думасында крестьян депутатлар һәм халык интеллигенциясенең демократик караштa торган сәяси оешмасы. «Трудовиклар» фракциясе, нигездә, демократик ирек, тыныч юл белән җирләрне национализацияләү (крестьяннарга бирелгән җирләрдән башка) өчен көрәшкәннәр. 1907 елда Һади Атласи 2 нче чакырылыш Россия Дәүләт Думасына Самара губернасыннан депутат итеп сайлана. Бу чакырылыш Дәүләт Думасы 1907 елның февраль – июнь айларында гына эшли. Патша карары белән июль аенда эшчәнлеген туктата.



*Айдарбәк Сарманбетов (1953) – күренекле кыргыз язучысы, тәрҗемәче һәм публицист. Төрле телләрдә дөнья күргән утыздан артык китап авторы, халыкара әдәби премияләр лауреаты. «Төрки дөнья әдәбияты» журналының баш мөхәррире.*

Айдарбәк Сарманбетов

# ДӨНЬЯ КИҢ УЛ, ӘГӘР КҮҢЕЛ КИҢ БУЛСА...

## Теләк

Пар килгән аккошлардай,
Айлы күлдә йөзикче;
Мәңге аерылмыйча,
Тиңнәр булып йөрикче.
Асыл көчем, хөрмәтлем,
Яшәү ямен беликче.

Күк муен күгәрчендәй,
Күкләрне гизик әле;
Күздә бәхет кабызган
Шатлыкны сизик әле.
Күрер күз, асыл затым,
Тормышның матур мәле.

Яшьлектә яшел уттай
Ялкынлап яныйк әле,
Яшәүдә мәңгелеккә
Янәшә барыйк әле.
Җанашым, мәхәббәтем,
Гел бергә калыйк әле.

## Искә ал

Шашып үткән гомердә
Шартлады кебек дөнья.
Җилдәй исәм, искә ал,
Кайчан нык яңгыр коя.

Күк терәге – тауларны
Очратсаң, мине күр дә...
Таң белән уян, елмай
Минем туган көнемдә.

Юл буенда ак каен –
Сиңа булсын бүләгем.
Болыт күрсәң искә ал,
Аклык – сиңа теләгем.

Күбекле күл дулкынын
Күрсәң, мине хәтерлә.
Күңелең төшкән булса,
Елмай, боегып йөрмә.

Китте диеп, үкенмә,
Китми торган җан бармы?
Елама, искә төшер:
Фани дөньяда миннән
Тагын нәрсәләр калды.

## Авыл юлы

Авыл юлы еракларга сузылган.
Дөнья буйлап күпме еллар узылган.
Иксез-чиксез офыкларга чакыра –
Галәмгә юл нәкъ авылдан сызылган.

Авыл юлы гел күңелне кузгата,
Искә төшеп, үткәннәрне уята.
Көн-төн ярга бәреп торган дулкындай,
Авылыма ашыгамын төн ката.

## Үзеңнән тора

Дөнья киң ул, әгәр күңел киң булса,
Галәм тирән, әгәр акыл тиң булса.
Гомер озын, әгәр тәкъдир язылса,
Адәм – изге, яхшылыкка уй борса.

Дөнья – серле, бәхет бары яр аша,
Бизмән кебек, әгәр шулай яраса.
Уйлый күрмә алган ташың җиңел дип,
Зар елама, ташың сиңа яраша.

Дөнья – бөтен, шөкер кылсаң барына,
Юкка елап, күз яшенә сарылма.
Маңгаеңа язылганнан узмыш юк,
Ходай бирә, син харамга кагылма.

## Үртәмәгез, кызлар!

Үртәмәгез, абый диеп, качмагыз,
Юкка-барга бимазалар асмагыз,
Чигәләрдә ак чәчләрем күренә –
Көмеш гасыр кешесе бит абзагыз.

Үртәмәгез, тамашага салмагыз,
Яшем санап, мыскыллауга алмагыз,
Бераз гына яшем олы булса да,
Синдәй яшьне тели әле абзагыз.

Үртәмәгез, коры сылтау тапмагыз,
Куллар сузып, әллә кая чапмагыз.
Утыз яшьтә утын ярып алсам да,
Утыз ирне җиңә ала абзагыз.

Үртәмәгез, йөземнең бар сырлары,
Бу тормышның озын әле юллары.
Ялкынланган утлы йөрәк барында
Тынамыни саф мәхәббәт җырлары?!

## Сер сүз

Күңел йөдәп, вак-төякләр туйдырса,
Таугa бар син, биек уйга уелсаң.
Олылыкта, тирәнлектә күңелең,
Хыялың юк, тау башыннан егылсаң.

Бу яшәүдә юмартлыкны теләсәң,
Таугa барып, биеклектән карасаң...
Күкләр – алда, җирдән өстә – уйларың,
Арасында син вакланып калмасаң.

Гомер үтеп, эчәр суың калмаса,
Таугa кара һәм шөкер кыл, и Аллам!
Сәфәр бетеп, соңгы сүзең әйтерсең:
«Таудан килдем, кабат тауга юл алам!»

## Уйлар

Сөйләмәсә кыргыз телендә,
Сөюе юк кыргыз иленә.

* * *

Кояш балкый, бу ялкынлы мизгел
Өметләрне тиз-тиз әсир итә.
Йөрәк түгел, тәнем генә тузган,
Гомер кыска... Ярсу еллар үтә...

* * *

Олуг сүз – үлми, мәңгелек,
Хакыйкать торсын түгелеп.
Артыңнан сүз-җаның кала,
Тән китә җиргә күмелеп.

* * *

Илең – бүгенгең, иртәгәң,
Ватаның – анаң, язмышың.
Кара төн килсә дә булсын
Илеңдә гомер агышың.

* * *

Мин – кыргыз, гасырлар аша килгәнмен бу көнгәчә!
Ил-җирем намус дип яши, туган телдә сөйләшә,
Үз җаныннан өстен куя киләчәген халкының,
Үлемсезлек шушы диеп, саклый бәхет ялкынын.

* * *

Ана телем – әниемнең ак сөтеннән,
Әтиемнең асыл, дөрес уй-сүзеннән.
Җан йөрәгем – саф су кебек агып яткан
Ала-Тауның түбәсенә ак боз кунган,
Ак болытлар йөзеп йөргән диңгезеннән.

* * *

Ирләр бар бит илем диеп сагышланган,
Хезмәтләре батырларга багышланган.
Ил-җиренең иртәгәсен уйлый-уйлый,
Көче белән ким булмаган арысланнан.

*Кыргызчадан* **Ленар ШӘЕХ** *тәрҗемәләре*

# XIV ГАСЫРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЯРТЫСЫНДА АЛТЫН УРДАДА ИСЛАМ ДИНЕ ИНСТИТУТЛАРЫ

*Дин тарату алымнары.* Тохта вафатыннан соң, тәхеткә аның туганы мәҗүси Үзбәк (1312-1340) утыра һәм 1313 елда ислам динен кабул итә, үзен «Солтан Мөхәммәд Үзбәк» дип атый башлый. Аннан соңгы барлык ханнар да мөселман була.

Галимнәр Үзбәкне прагматик максатта – шәһәр җәмгыятендә йогынтылы мөселманнар белән хезмәттәшлек итеп, хакимиятен ныгыту өчен – ислам кабул итте дип саныйлар. Үзбәк хан ислам динен таратуга каршы булган берничә әмирне сугышып җиңә, шулай ук күпсанлы уйгырларны юк итә, ягъни ислам диненә караш аңа үзенә лояль булмаган төркемнәрне ачыкларга һәм аларны җиңәргә сәбәп була.

Үзбәк хан хакимлек иткән өч дистә ел тарихка Алтын Урданың чәчәк аткан вакыты дип кереп кала: шәһәрләр һәм халыкара сәүдә үсү, товар әйләнеше арту һәм башка икътисади факторлар мөселманнарның йогынтысын көчәйтә. Мәҗбүриләүдән тыш та, көндәлек аралашу һәм вәгазьләү юлы белән исламның таралу географиясе киңәя, утрак тормышлы халыкның иманы ныгый бара. Үзбәкнең ислам динен дәүләт дине итү юнәлешендәге актив эшчәнлеген тагын да гайрәтләнеп һәм тырышып, киң масштабта улы Җанибәк (1342 – 1357) дәвам итә. Ул мәҗүсиләрнең гыйбадәт кылу урыннарын һәм табынган сыннарын җимерә, күпсанлы яңа мәктәп-мәдрәсәләр төзетә, гаскәриләргә башларына чалма чорнау тәртибен кертә, дини гореф-гадәтләрнең үтәлешен күзәтә. Шуны махсус әйтеп үтү кирәк: Үзбәк хан һәм Җанибәк, нигездә, ислам динен төрки күчмәннәр арасында гына мәҗбүри тараткannар. Моның шулай булуын Идел-Чулман төбәгендә яшәгән чуваш, мари, удмурт һәм мукшы халыкларының – мәҗүсиләр булып, ә русларның элеккечә православие динендә калулары раслый *(Гарустович Г.Н. Религиозная ситуация в Золотой Орде глазами современников // Ислам и власть в Золотой Орде. Казань, 2012. С. 89-93).*

*Дәүләт кәгазьләрендә һәм ханның эш-гамәлләрендә ислам дине билгеләре.*

Мөселман динен кабул иткән ханнар ислам илләренә илчелек җибәргәндә аның составына күренекле һәм гыйлемле шәехләрне кертә башлыйлар. Моны беренче булып, Бәркә эшли *(Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. С. 431)*.

Акрынлап, хан кәнсәләрендә моңарчы ярлыклар язган бахшиларны руханилар булып торучы хафизлар (Коръәнне яттан белүчеләр) алыштыра. Хан ярлыкларында күзгә ташланган иң зур үзгәреш – элек монголча язылган башламны кәлимәи шәһадәткә (*Әшһәдү ән лә илаһа иллә-Ллаһу вә әшһәдү әннә Мөхәммәдән габдүһү вә рәсүлүһү*) үзгәртү була *(Почекаев Р.Ю. Право Золотой Орды. Казань, 2009. С. 41.).*

Ул замандагы тәртип буенча, тәхеткә утырган һәрбер хан үзенә кадәр булган идарәче биргән ташламаларны раслап, ярлык яздыра. Руханиларга аталган ярлыкларда ташламалар һәм өстенлекләрнең күләме арта бара, кайсыбер өстенлекләр тормыш итү өчен әһәмиятлерәк булган ташламалар белән алыштырыла (*Усманов М.А. Этапы исламизации Джучиева улуса и мусульманское духовенство в татарских ханствах XIII – XVI вв. // Духовенство и политическая жизнь на Ближнем и Среднем Востоке в период феодализма. М.: Изд-во «Наука», гл. редакция восточной литературы, 1985. С. 179-180).*

Исламлашу йогынтысында хан ярлыкларында, хәтта вакыт исәбе – төрки-монгол хайван календаре – һиҗри буенча календарь белән алышына.

Үзбәк хан ислам динен кабул иткәч тә, 1314 елда Кырым шәһәрендә таштан

мәчетләр салдыра. Аның бу гамәле башка элита вәкилләренә үрнәк итеп эшләнгән дип тә әйтергә мөмкин. Хан, суфилар тарикатенә хөрмәт йөзеннән һәр җомгада хаҗи Низаметдин әл-Харәзми яшәгән тәккәгә үзе килеп, күрешә һәм фатихасын ала торган була. Ул көндезге җомга намазыннан соң олы мәҗлес уздыруны гадәткә кертә *(Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. Т.1. Извлечения из сочинений арабских. / В. Тизенгаузен. СПб, 1884. С. 290).*

*Үзбәк хан гаиләсендә ислам дине.*

Ибне Баттута Үзбәк ханның гаиләсе белән аралаша, аның дүрт хатыны белән дә сөйләшә, икенче хатынының Коръән укып утыруына шаһит була. Ханның кызы Ибне Баттута килү хөрмәтенә тирмәсендә олы мәҗлес оештырып, казыйны, сәетне, шәехләрне, фәкыйһларны, талибларны кунакка чакыра *(Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. С. 294, 295, 296)*. Күрәсең, хан хатыннарының берсе ислам динен мәҗбүри кабул иткән була. Иреннән рөхсәт алып, Византиягә әтисе янына бәбиләргә кайтып киткән хатыны Баялун туган илендә калып, кабат православлау диненә кайта. Ибне Баттута язганча, ул да үзен озата килгән мөселманнарны җирле халык тарафыннан кимсетергә ирек бирми *(Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. С. 304-305).*

Дәүләттә ике төрле дин дәгъвәтләү үзәкләре формалаша. Традицион ислам институтлары булган шәһәр мәдрәсәләре эшли, аларда теологик эзләнүләр алып баручы, шулай ук тормыштагы төрле вакыйгаларга дин күзлегеннән бәя бирү, аңлату һәм дини хезмәтләр язу белән шөгыльләнүче галимнәр әзерләнә. Урта гасырларда шәһәрләрнең чагыштырмача азлыгы һәм халыкның, шул исәптән шәһәрдә яшәүчеләрнең, күпчелеге укый-яза белмәү дини китапларның, асылда, голәмәләр арасында гына таралганлыгы турында сөйли. Без шушы ук төркемгә мәчет руханиларын да кертәбез. Алар шулай ук кала яки салада вәгазьләгәннәр.

Бу традицион рәсми институтлар белән янәшә рәсми булмаган суфи дини институтлар – күпсанлы дәрвишләр, изгеләр каберлекләре, ханәкәләр һ.б. булган. Үз чиратында, суфилар арасында ике төрле дәгъвәтләү үзәкләре барлыка килә. Беренче – шәех (остаз) җитәкчелегендә мөридләр яшәгән ханәкәләр. Аларның кайберләре үз мәктәпләрен формалаштырып, күпсанлы мөридләр туплаганнар. Бирегә кешеләр күңел тынычлыгы эзләп яки киңәш сорап килгәнннәр, теләсәләр, бу шәехнең тарафлары булып, ханәкәдә яшәп калганнар.

Ә шәех-остазлар яшәгән зәвияләр чын мәгънәсендә уку-укыту үзәкләренә әверелгәннәр. Күпсанлы күченеп йөрүче дәрвишләр шушы ханәкәләрдә һәм, бигрәк тә, зәвияләрдә белем туплап, остазларының укыту алымнарын, фикерләрен үзләштереп, туган якларына кайткач, динне тарату һәм аңлату белән шөгыльләнгәннәр. Ханәкә башлыгын хакимият билгеләсә, зәвиянең җитәкчесе суфилар арасыннан сайланган һәм танылган остаз булган *(Тримингэм Дж. Күрс. хезмәт. С. 29).*

Икенче төркем актив дәгъвәтчылар – суфилар. Ханәка, завияләргә кешеләр үзләре килсә, илгизәр дәрвишләр ерак торак пунктларында һәм җәйләүләрдә вәгазьләгәннәр. Күбесе төрле үләннәрнең сихәтләрен белеп, дәвалау белән дә шөгыльләнгән. Күрәсең, кайберләренең ниндидер өстәмә сәләтләре дә булган. Бер сүз белән әйткәндә, дөнья малына кызыкмаган, үзләрен Аллага якынаюга багышлаган суфиларның күчмәннәрне туган телләрендә вәгазьләве төрле могҗизалар белән үрелеп барган һәм җирле халыкка гаять көчле тәэсир иткән.

Шулай итеп, ханнар һәм элита вәкилләре тырышлыгы һәм сәүдәгәрләр иганәләре хисабына Идел буе, Кырым, Төньяк Кавказ шәһәрләрендә яңа мәдрәсәләр ачыла, аларда дин галимнәрен әзерләү җайга салына. Шул рәвешле утрак тормыш алып барган төркиләр арасында ислам дине шактый ныгый бара.

Без Үзбәкнең һәм Җанибәкнең төп казанышы дип, ислам дине белгечләре өчен уку йортлары ачу һәм монгол элитасын, төрки күчмәннәрне исламлаштыру дип саныйбыз. Шулай да аларның киң кыпчак даласында ислам динен таратырга вакыты

да, мөмкинлеге дә җитмәгән, шул сәбәпле ханнар административ ресурсны киң файдаланганнар.

*Тарикатьләр.* Ислам Җучи Олысында баштан ук суфичылык рухында, «халык исламы» булган дисәк, ялгышмабыз. Әйткәнебезчә, Алтын Урдада Ясәвия тарикате хакимлек итә. Шулай ук Көбравия тарикате дә таралыш ала.

Сәяхәтче Ибне Баттута үз юлында күпсанлы мәчетләр, руханилар һәм изгеләр каберләре күргәнен теркәп бара. Алтын Урдада Ясәвия тарикатенә кергән дәрвишләрнең даими торак урыннары булмыйча, алар, нигездә, шәехләрнең каберләре янында яшиләр, аларны саклыйлар һәм карап-тәрбияләп торалар. Ибне Баттута юлында очраган изгеләр каберлекләре мөҗавирләр тарафыннан сакланган һәм шәехләр, аларның мөридләре җыела торган урыннар булган *(Тримингэм Дж. Күрс. хезмәт. С. 82).*

Каберләрне изгеләштерү суфи тарикатьләрнең Алтын Урда халкына һәм хакимнәрнең иҗтимагый аңына тәэсир ясау омтылышыннан килеп чыккан. Суфи тәгълиматы шәехләрне генә түгел, ә аларның рухи көчен үзенә алып дәвам итүче суфиларны таный башлый. Яңа буын суфилар остазлары каберләре янына рухи элемтә булдырып, аларның җаннары белән аралашу өчен киләләр. Халык иҗтимагый аңында бу практика яңача яңгыраш ала: дин юлында йөреп вафат булган шәхесләрнең җаннары каберләрендә һәм исән чакта үзләре булган җирләрдә (биналарда) сакланып кала, шуңа күрә андый урыннарда үзеңә ярдәм-яклау сорарга кирәк дигән фикер урнаша (*Тримингэм Дж. Күрс. хезмәт. С.33*).

Алтын Урда чорында Идел-Чулман төбәгендә дә җирле түрәләр, шәехләр каберлекләре өстенә төрбә-мавзолейлар корыла. Археологлар тарафыннан Бүләр шәһәренең үзәгендә урнашкан Җамигъ мәчетенең көнчыгыш диварларына якын болгар аксөякләренең һәм изге дин әһелләренең каберләре өстенә куелган кирпеч корылмалар калдыклары өйрәнелде һәм фәнни әйләнешкә кертелде.

Г.М. Дәүләтшин Болгар шәһәрендәге Төньяк һәм Көнчыгыш төрбәләр, Кече манара янындагы зиратта «Хан төрбәсе», «Кара пулат» илгизәр дәрвишләр сыену урыны булган дигән фикердә тора, аларның төзелешләре белән Бохара, Харәзем яки Кавказ гүрханәләренә тартым булуын билгеләп үтә, күренекле тарихчы А.Ю. Якубовскийның Болгар төрбәләрен бизәгән майоликаларның Нәҗметдин Көбра гүрханәсендәге майоликаларга охшаш гына түгел, аларның эшләнешләре дә, бизәлешләре дә бер үк дигән сүзләрен дәлил итеп китерә *(Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 275, 276 б.).*

Урта һәм Түбән Идел буйларында һ.б. төбәкләрдә Алтын Урда чоры кабер ташларында сурәтләнгән алты почмаклы йолдыз «җәмигъ йолдыз» дип йөртелгән һәм сөнниләрнең символына әверелгән. Кулъязма китапларда ясалганда, аның почмакларына исемнәр, шул исәптән Мөхәммәд пәйгамбәрнең оныклары, Хәсән һәм Хөсәен, шулай ук аның фикердәшләре һәм көрәштәшләре булган беренче дүрт хәлиф исемнәре язылган. Коръәндә телгә алынган Сөләйман пәйгамбәрнең мөһере дә алты почмаклы булган һәм җен-шайтаннар бу мөһер сугылган әйберләргә зыян китермәгәннәр дигән караш яшәгән. Шуның өчен йолдызлы мөһер биналарга, ризыкларны саклау өчен савыт-сабаларга сугылган (*Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 279 б.).*

*Мәчетләр һәм мәхәлләләр.* Ибне Баттута Алтын Урда башкаласында яшәүчеләрне төркемләп санап чыга: бер өлеше – исламга күчкән монголлар, бер өлеше – мөселман динендәге аслар, христиан динен тотучы кыпчаклар, чиркәсләр, руслар һәм византиялеләр. Һәр халык бергәрәк тупланып көн күрә, ә чит ил сәүдәгәрләре койма белән әйләндереп алынган махсус урында яши.

Ул шәһәрдә биш вакыт гыйбадәт йортларының күп булуы турында хәбәр итә. Ягъни кавемнәргә тупланып, квартал-квартал булып яшәгән мөселманнарның һәрберсенең үз базары гына түгел, гыйбадәтханәсе дә булган. Димәк, төрле мәдәниятле һәм телле башкалада халык кавемнәре һәм тору урыннары буенча дини планда аерымланган булып чыга. Ислам мәзһәбләренең аерым төбәкләрдә һәм кавемнәр арасында таралган

булуын искәртсәң, бу бүленешкә мәзһәбләр дә тәэсир итәргә тиеш кебек. Чынлыкта, Ибне Баттута Сарай шәһәрендә 13 җамигъ мәчет, шуның берсе шафигыйларныкы булуын искәртә *(Тизенгаузен. Күрс. хезмәт. С.306)*. Күпчелек мөселман руханилар хәнәфиләр булган, мәчетләрдә гыйбадәт кылган дип фикер йөртергә мөмкин. Әгаилә мөнәсәбәтләре, мал бүлү, эти-әниләргә кагылышлы һәм башка мәсьәләләр буенча алар үз казыйлары янына барганнар.

*Мәхкәмәләр.* 1320нче елларда мөселман хокукы рәсми мәхкәмә органы буларак кулланылышка керә, Алтын Урда хакимияте вәкилләре арасында вәзирләр, наибләр, мөфтиләр пәйда була. Монгол хөкем йорты янәшәсендә даими хезмәттәге мөселман мәхкәмәсе эшли башлый. Фикъһы белгечләре утрак тормыш алып барган төбәкләрдәге һәм шәһәрләрдәге мәдрәсәләрдә укып чыккан голәмадан булган *(Почекаев Р.Ю. Право Золотой Орды. Казань, 2009. С. 41)*.

Ислам дине традицияләре тирән булган Урта Азия төбәгендә ислам мәхкәмәләре киң таралган булган. Бу уңайдан, Ибне Баттута Харәземдә күргәннәрен язып калдырган: шәһәр белән идарә итүченең йортына һәр көнне мәхкамә эшләре буенча казый, ислам хокукы белгечләре һәм язып баручылар килгән. Казый белән янәшә өлкән әмир утырган, бүлмәдә тагын сигез әмир һәм яргучы дип аталучы төрки шәехләр булган. Дингә кагылышлы бәхәсләрне – казый, дөньяви бәхәсләрне әмирләр тикшереп, карарлар кабул иткәннәр *(Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. С. 311, 312)*.

Ибне Баттута Алтын Урда башкаласында хәнәфиләр (Бәдретдин әл-Араж), шафигыйлар (Садретдин Сөләйман әл-Ләкзи), мәликиләр (Мисырдан килгән Шәмсетдин әл-Мисри) казыйларының, хокук белгечләренең исемнәрен атый *(Тизенгаузен. Күрс. хезмәт. С. 306)*. Бөек сәяхәтче хәнәфиләр һәм шафигыйлар мәхкәмәләрен, шулай ук, Кырым шәһәрендә очрата *(Юлай Ш. Высокая исламская культура в Золотой Орде // История татар с древнейших времен. В 7 т. Т. С. 592)*.

*Дин әһелләре.* Ислам йогынтысында акрынлап урнашкан иң зур уңай үзгәрешләр мөселман руханиларының социаль-сәяси статусларында чагылыш таба. Ханнарның ярлыкларыннан күренгәнчә, XIV гасырның уртасына кадәр руханилар ил белән идарә итүгә якын җибәрелмәгәннәр, фәкать кайбер очракларда идарәче чыңгызыйларның хөрмәтен һәм аларның яхшы мөнәсәбәтен тойганнар. Соңрак язылган ярлыкларда мөселман руханиларының дәүләт эшләрендә катнашулары күзгә ташлана: ханның мөрәҗәгате катлаулы һәм бер үк вакытта стандарт форма ала, руханилар исемнәре гади чиновникларга кадәр языла, ягъни дәрәҗәләре буенча руханилар югары дәүләт эшлеклеләре белән тиңләшәләр диярлек *(Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV – XVI вв. Казань: изд-во Казан. ун-та, 1979. С. 128)*. Ярлыкларда Үзбәк администрациясендә эшләгән хакимнәр, сәетләр, вәкилләр һәм башкаларның исемнәре атала *(Почекаев Р.Ю. Күрс.хезмәт. С. 41)*.

Ибне Баттута «шәрифләрнең башлыгы мөхтәрәм сәет» дип атаган башлык кул астындагы руханилар иерархиясе фәндә төгәл ачыкланып җитмәгән. Югары катлам руханиларга дини һәм тормышта килеп туган төрле мәсьәләләр буенча фәтва бирүче гыйлем ияләре – мөфтиләрне, олы хөрмәткә лаек суфи шәехләрне кертергә кирәк. Ислам дөньясында элемтәләр горизонталь булып, дин әһелләренең үзара, дәүләт эшлеклеләре арасында һәм җәмгыятьтә абруйлары аларның белем дәрәҗәләре һәм мөселманча тормыш рәвешләре белән билгеләнгән. Шуңа күрә мөфтиләргә янәшә тирән дини белемгә ия хокук белгечләре – фәкыйһларны, хөкем карарлары чыгаручы казыйларны һәм гаскәри руханилар – наибларны куярга мөмкин.

Аннан соңгы баскычта – хәнәфи мәзһәбе мәчетләре имамнары, алардан соң ук тарихи чыганакларда дәрвишләр, фәкыйрьләр һәм мөҗавирләр (изге каберлекләр каравылчылары) күрсәтелә. Түбән баскычта мөәзиннәр булуын да искәртү сорала. Чыганакларда тагын талибларны һәм муллаларны телгә ала *(Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 250 б.)*.

*Мәктәп-мәдрәсәләр.* Урта Азиядә һәм Идел-Чулман буйларында – Алтын Урда

дәүләтендәге ике иң көчле ислам дине үзәкләрендә – монгол яулары узуга, ислам укыту системасы, әгәр дә голәмәләр, мөгаллимнәр исән калган булса, тиз арада торгызылган дип әйтергә мөмкин. Чөнки төбәкнең мөселман элитасы дини белем һәм әхлакый тәрбия турында кайгыырткан. Әлбәттә, бу уку йортлары чагыштырмача күп булмаган, шулай да җитәрлек күләмдә дини кадрлар әзерләргә мөмкинлек биргән дип уйларга нигез бар. Тирән дини белем алырга теләүчеләр Алтын Урда чорында Мисырга яки башка төбәкләрдә яшәгән мәшһүр фикер ияләре янына барып, белем туплаганнар. Ислам динен кабул иткән чыңгызыйлар тарафыннан мөселман уку йортлары ачу һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү турында кайгырту дәүләткүләм эш дип кабул ителгән. Әйтик, Бәркә Мисыр мәмлүкләре хакименә язган хатында зур сөенеч белән балаларның мәктәпләрдә Корьән укуларын хәбәр итә (*Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. С. 431)*. Дини белем бирү системасын көчәйтү һәм киңәйтү Үзбәк һәм Җанибәк ханнар тарафыннан киң масштабта тормышка ашырыла.

*Дин галимнәре.* Җучи Олысының дин галимнәре әсәрләре күп сакланып калмаган. Без бу күренешне Багдад җимерелгәч, ислам дини тәгълиматы өлкәсендә башланган торгынлыкның бер чагылышы дип уйламыйбыз. Күрәсең, дәүләтнең күпчелек халкы күчмәннәр булуы, дини тормышта һәм вазгыятьтә суфиларның мөһим роль уйнаулары күпмедер дәрәҗәдә йогынты ясаган. Билгеле булганча, күп вакыт, көч һәм тирән гыйлем таләп иткән хезмәтләр билгеле бер максатны күздә тотып яки нинди дә булса бәхәсле мәсьәләне шәрехләү өчен язылганнар. Күрәсең, чит илләрдән чакыртылган яки килгән дин галимнәре ул заманда туган төрле катлаулы хәлләрне ачыклауга үз өлешләрен кертканнәр. Шулай ук Алтын Урдада туып-үскән шәхесләрнең ислам илләренә китеп, шунда яшәп калуларын да исәптән чыгарырга ярамый. XIV гасырның соңгы өч дистә елында Җучи Олысында көчәйгән сәяси тотрыксызлык берничә дистә гыйлем иясен Мисыр һәм Сүрия мәдрәсәләренә китәргә мәҗбүр итә. Алар арасында мөселман хокукы, мантыйк, риторика фәннәре буенча зур белгеч әз-Заһиди (1374 елда үлә) шәхесе игътибарга лаек *(Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 334 б.)*.

Алтын Урда шәһәрләрендә берничә мәзһәб голәмәләре яшәү һәм алар арасындагы фикер аерымлыгы гади мөселманнар арасына чыкмаса да, дин галимнәренә, күрәсең, руханиларга һәм суфиларга аңлату өчен, үз мәзһәбләре турында хезмәтләр язарга этәргән. (Әйтергә кирәк, бу өлкәдә шәфигый мәзһәбе голәмәләре зур тырышлык куйганнар *(Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 367 б.))*. Алтын Урдада өстенлек иткән мәзһәб вәкиле булган XIV гасыр болгар галиме Борһанеддин Ибраһим бине Хозыр әл-Хәнәфинең 1350 елда «Ислам мәзһәбләренең башлангычы» исемле китапны үз фикерләрен кертеп күчерүе билгеле. Соңрак ул «Осулел-Хөсами» («Хөсами өйрәтмәләренең нигезләре») хезмәтен яза. Бу китап 1246 елда вафат булган күренекле дин тәгълиматчысы Хөсамеддин Мөхәммәд Акситәни фикерләрен шәрехләүдән гыйбарәт. Ибраһим шәех бине Мөхәммәдхуҗа бине Таҗеддин әл-Кыртимәнинең «Усуле имам Фәхрелислам» (1363) китабы да билгеле. Ибне Бәззазның үз чорында атаклы «Әл-фәтави әл-Баззазия» хезмәтендә хәнәфи мәзһәбенең төп кагыйдәләре тупланган *(Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 365-366 б.)*.

Җучи Олысында аерым галимнәрнең үз остазларының әсәрләрен шәрехләп, хезмәтләр язуын ислам интеллектуаль даирәсендә күренешкә әйләнә башлаган тәкълиднең, иярүнең бер чагылышы дип тә бәяләп буладыр. Мәсәлән, Алтын Урдада яшәгән шәех Минһаҗеддин Ибраһим бине Сөләйман әс-Сараи үзенең остазы, Харәземдә туып үскән Исмәгыйль бине Мәхмүд бине Мөхәммәд әл-Кәрдәринең «Фаваидел-Масаими-Зарурия» китабына аңлатма рәвешендә «Мәфатихел-әкъфаль» («Йозакларга ачкычлар», 1369) дигән әсәр яза. Әхмәд бине Габдулла әл-Кырыми Йосыф бине Җинд әт-Тукатиның «Тәлвих», «Шәрхе Гакаиден-нәсәфи» хезмәтләрен шәрехли *(Дәүләтшин Г.М. Күрс. хезмәт. 374 б.)*.

Алтын Урда чорында яшәгән фикер ияләре төрле өлкәләрдә – дин белеме, фән, әдәбиятта атказанганнар. Шулар арасында, мисал итеп, Сәйф Сараины (1321 – 1396)

китерергә мөмкин. Сарай-Бәркә шәһәрендә укып, шагыйрь буларак Сараи тәхәллүсен алып, ул 1370 – 1380 еллар аралыгында Мисыр-Сүриягә күчеп китә. Читтә иҗат ителгән «Гөлестан бит-төрки» (1391) кульъязмасы төрки телдә укучысына ислам дине, әхлагы, тормыш һәм яшәеш турында сөйли. Аның 8 бүлегендә патшалар тормышы (1), дәрвишләр әхлагы (2) бәян ителә, аз белән канәгать булып яшәү (3), дәшми тору (4), мәхәббәт һәм яшьлек (5), картлык һәм зәгыйфьлек (6), тәрбия мәсьәләләре (7) һәм аралашу тәртибе (8) турында сөйләнелә. Болгар чоры дини рисаләләре, аерым алганда, Дауд Суваринең гарәп һәм фарсы телендәге хезмәтләре, 1358 елда Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрендә Мәхмүд бине Гали әл-Болгари иҗат иткән «Нәһҗел-фәрадис» традицияләрен дәвам иткән бу китап үзеннән соң күп кенә төрки-татар шагыйрьләре-галимнәре тарафыннан үрнәк итеп алына.

Әдәбиятта Сәйф Сараи – «Сөһәйл вә Гөлдерсен» (1394) поэмасының авторы фәндә иң беренчеләрдән булып, әлеге дастанында Җирнең Кояш тирәсендә әйләнүен әйткән фикер иясе буларак та мәшһүр. Бу мисал Алтын Урда голәмәләренең талантлы, укымышлы, зыялы шәхесләр булуын тагын бер кат искәртә.

Шулай итеп, санап кителгән мисаллар Җучи Олысында дини әсәрләр язылганны, биредә тупланган дини фикернең ислам тәгълиматының бер өлеше булганын раслый.

## XIV гасыр ахырында Алтын Урдада ислам. Йомгак урынына.

М.Госмановның Алтын Урдада ислам дине таралу этапларының өченчесендә исламлашу көчәя барган дигән фикере бүген күп сораулар уята. Бу тезис, нигездә, утрак тормыш алып барган һәм күптәннән мөселман мәдәниятендә яшәгән халыкларның исламлашуына туры килә. Чынлыкта, Бирдебәк хан (1357 – 1359) үтерелгәннән соң Алтын Урда дәүләтендә башланган хакимият өчен көрәштә тәхеткә дәгъва итүче чыңгызлыларның бер-берләрен үтерүләре тирән торгынлыкка илтә, илнең аерым өлешләргә таркалу механизмын хәрәкәткә китерә. 1376 елда тәхеткә утырган Туктамыш дәүләтне берләштерсә дә, аның 1393 һәм 1395 елларда канкойгыч сугышларда Аксак Тимер гаскәренә җиңелүләре һәм тәхетен югалтуы Алтын Урдада шәһәрләрнең һәм халыкара сәүдәнең сүнүенә, илдә тәртипнең һәм сәяси тотрыклылыкның юкка чыгуына китерә. Бу вакыйгалар исламлашу барышына тискәре йогынты ясый. Галимнәр фикеренчә, XIV гасыр азагында Җучи Олысында шәһәр цивилизациясе күчмәннәр мәдәниятенә буйсына. Идарә итү системасы гадиләшә, ягъни Төрки каһанлыктагы кебек юлбашчы төп рольне уйнаган модельгә кайта, шул сәбәпле XIV гасырның беренче яртысында төзелгән хакимият институтларының, шул исәптән мәхкәмәләрнең кирәге калмый.

XIV – XV гасырларда Алтын Урданың көнчыгышында яшәгән күчмәннәр арасында ислам дине бик акрынлык белән тарала. Туктамыш хан (1379 – 1395) ислам динен далада тарату өчен зур тырышлык куя. Гасырлар чигендә марионет ханнар куеп ил белән үзе идарә иткән бәкләрбәге Идегәй (1397 – 1419) күчмәннәр арасында динне мәҗбүриләп таратып шөһрәт казана. 1416 елда аның хатыны хаҗ кылып кайта. Шул рәвешле хакимият һәм дәгъватчеләр тырышлыгы белән XV гасырда Алтын Урда мөселман дөньясының аерылгысыз өлешенә әверелә *(Гарустович Г.Н. Күрс. хезмәт. С.94-95).* Мәҗбүриләү мәҗүсиләрне үз диннәрен яшереп тотуга этәрә.

Алтын Урда шәһәрләре янындагы мөселман каберлекләрендә археологлар еш кына ислам кануннарына туры килеп бетмәгән рәвештә күмелгән кеше сөякләре таба. Еш кына каберләргә хатын-кызларның бизәнү әйберләрен, тәңкәләрен, баш киемнәрен салу күренеше очрый. Исламча күмелеп, мәҗүсилек элементларын саклаган каберлекләр Дон елгасы (XIV гасыр), Төньяк Кавказ (XIV гасырның икенче яртысы – XV йөз башы), Шарахалсунда (XIV йөзнең икенче яртысы, хәзерге Ставрополь өлкәсе) һ.б. урыннарда теркәлгән *(Иванов В.А., Злыгостев В.А., Антонов И.В. Күрс. хезмәт. С.175).*

Кыпчаклар ислам динен кабул иткәч тә элеккечә потларга һәм йолдызларга табынуларын дәвам иткәннәр, аларда күпсанлы ырымнар сакланып калган. Әйтик, теге дөньядагы җеннәрне мөселман җеннәренә һәм гәүр җеннәренә бүлгәннәр. Ислам динендәге җеннәр сихерче-багучыларга авыру кеше тәненнән гәүр җеннәрне куарга ярдәм итә дип саналган. Сихерләү йоласын башлар алдыннан алар башта Йасин йоласын укыганнар һәм Алладан ярдәм сораганнар. *(Пилипчук Я.В. Күрс. хезмәт. С. 212)*. Бу мисал үзе генә дә исламның һәм мәҗүсилекнең халык аңында ни дәрәҗәдә кушылганлыгы турында сөйли.

Шулай итеп, исламлаштыру барса да, күчмәннәр арасында аның нәтиҗәләре югары булмаган дип әйтергә нигез бар. Кайбер галимнәр, утрак тормыш алып барган төбәкләрдә яшәгән мөселманнар йогынтысында күчмәннәрнең бер өлеше исламча яшәргә омтылган, бу халәт алар далага, җәйләүләргә күченеп киткәч, кабат юкка чыккан дип саныйлар, моның шулай икәнен археологлар тапкан күчмәннәр каберлекләре раслап тора.

Алтын Урда халкының исламлашуы тәгәлләнмәгән булу, дөресрәге, бу барышның күчмән яки утрак тормыш алып баручы, яки шәһәр халкы арасында төрле дәрәҗәдә булганлыгы дәүләт таркалгач тагын да ачык күренә. Алтын Урданың кыйпылчыклары булган Кырым, Казан, Бохара, Хива ханлыклары утрак тормышка хас ислам тарафдарлары булып кала. 1505 елда Кырым ханы тарафыннан җимерелгән Олуг Урдада һәм Әстерхан ханлыгында исламның йогынтысы көчле булмау аларда күпчелек халыкның күчмәннәр булуы белән аңлатыла. Себер ханлыгында ислам дәүләт дине итеп XVI гасырның 70нче елларында Күчем хан тарафыннан игълан ителә, мондагы төркиләрнең исламлашуы XVII – XVIII гасырларда көчәя *(Тюменское и Сибирское ханства: коллективная монография. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2018. С. 242-243)*. Нугай Урдасы, Күчмән үзбәкләр дәүләте һәм Казакъ дәүләтләре тулысы белән күчмән җәмгыятьләре кануннары буенча яши башлый. Аларның элиталарында сакланган ислам кануннары синкретик характерда булып, дин кагыйдәләрен төгәл үтәү турында сүз, гомумән, бармый. Казакълар арасында исламлашу XVIII йөз азагы – XIX гасырда гына киң җәелә.

С.Г. Кляшторный, Т.И. Солтанов һәм тагын кайбер галимнәрнең Алтын Урдада бердәм мәдәният һәм дин булмаган, Җучи нәселе вәкилләренең ислам дине кабул итүе Алтын Урдада бердәм дәүләткүләм идеология тудырмаган дип язулары да шул хакта сөйли, күрәсең (*Кляшторный С.Г., Султанов Т.И. Государства и народы Евразийских степей:от древности к новому времени. 3-е изд., исправл. и доп. СПб.: Петербургское востоковедение, 2000. С. 275-281*).

*Кыргыз-кайсак (казакъ) җәйләүләрендә* йөргән *сәяхәтче Г.Георги аларны «ялкау мөселманнар» дигән фикерен, җәйләүләрдә ислам дине турында мәгълүматлы кешеләр аз, әмма киләчәкне юраучылар, һава торышын фаразлаучылар, төрле-төрле күрәзәчеләр күп, дип шәрехли. Исламны хөрмәт итсәләр дә, үзләренең мәктәпләре дә, зур-зур олысларда бер муллалары да юк, үзләре бик нык хорафатлы диюе бу хәлнең сәбәбен дә ачык күрсәтә (Георги Г. Описание всех обитающих в Российском государстве м. народов. Ч.2. О народах татарского племени. СПб., 1799. С. 140).*

*Йомгаклап әйткәндә, исламлашкан күчмәннәр үзләрен мөселман дип санаганнар, беренче урынга иманны саклауны куйганнар, диннең «биш баганасын» үтәүгә тиешле дәрәҗәдә игътибар бирмәгәннәр, иң мөһиме – аларның көндәлек тормышында мәҗүсилек элементлары һәм гореф-гадәтләре мөһим урын алып торган. Исламлашу, нигездә, күчмәннәрең кабилә җитәкчеләре арасында чагыштырмача нык булган, чөнки алар дәрвишләр яки башка дин әһелләре белән аралашып, гаиләләрендә дини традицияләрнең өзелмәвен тәэмин иткәннәр.*

**Илдус ЗАҺИДУЛЛИН,**
*тарих фәннәре докторы*

# КҮП НОКТАЛАР НИ ТУРЫНДА СӨЙЛИ?

*(Лилия Гыйбадуллинаның «Дәвам» циклы ( 2021 ел, №7) турында)*

«Казан утлары» журналының 1921 елгы җиденче санын кулыма алу белән алдымда шигъри алан ачылды. Журналда мондый да зур күләмдәге шигырь тупламасын соңгы елларда хәтерләмим дә. Әдәбиятның әнкәсе дип аталган шигъриятькә шундый аз урын бирәләр, романнар, повестьлар 50-100әр бит урынны били ләбаса дип үпкәләбрәк тә йөри идем әле, һәм менә өстемә бәхет ишелеп төштемени: 12 бит! Бар дөньямны онытып, шигырь урманына ташланам.

Тәүге «Эз» исемле шигырьне укып чыгуга, аннан Мөдәррис Әгъләм аһәңнәрен ишетеп алам һәм шунда гына авторына игътибар итәм: кем соң әле бу? Аһ, мин яраткан шагыйрь икән бит – Лилия Гыйбадуллина! Миннән 40 яшькә диярлек яшь ул. Ә үзе өлкәннәрчә фикер йөртә, тик аның үз тавышы, шигъриятьтә үз табышы, үз ачышлары ярылып ята.

Шигъри чишмә бәреп чыга икән, яшеңә, яшәү рәвешеңә, матди хәлеңә карап тормый, ага да ага, ташый, актара, актарыла бит ул. Менә Лилия Гыйбадуллина атлы шагыйрь дә чишмә ихтыярына бирелгән, чөнки чишмә табигый агым бит ул! Ә табигать көченә каршы тора алган адәми затны дөнья белми әле. Агымнар... Алар, әлбәттә, бик күп төрле, тик шигърият чишмәсе шагыйрь булган затның җаны аша ага һәм шагыйрьнең генә түгел, шигырьне ишетүче, аңлаучының да җанын дәвалап уза ул.

*Үзебез дә – кемнәрнеңдер эзе, –*
*Ашыгабыз киләчәккә таба...*

– ди автор.

– Әлбәттә, әлбәттә! – дип җөплим дә алга таба ашыгам.

«Моң» дип атаган ул бу шигырен. Әлегәчә моңның ни икәнен кистереп кенә әйтә алган, билгеләмә бирә алган кеше юк шикелле, ләкин аның инде ачып бетермәслек тылсым икәнен һәр моңлы зат белә.Ә Лилия исә:

*Шушы моң сагалый һәрзаман,*
*Хәтта ки яңадан тусаң да, –*

дигән нәтиҗәгә килгән. Ә ни соң ул шундый хикмәт, шундый тылсым?!

Бу шигырь шундый югары накалда язылган ки, Лилиянең хәлләренә кереп, тиз генә аңа бер чынаяк су сузмакчы булам. Тик ул минем алдымда түгел ләбаса! Ул бит Чаллыда яши һәм аңа янган чакта су бирер, егылганда, кул сузар яры да, балалары да бар икән. Алай да, йа Ходам, бирсәләр генә ярар иде дип уйлап куям. Күзләремне янудан саклагандай, карашымны тиз генә алдагы шигырьгә күчерәм.

Монысы тагы да ярсурак, бүреләр нәселенә эндәшә ул һәм: «Минем канда ана бүре улый», – ди. Алга таба инде мин аны ана бүре буларак тыңлыйм, мин ана бүрене тыңлыйм. Тик ул ана бүре «Без белмәгән телдә улый», ди һәм тагы үз «Сүз»ен әйтә. Мин аның ил ирләреннән ни көткәнен, ни өмет иткәнен аңларга тырышам:

*Чал карашлы күктән,*
*Чуерташлы җирдән*
*Кайтавазын көтәм мин бу өннең.*
*Очкын булып чәчрәп,*
*Яшен булып яшьнәп,*
*Ярыр сыман берчак кара төнне*
*Бүре өне,*
*Ап-ак сагыш булып,*
*Ап-ак өмет булып,*

– ди икән бит ул.

Әйе, аналарыбыз имезгән күкрәк сөте, рухи моң кайтавазын көтә бит ул!

Шагыйрь үз халкының, кавеменең үткәнен, тарихын белмәсә, халкына хак сүз дә җиткерә алмас иде. Ул тарихка аяк-куллары белән чумган. Ул нәфис куллары белән күмелгән хәрабәләрне актара, чишмәләрне ача. Алар астыннан үз-үзен, халкын, аның сүнмәс рухын эзли. Әйтәм бит, шагыйрь булган шагыйрьнең бүгене генә түгел, үткәне, тарихы да җаны аша ага һәм шагыйрь җирдә яшәеш өзелмәсен өчен киләчәккә китә. «Сүз» шигыре – шушы хикмәтнең ачык күренеше, дияр идем.

*Сүз булып, гасырлар аркылы*
*Мин сине эзләдем... –*

ди шагыйрь.

Әгәр ул тарихтан кавемен, халкын тапса, ул аны киләчәккә алып барачак, чөнки халкын, милләтен киләчәккә алып бару – нәкъ шагыйрьләр миссиясе. Ул аны киләчәккә алып барырга, үз телендә, үз рухы белән киләчәк буыннарга тапшырырга тиеш. Нәкъ шуның өчен дә шигърият әдәбиятның әнкәсе – ана бүресе дип атала да, замана, халкы йөрәге белән шагыйрь йөрәге бергә типкәнгә! Күрәсез, шагыйрь булу белән шигырь сырлау бер үк нәрсә түгел. Күпләр шул ритмга керә алмыйлар, чөнки анда гел уңайлы-җайлы гына түгел, чөнки цивилизация җимнәрен күпчелек эләктерергә авызын ачып тора, ә шагыйрьләр исә табигать биргән шартларга риза булып тереклек итә. Элегрәк, адәми зат табигатькә якынрак торган заманнарда (бүген табигатьне яралтучысы итеп танымый да инде ул) әле ханнар шагыйрьләр катына килә торган булганнар. Шагыйрь фикере белән, ягъни табигатьне аңлаучы фикере белән исәпләшкәннәр, ә бүген үзләренә яраклашканнарын гына кабул иткәлиләр, әле кабул итсәләр... Бүгенге тәхеттәгеләргә хак фикер кирәкми дә шул.

«Кала» шигыренә шагыйрь ифрат та нечкә тоемлаучы шагыйрь, проза остасы Марсель Галинең сүзләрен таяну ноктасы итеп алган.

*«Җир китсә дә, ил китсә дә, Тел китсә дә –*
*Барыберме сезгә? Безгә барыберме?!»*

– дип әрнеп оран сала Марсель Гали һәм бу сорауны Лилия Гыйбадуллина эләктереп алып, җанына уздыра да үзе белгән тарихны, үз заманы яшәешен дә өстәп, милләт өстенә өелгән эскертне тагы да биегәйтеп күрсәтә. Өелгәне – чарасызлык... Чарасызлык... Чарасызлык...

*Далалардан калаларга күчеп,*
*Калалардан салаларга калып,*
*Без барабыз, без барабыз җәяү,*
*Без атлыйбыз читекләрне салып.*

(Сүз уңаеннан, Арча читек фабрикасын да ябып куйганнар икән бит.)

*Без өненнән качкан киек кебек,*
*Карурманнан бизгән җәнлек сыман.*
*Калаларга ымсынабыз – үргә,*
*Без – нигезен җуйган юлчы һаман.*

Һай сеңлем генәм лә, балакаем, дип сөепләр эндәшер идем дә, шагыйрьләрнең яшен танымыйм бит. Алар барысы да шигырьләре олылыгында, шигырьләре яшәгән яшендә шул минем өчен. «Шагыйрь!» – дип дәшәм! Аһ шагыйрь, син бит минем уйларыма тәңгәл уйларны шундый да камил калыпларга салып, шундый да сүзләр табып, дөньяга чыгаргансың, мондый шатлык-сөенечне миңа үз гомеремдә фәкать Мөдәррис Әгъләм шигырьләре генә бирә алгандыр. Тик син – яңа, тик син нәкъ минем күңелемнең бу язындагы яңа бөресе, чәчәге, тирәге, имәне! Әйе, имәне! Ирләрне генә имәнгә тиңлиләр иде дә бит, ирләр йомшарды. Әллә инде усакка калдылар, димме... Алай да Лилиянең карашы ир-атлар тарафына төбәлгән, әледән-әле шагыйрьләр иҗатыннан

энҗеләр таба да таяну ноктасы итеп ала ул аларны. «Алтын Урда» шигыренә дә Рүзәл Мөхәммәтшаның  дүртьюллыгын алган. Шигырь «Мин сүрән кояшның нурында җылынам» ди, ә Лилия үз шигырен Мөдәррис шигырендә бик җете яңгыраш тапкан «Бутама!» сүзе белән тәмамлый. Ни-нәрсәнедер исли алмый уздым: әллә сүрән кояш җылысында җылыну яшәү түгел, яшәү белән тереклек итүне бутамаска чакырамы? Аклыймы бу эпиграф үзен, бу шигырь өчен таяну ноктасы була аламы? Ә «Алтын Урда» шигыренең һәр юлы вулкан булып атылырдай өлгергән, тулган, киерелгән җәядәй тоелды миңа... Әйе, һәркем туган җирен жирнең уртасы дип аңлар дәрәҗәгә күтәрелә алса гына, олы илен дә күтәрә ала. Башкача юк!

Әле менә «Таяну ноктасы» тапшыруында бәхәсләшкән булалар: шәхес милләтне күтәрәме, әллә милләт шәхеснеме? Бер капчык бодай да бөртекләрдән тора. Бер черек бөртек бөтен капчыкны бозарга да мөмкин.

Лилия бу хакыйкатьне, әлбәттә, белә һәм үзенең «Сөрән» дигән шигыре белән бу сорауга җавабын да бирә:

*Уннан бер, йөздән бер, меңнән бер. . .*
*Чирүне ил итә – ир кеше.*
*Чирүне ил итә – бер кеше.*
*Меңәүләр берәүдән башлана,*
*Чиксезлек – берәүдән башлана,*

– ди дә дәвам итә:

*Син чиксәң – югала бөтенлек.*
*Меңәүләр чигенә, син чиксәң.*
*Нәселең, ыруың, өммәтең,*
*Илең дә тез чүгә – син чүксәң.*

Бу шигырьнең һәр юлы мөстәкыйль афоризм булып яши ала дияр идем мин. Их! Мәктәп мөгаллим-мөгаллимәләре, сез шушы гына шигырьне бар булганы белән шәкертләрегезгә җиткерә алсагыз иде, заман батырлары булыр идегез, билләһи! Бу – ил тарихы, рух тарихы! Бу киләчәккә гадәти өндәү генә түгел, бу – СӨРӘН! Бу шигырьләр барысы да шагыйрьнең уч төбе кадәр генә китабына сыйганнар. Мөдәррис Әгъләм дә үзенең шундый гына, тик вакытында чыгып өлгергән китабын иң зур уңышы дип саный иде. Чөнки сүзнең вакытында әйтелгәне, гамәлнең вакытында кылынганы кыйммәтле. Ә калганнары буш сүз яки буш савыт шалтыратуга тиң.

Шигырь – ут ул! Ул үз вакытында тиешле урынга очкын булып төшми икән, шагыйрьнең үзен яндыра башлый. Ут тиешле җирлеккә төшмәсә, афәт тә чыгарырга мөмкин... Әле безнең заманда мондый шагыйрь хатыннар тууы хакында киләчәк аерым сүз әйтәчәк! Әйтәчәк! Мин ышанам! Чыннан да, Табигать кануннары өстенлеген хатыннар ныклыгы, чыдамлыгы янә бер кат раслый:

*Киләчәк сагаеп төбәлгән*
*Үзеңә – чирме бу? Ирме бу?*
*Йөздән бер, меңнән бер адәмнән*
*Тупланган чирүме? Илме бу?*

– дигән риторик сорау тәмамлый шигырьне. Бүгенге милләт фикерен, аның рух сөрәнен шуннан да көчлерәк сүзләр белән дөньяга чыгара алсагыз, чыгарыгыз! «Мин каршы түгел», – дияр иде Мөдәррис тә.

«Рух» шигырен укый башлауга, җанда таңгы уяну наме тоемлана:

*Буыннан буынга, күңелдән күңелгә*
*Кагылып җай гына, сак кына,*
*Ул – җәйге тургай күк, һавада*
*Талпына, талпына, талпына...*

Ә уяткач, тарих буйлап сине талкый гына инде! Уй дәрьясына ташлый: ник алай, ник болай? Казан, чыннан да – татарның тәрәге. Тик черек тәрәккә терәтелмәгәнме соң ул? Әйе, Казан ханлыгы бөек булган. Мөселман бервакытта да үтерү – кан коюягында тормаган. Безне әллә үтерергә теләмәгән өчен үтерәләрме ул?

*Әй Казан ханлыгы, рух булып,*
*Каннарда, җаннарда калгансың.*
*Син үксез халкыңны ярлыкап,*
*Һәрзаман озата баргансың,*

– ди шагыйрь.

Ә безнең заман, безнең татар станы кемне, кая озата барырлык, кемне ни өчен ярлыкарлык? Хакимнәр алдында гаебе дә юк бит, ичмасам, милләтнең. Азатлык өчен җанын ярып бирердәй булып тавыш бирде. Түз дигәч, дәшми дә түзде. Кем кемне ярлыкарга тиештер бит? Киләсе буын канына шундый куркаклык, мескенлек кенә сеңеп калмаса иде, Ходаем!

Җанда йокымсыраган сорауларны да, кында кыбырсыган кылычларны да уятыр куәт бар Сүздә! Һаман шигырь юлларын китерә, күпкә дә китте дияргә мөмкиннәр. Әмма шагыйрьнең сүз көченнән дә көчлерәк сүз таба алмаганда, шуны әләм итеп, бар гавамга күрсәтәсе килгәндә, шулай була ул. Бүгенге Казан хакында шагыйрь ни ди?

*Һәр урамда мин үземне табам,*
*Һәр урамда калам җуелып.*

«Мин дә шулай. Мин дә шулай!» – дип кычкырасы, сөрән саласы гына кала.

Сөрән – тарихка хәбәр салу, чакыру ул! Ә менә шагыйрь «Калу» дип атаган шигыреңдә татар хакында «Без өненнән качкан киек төсле» дисә, «Типтәр» шигырендә «Карурманын җуйган киек төсле», – ди. Бу тарихта баскыннарның гамәлләрен ифрат та нечкә тоемлаудан сыгылып кына чыккан хакыйкать агымы, моң чыңлавы. Ул моң кебек, Аллаһ кебек, һәр җирдә, һәрвакыт бар тылсымлы көч, хис, уй, уелу да.

Миңа бүген Лилия миннән кырык яшькә якын яшьрәк түгел, ә тарихларны үтеп яшәгән дөнья карчыгы, бер шигырьдә сөрәнче дә, Коръәнче дә, мөгаллимә дә, вәгазьче дә, төзүче дә, сөзүче дә була ала торган тылсымбикә булып тоелды! «Улым» шигыре.

Күңелләре сукыр булмаганнар «Ярлыкау» шигырендәге канатлы сүзләрне күрми калмас. Тик мин Кадыйр Сибгатуллинның «Мәңгелек тамыр гына» дигән фикеренә каршы төшмәкчемен. «Тамырыңны корытырмын» дигән гыйбарә дә буш урында тумаган лабаса. Тамырлары корып, тарихтан гаип булганнарның санын кем белсен?

Шагыйрь үзенен әбекәенә багышланган шигырендә:

*Мин һаман да синең таганыңда,*
*Әбекәем, күккә талпынам...*

– дигән дә күп нокталар куйган. Әйе, гади генә көнкүрештәге бер деталь сыман гына юкса. Әмма бу – шагыйрьләрне шагыйрь иткән рухи таяну ноктасы. Җирдән аерылып, күккә югары күтәрелә алмаса, шагыйрь дөньяны иңли алмас иде. Очуларның бәһасен, аһ, ничекләр генә беләм мин!

Татар шигъриятенә тагын бер көчле шагыйрь килгән. Ул тарих буйлап шулкадәр иркен йөри һәм үз сүзен дә иркен әйтә. Иркен атлап, заман ишекләрен дә ача. «Яугир» шигыре – нәкъ шуның мисалы. Әйе, «Сансызлык кан белән түләнә». Тере җан иясе өчен башка чара юк. Әйе, «сугышның бөеге, вагы юк» Тик... җиңүләр... Алар сугышларның нәтиҗәләре ләбаса. «Вакыт» – бу хакта да уйланырга вакыт.

Мин шагыйрьләрнең уйлау органнары баш мие түгел, йөрәк дигән фикердә торам. Галимнәр, булдыра алсалар, киресен исбат итсеннәр. Шагыйрь – ул җир йөзендә үзгә материя. Ул үзенә тарих тирәнлеген, тарих рухын сеңдергән, тарихларны заманнарга һәм киләчәккә ялгый торган материя! Ул материянең үзенчәлеге ачыла калса, җирдәге шагыйрьләр һәм шигъри сүз үтереләчәк...

«Ташу»лар таша тора һәм адәми зат аларын гына да буйсындыра алмый. Чөнки алар – шагыйрь белән бертуганнар. Алар шагыйрь уе кебек гел алга, киләчәккә ага. Бу шигырьдә үзең тарта алмасны икърарлау да бар, ахры.

Дөньяның үзенең дә яралу серләрен бер генә кемсә дә белми бит әле. Андый чакларда без, бер Алла белә инде, дип котылабыз. Тик мин Аллага ук барып җитмәстән, күпләр яки күпмедер катлам кешеләр дә белә торган билгеле сүз-аһәңнәрне авторсыз гына куллану (моны үзләштерү дияргә дә була) очракларына да абынгаладым һәм студент елларында булып узган бик кызыклы бер вакыйганы исемә төшердем.

Соңгы курста педпрактика узган вакытларда булды бу. Безнең 476 нчы төркемнең җитәкчесе бик тә үзенчәлекле, үзсүзле профессор Ибраһим ага Нуруллин иде. Аның өчен хак сүз һәрвакытта да Алла булды. Үзе гел таякка таянып йөрсә дә, бер сөйләшү барышында: «Мин таякка түгел, Аллаһка таянып яшим», – дигән иде. Шушы профессор, без әдәбият дәресләре биргәч, дәресләребезгә үзебездән үк анализ ясата, бәя бирдертә. Бу аның төп эш алымы да иде, ахры. Минем дәрескә дә анализ ясалды. Дәресем шәриктәшләремә бик тә ошаган булып чыкты. Мактау сүзләрен яудырдылар гына. Тик Ибраһим ага гына боларның бәяләре белән килешеп бетми бит: алай ук була алмый, бер булса да хатасын күрсәтегез, ди. Аудиториядә бер мизгелгә тулы тынлык урнашты ул чакта. Ибраһим ага иреннәрен чәйнәгәндәй итеп, студентларга сынаулы карашын текәгән. Идият Әширов дигән студент кулын күтәрмәсенме: мин таптым хатасын, ди. Йөрәгем жу итеп китте. Ниндирәк хата җибәрдем икән? Мине бу хатаның практика билгесенә тәэсир итүе түгел, ә миннән – укытучы апаларыннан алданган, ялган мәгълүмат алган унынчы интернат-мәктәп укучыларының язмышы борчый. Уй өермәсе узып китәргә дә өлгермәде, Барда районыннан килгән кара тирән карашлы егет минем хатаны әйтеп тә салды: Нәҗибә ул кайбер күпнокталар куя торган урында өч кенә нокта урынына дүртәр, кайчак бишәр нокта да куеп җибәрә. Ул чакта аудитория өстеннән җиңел генә көлке җиле узып китте кебек. Тик профессорның йөзенә тамчы да елмаю чыкмады. «Әйе, – диде ул җитди тон белән. – Бу бик җитди хата». Ул чакта бу хатаны шаяру дип кенә кабул иткән идек тә. Уйланырга этәргән икән бит Ибраһим ага, ашыгуның нинди җитди хаталарга китерүен кем генә татымагандыр үз гомерендә.

Мин Лилия Гыйбадуллинаның үзен очраткач, читләтеп кенә шул ашыгуларга ишарә ясаган идем дә, ул аптырап ук калды. Ник автор сүзләрен файдаланганда, куштырнаклар куймадың, искәрмәләр бирмәдең, дип кенә әйткән идем. Мин ул авторларнын сүзләрен һич кенә дә шагыйрь җаныннан тартып алырга җыенмыйм, әлбәттә. Үзләре дә аера алмаслык итеп сеңдергән икән, сеңсеннәр. Тик бераз ашыкмаска гына, ни-нәрсәнең каян, кемнән килгәнен, иҗатыңа азык биргәнен чамаларга һәм тамгаларга тиеш автор, әдәби этикетны, кануннарны истән чыгарырга ярамый. Менә шулай мин дә Идият сабакташым кебек күп нокталар, өтер-сәкеннәргә бәйләнеп аласы иттем әле һәм шуларның бер-икесенә генә төртеп күрсәтәсем дә килде. Күрсәтмәскә хакым да юк, чөнки Мөдәррис шигърияте белән минем кебек дистә еллар дәвамында бер казанда кайнаган тагы кем бар? Шулай булса да, мин аны – Мөдәррис Әгъләмне көн саен ачам. Шуңа да аның шигъри юллары минем күзгә бик тиз ташланды һәм аныкылар гына да түгел... Гасырлар дәвамында халык җырлары булып яшәгән «Кара урман» сүзләрен, әлбәттә, куштырнаклар эченә алырга, һич югы йолдызчыклар куеп, искәрмә бирергә кирәк иде. «Аерылмаек» шигыре үз эченә бер генә түгел, берничә җырның сүзләрен сыйдырган. «Кара да гына урман, караңгы төн», «Төлке уйный торган үрләр бар» – Болар татар халкының җан энҗеләре ләбаса!

Шигырьнең икенче куплеты исә, тулаем «Карурман» җырын үзгәртебрәк кенә куллануга кайтып кала. Соңгы куплетта да шул ук хәл:

*Идел-Урал җире...*
*Юллар урау (инде),*

*Яхшы атлар кирәк үтәргә.*
*Юллар урау, караңгы төн,*
*Дус-иш кирәк дөнья көтәргә.*

«Вакыт» шигырендә Күлтәгин язмасына да искәрмә биреп тормаган автор.

Икенче куплеттагы сүзләр исә дәрвиш шагыйрь Мөдәррис Әгъләмнең бүген дә, шөкер, исән-сау иҗатка чумган Газинур Морат атлы шагыйрьгә багышлап язылган «Тәрәзәгез булса...» шигыреннән. Бер сүз урыны алмашканнан гына шагыйрьнең шигъри ачышы синеке була алмый! Мөдәррис аны хәтта үз шигыренең рефрены итеп кабатлап барган лабаса!

Шул ук шигырь һәм Мөдәррис Әгъләмнең «Кан тамырын кистем» исемле китабыннан «Кан җибәргәч» шигыре:

*«Кан җибәргәч җиңел була, энем»,–*
*Табиб шулай диеп акыл сата.*
*Мин ышанып, кан тамырын кистем,*
*Исем китте... –*
*Шигырь агып ята.*

Мөдәррис үзе генә белгән табиб сүзләрен дә куштырнаклар эченә алган. Әйе, чөнки ул сүзләр табибныкы. Мөдәрриснеке түгел. Ә инде «Дөньяныкы – дөньялыкта» гыйбарәсе – Мөдәрриснең «Кан тамырын кистем» китабында шигырь хакындагы күренекле язмасының исеме үк!

Мондый очракларда ашыкмаска, яраткан шагыйрь иҗаты күпме генә синең җаныңа сеңсә дә, үзеңнеке итәргә ашыкмаска кирәк иде.

Ибраһим аганың нинди хата эзләткәнен, ә тапкач, шул «пүчтәк» хатаны ник җитди дип атавын мин бүген тагы да тирәнрәк аңладым. Шуңа күрә дә үземнән кырык яшькә якын яшьрәк шагыйрьгә боларны да җиткерүне үземнең бурычым дип санадым.

Шагыйрьнең яңа китабын – «Сөрән»ен минем җаным кабул итте. Аңа фәкать «Чигенмә! Бирешмә! Борылма!» дип кенә әйтәсем килә. Алай да, Мөдәррис сүзләре белән: «Бутама! Тукталма!» – дип, Лилиянең үз сүзләре белән «Кармаланма! – дип, нәсыйхәтемне дә биреп тәмамлыйм.

**Нәҗибә САФИНА**

## ҖАВАП СҮЗЕ

«Дәвам» шигырьләр циклын укучыга тәкъдим итүе өчен «Казан утлары» журналына ихлас рәхмәтлемен. Иҗатыма игътибары өчен Нәҗибә апа Сафинага зур рәхмәт! Шигырьләремә карата фикерләрен олы бәя дип кабул итәм.

Дәгъваларга килгәндә, «Аерылмаек» шигыре махсус «Иске карурман» җырына ияреп, шушы әсәрне һәм аңа салынган асыл мәгънәне искәртеп язылды. Укучының шигыремдә халык авыз иҗатыннан әлеге ядкарьне тануына һәм гасырлар элек җырга күчкән фикернең актуальлеген абайлавына иманым камил. Халык җырларының иң билгелесен, бөтен татар белә торганын сайладым. Өстәвенә, әлеге җырны башкорт халкы да үзенеке саный. Шул ягы белән дә максатка ярашлы дип таптым аны. Инде ни әйтим, икмәк киштәсе астына икмәк дип язып куймасаң, икмәкне танымаслармы? Мөдәррис Әгъләм шәхесе һәм иҗаты дип янып яшәгән Нәҗибә ханымның хафалануларын хөрмәт иткән хәлдә, «Вакыт» шигыренә нисбәтле дә сүзем шул. Укучының әлеге әсәрдә Әгьләм шигъриятеннән гомумбилгеле гыйбарәләрне генә түгел, Тукай, Дәрдемәнд сүзләрен дә тануына һәм бөекләребез рухына догада булуына өметләнәм – шигырь эпиграфында әйтелгәнчә. Уңышлар телим!

**Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА**

# АЛТМЫШ – АЛТЫН ЧОР БАШЫ

Шагыйрь һәм прозаик **Ләис Зөлкарнәй (Ләис Мәүлит улы Харрасов)** – узган гасырның җитмешенче еллары ахырында әдәбият мәйданына чыккан сәләтле яшьләрнең берсе. Дистә еллар буена аның исеме көндәлек матбугат битләрендә даими күренә, үзенчәлекле шигырьләре, форма өлкәсендәге кызыклы табышлары һәм яңача тәҗрибә-экспериментлары белән каләмдәшләре арасында абруй казана.

Ул 1962 елның 2 апрелендә Башкортстанның Бакалы районы Саскүл авылында дөньяга килә. 1979 елда шул ук районның Куштирәк авылында – урта мәктәпне, 1984 елда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлый. Бала чагыннан ук әдәби иҗатка тартылып үскән егет студент елларында журналистлык эшчәнлеген башлап җибәрә. Башта «Ялкын» журналында әдәбият бүлеге мөхәррире, аннары, 1989 елда, татар яшьләренең «Идел» әдәби-нәфис журналы чыга башлаган көннән 2002 елга кадәр әлеге журнал редакциясендә бүлек мөхәррире, бүлек мөдире вазифаларында була. 2003 елдан коммерция-бизнес эшенә күчә.

Ләис Зөлкарнәй «Балачак күге» (1984) һәм «Кар өстендә алмалар» (1988) исемле җыентыклары белән үз укучысын тапты.

*QR-код ярдәмендә игътибарыгызга Ләис Зөлкарнәйнең 2021 елда бертуган абыйсы – күренекле журналист һәм язучы Фәиз Зөлкарнәйне искә алу кичәсендә ясаган чыгышы тәкъдим ителә.*

***

Балалар шагыйрәсе, журналист **Йолдыз Шәрәпова** 1962 елның 10 апрелендә Татарстанның Буа районы Яңа Тинчәле авылында укытучы гаиләсендә туа. 1979 елда Яңа Тинчәле урта мәктәбен тәмамлап, укуын Казан дәүләт университетының филология факультетында дәвам иттерә. 1984 елда бер елга якын «Ялкын» журналында, аннары бер ел Биектау район газетасында корректор булып эшли. 1986 елдан ул – «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы хезмәткәре, соңгы елларда редакциянең әдәбият бүлеген җитәкли. Хәзерге вакытта «Шәһри Казан» газетасында хезмәт куя.

Йолдыз Шәрәпова – әдәби иҗатын балалар дөньясына багышлаган каләм иясе. 1994 елда аның «Антенналы бәрәңге» дигән беренче шигъри җыентыгы дөнья күрә һәм укучылар арасында үткәрелгән «Ел китабы – 94» бәйгесендә икенче урынны яулый. Шул вакыттан башлап, берничә буын балаларыбыз аның әсәрләре йогынтысында тәрбияләнә. Шагыйрә 2002 елда республика журналистларының «Журналистикада абруйлы исем» номинациясендә «Бәллүр каләм» бүләгенә лаек була, 2004 елда аңа А.Алиш исемендәге әдәби премия бирелә. Күп кенә шигырьләре мәктәп дәреслекләренә, хрестоматияләргә кертелә, балалар язучыларының күмәк җыентыкларында урын ала.

*Ә хәзер, әйдәгез, QR-код ярдәмендә безнең сайтка кереп, Татарстан радиосы журналисты Дания Гайнетдинованың Йолдыз Шәрәпова иҗатына багышлап әзерләгән «Язучылар – балаларга» тапшыруын тыңлыйк.*

***

Шагыйрә һәм прозаик **Лилия Садриеваның** исеме әдәбият сөючеләргә «Өр-яңа яз» (2002), «Күңелләр чәчәк теле» (2012) кебек шигырь җыентыклары һәм дистәләгән популяр җырлары аша таныш.

Ул 1962 елның 14 апрелендә Мөслим районының Дусай авылында туа. Дусайда – башлангыч, Баек мәктәбендә урта белем алып, Казан дәүләт культура институтына – режиссёрлык факультетына укырга керә.

1982 елда Баек авылы мәдәният йортына директор итеп билгеләнә. 1985 елдан районның «Авыл утлары» газетасы редакциясендә эшли, тагын бер елдан район мәдәният йортына инспектор булып күчә, аннары аңа районның үзәк китапханәсе директоры вазифасын тапшыралар. Шул елларда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исемгә лаек була.

Л.Садриеваның шуннан соңгы хезмәт юлы дәүләт эшенә, җаваплы вазифаларга бәйләнгән. Ул берничә тапкыр район Советы депутаты итеп сайлана, район хакимияте башлыгы урынбасары дәрәҗәсенә күтәрелә. Хәзерге вакытта бизнес һәм әдәби иҗат белән шөгыльләнә.

*Шагыйрә иҗатының бер үрнәге итеп, аның студент елларында ук танылган автор-башкаручы Илһам Хисмәтуллин белән берлектә язылган «Күрми дисеңме әллә?» дигән җырын сайтыбызга урнаштырдык.*

***

**Сания Әхмәтҗанова** 1962 елның 20 апрелендә Татарстанның Арча районы Курса Почмак авылында колхозчылар гаиләсендә туган.

Сигезьеллык мәктәпне, аннары Арча педагогия училищесын тәмамлый, Казан дәүләт педагогия институтының рус-татар бүлегендә югары белем ала. Хезмәт юлын Казанда башлангыч сыйныфлар укытучысы буларак башлый. Балалар бакчасында тәрбияче, соңрак татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли. 2000 елда журналистикага күчә.

Беренче шигырьләре һәм яшь хәбәрче язмалары мәктәптә укыганда, «Яшь ленинчы» (хәзер «Сабантуй») газетасында басыла. Педучилищеда белем алган елларында шигырьләре һәм булачак укытучылар тормышыннан язмалары белән район газетасында даими катнаша.

Шагыйрәнең «Оч иреккә, җырым» (2002), «Пар алма» (2008), «Гәрәбә» (2012), «Язмышлар такыясы» (2019) кебек җыентыклары әдәбият сөючеләр тарафыннан яратып кабул ителде.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен Сания Әхмәтҗановага «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде (2012), ул Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Һади Такташ исемендәге премиясенә ия булды (2016).

*Сания Әхмәтҗанова популяр җыр текстлары авторы буларак та, халыкта танылу алды. QR-код ярдәмендә шундый җырларның берсен тәкъдим итәбез – «Пар алма». Зөфәр Хәйретдинов музыкасы. Җырны Зөфәр Хәйретдинов һәм Алсу Хисамиева башкара.*

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*

# ХӨРЛЕК СҮЗДӘ ТҮГЕЛ, ЙӨРӘКТӘ



*Башкортстан Республикасы башлыгы Радий Хәбиров Ирек Габбасовка «Башкортстанның атказанган азык-төлек индустриясе хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирү турында таныклык тапшыра.*

Кечкенәдән китап укыган кеше башкалардан кайсы ягы белән аерылып тора дисезме? Андыйлар аралашкан чакта теге яки бу әсәрдән мисал китерә, яисә фикерен билгеле шәхес сүзләре белән ныгытып куя. Бүгенге героебыз да – шундыйлардан...

Ирек Мөфәздал улы Габбасов тумышы белән Баулы районының Исергәп авылыннан. Бүгенге көндә Башкортстанның Мәләвез шәһәрендә урнашкан зур җитештерү комплексын җитәкли. Аның турында Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән «түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелгән» дип әйтергә була. Әтисе Мөфәздал белән әнисе Саимә – сугыш чоры балалары. Ул вакытның бөтен авырлыкларын үз җилкәләрендә татыганга күрәдерме, уллары тугач, исем эзләп, озак баш ватмаган алар. Тормышта үз юлы, үз фикере булсын дип, балага Ирек дип исем кушканнар. Ирек әфәнденең исеме җисеменә туры килә – кечкенәдән мөстәкыйль эшләргә, карар кабул итәргә өйрәнеп үсә ул.

– Алтынчы сыйныфны тәмамлагач, җәйге елларда эшкә урнаштым – ат җигеп, колхоз кырларын тикшереп йөрдем. Әти белән бергәләп, кышка утын, печән әзерләү, берничә гектар мәйданда колхоз чөгендерен эшкәртү, үз бакчабызда күпләп бәрәңге утырту – барысына да өлгерә идек, – дип искә ала ул үзенең үсмер чагын.

Ирек әфәнде балачактан атларга мөкиббән. Кече яшьтән үк ат чабышларында катнаша. Шулай ук үзлегеннән әтисе бүләк иткән баянда уйнарга өйрәнә дә мәктәптә тәнәфесләрдә укучыларны биетә.

– Мәктәптән соң Зенит-ракета хәрби училищесына укырга керергә карар кылдым. Әни биргән 50 сум акча белән Оренбургка юл алдым. Әмма конкурс бик зур иде, үтә алмадым һәм Исергәптән ерак булмаган Октябрьский шәһәрендәге нефть көллиятенә барып кердем. Аны тәмамлап, эшкә урнашкан идем, хәрби хезмәткә чакыру кәгазе килде, – дип, хатирәләрен яңарта Ирек әфәнде.

Актив кеше кайда да тик тормый инде ул. Эчке эшләр министрлыгының Дзержинский исемендәге эчке гаскәрләрендә хезмәт итүче егетне спорт эшләрен оештыручы итеп билгелиләр.

– А.Суворовның «Җиңүнең нигезе – тәртип» дигән канатлы сүзе бар. Армия мине баштанаяк үзгәртте. Дисциплинага, үз алдыма куелган максатка ирешергә, чыдам булырга өйрәтте, шулай ук физик яктан чыныктырды. Миңа ул тормыш мәктәбе шулкадәр ошады ки, контракт буенча тагын алты ел хезмәт итәргә карар кылдым. 1986 елда мине, өстәмә әзерлекне күздә тотып, Мәскәүгә юлладылар, анда да кул сугышы, ату буенча өйрәнүләремне дәвам иттем, – ди әңгәмәдәшем.

Ирек әфәнденең гаилә тормышын башлап җибәрү чоры үзгәртеп кору елларына туры килә. Хезмәт хакын бирүдә тоткарлыклар була башлый, хәрби хезмәткәрләр

өчен ташламалар да бер-бер артлы юкка чыга. Яшь гаиләдә инде бу вакытта Элина һәм Элиза исемле ике кызчык үсеп килә.

– Бергә хезмәт иткән иптәшләрем белән сөйләштек тә үзебезне эшмәкәрлектә сынап карарга булдык. Ул чакларда өйдә бик сирәк була идем, шуңа күрә йорт эшләре, балаларны үстерү-тәрбияләү тулысынча тормыш иптәшем Гүзәл җилкәсенә төште. Бер дә зарланмады ул, миңа һәрвакыт терәк булды.

Белгәнебезчә, узган гасырның туксанынчы елларында бизнес белән шөгыльләнү җиңелләрдән булмый: кайсы өлкәне генә алсаң да, сынаулар көтеп тора. Андый чакларда героебыз Генрих Фордның «Берләшү – эшнең башы, бергә калу – прогресс, бергә эшләү – уңышның нигезе» дигән сүзләренә таяна. Аның тормыш багажында аяк киеменнән башлап, җиңел машиналар сатуга кадәр тәҗрибә тупланган.

Ә яңа гасыр башында Ирек әфәнде алып-сатудан китеп, үзен җитештерү өлкәсендә сынап карарга була. Чиләбедә алкогольсез эчемлекләр заводы төзи, ә берничә елдан аңа әнисенең туган ягы – Башкортстанда банкротлыкка чыккан бер оешманы сатып алырга тәкъдим итәләр.

– Мәләвезгә килгәч, ике айлап вакытымны документлар өйрәнүгә, җитештерүне торгызу мөмкинлеген ачыклар өчен төрле икътисади исәпләүләргә багышладым, – ди бүгенге көндә азык-төлек өлкәсендә аерым бер бренд булдырган җитәкче.

Өч ел дигәндә, оешма табыш китерә башлый. Ул җитештергән продукция Башкортстан чикләрен үтеп, Оренбург өлкәсе, Казакъстан якларында танyла. Бу хакта сөйләгәндә, әңгәмәдәшем совет язучысы Дмитрий Фурмановның «Дисциплинасыз – коллектив, коллективсыз оешма юк» дигән сүзләрен искә төшерә, аннары «Бердәмлектә – көч» мәкален өстәп куя. Дөрестән дә, куелган максатларга ирешү өчен ныклы, бердәм коллектив булдыру мөһим.

Күп тә үтми, бар нәрсәне төгәл итеп, җиренә җиткереп башкарырга өйрәнгән җитәкче башкортчадан «чиста су» дип тәрҗемә ителә торган матур яңгырашлы сүзне рәсмиләштереп, патент ала һәм үз продукциясен халыкка «Нугуш» исеме белән тәкъдим итә башлый. «Саклау вакыты кыска булса да, бары тик натураль продукция чыгаруны максат итеп куйдык, – ди Ирек Мөфәздал улы. – «Нугуш»ны үз итүчеләр көннән-көн арта».

Тик героебыз ирешкәннәр белән тукталып кала торганнардан түгел. Яңалыкка, теоретик белемгә һәм гамәли эзләнүләргә омтылып, ул Көньяк-Урал дәүләт университетында, соңрак К.Г.Разумовский исемендәге Мәскәү дәүләт технология һәм идарә университетында укый. Башкорт дәүләт университетында аспирантура тәмамлый. Моннан тыш, көндәшлеккә сәләтле булу, заманнан артта калмас өчен, белгечләрен ияртеп, төрле предприятиеләргә бара, азык-төлек җитештерү өлкәсендәге яңа юнәлешләрне өйрәнә.

– Борынгы грек фәлсәфәчесе Сократ әйтмешли, «мин үземнең берни белмәгәнемне генә беләм». Гел хәрәкәттә булсаң гына, тормыш арбасыннан төшеп калмыйсың. Ирешелгән нәтиҗәләр белән генә канәгать калып булмый, бигрәк тә бүгенге көндә. Ә көндәшлеккә сәләтле булу өчен төрле өлкәдә белемеңне арттырырга, уңышка ирешкән шәхесләр белән аралашырга кирәк.

*Яшәр өчен бетмәс көч алырга*
*Туган ягы кирәк кешегә.*

Эшенең никадәр генә тыгыз булуына карамастан, Ирек Мөфәздал улы гаиләсенә дә, яраткан шөгыльләренә дә вакыт таба. «Эш дигәндә янып торучы хезмәттәшләремнән, өйдә гаиләмнән уңдым», – ди ул горурланып.

Инде үзе дә оныкларының яраткан дәү әтисе булган Ирек әфәнде балачагын искә төшереп ала.

– Күршеләребез белән бик дус яшәдек. Көн аралаш җыелып, дөнья хәлләре турында



*Башкортстан Республикасы Премьер-министры Рөстәм Мәрдәнов (сулда) белән. 2015 ел.*

сөйләшүләр, кирәк чакта бер-береңә ярдәм итешүләр, эшләр тәмамланганнан соң табын корып, җырлап юанулар күңелдә сабыйлыкның гүзәл бер хатирәсе булып уелып калды. Халык тикмәгә генә: «Күрше хакы – тәңре хакы!» – дими инде. Олылар үрнәгендә без, балалар да, күмәкләшеп эшләргә, бергәләп ял итәргә, дуслыкның кадерен белергә өйрәндек. Кызганыч, күптән түгел әниебезне соңгы юлга озаттык. Әтием янына Баулыда яшәүче сеңлем Ләйлә ешрак кайтып йөри. Мөмкинлек булган саен без дә аның янына ашыгабыз.

Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китерер җимеш, ди халык. Олы тормышка яхшы старт биргән туган ягын да, бүгенге көндә үз алдына куелган максатына ирешә торган җитәкче булып таныткан Мәләвезне дә, аның кешеләрен дә үз күрә Ирек әфәнде. Ипи-сөт, газлы сулар, квас, прәннек һәм башка эчемлек, сый-нигъмәтләр җитештерү белән беррәттән, ул район һәм шәһәр тормышында актив катнаша, ярдәм сорап килүчеләргә матди яктан булыша.

Мәләвез муниципаль районы Советы депутаты буларак та Ирек Мөфәздал улы игелекле эшләрне шактый башкарган. Саксызлык аркасында килеп чыккан янгыннан соң йорт-җирсез кала язган ханым да рәхмәтле аңа. Бүгенге көндә фатирында ремонт эшләнгән, яшәү өчен кирәкле җиһазлары да бар аның. Шулай ук Ирек әфәнде Балалар һәм яшүсмерләр иҗаты сарае, Инвалидлар җәмгыяте, Әфганстан ветераннары берләшмәсе, картлар һәм балалар йортларына да шактый ярдәм итә. Бу урында татар халкының «Яхшылык эшлә дә суга сал, халык белмәсә, балык белер, балык белмәсә, Халикъ белер» дигән мәкале искә төшә.

– Уңышка, матди байлыкка ирешү турында уйлаганда да, рухи кыйммәтләр, кешелеклелек, сәламәтлек, гаилә, хобби турында онытмаска кирәк. Минем өчен алар беренче урында. Кендек каным тамган авылыма кайткан саен туган-тумача, авылдашлар белән очрашырга, аларны борчыган мәсьәләләр турында фикер алышырга, хәл кадәри ярдәм итәргә тырышам, – ди олы йөрәкле Ирек әфәнде.

Авылны авыл итеп тоткан мәктәп һәм мәчеткә дә кермичә китми ул. Бүгенге көндә белем йортын җитәкләүче, педагоглар династиясен лаеклы рәвештә дәвам итүче Ландыш Габделованы, өч дистә елдан артык вакыт балалар күңелендә туган телгә һәм әдәбиятыбызга мәхәббәт тәрбияләүче Римма Нәгыймованы да рәхмәт сүзләре белән телгә ала.

– Нәкъ менә аларның тырышлыгы белән мәктәбебездә музей торгызылды. Бу – бәяләп бетерә алмаслык зур эш. Яшь буын туган авылының, мәктәбенең тарихын, атаклы шәхесләрен, геройларын белергә, аларның истәлеген үз балаларына ирештерергә бурычлы, – ди ул һәм фикерен мәчет белән бәйләп дәвам итә. – Аллаһ йортыбыз да, шөкер, авылдашларыбыз өчен хезмәт итә. Һәр кешене кайгыртып, тыңларга җай һәм вакыт табучы имамыбыз Камил хәзрәт Шәмсуаров та – халык арасында абруй һәм ихтирамга лаек кеше. Үткәнебезне барлап, киләчәгебез өчен җан атып торучы шундый шәхесләр булганда авылыбыз, һичшиксез, яшәячәк әле.

Сәламәт тәндә – сәламәт рух дигәнне истә тотып, эше никадәр генә тыгыз булса да,



*Икътисад министры җитәкчелегендәге хөкүмәт делегациясе белән.*

спорт белән шөгыльләнергә дә җай таба героебыз. Хезмәткәрләрен дә шуңа өнди. Оешманың үзендә үк спорт залы бар. Теләгән һәр хезмәткәр анда түләүсез йөри ала.

– Әле тагын йөзәргә, Барс кушаматлы тугры этем белән бергәләп җәяү йөрергә яратам. Китап укырга да җай табарга тырышам. Вакытны дөрес бүлү ярдәм итә инде. Ә күңелгә иң якын шөгылем – кичләрен бергә җыелгач, иң кадерле кешеләрем янында баянда уйнау. Ул вакытта тормыш мәшәкатьләре онытылып тора. Оныкларым белән уйнау, аралашу да күңелгә ямь өсти. Минем өчен гаилә – ул ышанычлы тыл һәм терәк, ә өем – чыгып киткәч тә кайтырга ашкынып тора торган җир, – ди Ирек әфәнде, горурланып.

Моннан 34 ел элек тормыш корып җибәргән Гүзәл белән Ирек Габбасовларның бер ул, өч кызлары бар. Өлкән кызлары башлы-күзле булган инде. Бүгенге көндә аларның бала тәрбияләү белән мәш килгән чаклары. Яшьрәкләр Карина белән Альберт исә югары белем алалар. «Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, ди халык. Бер-беребезгә ихтирам хисләрен, эш сөючәнлек, максатка омтылыш, үз дигәнеңә ирешү сыйфатларын балаларыбызда да тәрбияли алганбыз дип ышанам», – ди ата кеше.

«Көн арты көн башкарган эшләребез аша шәхес булып җитешәбез. Эш-гамәлләребез белән идарә итү характерыбызны чыныктыра. Ә ныклы характер, кирәк чакта фикереңне әйтергә өйрәнү, тормышны үз кулыңа алу – мөстәкыйльлек билгесе». Ирек әфәнде әйткәнчә, Аристотельнең бу сүзләре белән килешми мөмкин түгел.

– Җитәкченең уңышка ирешүе – ул еллар буе даими хезмәт итү һәм бердәм команда туплау нәтиҗәсе. Командада уртак эш өчен янып торучы, акыллы, креатив, һәрвакытта бер-берсенә ярдәмгә килергә әзер торган хезмәткәрләр белән генә уңышка ирешеп була. – Агымдагы елның ноябрендә үзенең 20 еллык юбилеен билгеләп үтәчәк оешма җитәкчесе шундый фикердә.

Бер карасаң, әллә ни зур дата да түгел кебек. Тик шулай да предприятиенең эш чылбырындагы һәр буынга яңа сулыш өргән, кулланучылар өчен сыйфатлы азык-төлек продукциясе җитештерү өчен тырышучы, хезмәтенең уңай нәтиҗәсен күрүче коллектив башында торучы исә әлеге датаны зур бәйрәмгә тиңли. Бүгенге көндә Мәләвездә җитештерелгән продукцияне Башкортстанда гына түгел, ил буенча беләләр, таныйлар, көтеп алалар. Берничә дистәдән артык Мактау грамоталары, сертификатлар да оешма җитештергән эчемлек һәм ризыкларның тәмле һәм сыйфатлы булуы хакында сөйли.

– Габдулла Тукай сүзләре белән әйтсәк, эшкә бирсәң чын күңел... Шул чакта сайлаган юлыңнан тайпылмыйча атларга мөмкинлекләр ачыла, башкарган хезмәтеңнең нәтиҗәсе сине һәм башкаларны да куандыра, – ди Ирек әфәнде. Бусы исә аның исемендәге генә түгел, иң беренче чиратта, күңелендәге хөрлек белән килешеп яшәвен, тормыш принципларына тугры калуын күрсәтә.

**Ландыш НӘСЫЙХОВА**

*Фотолар Ирек Габбасовның шәхси архивыннан.*

# ЧИРАТСЫЗЛАР ЧИРАТЫ

## Авыл валютасы

*(оптимист авызыннан)*

Бер дә көтелмәгән җирдән башка төште бер бәла –
Доллар «сикерә», евро «бии»... Безгә нишләргә кала?!
Башны имик әле алай, исәң ул – идерерләр.
Ирек бирсәң, муеныңа пар камыт кидерерләр.
Үсәләр дип тә кайгырмыйк, яшәдек алар юкта.
Җитмәсә, авылда бар бит җирле, җайлы валюта.
Чоланнарда эленеп торса, эшләрең бара гөрләп.
Майларга да, җайларга да шушы валюта кирәк.
Баланы укырга кертә, авыруны терелтә.
Табибка да, деканга да һәммәсе шуны төртә.
Мәҗлесләрдә – өстәл күрке, ансыз узмый бер никах.
Урысчалап әйткән чакта, бу валютасыз никак.
Доллар теләсә нишләсен, хет төшсен дә хет менсен.
Оя тулып бәбкә чыксын, казлар исән-сау үссен!

## Җавапсыз сорау

Быел җәй яңгыр яумады, бер тамчы да таммады.
Бакчаларда,болыннарда гел яшеллек калмады.
Бернәрсә дә үсмәде шул: кишер, суган, редис та.
Көзен бәяләр артканны сылтадык без кризиска.
Ач үләрбез дию хата – Израильдән кишер кайта.
Кибетләрдә тулып ята Мисырдан килгән редис.
Җанны сорау аптырата: «Юк микәнни соң аларда
Безнең җелекләргә үткән корылык һәм кризис?!»

## Династия

Элек бездә бар иде хезмәт династиясе:
Атасы да, улы да тырыш хезмәт иясе.
Ә бүген безнең илдә түрә династиясе.
Атасы да, улы да күн кәнәфи иясе.
Күрмәс өчен эшләпәмне әллә батырып киясе?

## Сөенеч

Тәрбияче Гөлинә эшкә сөенеп килә –
Төркемендә бер малай татарча биш сүз белә.
Тыңлагыз, яме, көлми, нишләсен соң сөенми?! –
Башка балалар бакчада «ләм-мим», татарча белми...

## Кызлар

Кияүгә чыгасы килгәч
Ачтылар бар чикләрне.
Әйбәт кияү эзләп әнә
Үз иттеләр читләрне.

Кайларга гына китмиләр:
Һиндстанга, Кытайга.
«Бай кияүләр бар!» – дисәләр,
Менәрләр иде айга.
Һич югы тик бер айга...

## Җилкәсендә «Жигули»

Онык беренчегә бара, булдым букча алырга.
Тиздән безне шатландырган «5»леләрен салырга.
Букчаларның төрлесе бар, күзнең явын алалар.
Иң-иң шәбен тапты онык – сайлый белә балалар.
Тик менә бәясе генә ун меңнән узып китте.
Фатирга түләгәч калган пенсиям көчкә җитте.
Шәп машина ала идек элек мондый акчага.
Җилкәгә «Жигули» астык – сөенечкә юк чама.

## Көтү

*(кара юмор)*

Безнең кечкенә авылда
Кышын хәлләр авыр ла.
Әгәр дуласа буран,
Үтәрлек булмый урам.
Булмый күршегә кереп,
Хәл дә белешеп йөреп.
Үлем-китем булса гына
Эш арта бар ир-атка.

Трактор белән эттерәләр
Юл ачалар зиратка.
Менә тагын буранлый...
Каплый инде урамны.
Әгәр бөтенләй күмсә?
Гаҗәп түгел, башкаларны
Җәлләп берәрсе үлсә.

## Рәхмәт

Көлешәләр, сөйләшәләр –
Яшьләр бара утырып.
Бар вагонны яшьлек дәрте
Һәм ямь белән тутырып.

Мин торам шунда басып,
Авыр сумкалар асып.
Бик арып, хәлем китеп,
Буш урын өмет итеп.

Юк, берсе дә күрмәде,
Торып, урын бирмәде.
Сөенеп куйды күңел –
Димәк, мин бик карт түгел!

Рәхмәт сезгә, егет-кызлар,
Барган өчен утырып.
Урын бирмәвегез өчен,
Мине күргәч тә торып.

## Чиратсызлар чираты

Кибет янында чатта кем генә юк чиратта:
Тора әби-бабайлар, тора эти-малайлар
Ләкин кәттә ир-атлар, юк, басмыйлар чиратка –
Озын чиратлар тору гөнаһ мондый ир-атка.
Ул чиратсыз алачак – бик канәгать калачак,
Чиратта тормаячак, товарсыз калмаячак.
Белә, беркем эндәшмәс авыз ачып, сүз катып.

Чөнки һәммәсе аңлый: кәттәләрдә юк вакыт.
Тагын бер егет килде тегесеннән дә кәттә
Чиратта тормаячак монысы да, әлбәттә.
Янә берәүсе килде – монысы да тормас инде.
Кызык хәзер чиратка: бармак төртеп көлешә,
Күрсәтеп бу ир-атка, –
«Әһә, алар гына түгел,
Чиратсызлар чиратта!..»

## Телефонсыз көн

Онытылган бит юньсез – мин бүген телефонсыз.
Хәлләремне белмисез, мин бүген ике кулсыз.
Мин бүген фикер-уйсыз, хәтта ки, барыр юлсыз.
Шалтырата да алмыйм, җавап та бирә алмыйм.
Чакыру килеп җитмәгәч, кирәк җиргә баралмыйм.
Җаныма урын тапмыйм, урнымнан торып чапмыйм.
Ризык күңелгә ятмый, вакыт узмый бүген һич,
Кайчан җитәр инде кич. Гүя, мин тирән базда
Юк бер хәбәр, аваз да. Телем дә эшсез бүген,
Ялкауланды авыз да. Тик менә колак кына
Пышылдый тыйнак кына: «Тынычлык рәхәт иде,
Онытылган телефонга миннән зур рәхмәт инде».

## Табылмасмы берәр җай

Бер айлык фатир хакым,
Бер айлык хезмәт хакым –
Икесе дә бертигез,
Әйтерсең, алар игез.
Юкса, белемем югары,
Стажым да җитәрлек,
Исемнәр дә гел юк түгел,
Ник болай – искитәрлек.

Яңа эшкә күчтем быел –
Артты хезмәт хакым да...
Кайсы юньсез җиткергәндер
Бу яңалык хакында –
Хезмәт хакым белән бергә
Артты фатир хакы да...
Су агызмый, ут кабызмый,
Авызны элеп чөйгә,
Яшәп ятыш әле менә
Акрын гына бер көйгә.

Транспортка бәя арткан –
Сөйләделәр бер чатта.
Күңелдә өмет җемелди
Ишеткәч тә бу хакта.
Эшләр барса гел болай,
Табылмасмы берәр җай –
«Очыгыз!» – диеп, канатлар
Бирмәсме әле Ходай?!

**Йолдыз ШӘРӘПОВА**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## КОМИССИЯ УТЫРЫШЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында ТР Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенең киңәйтелгән утырышы булды. Аны ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Комиссия рәисе Марат Әхмәтов алып барды. Утырышта ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова, ТР яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов, ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев һ.б. чыгыш ясады. Алар Комиссиянең татар телен саклау һәм үстерүгә зур өлеш кертүен, бу максатта күп кенә чаралар уздырылуын билгеләп үттеләр, киләчәктә гамәлгә ашырасы бурычларга тукталдылар.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА – 135 ЕЛ

12 март – татар әдәбияты классигы, галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның туган көнендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары, ТР Мәдәният, Мәгариф һәм фән министрлыклары, Казан шәһәре башкарма комитеты, җәмәгатьчелек вәкилләре Казандагы Г.Ибраһимов исемендәге 17 нче татар гимназиясе каршында әдипнең бюстына чәчәкләр салдылар.

***

Г.Ибраһимовның тууына 135 ел тулу уңаеннан КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында яшь галимнәрнең «Галимҗан Ибраһимов – язучы, тәнкыйтьче, методист, җәмәгать эшлеклесе» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференциясе булып узды. Гыйльми җыенда галимнәр, аспирантлар, студентлар, укучылар катнашты.

***

М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университетында ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Татарстан китап нәшрияты белән берлектә бастырып чыгарган Г.Ибраһимовның – 15, «Татар әдәбияты тарихы»ның 8 томлыкларын тәкъдим итү булды.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында Галимҗан Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлына багышланган «Без түбәннән күтәрелдек» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Анда язучылар, әдәбият галимнәре, сәнгать әһелләре катнашты.

## ЮБИЛЕЙЛАР

Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык язучысы, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт, М.Җәлил исемендәге республика премияләре лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ркаил Зәйдуллага 60 яшь тулу уңаеннан «Чын шигырьгә әверелә шагыйрь...» дип аталган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Бәйрәмдарны ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады, аңа «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орден медален тапшырды. Ул ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев котлавын да, ТР Дәүләт Советы Рәисенең Рәхмәт хатын да ирештерде. Кичәдә юбилярны котлаучылар арасында ТР Премьер-министр урынбасары – Бөтендөнья Татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев та бар иде. Шулай ук дәрәҗәле кунаклар: ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Марат Әхмәтов, ТР Дәүләт Советының Мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, Бюджет, салымнар һәм финанслар комитеты рәисе урынбасары Камил Нугаев, ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, ТР мәдәният министры Ирада Әюпова һ.б. катнаштылар. Язучы, мөхәррир Равил Сабыр каләмдәшен «Татнефть» компаниясе исеменнән котлады. Россия язучылар берлекләре Ассоциациясе рәисе Сергей Шаргунов, Азәрбайҗанның халык шагыйре Әкбәр Гошалы, рус ПЕН-үзәге Президенты Евгений Попов, Башкортстаннан язучы-прозаик, «Шоңкар» журналының баш мөхәррире Айгиз Баймөхәммәтов, Балкар шагыйре, «Минги тау» журналының баш мөхәррире Әскәр Додуев, Төркиядән шагыйрә Лилия Газизова видеокотлаулар җибәргәннәр. Бәйрәмдә Ркаил Зәйдулланың шигырьләре, чәчмә әсәрләреннән өзекләр (аларны автор үзе, Г.Камал,

К.Тинчурин, Г.Кариев исемендәге театрлар артистлары Фәннүр Мөхәммәтҗанов, Ришат Әхмәдуллин, Ирек Хафизов, Зөлфия Вәлиева, Фәнис Кәлимуллиннар укыды), шагыйрь сүзләренә язылган җырлар (җырчылар Зәйнәп Фәрхетдинова, Рәсим Низамов, Азат Тимершәех, Алинә Шәрипҗанова, Илгиз Мөхетдинов башкарды) яңгырады, юбилярның драма әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән өзекләр (рольләрдә Г.Камал, Түбән Каманың Туфан Миңнуллин исемендәге, Буа театрлары артистлары уйнады) күрсәтелде. Кичәдә шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Лилия Гыйбадуллина, Р.Зәйдулланың якташлары – Чувашиянең Урмай авылыннан «Мишәр» җыр һәм бию ансамбле дә чыгыш ясады. Бәйрәмне Фәнис Җиһанша белән Айзилә Батырханова алып бардылар.

***

Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театрында Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, галим, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстанның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт, Һади Такташ, Шәйхи Маннур исемендәге әдәби премияләр лауреаты Рифат Җамалның 70 яшьлек юбилеена багышланган «Күңелем сүрәләре» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булып узды. Бәйрәмдарны ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин (ул ТР Президенты Указы нигезендә Р.Җамалның «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» исеменә лаек булуын игълан итте), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла (ул Татарстанның Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллегенең Г.Тукай юбилеена чыгарган медален тапшырды), Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Илгиз Халиков (ул Бөтендөнья Татар конгрессы медален ирештерде), ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Ленар Гарипов, ТР Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе җитәкчесе Алмаз Хисаметдинов, Арча районы башлыгы Илшат Нуриев (аның якташлар исеменнән котлавына җырчылар Расих Галимҗанов, Диләрә Хәйдәрҗанова, гармунчылар ансамбле, «Мирас» бию төркеме дә кушылды) котлады. Кичәдә Г.Камал театры артисты Илдус Әхмәтҗанов, К.Тинчурин театрыннан Гөлназ Нәүмәтова, Илфак Хафизов, шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин, Фәнил Гыйләҗев, Рифат Сәлах юбилярның шигырьләрен укыдылар. Җырчылар Мирсәет Сөнгатуллин, Алмаз Хәмзин, Азат Тимершәех, Рамил Миндияр, Фәрит Мирзануров, Рәсимә Нигъмәтуллина, баянчы Рафинат Сәләхов, Буа театры директоры һәм сәнгать җитәкчесе Раил Садриев котлауларын җыр, музыка һәм мәзәк белән ирештерделәр.

### ЯЗУЧЫ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ

Казандагы 171 нче урта гомуми белем бирү мәктәбендә язучы Зиннур Хөснияр иҗатына багышланган фәнни-гамәли конференция булды. Анда «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте, Казан шәһәре мәгариф идарәсе вәкилләре, әдәбият галимнәре, язучылар, укытучылар, укучылар катнашты.

### УНЫНЧЫ КИТАП

«ТАТМЕДИА» бинасындагы «Әдәби кафе»да язучы, публицист Фирдәвес Хуҗинның «Суслонгер» китабын тәкъдим итү булды. Бу – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте ярдәме белән «Казан утлары» журналы китапханәсе» сериясеннән басылып чыккан унынчы китап. Яңа китап бәйрәмендә «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстанның халык язучылары Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова, язучылар Камил Кәримов, Зиннур Хөснияр, Асия Юнысова, К.Тинчурин театры артистлары Резедә Сәләхова, Артём Пискунов, Айдар Фәтхрахманов чыгыш ясадылар. Авырып китү сәбәпле, бу чарада автор үзе катнаша алмады. Ул, китапны нәшер итүчеләргә рәхмәт әйтеп, видеочыгыш җибәргән иде. Яңа китап тәкъдим итү бәйрәмен язучы, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире Рафис Корбан алып барды.

2022 елның 27 февралендә 86 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, прозаик, публицист, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе **Илдар Мәлик улы Низамов** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Әтнә районы Чишмәле Сап авылында җирләнде.

2022 елның 5 мартында 75 нче яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты, Татарстанның атказанган химигы **Рифкать Гаян улы Имаев** вафат булды.

Мәрхүмнең җәсәде Балык Бистәсе районы Мәмли Казак Чаллысы авылында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть Н.ХАРИСОВОЙ «Прошло уже...», повесть К.КАРА «Высокие горы счастья», рассказ И.ИКСАНОВОЙ «Траур»; стихи С.АХМЕТЗЯНОВОЙ, Л.ЗУЛЬКАРНАЯ, Р.ГАЗИЗОВА, М.БАКИРОВА.*
*«Драматургия»: драма М.ГИЛЯЗОВА «Последний мираж».*
*«Новые имена»: стихи Ф.ЯР.*
*Литературный конкурс «Майдан - для батыров»: рассказ Р.НИЗАМИ «Встреча на ковре».*
*«К 100-летию журнала «Казан утлары»: статья И.ИБРАГИМОВА.*
*«Казан утлары» - в моей судьбе»: статья Э.ШАРИФУЛЛИНОЙ.*
*«К юбилею»: фотоархив.*
*«Литературная критика»: статья Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ.*
*«Юбилеи»: статья Р.ГАТАША, посвящённая 60-летию поэта Л.Зулькарная.*
*«Искусство»: статья А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ.*
*«Обзор книги»: статья М.ИБРАГИМОВА.*
*«История одного юбилея»: статья Л.ЛЕРОНА.*
*«Бриллианты эпохи»: воспоминания Б.УРМАНЧЕ (подготовил З.МУХАМЕТШИН).*
*«Литература родственных народов»: стихи А.САРМАНБЕТОВА в переводе Л.ШАЕХА.*
*«1100 лет со дня принятия Ислама в Поволжье»: статья И.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Отклик»: статья Н.САФИНОЙ.*
*«Бесценные голоса»: статьи к юбилеям поэтов Л.Зулькарная, Й.Шараповой, Л.Садриевой, С.Ахметзяновой. Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.*
*«Современник»: статья Л.НАСИХОВОЙ.*
*«Сенной базар»: стихи Й.ШАРАПОВОЙ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Музей Тукая – Дом Шамиля. Фото И.АБРАМОВОЙ.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: story by N.KHARISOVA «It has already passed ...», story by K.KARA «High mountains of happiness», story by I.IKSANOVA «Mourning»; poems by S.AKHMETZYANOVA, L.ZULKARNAY, R.GAZIZOV, M.BAKIROV.*
*«Dramaturgy»: drama by M.GILYAZOV «The last mirage».*
*«New names»: poems by F.YAR.*
*Literary competition «Maidan is for batyrs»: story by R.NIZAMI «Meeting on the carpet».*
*«To the 100th anniversary of the Kazan Utlary magazine: article by I.IBRAGIMOV.*
*«Kazan Utlary» is in my destiny»: article by E.SHARIFULLINA.*
*«To the anniversary»: photo archive.*
*«Literary criticism»: article by D.ZAGIDULLINA.*
*«Anniversaries»: article by R.GATASH dedicated to the 60th anniversary of the poet L.Zulkarnay.*
*«Art»: article by A.AKHMETGALIEVA.*
*«Book review»: article by M.IBRAGIMOV.*
*«History of one anniversary»: article by L.LERON.*
*«Diamonds of the era»: memories by B.URMANCHE (prepared by Z.MUKHAMETSHIN).*
*«Literature of kindred peoples»: poems by A.SARMANBETOV translated by L.SHAEH.*
*«1100 years since the adoption of Islam in the Volga region»: article by I.ZAGIDULLIN.*
*«Response»: article by N.SAFINA.*
*«Priceless voices»: articles for the anniversaries of the poets L.Zulkarnay, Y.Sharapova, L.Sadirieva, S.Akhmetzyanova. The column is led by N.AKMAL.*
*«Contemporary»: article by L.NASIKHOVA.*
*«Hay Bazar»: poems by Y.SHARAPOVA.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Tukay Museum - Shamil's House. Photo by I.ABRAMOVA.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Тукай музее – Шамил йорты. *И.Абрамова фотосы.*